

# КАЗАН УТЛАРЫ

6
ИЮНЬ
1981

# КАЗАН УТЛАРЫ

**АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ**
**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ**
**1922 елның май аеннан башлап чыга**

**6**
ИЮНЬ
1981


## *Бу санда*


**Щ. БИКЧУРИН.** Тирән катлам. Роман . . . . . . 3
**Р. МИНГАЛИМ.** Ике авыл арасы. Поэма . . . . . 59
**Т. МИҢНУЛЛИН.** Хәсән Вәгыйзович. Повесть . . 65
**М. ГАЛИЕВ.** Яңгыр шавы... Шигырьләр . . . . . 100
**Н. ИЗМАЙЛОВА.** Ракеталар, нервлар һәм акыл. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 104

1 ИЮНЬ — БАЛАЛАРНЫ ХАЛЫКАРА ЯКЛАУ КӨНЕ

**В. ИХСАНОВА.** И гүзәл җир, и газиз бала! . . . 107
**Ш. ГАЛИЕВ.** Безнең йорт малайлары... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 111
**З. НУРИ.** Күпне беләсе килә... «Нәниләр китабы»ннан . . . . . . . . . . . . . 114
**Ш. РӘКЫЙПОВ.** Саубуллашу җыры. «Кайдан син, Жан?» повестеның икенче кисәгеннән . . 119
**Р. МИҢНУЛЛИН.** Энекәш кирәк миңа... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 131
**Р. ВӘЛИЕВ.** Кайтаваз кайда яши!.. Шигырьләр . 133
**А. ТИМЕРГАЛИН.** Күрешү. Фантастик хикәя . . 135

ОЧЕРКЛАР

**Л. СЫРКИН.** Идел бөркете . . . . . . . . . 147
**К. ШАКИРОВ.** Кырыс язмышлар . . . . . . . 154

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Т. ГАЛИУЛЛИН.** Бизәкләр төрлелеге . . . . . 160

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Ө. МӨХӘММӘДИЕВ.** Тәңкәләр телгә килсә . . 170



**КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА һӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ КАЗАН**

**Кечкенә рецензияләр** . . . . . . . . 176

ТӨРЛЕСЕННӘН

**Р. МОСТАФИН. ЭВМ ни әйтер!..** . . . . . . . . 179

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**С. САБИРОВ. Садри Җәләлнең тууына 90 ел** . . 185
**Г. БӘШИРОВ. Игелекле юңат.** Гарәфи Хәсәновка 60 яшь . . . . . . . . . . . . 186
**Р. ГӘРӘЙ. Габделхәй Сабитовка 50 яшь** . . . 188

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 191

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

**Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ** (баш редактор урынбасары), **РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** (җаваплы секретарь), **СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ**

---

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

---

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

---

Производствога бирелде 24/II-1981 ел. Басарга кул куелды 26/V-1981 ел. ПФ 09037. Кәгазь форматы $70 \times 108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 103 644 экз. Заказ Д-80. Бәясе 50 тиен.

---

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1981 ел.

Шамил Бикчурин

# ТИРӘН КАТЛАМ

РОМАН

## II



Черек кулгә Курамшин эчендәге барлык юшкыннарын коеп бетереп килде. Тыныч күңел, эш рухы, яхшы кәеф белән килде. Әйтәсе әйтелгән, югалтасы югалган, табыласы табылган иде.

Машинадан төшү белән үзенең диспетчер бинасына ашыкты. Хәзер аңа ныклап, җиң сызганып эшкә керешергә кирәк. Ун-унбиш көн, бәлки бер ай да үтәр, ләкин бу егетләр белән ул җиһазларның байтагын — иң авырларын, техник яктан иң катлаулыларын урнаштырырга өлгерер. Өлгермәгәнен күрсәтеп, өйрәтеп калдырыр.

Ул кергәндә Курамшинның күз өстендәге каш кебек өч бөртек егете — Рафат, Касыйм һәм Гриша кичә күрсәтеп киткән эшләрен дәвам итәләр иде. Алларында счетчиклар, сигнал аппаратуралары, ачкычлар һәм кнопкалы станцияләр туздырып ташланган: схемалар белән чагыштыра-чагыштыра шуларны җыялар, җайга салалар. Күреп тора Курамшин: эш күп, катлаулы, ә егетләрнең тәҗрибәсе юк.

— Сәлам үрмәкүчләргә! — Курамшин, студент гадәте буенча, алар белән шулай исәнләшә иде.

— Исәнмесез, Кәрам Ризванович.

— Хәерле иртә.

Касыйм арада үзен зурга исәпли, эрерәк тота:

— Салют начальник! — дип кенә җибәрә. Аның холкына төшенгәч, инде Кәрам Ризванович та гаҗәпләнми.

— Нәрсә, нәчәл, сәгатең туктадымы әллә, соңлап киләсең? — Бу — һаман да шул тупас телле Касыйм.

— Начальство соңламый, тоткарлана гына! — диде Курамшин да соравына күрә җавап итеп. — Бер яңалык әйтимме, егетләр?

— Нәрсә, әллә ашханәгә берәр тәмле нәрсә китергәннәрме? Пилмән-мазар?..

— Тукта әле, сиңа тыгынырга гына булсын! — дип сүзен кисте аның Гриша.

— Ашау өчен яшибез, яшәү өчен ашыйбыз.

Кәрам Ризванович, кулларын өскә күтәреп:

---

Ахыры. Башы журналыбызның дүртенче, бишенче саннарында.

— Яңалыкның да ниндие әле! — дип кычкырды.— Безгә эшкә бөтен бер бригада килә. Сөлек кебек егетләр!

— Кайдан соң ул «сөлекләр»?

— Демобилизованный солдатлар. Элемтәче егетләр!

— Ничек килергә җөрьәт иткәннәр соң алар? — диде Рафат шаярып.

— Ничекме? Менә, Черек күл дигән урында өч борынның гына тирләп-мышнап ятканнарын ишеткәннәр дә килгәннәр. Безне кызганып, бөтен бер отделениеләре белән... Яшибез болай булгач, егетләр!

— Сезне, Кәрам абый, аңламассың,— диде Рафат шелтәле тавыш белән.— Кичә генә Әлмәткә, хатын янына кайтам, дип очынып йөри идегез, бүген инде «яшибез» дип кычкырасыз.

Кәрам Ризванович көрсенеп алды:

— Әйе. Нишлисең, шулай килеп чыкты. Тагын беразга калдырырга булдылар...

— Ә сез: «Әйткән сүз — аткан ук!» — дия идегез.

— Әйттем, ишетергә дә теләмиләр! «Кунак — хуҗаның ишәге»,— диләр. Син рядовой солдат, без ни кушсак шуны үтәргә тиеш, диләр.

— Ә мин, кайта-нитә калсагыз дип, өйгә кучтәнәчләр әзерләп куйган булам.— Рафат авызын балаларча турсайтты.

— Бозыла торган нәрсәләр түгелдер бит? Түгел дисең? Шулай булгач, торсын алар, ашарга сорамыйлар. Менә бер унбиш көннәрдән мин аларны ипләп кенә алып китәрмен. Садәңә булса, аңа персонально сәламнәр әйтеп, үз кулларым белән тапшырырмын.

— Ул үзе минем яныма киләчәк.

— Бик яхшы. Чакыр гына син аны!..

Өч егет, үтә дикъкать белән, кызыксынып, көнләшеп карап торалар Курамшинга. Ул аппаратура, механизмнар тирәсендә сихерче кебек: ялт итеп аларның капкачларын борып ачар, шундук кулы белән корпус эченә кереп китәр дә шул мизгелдә үк бер көлтә нечкә чыбыклар арасыннан, бармаклары белән капшанып, нинди дә булса чыбыкның очын әләктереп чыгар: монысы дөрес ялганмаганы, я начар беркетелгәне.

Менә хәзер дә ул, кнопкалы станцияләрнең вак, күзгә чак кына күренеп торган клеммалары арасыннан бер нечкә чыбыкны табып алды да «Кем куйды?» дип сорады.

Бу эшне Гриша башкарган иде. Ул мондый четерекле механизмнар тирәсендә сай йөзә, шуңа бик борчыла һәм эче поша.

— Әйттем, мин сезнең эшкә кермим дип, Кәрам Ризванович. Булмый миннән дим ич. Миңа шул монтер булып йөрергә генә...

— Өйрәнерсең! Аюны да биергә өйрәтәләр...

Аннан дүртәүләп сызым өстенә иеләләр. Күзгә чак кына беленеп торган пәрәвезләр буйлап сәяхәт китә. Карау, тикшерү, җеп очын эзләү...

— Менә, энем Гөргери,— ди Курамшин үзенең сизелер-сизелмәс юморы белән,— син монда күршең Чтепаннарга керәм дип, югары очтагы Митрей дәдәңнәргә китеп баргансың...

Курамшинның ачуланмыйча, шулай җиңелчә шаяру, төртмә сүзләр белән генә әйтүе егетләрнең күңеленә хуш килә. Алар әкрен генә үз эшләренә тотыналар.

Курамшин да гел күзәтеп, өйрәтеп кенә тормый. Аның үз эше — ул иң катлаулы аппаратларны урнаштыру схемалары белән мәшгуль.

Монтаж бинасында эш тагын шунысы белән күңелле — көндезләрен, һич кая барып бәрелер урын тапмыйча, Ишәй абзый керә. Аңарда инде бөтен әкәмәт. Керә дә, исәнлек-саулык сорашудан битәр:

— Нефть чыкмадымы әле? — дип сорый.

Төш житәрәк, үзенең яшь нарат агачыннан ясалган шома таягына таянып, бүген дә кереп житте карт.

— Нефть чыкмадымы әле?

Башкаларына кызык тоелса да, арада Касыйм бу сүзне күтәрә алмый иде:

— Күпме әйтергә кирәк инде сиңа, Ишәй абый: нефть монда чыкмый! Беләсең килсә, әнә, Аввакумовтан сора!

— Нишләп кенә утырасыз соң, алайса?

— Тире җыеп, күн эшләп!

Бүлмәдә бераз тынлыктан соң:

— Ну, Ишәй абзый, соңгы хәбәрләр ничек? — дип сорый Рафат.

Мондагылар беләләр: Черек күлдә булган бөтен яңалыкларны, гайбәтләрне иң беренче булып Ишәй абзый ишетә, аларны үзенчә кызык итеп сурәтләп бирә. Кайчакларда исә, әкият сөйләп чыгып китә, кайчагында үз башыннан үткәннәрен зар кыла иде.

— Соңгы хәбәрләр дисезме? Үлем-китем юк, аллага шөкер. Тик, әнә, бичара Кузьма Николаевичның гына күз төбенә күмгәк утыртканнар. Бер дә килешми. Пичуговны әйтәм, зам. начальникны. Заманында бергә эшләгән идек.

— Кем утырткан соң аңа күмгәк? — дип, иптәшләренә күз кысып сорый Гриша.

— Кем булсын, катыннары инде.

— Әллә шулай хатыннары күп? — дип, юри төпченә Гриша.

— Юкны сөйләмә әле, Ишәй абзый,— дип, Кәрам да кушылып китә.— Син генә бит ул элек ике хатын белән торгансың!

— Хәзер дә торалар! Бөтенегезнең бер-ике катын, язылышмаганнар гына.

Ишәй абзый, нарат таягын идәнгә төртә-төртә, егетләр янына килеп утыра. Рөхсәт сорап тәмәке кабыза.

Гриша һаман Ишәйне сөйләтмәчке:

— Тагын нинди яңалыклар бар, Ишәй абзый, дөньяда?

— Үлем-китем юк, аллага шөкер. Мәнә шәһәрдән миңа яңа фатир бирмәкче булганнар. Әйттем әлеге Кузьма Николаевичка: ниемә ул миңа яңа фатир? Нишлим мин аның белән? Мәйтәм, нәрсә, Кузьма Николаевич, мине пенсиягә җибәрмәкче, эштән кумакчы буласыңмы? Юк, ди бу, сиңа положено, ди. Миңа түгел, әнә Фәнүзәгә положено, мин әйтәм, бик телисез икән,миңа дигәнен аңа бирегез!

— Бирәме соң?— дип кызыксынды Кәрам Ризванович.

— Юк ди, аңа не положено, ди. Вәт син, ә? Прәме мине моннан китәргә заставить итә.

— Тагын нинди хәбәрләр, Ишәй абзый? — дип аны тагын Гриша бүлде.

— Үлем-китем юк, аллага шөкер. Аввакумов янында булган идем, анда да һаман нефть чыкмый икән.

— Менә баш инженер табылды! — дип, эшләгән җиреннән кузгалып китте Касыйм.— Нефть тә нефть! Нигә кирәк соң әле сиңа ул?

Ишәй абзый әкрен генә урыныннан торды, таягы белән идәнне тукылдата-тукылдата ишеккә таба китте дә, борылып:

— Сезгә рәхәт, нефть чыкса мин кая барырмын? — дип кычкырды һәм ишекне каты ябып чыгып китте.

Барысы да аның хәлен төшенделәр: нефть чыкса эшсез калам, дип курка икән карт.

## III

Ишәй абзый әбәткә чаң какты.

Иртәдән бирле диярлек эчен уып, шуны гына көтеп утырган Касыймга җитә калды — кулындагы бар нәрсәләрен ташлап, сикереп торды: «Уф, ачка үлем дип торам!»

Иптәшләре көлешергә тотындылар.

— Әйе, Ишәй абзый тагын бер генә минутка соңга калган булса да бетә иден!

— Күтәреп алып барырга кала иде ашханәгә!

— Соң ни өчен Ишәй абзыйны куып чыгарды дип беләсез? Ул карт, сүзгә мавыгып, үзенең төп вазифасын да онытып җибәрә кай вакыт. Эченне тотып сызланып утыр аннан...

Курамшин өчен дә үзенә күрә бер юаныч иде Касыймның бирән гадәте. Ә менә Факиһәгә булган мәхәббәте, ай-һай, шикле...

Касыйм бүген дә «Табаның тапылдамаса, авызың шапылдамас» дип ашханәгә беренче барып керде. Аргы стенада бүрәнәләргә кагылган чөйләргә киемен тиз генә элде дә Факиһә янына килде.

— Факиһә, күбәләгем, белсәң иде ничек ачыкканымны! Ну, хәл-әхвәлләрең ничек?

Үзенең күз карашы, авызын җыя алмый елмаюы белән Факиһәне эретте дә ташлады.

Факиһә ханым Касыймга дигән махсус коштабакны алды, озын саплы чүмече белән казанның төбен айкап эре-эре бәрәңгеләрне, кисәккисәк итләрне актарып чыгарды, аш салды.

— Җитмәсә, оялып торма, тагын кил.

Ул Касыймның ашаганда колаклары ничек селкенгәнен, чигә тамырлары уйнаклап торуын тын да алмый карап торды. «Ошамасам, ашымны да яратмас иде»,— дип сөенде.

— Соң, эшләр авыр түгелме, Касыйм?— дип сүз кушты аннан. Һаман да инде егетнең үзенә карашын белү, тел төбен аңларга тырышу.

— Эшкә чыдарга була, тик менә ашыйсы килүгә тәкать юк.

Егетнең авызыннан һаман юанырлык сүз чыкмагач, Факиһәнең ачуы кабара башлады: «Һи, тапты бер сүз: ашыйсы да ашыйсы! Әйтерсең бу дөньяда аннан башка нәрсә юк!»

— Соң анда общежитиедә ничек, күңелсез түгелме?

— Сорама инде, Факиһә күбәләгем, кайтасың — буфетта йозак, китәсең — тагын бикле! Ачтан үтерәләр инде ул торакта.

«Бирән тәре, тагын ашау турында!» — дип, эченнән сүгенеп, кәефе кырылып, Факиһә кухнясына кереп югалды.

Инде башкалар да шау-гөр килеп ашханәгә керә башладылар. Савытына борынын терәп диярлек иелгән Касыймны күреп, көндәгечә көлешергә, аны үртәргә керештеләр:

— Касыйм эш башлаган, җәмәгать.

— Калҗага иләләшкәнме бу, әллә марҗагамы?

— Әй, бар дип белә дисезме Касыйм хатын-кызны! Ул аларның җыенысын бер коштабак ашка алыштырмый...

Көн дә булып торган мондый сүзләр Касыймның бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга, кешеләргә каш астыннан гына карап, ашавын белә. Ул үзенең тамаксаулыгы белән горурлана иде бугай. Аның аш һәм ашау турында кемнәрдәндер ишеткән әллә күпме мәкаль һәм әйтемнәре бар, үзеннән көлгән кешеләрнең авызларын шулар белән томалый: — Иренмәгәннең ирене ашлы. Эшләмәгән ашамый, ашамаган — яшәми. Теше барның көче бар...

Касыйм янына Рафат белән Гриша барып утыра. Әлбәттә, аны ирештерер өчен. Аларны тыңларга Курамшин да килә.

Гриша сүз башлый:

— Шулай да, Касыйм, әйт әле: синең берәр вакыт туйганчы ашаганың булдымы?

— Туйганчы ашаганым дисеңме?— Касыйм юри уйга калган булып утыра.— Чыннан да, булды микән соң минем берәр шундый чагым? Хәтерләмим. Ә, искә төште... Туйганчы ук булмаса да туя язган идем

төсле... Үги әни, күпсенә торгач, миңа авылыбызның бик мул тормышта яшәгән амбарчы кызын димләде. Янәсе, балакаем, сиңа аларның кызыннан да кулае табылмас. Нишлисең, амбарчы кызы булгач ризалаштым. Ничек тә өйдәге такы-токы булмас, амбарчы бабай киявен рәнҗетмәс әле, дим. Аларның сыерлары, көтү-көтү сарыклары, шуның өстенә кош-кортлары да ишек алды тулы... Өйләндем теге мунча ташына. Үзегез беләсез инде, кияү булгач, бабайның кунакка чакырмый хәле юк! Мин дә ялындыра торган назлы кияүләрдән түгел.

— Я, я, шуннан? — дип кызулый аны Гриша, ашаган җиреннән туктап көлә-көлә.

— Тегеләр күрәсең мине әүлия диеп уйлаганнар — килүемә бер генә бәлеш салганнар. Анысы да түбәтәй хәтле генә! Үзегез уйлап карагыз: минем бу гәүдәмә нәрсә ул сыңар бәлеш? Дөресен әйткәндә, кече телгә дә йокмады.

— Шуннан, шуннан?

— Тора-бара табынга ике бәлеш куя торган булдылар. Ындыр табагы хәтлеләр. Аның өстенә бер казан шулпа, бер тавык. Тырышсаң түзәргә була инде. Бабай: «Аша, кияү, аша»,— дип кенә тора. Кияве хәлен аңлый. Ашы юкның эше юк, дигәннәр бит.

— Анысы мәгълүм. Син безгә үзең хакында сөйлә!

— Тик әби генә бик саран нәрсә булып чыкты. «Юк, түзә алмыйм бу кияүгә. Пешереп өлгертер чама юк, сыпыра да бетерә»,— дип зарлана икән. Менә бит, кызы белән торганга рәхмәт юк, ә ул бәлешен күпсенә, ничә баш сарыкның, ничә баш тавыкның башына җиткәнне саный. Тәки алып китте кызын.

Курамшин шул кадәр ашауның хикмәтен белергә тели иде. Касыймның тирләп чыккан юан муенына, киң күкрәгенә карап ала да:

— Ничә килограмм син, Касыйм, йөз егермеләр бармы? — дип сорый, Рафат белән Гришага күз кысып.

Касыйм торып китә дә, биш-алты котлет салынган дөге, өч стакан каймак һәм өченчесенә тагын ике стакан кофе алып килеп утыра. Ашыйашый, бая Курамшин сораганга җавап итеп, зарлана башлый:

— Син, Кәрам Ризванович, килограмм дисең. Аннан ни файда? Гәүдәң зурайган саен ашарга күбрәк кирәк, шул гына. Менә хәзер мин, мәсәлән, йөз утыз кило. Ярый син инженер, күп аласың, ә минем получка ашарга җитми! Эх, шушы түшкәм армиядә чакта булса икән! Бушка, казна хисабына ашап ятканда булмады бит! — Касыйм, кашыгын өстәлгә куеп, тирән итеп сулап алды.— Мин анда сиксән сигез кило гына идем шул. Ә туксан булсаң ике паек бирәләр. Уйлап карагыз инде, Кәрам Ризванович: менә шушы Рафат кебек илле-алтмыш кило тарткан йолкыш этәчкә дә бер норма, синең әзмәвер гәүдәңә дә бер! Кайда гаделлек?

Касыймның чын-чыннан ачуы килде бугай — тиз-тиз генә алдындагы котлетларын йотып куйды. Ашап туйганнар да мәзәк тыңларга Касыйм янына җыела башладылар.

— Ни тырыштым солдатта авырлыкны туксан килога җиткерергә, ни азапландым — булмады. Ахырда, бер көнне шәһәргә чыккач, сәгатьне саттым да ныклап ашарга булдым. Иртәгә үлчәнәсе көн, ничек булса да туксанга тутырырга кирәк! Столовойга кердем дә күземә ни туры килсә шуны сыпырттым гына. Өчәр порция пилмәне дә, шулпасы, пәрәмәчләре дә, берсе дә калмады. Шәһәр паркында үлчәнә торган урын бар иде — шуңа барып бастым. Тулмый бит туксанга! Хет үтер — ике йөз грамм җитми! Яңадан киттем столовойга, ачудан тагын аш, ботка, пилмән, ипи ашадым. Туеп та киттем төсле. Күңел күтәрелде. Менә, мин әйтәм, хәзер сөйләшеп карагыз ефрейтор Касыйм Яфизов белән, иртәгә туксан килоны гына түгел, туксан ике булачак! Старшина күреп шаккатсын әле. Ике норманы көн саен ашыйм да ашыйм болай булгач!

Хикәятнең шушы төшенә житкәч Касыйм авыр көрсенеп кулын селтәде.

— Нәрсә, ышанмадылармы? — дип ава-ава көлә Гриша.— Әллә тагын житмәдеме?

— Ашаудан бәхет инде минем. Частька кайтканда әй эчнә борып алды, мин сиңа әйтим, әй бөтереп алды, юл буена йорт саен кергәләп кайттым... Икенче көнне үлчәделәр. Кая сиңа туксан кило, сиксән бишкә төшкән...

## УНАЛТЫНЧЫ БҮЛЕК

Мәснәви эштән кайтышлый автобустан төшеп калды да, төймәләре каптырылмаган плащ чабуларын жилфердәтә-жилфердәтә, Олы урам буйлап шәһәр Советына китте. Анданиндидер вербовщик килгән, читкә эшкә китәргә теләүчеләр белән договорлар төзи дигәннәр иде.

Китә Мәснәви. Булмады, юньләп тора алмады хатыны Сара белән. Фәнүзә киткәч алар яңадан кушылганнар иде, тыныч кына яши алмадылар. Мәснәви, язмышы белән килешеп, басылып кына торырга исәпләгән иде, ләкин Сара аны Фәнүзә исеме белән көн-төн битәрләде дә көн-төн талады. Эт оясына охшап калды квартира.

Күптән китә иде инде бу шәһәрдән, күптән кача иде, ләкин һаман Курамшин кайтмады. Ике айга командировкага киткән кеше — суга чумган кебек югалды. Ике ай да булды, дүрт ай, биш ай да үтте, ә командировкадагы кешебез әле дә булса юк. Шунда, Себердә, имеш, жибәрмиләр, кол урынына эшләтеп яткыралар, имеш. Моны хатыны Хәтимә шулай сөйләп йөри. Чынлыкта, ул анда зур начальник булып бөтенләйгә калган булырга кирәк. Сүзләр шулайрак йөри. Гомумән кайтырга түгел ахры аның исәбе. Ә монда вакытлыча аның урынына калган Мәснәви юк-бар гыйлеме белән сөйрәсен аның участогын! Юк инде, иптәш Курамшин, кайтырга булмагач, үз урыныңа берәр инженерны калдыралар аны. Шуның өчен дә инженер алар, эшче түгел.

Урамнан барышлый ул, үзе дә сизмәстән, базар каршына туктады, төрле төстәге афишалар, белдерүләр ябыштырылган койма каршына килеп басты. Эреле-ваклы такталарда, фанераларда, һәрберсендә диярлек русча-татарча «Организованный набор рабочих», «Эшчеләрне оешкан төстә жыю» дигән белдерүләр, плакатлар. Зур гына бер плакатта алсу, көләч йөзле егетләр һәм кызлар кулларын алга сузып: «Себернең бай яклары сезне көтә. Якутия урманнарын үзләштерергә килегез!» дип кычкырып торалар. Икенчеләрендә исә кечкенә генә авызлы бер чибәр кыз трактор кабинасыннан башын чыгарып: «Комсомоллар һәм яшьләр! Сезне чирәм жирләр чакыра!» дип өнди. Тагын бер тактада биек йорт рәсеме. Йорт башында каска кигән, кулларына мастерок белән кирпеч тоткан бер мыеклы абзый: «Син, иптәш, илебезнең удар төзелешләренә язылдыңмы?» дип сорый. Әһә, менә мондагы тактада нарат урманы рәсеме төшерелгән һәм агачлар арасыннан буровой вышкасы калкып тора. Димәк нефтьчеләр хакында. Әнә буровой астында язуы: «Көнбатыш Себер нефть предприятиеләрендә эшләү өчен инженер-техник работниклар, бораулаучылар, вышка төзүчеләр, нефть һәм газ чыгару операторлары таләп ителә». Шунда ук эш хаклары, күчену, тору шартлары күрсәтелгән.

— Китсәм эшкә аптыраш юк икән,— дип сөенеп куйды Мәснәви, калын иреннәрен ялап. Ни өчендер, бүген иртәдән бирле аның иреннәре кибешә иде. Көнбатыш Себергә, Төмән өлкәсенә барса, һичшиксез ул анда Фәнүзәне очратыр төсле иде. Күңеле шулай сизә аның. Фәнүзәнең кая киткәнен сеңелесе дә, башкалар да әйтмәде, ләкин Мәснәвинең тә-

не-жаны шунда, Себергә тартылды. Китсә, Мәснәви бары тик Төмән өлкәсенә генә китәчәк. Шуннан эзләячәк ул Фәнүзәне.

Шәһәр Советына кереп, Мәснәви теге «Хезмәт ресурслары» бүлеген эзләп тапты.

Караңгы коридорда кешеләр бер-берсе белән әкрен генә сөйләшеп утыралар, нәрсәләрдер сорашалар, бәхәсләшеп тә китәләр.

Ишек бер ачыла, бер ябыла. Кешеләр керәләр, чыгалар. Чыккан берен коридордагылар урап алалар да төпченергә тотыналар:

— Ну, нәрсәләр инде? Вербовщик нинди язулар таләп итә?

— Күпме акча биреләчәк? Озаккамы договорлаша?

— Хатын-кызларны балалары белән ала микән, белмәдегезме?

Берәве чыкты да:

— Мать якасына! Мондагы бер сум анда да бер сум икән! — дип сүгенә-сүгенә китеп барды.

Икенчесе чыкты:

— Тәвәккәлләп карарга ярый,— дип диванда утырган абзыйга сөйли башлады.— Хезмәт хакы, премияләре белән аена 800 сумга хәтле, ди. Шуңа договор өчен плюс 200, ди. Һәр семья членына, тагын килеп, йөзәр сум акча, ди. Андый сумнар бит эле җирдә аунап ятмый, брат!

Өченчесе чыкты. Авызы колагына җиткән. Үзе кызмача.

— Ну, җәмагать,— дип сөйли.— Яткандбыз икән монда бакыр тиеннәр санап! Әнә нәрсә ди вербовщик абзыегыз: мин сезне колагыгыздан тотып алтынга манам, ди.

Халык гөжләшергә тотынды. Бу исерек ирнең сүзләреннән соң, кайберәүләрнең алга басасы, алданрак керәсе килә башлады. Берәү, хәтта, чиратыннан чыгып кешеләрне этә-төртә, оятсыз рәвештә эчкә дә чумды.

Чиратта соңгыларның берсе булып баскан Мәснәви ишеккә килгәндә, вербовщик дигәне, кулын селки-селки тәртип урнаштырырга маташа иде:

— Кем чакырды әле сезне кабинетка? Вәт сатаналар! Ну-ка, марш кабинеттан! Әйттем бит берәм-берәм генә керергә дип, вот сатаналар!

Кешеләр төрлесе-төрле яктан сорау яудырдылар:

— Аңлатып бирүеңне сорыйбыз: чират торырга стоитмы, юкмы?

— Может вакыт уздырырга да кирәкмидер: ничек анда, Себердә тормыш?

Кешеләр арасыннан вербовщик дигәнен күрми Мәснәви, тик тавышын гына ишетә:

— Нинди сорау кызыксындыра сезне? Хезмәт хакымы? Әйтсәм әйтим, үзегезгә генә сер итеп: хезмәт хакы мировой! Балагызның баласына җитәрлек! Әгәр дә мәгәр бораулаучы икәнсез — аена мең тәңкә! Шуннан да ким алмассыз. Әгәр вышкачы булсагыз — сигез-тугыз йөз! Кай вакытларда меңгә кадәр куалар! Мин моны үзегезгә генә әйтәм. Нефть чыгаручы икәнсез — шулай ук сигез-тугыз йөз. Кулымны кисәргә бирәм! Төзүче, бетончы, балта остасы да аннан ким алмый... Чукынып китим менә!

— Каян өйрәнеп алган диген тагын менә мондый сүзләрне.

— Бәлки сезне Себер үзе, аның табигый байлыклары кызыксындырадыр? Әйтсәм әйтим: Себер — ул хәзер дөньяның кендеге. Себер ул алтын чыганагы, алмаз таулары, нефть диңгезе. Себер — ул үзенә бөтен Менделеев таблицасын җыйган галәмәт зур ил. Аның бер Черек күле генә ни тора!

Мактануны учлап кына түгел, чиләкләп сипкәндә, вербовщикны бер ир бүлдерде.

— Байлыгы байлык та, байлыкларны бит бушлай өләшмиләр...

— Я, бүлдермә әле, вербовщик сөйләсен! — дип аны туктаттылар.

— Үзегезгә генә сер итеп әйтәм, язылып калыгыз,— ди ул.— Тиздән

Татарстанда нефть бетәчәк, скважиналар ябылачак, буровойлар эштән туктаячак. Нефть түгел, су килә башлады хәзер монда җир астыннан, шуны белегез. Акыллы кешеләр күптән киттеләр инде моннан. Вах шәһәре дә, Черек күле дә Әлмәт ягы кешеләре белән тулды анда. Ышанмасагыз барып карагыз: Курамшин булып Курамшин, Әлмәт нефтенең иң зур инженеры да анда эшләп ята. Чукынып китим менә...

Бу сүзләрдән, бигрәк тә Курамшин исеме дә ишетелгәч, Мәснәви сагая калды.

— Тукта, тукта, кем соң әле бу «чукынып китим?» Кем соң әле шул сүзне минут саен кабатларга ярата иде? — Исенә төшергәч, хатын-кызлар кебек, бот чабып куйды Мәснәви.— Кара, Җәмил түгелме соң бу? Билләһи, тавышы да, «чукынып китим»нәре дә анык ич! Җаен Җәмил!

Җәмил Мәснәви белән бергә оператор булып Курамшин бригадасында эшләгән иде — эшкә салкын караган, алдаган, прогуллар ясаганы өчен аны бригададан кудылар. Әкияттәгечә килеп чыга: «Үләргә киткән түтәкәең баеп кайта түгелме?» Җәмил үзе дә бит киткән чакта: «Башым исән чакта нефтьтән башка да үлмәм әле»,— дигән иде. Бик астыртын, хәйләкәр малай иде ул Җәмил. Җәмилне тикшергәндә бригада җыелышында Мәснәви дә катнашты катнашуын, ләкин аны яклап та, яманлап та сүз әйтмәде. Бүген-иртәгә үзенең дә тәртибен тикшерергә торалар иде. Җыелышта Мәснәвинең каршы чыкмавына ул чакта Җәмилнең күңеле булган иде: «Бригадада бер генә дустым бар икән минем. Ул да булса — син!» дип әйткән иде чыккач Җәмил.

Җәмил буй-буй зәңгәрдән бик затлы габардин костюм кигән, ал күлмәгенә пионер галстугына охшаган кып-кызыл галстук таккан. Тик галстук уң якка кыйшаеп, яка астына ук кереп киткән иде.

Җәмил дә Мәснәвине күрде бугай, башын икенче яккарак борды, үзенең яңгыравыклы һәм мактанчык агитациясен йомшарта төште.

— Тәртип белән генә килегез, иптәшләр. Берәм-берәм генә. Ашыкмагыз, өлгерерсез, чыгып качмыйм. Паспортларыгызны әзерләгез, хезмәт кенәгәләрегезне...

Мәснәвигә чират кичке сигез тирәләрендә генә килеп җитте. Җәмил әле һаман баш күтәрми эшем кешесе булып утыра, паспортлар, хезмәт кенәгәләрен актарып, договорлар тутыра иде. Алдына Мәснәвинең паспорты төшкәч һәм аның исем-фамилиясен укыгач кына күтәрелеп карады ул:

— Ә-ә, Мәснәви дус, син мени әле бу? — дигән булды гаҗәпләнгән кыланып.— Карыйм, карыйм да, бу нинди таныш исем икән, мәйтәм.— Ул кулын Мәснәвигә сузды.— Я, ниһәл? Син дә, патриот, Төмән якларына юл алырга булдыңмыни?

Мәснәви салкын гына кул бирде.

— Шулай туры килде. Син соң әле ничек болай нәчәл булып киттең? Кара син, Себер бае мени!

Артта әле тагын берничә кеше бар иде — Җәмил, эш сәгатем бетте диде дә, аларны кабул итмәде, эчтән ишекне бикләп куйды.

— Ну, дус, үзебез генә иркенләп утырыйк әле,— диде ул, ялтырап торган сары туфлиләре белән идәнне шыгырдатып йөренә-йөренә.— Я, сөйлә, ни хәлләр? Ничек кузгалмак иттең урыныңнан? Хәер, сине Курамшин чакыра торгандыр инде?

— Беркем дә чакырмый, үзем барам.

— Син тагын, Мәснәви дус, монда мин мактагач та Себерне тоташ ал да гөл икән, дип уйлый күрмә. Сиңа сер итеп кенә әйтәм: саз һәм чебен-черки оясы да ул. Моннан киткәч нефтькә эшкә кереп караган идем — шул бөҗәкләр талап үтерә язды!

— Алайса, нигә кешеләрне алдап утырасың?

— Әй туган, дөнья бит ул!

Җәмил Мәснәви янына килеп утырды, ялтырап торган көмеш портсигарын чыгарып, аның кнопкасына басты. Басуы булды — капкачы ачылып китте дә аннан папирос чәчрәп чыкты. Кесәсеннән зажигалка алды. Анысы да гади түгел — шәрә кыз итеп ясалган. Шул шәрә кызның кендегенә баскан иде — кыз авызында ут кабынды һәм тәмәкесен бик зур ләззәт белән шуннан көйрәтте Җәмил.

— Яши беләсең үзең!

— Ачтан үләр дип уйлаган идегезме?

— Я, мактанма! Кая договорың, яз да, китәм.

— Кызыкма Төмән якларына, Мәснәви! Дус итеп үзеңә генә әйтәм: нәрсә ул Төмән тайгасы — сазлык, баткак, кышын пурга, җәен черки!

— Китәм! Яз договорыңны!

— Миңа нәрсә, әйттем исә кайттым,— дип Җәмил өстәл артына кереп утырды, кулына ручкасын алды.— Тик, үпкәләштән булмасын!

Җәмил, Мәснәвигә шикле караш ташлады да, договор бланкасын алды.

— Беләм инде, дустым, анда нәрсәгә баруыңны! Фәнүзә янына качасың, шулай бит?

— Фәнүзә?! — дип сикереп торды Мәснәви.— Фәнүзә анда мени?

— Маташма, дустым, кыланма! Беләбез.

— Ялгышмадыңмы? Әллә башка берәр хатын белән бутыйсыңмы?

Һаман-һаман Фәнүзә турында сорашу Җәмилнең дә ачуын китерә башлады бугай:

— Соң инде, я, әйт, кем белми дә кем танымый бөтен Әлмәткә даны таралган Ризатдин кызы Фәнүзәне?! Ах, ялгыш ычкындырдым! Заманында син үзең дә типтердең бит әле аның белән.

Җәен Җәмилнең җәенке авызына сугып җибәрәсе килде Мәснәвинең. «Даны таралган Ризатдин кызы» ди бит, кабәхәт! Җитмәсә: «Ул анда да почем зря типтерә»,— дип утыра сволочь.

— Себергә барган кеше тик ятмый анда, малай! — дип папиросын уңга-сулга төтәтә-төтәтә тагын сөйләп китте: — Курамшин да монда чакта судан ак, сөттән пакь булып кылана иде. Җитмәсә, җыелышлар җыеп, кеше поведениеләрен тикшергән булды. Ә үзе? Күрсәң, малай! Тукай бабайның «Ысулы кадимче»сеннән бер дә ким түгел. Ресторанда бер кулы белән сыра эчә, икенчесе белән маржа коча!

— Кит, сөйләмә булмаганны!

— Ә маржасы, мәйтәм, Курамшинның, әйбәт! Икәү «Кедр» ресторанын бетереп танцевать итәләр! Сөлек кебек маржасы, чукынып китим!

Мәснәви түзде-түзде дә, кинәт бар көченә кизәнеп, йодрыгы белән өстәлгә сукты: «Җитәр!»

— Син нәрсә? Син нәрсә!..— дип куркып сикереп торды Җәмил.

— Гайбәтче! Тәрәзәдән тотып атам мин сине моның өчен!

— Шашма, дус, бу хөкүмәт учреждениесе, шашма!

— Намуслы кешегә яла ягасың! Кайда шаһитларың?

— Бар алар!

Җәмил, калтырана-калтырана, сумкасын актара башлады. Үзе ирен-нәрен шапылдата-шапылдата сөйләнә: «Әйе, бик тә намуслы кеше шул Курамшин, әйтерең бармы...» Сумкасындагы кәгазьләр арасыннан берничә фоторәсем чыгарып, Мәснәвинең алдына ташлады.

— Мә, кара, ахмак!

Мәснәви фотоларны әйләндерә-әйләндерә карый һәм үз күзләренә үзе ышанмый. Улмы бу? Шушы хәлгә төшкәнме Кәрам Курамшин? Ни булган аңа?

Рәсемнәрнең берсендә — Курамшин ресторанда. Шешәләр. Чибәр генә хатынны кочаклап утыра... Икенчесендә шул ук зифа буйлы, зур

күзле чибәр хатын белән танцевать итә... Менә монысында да шул ук Кәрам Ризванович. Тышта, баскыч янында. Үбешәләр кебек...

Әле генә бүре урынына чәйнәшкән Мәснәви юашланып калды.

— Син боларны, Җәмил, больше беркемгә дә күрсәтмә...

— Курамшинның нинди яхшылыгы өчен?! Мине бригададан куганы өченме? Нигә аны яклыйсың? Әллә үзеңне ботарлаганы өченме, куарга карар чыгарганы өченме?

— Алай эчкерле, мәкерле булырга ярамый.

— Таш атканга аш ата алмыйм мин... Җитәр! Күрсеннәр «бер гөнаһсыз» Курамшинның да кемлеген! Хатыны да, балалары да, иптәшләре дә күрсен.

— Вак җан син. Бригададан сине бик белеп куганнар!

Мәснәви, фотоларны ертып идәнгә атты да, аларның әшәкелеге ябышып калмасын дигәндәй, шап-шап итеп учларын кагып куйды.

Җәен Җәмил авызын зур итеп ерып көлә иде.

— Ерт, туган, ерт! Ертып кына бетереп булмый аны. Ул фотолар, кирәк булса, миндә йөз штук, мең штук...

Мәснәви, сүз озайтырга теләмичә, кулын кискен генә селтәп чыгып китте.

— Синең договорыңнан башка да китәрмен әле!

## УНҖИДЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Эш сәгате чыккач та әле, Кузьма Николаевич, йомыш белән килгән кешеләрне кабул итеп, бик озак утырды. Андыйлар баштарак унбишегерме иде — хәзер утыз-утыз бишкә җитә. Бастылар бу клиентлар Пичуговның кабинетын. Кайсы квартира сорап, кайсы торакка урнаштыруны үтенеп килә. Берәүләргә үз йортын төзү өчен машина, такта, шифер кирәк, икенчеләре баласын яслегә я бакчага урнаштыра алмый интегә. Өченчеләре вахта машиналарының вакытында килмәвенә зарлана — эштән икешәр-өчәр сәгать кайта алмый азапланалар икән. Барысы өчен дә җаваплы Кузьма Николаевич: шәһәрдә яшәүче нефтьчеләрнең утыннан-суыннан алып, эш киемнәренә, мунчасына, парикмахерскойларына кадәр.

Гомумән, телиме-теләмиме, аңа коммуналь-торак бүлеге эшләренә дә, транспортчылар вазифасына да, профсоюз хәл итәсе мәсьәләләргә дә катнашырга туры килә.

«Нигә барысына да тыкшынасың?» — дип битәрли Курамшин аны. Шәһәр учреждениеләрендәге вывескаларга күз салмый микәнни ул? Нәрсә дип язылган анда! «Вах нефть идарәсенең кунак йорты», «Вах нефть идарәсенең коммуналь-торак конторасы», «Вах нефть идарәсенең эшчеләрне тәэмин итү бүлеге». Барысы да «Вах нефть идарәсенең!» Хәтта мунчасы, кер юу урыны, парикмахерское, кием тегү, аяк киеме төзәтү мастерскойларына кадәр нефть идарәсенеке! Ә алар эшен кем күзәтеп торырга тиеш? Әлеге де баягы нефть идарәсе, аның көнкүреш буенча начальник урынбасары шушы Пичугов лабаса! Шуңа күрә аны «Зам. начальника по общим вопросам» дип атаганнар да.

Бу сүз, дөресен әйткәндә, Пичуговның үзенә ошамый иде. Ничек инде «гомуми эшләр»? Аны элек «көнкүреш буенча», дип йөртәләр иде, хәзер мә сиңа: «Гомуми эшләр»! Кәрам әйтмешли, бер генә конкрет эше дә юк микәнни?

«Эх, «менә шуны эшлим, шуның белән шөгыльләнәм», дип әйтерлек

төгәл генә бер вазифаң булса икән! Күрәсең, бәхете шундый эшләрдәндер инде Кузьманың.

Пичугов үзе дә шунда яшәрмен, эшләрмен, тынгысыз күңелемә дәва табармын, дип уйлады. Татьяна да, ниһаять, чегән тормышыннан туяр, яшьлек романтикасы сүрелер, шәһәргә кайтып берәр җиргә төпләнеп эшли башлар, дип өметләнгән иде.

Уйлар-хыяллар күп булды, татлы булды, тик һаман тормышка гына ашмады.

Тормышка ашу түгел, бөтенләй дә кирегә тәгәрәп бара әле Кузьма Николаевичның эшләре. Баштарак, сугалмаган зур күтәрер дигәндәй, дәрт, гайрәт белән керешкән иде бу яңа эшкә. Ул шәһәрдәге бөтен төзелешләрнең заказчысы. Югарыда расланган генераль план буенча нефтьчеләр өчен зур-зур йортлар, культура сарайлары, мәктәпләр, кибетләр, ясләләр, тагын әллә нәрсәләр салдыру. Шулар белән беррәттән парклар, спорт корылмалары, ателье һәм мастерскойлар булдыру кебек капиталь төзелеш мәсьәләләре белән җитәкчелек итү. Болар барысы да турыдан-туры идарәгә, аның капиталь төзелеш бүлегенә һәм конкурс буенча урынбасарга карыйлар.

Ә нәрсә генә булдыра алды Пичугов? Юк, мондый киң, зур масштаблы эшләргә аның теше үтми икән. Белеме дә, тәҗрибәсе дә, колачы да җитми икән әле урынбасар булып утыру өчен. Завхоз дәрәҗәсеннән ерак китә алмаган Кузьма Николаевич, күтәрә алмый икән әле авыр йөкләрне.

Сәгатенә карап алды, кайтырга дип бүреген, пальтосын киде. Өстенә киенү белән аптырап кала торган гадәте бар Пичуговның: кая барырга? Ресторанга, Зоя янына кереп тамак туйдырыргамы, әллә өйгә кайтыргамы? Квартираның кайсына кайтырга — Зояныкынамы, әллә үземнекенәме? Әллә Кәрам янына кереп гәпләшеп-аңлашып чыгаргамы? Әле кайчан гына үзенең «биек креслосы» белән горурланып, эчтән генә масаеп йөргән Кузьма хәзер ихлас күңеле белән Кәрамнан көнләшә: «Әйе, ни әйтсәң дә, Кәрам үз урынын тапкан. Бәхетле ул. Ике кулына бер эш. Үзенең автоматларын гына кайгырта, шулар өчен генә яна-көя, башкасын бар дип тә белми...»

Кузьма өстәл тартмасыннан кесә фонарен алды. Караңгыга калган көннәрне аяк астын яктыртып кайтырга ярата иде ул. Кабызып карамакчы булды — ни өчендер фонарь кабынмады. Лампочкасы янып чыккан булса кирәк.

Ашыкмый иде Кузьма чыгарга, кая булса да барырга омтылып тормый иде — утырды, фонарьны әкрен генә сүтәргә тотынды. Мышныймышный линзасын алды, лампочкасын борып чыгарды. Барысы да төзек, лампочканың контакты бушаган булган икән, шуны борып беркетте, линзаны әйләндергәли башлады. Кайсы ягы белән куелган иде соң әле?

Линзаны люстраларга юнәлтеп, уч төбен яктыртып карады — нурлар бер ноктага җыйналдылар. Икенче ягын әйләндерде — нурлар таралды. Линзаны тагын, тагын әйләндерде, нурлар бер җыелды, бер читкә сибелделәр. Шунда үзе өчен зур ачыш ясагандай булды Пичугов. Тормышта да менә шулай юк кына нәрсәләрдә буталып калды бит ул. Аның тормышы нәкъ шушы линза кебек икән ич, кире ягы белән куелган линза кебек. Нурларны җыймаган ул, ә тараткан.

Инде чыгып китәргә дип ачкычларын алган иде Кузьма Николаевич — ишек шакыдылар.

— Керегез!

Итекләре, өс киемнәре, мамык шәле белән кар, салкын ияртеп керүче бу хатын Фәнүзә иде. Квартира даулап Пичуговның тәмам теңкәсенә тигән хатын. Дөрес, Фәнүзә үзе килеп йөдәтмәде — аның өчен бүтәннәр килделәр. Бергә яшәгән торак кызлары дисеңме, аның началь-

никлары дисеңме — бөтенесе килеп бетте. Барысы да Фәнүзә Ризатдинова ягында: имеш, Ризатдинова Черек күлдә хатын-кызлардан бердәнбер механизатор, тракторында да, бульдозерында да ул, кирәк икән — күтәрү кранында, кирәк икән — торба салгыч машиналарда эшли ала. Җитмәсә, яшь бала үстерә, диләр. Монысы белән Пичугов һич тә килешә алмый иде инде: бөтен кыз-кыркын бала табып торакта яши башласа, тәртип кая китәр? Соңгы вакытта квартира юллау мәсьәләсенә якташы Курамшин да кушылды. Аввакумов белән Ишәй абзый да катнашты.

— Ни булды, Ризатдинова?

— Белешергә дип килгән идем.

— Әйтелде бит инде сиңа бирәбез дип. Бер атнадан килерсең.

— Күңел ышанып җитми. Тагын төп башына утыртып калдырырсыз төсле.

— Анысына син үзең гаепле.

— Ә аннан алдагысында? Миңа дигән ордерны үзегез кемгәдер бирдегез бит.

Чыннан да бик тавышлы булып чыкты Ризатдинова аласы квартиралар. Бер мәртәбә, инде хәл ителде, ордер бирү өчен Фәнүзәне чакыртырга дип кенә торганда, идарә начальнигы дәшеп алды. «Эшкә институт бетергән яшь белгеч җибәрделәр. Хатыны, баласы бер. Хәзергә Ризатдиновага дигән бүлмәне биреп тор, квартира табылу белән ул инженерны күчерербез», — дип туктатты.

Икенче тапкырында, Фәнүзә ордер алырга дип килгәндә, шушы бүлмәдә яшь балалы бер хатын елап утыра иде. Ире күптән түгел генә авария вакытында үлгән, бу хатын да, Фәнүзә кебек, торакта баласы белән калган икән. Фәнүзә аңа үз чиратын бирергә тиеш тапты.

Ниһаять, җае табылды — Ишәй Ишбулдин үз чиратыннан баш тартты һәм квартирасын Фәнүзәгә тәкъдим итте.

— Бар, кайт та, тыныч кына йокла, Ризатдинова,— диде Пичугов Арганлыгын белдереп учына иснәп алды.— Сиңа Ишәй абзый үз квартирасын бирә.

— Ишәй абзый?! Туктагыз әле, ә үзе?

— Үзем әлегә вагонда йоклап торырмын, миңа кайда да бер ди.

— Ничек инде кайда да бер? Килешмәгәнне! Юк, юк, мин аның квартирасына кермим!..

Пичугов ачуланып урыныннан торды, ишеккә юнәлде.

— Ах, чәүчәләк тә хатын! Ярый, синеңчә булсын: без аны Ишбулдинга түгел, Фәнүзәгә бирдек диярбез! Шулай дип язарбыз беркетмәгә! Инде ризамы?

Кузьма Николаевич, Фәнүзәне төртеп диярлек чыгарды да, ишеген бикләп китеп барды.

## II

Идарәдән чыгып, шәһәр үзәгенә таба атлаганда да әле ул кая барасын төгәл генә белми иде: өйгәме, әллә ресторанга, Зоя янынамы? Бер генә дә күңеле тартмый шул Зояга. Җитмәсә аның элеккеге ире Сергей белән дә очрашкалый дип сөйлиләр. Монысын ничек аңларга инде тагын?

Эш вакытында көндәлек ыгы-зыгы белән дөньясын онытып тора Кузьма Николаевич, ә менә кич җитеп кайтырга чыкты исә, аптырашның да аптырашы — «нишләргә?» дигән сорау башына тау булып ишелә дә төшә.

Ничә айлар инде, үз хисләре белән үзе сугышып шушы урамнан кайта-кайта да, теләр-теләмәс кенә ресторанга борыла Пичугов. Ашарга дип керә, аннан йөрәген басар өчен Зоядан аракы китертеп эчеп куя.

Тегесе сырпаланып, елмаеп йөргәндә, ничектер, күңелендәге Таня да арткарак күчә, тора-бара томан эченә үк кереп югала һәм күз алдында бары тик Зояның кылган үләне төсле аксыл чәчләре җилберди дә тигез тешләре җемелди. Зояга, күрәсең, Кузьма Николаевичны тилертеп, үзенә каратып утыртуы рәхәт — ул елмаеп-көлеп, бер басасын биш басып, бөтерелеп йөри...

Бераздан шау-шулы ресторан ябыла, алар култыклашып кайтырга чыгалар. Зояның җылысын тоя-тоя, Кузьма Николаевич сүзсез генә атлый. Татьяна белән яшәгән өй турыннан үткәндә, квартирасының караңгы тәрәзәләренә карап, үзе дә сизми туктап кала икән Пичугов. Тик Зоя аның кулын келәшчә урынына кысып алган, җибәрми. Монысы, сызлана-сызлана булса да, иярергә мәҗбүр.

Йокларга яткач, Танюшасы тагын күпмедер онытылып torгандай була. Кузьма, караңгыда песи баласыдай, бөгәрләнеп куенына кергәч Зояның кайнар, йомшак тәнен кочып, болыт булып кабарган чәчләрен капшап ята. Шулай иркәли-иркәләнә торгач, Зояның муены тирәсенә борынын куеп йокыга киткәнен дә сизми кала. Иртән уянып китсә, Кузьма үзе янында кулларын моның муенына салып, чәчләрен туздырып йоклап яткан Зояны күреп хәйран кала, тәненә суык йөгерә. Бу чәчләрне бит ул Танюша чәчләре дип сыйпаган, Зоя белән түгел, ә Танясы белән йоклыйм дип йоклаган лабаса?!.

Иртән торгач, Зоя Кузьмага үпкәләп йөри, иренен турсайтып: янәсе, нигә син һаман миңа «Таня» дип эндәшәсең, Танядан минем кай җирем ким?

Татьянаның исемен телгә алмаска, аның турында уйламаска дип күпме мәртәбәләр ант итте, тик ычкына булгач, ычкына...

«Юк, бүген рестораннан туп-туры өйгә, үз квартирама кайтачакмын!— дип беркетеп куйды Кузьма Николаевич, ресторан каршына килеп туктагач.— Җитте, араны өзәргә кирәк бу Зоя белән. Ишекне бикләргә, утны сүндерергә дә, бер нәрсә турында да уйламыйча ятарга да йокларга!..»

Ресторанның кызган чагы иде. Эчтә оркестр уйный, моңлы җыр ишетелә. Түбәннән Пичугов чакыртып китергән әлеге меццосопрано тавышлы артистка — Лидия Куликовская җырлый:

> Мне теперь всеровно, я тебя не ревную,
> Мне теперь всеровно, ведь ты любишь другую

Тәрәзә янында поднос белән савыт-сабалар күтәргән Зояның гәүдәсе чалынуга, Кузьма, ни өчендер, ут яктысыннан читкә тайпылды. Зояны караңгыдан торып күзәтә башлады ул. Моннан караганда Зоя тагын да матуррак, сылурак икән. Әнә ул, кемнәргәдер, аш китерде. Тигез тешләрен җемелдәтеп көлә, елмая...

Пичуговның караңгыда яшеренә-поса Зояны шулай күзәтүе гади кызыксынудан узган, утка-ялкынга кабынган чын көнче карашы иде.

— Шулай 'ук монысы да ир-атлар белән өстерәлә башлармы? — дип тешләрен кысты да папирос алып кабызды. Аңа, хәтта тәмәке төтене дә кайнар булып тоелды — йөткерергә тотынды.

— Кузя, бу синме? Ник кермисең?

Кузьма сискәнеп китте. Форточкадан башын тыгып Зоя эндәшә иде. Каян күреп алган соң әле ул аның монда икәнен?

— Хәзер, тартып бетерәм дә...

...Пичугов каты итеп ишек дөбердәткәнгә уянып китте. Зоя, торып, караңгыда халатын капшап тапты, башмакларын кия башлады.

Ә ишек, стеналарны селкетердәй булып, һаман дөберди. Кем булыр бу? Кузьма әле һаман йокысыннан айный алмый, үзенең кайда икәнлегенә төшенми интегә иде. Әле генә ул дөбер-шатыр килеп такталар арасында чабып йөри иде — төш булган икән...

Ишек яңадан да каты дөбердәгәч:

— Бу ул, тор! — диде Зоя. Кузьманың киемнәрен ятак өстенә китереп ташлады.

«Бу ул»ны яхшы төшенә Пичугов: димәк, Зояның ире Сергей кайткан...

— Ачма! — дип куркып пышылдады Кузьма. — Ача күрмә!

Ләкин Зоя Кузьманы тыңламады, берни булмагандай шырт итеп ут алды, ишеккә барды.

— Кем бар?

— Мин.

Бу хәлендә бик уңайсыз калачагын сизенеп, Кузьма шулай да тиз-тиз генә өстенә киде, тик сәдәфләрен генә каптырып бетермәде бугай.

Аннан соң булган хәлләр дә төштә кебек кенә. Сергей, керү белән туп-туры карават янына килде, берсүзсез Кузьманың күлмәк якасыннан умырып тотты да, идән буйлап сөйрәп китте һәм каты гына итеп ишеккә бәрде. Кузьма артыннан баскычка бер-бер артлы пальто, бүрек, итекләр очты...

Өенә кайтып җитәрәк, нәрсәдер төшенә дә башлады кебек Кузьма Николаевич. Әйе, соң булса да төшенә башлады ул. Барысы да көнләшүдән килеп чыккан нәрсә. Зоя — елан, Татьянадан көнләп, ирennән үч алмакчы булган. Төрлечә котыртып, үзе генә түгел, Пичуговны да хатынынннан көнләшергә мәҗбүр иткән. Үз семьясына гына түгел, Татьяна белән Кузьма арасына да таяк тыгып бутаган.

— Нинди генә ахмаклыклар эшләп бетермәдем бит, ә?! — дип үз алдына сөйләнде Пичугов өе ишеген ачып кергәч. Аның тавышы буш бүлмәләрдә кайтаваз булып яңгырады.

Өстен-башын гына салды да костюм чалбары белән диванга ятты. Аның йоклыйсы килми, эчен бертуктаусыз рәнҗү катыш үпкә, ачу килү, тагын әллә нәрсәләр әрнетеп тора иде. Шулар арасында моңа кадәр тормышта үз урынын таба алмау ачысы да бар. Анысы, бәлки бөтенесенә караганда да зуррак, фаҗигалерәктер. Инде нишләргә?

Диван каршысында өч-дүрт адымда гына стена, стенада ниндидер болан мөгезләренә охшашлы бизәк төшерелгән келәм, келәм өстендә мылтык эленеп тора: Ишәй абзыйның снайпер мылтыгы.

— Шуның берәр патроны да юк бит, ичмасам! — дип, өскә карап ятты Пичугов. Моны ни өчен әйтте — үзе дә абайламый калды.

Түшәмдә, борынгы лампа куыгы рәвешендә, өч япьле болан мөгезенә куеп ясалган люстра эленеп тора. Аны, кайчандыр, Татьяна белән торганда Кузьма үзе ясап куйды. Соклапмаган кеше юк иде аны күреп. Түшәмгә карап ята торгач, шул люстрага игътибар итте Кузьма Николаевич. Матурлыгына соклanудан түгел, ныклыгын тикшереп: «мине күтәрә алыр микән?» Үз сүзләреннән үзе куркып, диваннан сикереп торды. Юк, кирәкми! Бу фани дөньяда Кузьма Пичугов болай да бик күп ахмаклыклар эшләде, җитте!

Йөзеннән нуры качкан хәлдә диван кырында биш минутлар хәрәкәтсез утырып торганнан соң, тагын бер карарга килде:

— Китәргә кирәк, моннан! Кая булса да китәргә...

Сәгатенә карап алды да, ашыга-ашыга итекләрен киярgә керешtе. «Төнге өч булмагае чурт булсын. Кәрам янына барам. Кәрам төпле малай, ул нәрсә дияр?»

### III

Дусты Кузьманың иртәнге дүртләрдә, бигрәк тә маңгаенда шактый зур күмгәк белән килеп керүе Курамшинны каушата калдырды.

— Кызыкмы? — дип туп-туры Курамшинга текәлде Пичугов. — Кызыктыр шул. «Если морда не побита — он не похож на бандита». Шулаймы?

Ниһаять, Курамшинга да өн керде. Чалбарын киеп алды, күлмәгенә тотынды.

— Ешка китә башласа, кызыгы бетә шул, туган... Хәтта хатынын сукканга да ышанмый башларлар...

Кәрам, Кузьмага урындык бирде дә, караватына барып утырды. Инде тавышын шактый күтәрә төшеп әрләргә кереште:

— Нәрсә син, хатыныңа баш була алмыйсың?

Кузьма Николаевич, ләм-мим димичә, башын иеп тыңлап торды да:

— Китәм мин моннан,— диде.

— Бәлки кирәктер шул. Болай йөрүләр килешми сиңа.

— Син шуны әйт әле миңа: сезнең Әлмәт яклары белән квартираны алыштырып, шунда эшкә китсәм нефтькә алырлармы мине?

— Нигә алмасыннар, син нефтьче ич.

— Син, мәсәлән, анда автоматчик итеп алыр идеңме?

Курамшин уйга калды. Уйга да калмады, бу сүзне әйтергә уңайсызланып торды!

— Автоматчик? Хәзер, Кузьма туган, синең белән без укыганда өйрәнгән автоматлар юк инде алар. Андыйлар куелмый скважинага. Эшне дә, уку-өйрәнүне дә яңадан башларга туры килер сиңа.

— Бригадирдан дисең инде...

— Минемчә, гади слесарьдан, монтажчыдан тотынып.

Пичугов, ток суккан кебек сикереп торды, бүлмә буйлап йөренеп китте.

— Нәрсә син, югары белем белән?..

— Синең ун ел инде тимер тотканың юк. Автоматлар турында әйтмим дә...

Пичугов, бу сүзләрдән бик кәефе китеп, кайтырга җыенды. Чыкканда, ишек төбендә туктап, кулын Курамшинның җилкәсенә куйды да, әрнеп:

— Бәхетле син, Кәрам! — диде. Шунда, ничектер күңеле йомшап, күзләренә мөлдерәп яшь килде. Кәрам аларның сабый күз яшьләре кебек чиста, гаепсез һәм самими булуына ышанды.

## УНСИГЕЗЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Хәтимәгә фотолар бер-ике көннән соң заказлы хат белән килде.

Башта Хәтимә ул карточкаларга карады да көлде, карады да көлде. Авылда бер җүләр кыз бар: ни күрсә дә шаркылдап көлә — шуның сыман. Бигрәк әкәмәт бит: Курамшин шешә тулы өстәлләр янында эчеп-исереп утыра! Күзе-башы тонган, иреннәре салынып төшкән. Җитмәсә, үзенең янына сыенып утырган ниндидер бер хатынны кочаклап алган. Бу хатынның йөзен, кыяфәтен күрсәң инде менә шартлап ярылырсың: оҗмах кошы тотканмыни — елмая, көлә, шатлана. Бергә биегәч тә, Курамшин аңа карар, яр булыр дип ышанамы әллә бу мескен хатын?

Фотоларны тегеләй дә, болай да әйләндереп карады Хәтимә, ләкин мондагы күренешнең серенә төшенә алмады. Шунысы гаҗәпләндерә: нигә, нәрсә дип салган Курамшин бу карточкаларны — мактану, үзенең андагы күңелле тормышын күрсәтү өченме, әллә «яратмасаң монда Себердә синнән дә яхшыракларны табам, менә күр»,— дип әйтүе, Хәтимәсен көнләштерергә, тагын да яраттырырга тырышуымы? Ни өчен хат эчендә бер генә авыз да сүз юк?

Нәрсәгәдер, конвертны алып карыйсы итте һәм конверт тышында Курамшин язуын түгел, чит кулны күрде. Бөтенләй таныш булмаган почерк. Штамп та Себердә түгел, ә биредә Әлмәттә сугылган.

— Нинди хәл бу? Монысын нәрсә дип әйтергә, ничекләр юрарга?

...Хәтимә агарынып катты. Мәсьәлә ачыклана башлады төсле. Әйе, әйе, Хәтимәгә күрсәтү өчен Курамшинны белгән кешеләр салып җибәргән.

— Әллә, тегеләй-болай Рафат кайтып, бу фотолар белән керергә уңайсызланган да, почтадан ул юллады микән?

Тиз генә киенеп, Рафатларның өйләренә барып кайтты Хәтимә. Әти-әниләренең әйтүләренә караганда, Рафат әле дә булса Курамшин кулы астында эшли. Яңа ел алдыннан гына кайтачак, күршеләре Садә исемле кызга өйләнеп, аның белән яңадан Себергә торырга китәчәк икән.

Кич, караңгы төшкәч Мәснәвиләр квартирасына шалтыратты. Кем дә булса Себергә бармаганмы, Курамшинны күрмәгәнме, дип сорашырга иде исәбе — хатыны Сара гына туры килде. «Белмим, Мәснәвинең бу көннәрдә кайтканы юк»,— диде дә, шалт итеп трубканы куйды.

Хәтимә, сәке кебек киң софада, аякларын-кулларын як-якка ташлап, изрәп йоклап ятучы улларына карап торды. Йоклаганда гына шулай тыныч, басынкы алар. Таң гына атсын — берсе артыннан икенчесе уянып, гөж килә башлыйлар. Ватмаган-җимермәгән нәрсәләре калмый.

Шулай да Хәтимәгә алар белән кызык, алар белән генә рәхәт. Ә Курамшин, яше кырыкка җиткән ата кеше: «Минем матур-матур өч улым бар, алар ничек үсәләр икән?» — дип чак кына да уйламый микәнни? Юктыр. Уйласа, менә болай башын юләргә салып, читләр-ятлар белән эчеп, күңел ачып, типтереп йөрер иде мени? «Эш күп, эш авыр, вакыт юк»,— дип хатлар яза, телефоннардан сөйләшеп яткан була бит әле җитмәсә. Менә син ирләргә ышан. Менә син озат аларны әллә кайларга командировкага!

Залга чыгып, балалар күзеннән яшергән урыныннан — шкафның иң югары киштәсеннән тагын фотоларны алды Хәтимә. Диванга утырды, дикъкатьләп-дикъкатьләп Курамшинның кыяфәтен, кыланышларын карады, иелеп-иелеп күләргә тотынды.

Башта иелә-бөгелә күз яшьләре чыкканчы көлде, аннан тирән уйга калып лыш-лыш еларга керешде. Яше унсигез дә тулмас борын Курамшинга иргә чыгулары, институтка укырга бармый калулары өчен дә, бер-бер артлы өч бала табып, эшли алмыйча, дүрт стена эченә бикләнеп ятулары өчен дә, хәзерге ялгызлык, һәм, ниһаять, ирен сагынып көтеп тә алданулары, буш өметләре өчен дә түкте ул күз яшен.

Соңыннан, бераз ис алгач, үз-үзен юатырга керешде:

— Булмас. Курамшин болай азарга тиеш түгел... Укымышлы кеше тиз бирешмәс. Ул бит мине ярата. Минем өчен дә, балалары өчен дә үлеп тора. Рәсемгә шаярып төшкәндер ул, мәхәббәтсез!..

Шул ук мизгелдә ире өчен хафалана, кайгыра да башлады:

— Болар барысы да чын икән — бозганнар булып чыга Курамшинны. Беркатлы, тиз бирелүчән кеше бит ул — күп кирәк мени ир-атка. Әх, Курамшин, Курамшин, Себер дия-дия башыңны да югалтасың инде ахры?!

Аны кичекмәстән коткарырга, бу бәладән йолып калырга дигән карарга килде Хәтимә. Ә ничек? Юлы бары бер генә: эш узмас борын, янына барырга, кулыннан җитәкләп алып кайтырга,

Тагын бер юл бар: Курамшинның бик кайтасы килми икән — Себергә күченеп китәргә! Әйе, әйе, квартира алыштыручылар булганда нигә аптырап торырга?

Өстәл тартмасыннан майга буялып беткән иртык бер газета кисәген алды. Бу моннан ике атналар элек кибеттән сабын төреп кайткан кә-

газь. Сабынны куярга дип төргәкне сүтеп маташканда күзе төште бит Хәтимәнең шундагы бер игъланга. «Өч бүлмәсе, кухнясы, ваннасы, суы, газы, үзәктән җылыту системасы белән бөтен уңайлыклары булган квартирамны Әлмәттәге шундый ук квартирага алмашам», дип язылган. Адресы — Төмән өлкәсе, Вах шәһәре, йорт № 13, квартира 72. Пичугов Кузьма Николаевичка мөрәҗәгать итәргә.

Хәтимә, ни арададыр каударланып, өч бүлмәне дә урап чыкты, ванна ишеген ачып ташлады, кухняга керде. Газ плитәсен, батареяларны тотып карады. Ул игъланда әйтелгәннәрнең барысы да урынында: өч бүлмә, кухня, ванна, газ, су, бөтен уңайлык. Тәп-тәңгәл туры килә. Башка — баш. Бернинди югалту юк!

— Алмашам! — дип кисте ул. — Китәм! Пичугов дигәненә ризалык биреп телеграмма сугам, я телефоннан сөйләшәм дә күченәм Себергә! Курамшин тәмам бозылса, соң булыр аннан...

Искәрмәстән генә Себергә, Вах шәһәренә килеп төшеп, ирен ничек тетрәндереп җибәрәсен уйлап, Хәтимә канәгатьлек белән елмайды. Ул әле квартира алышуның тәртибен дә, мәшәкатьләрен дә, квартираның төп хуҗасы Кәрам Курамшинның ризалыгыннан башка бу эшнең мөмкин түгеллеген дә белми иде.

Себер белән, шул Пичугов дигән кеше белән телефоннан сөйләшү өчен хәзердән үк заказ бирергә ниятләгән иде дә, анда бу сәгатьләрдә төн урталары икәнен исенә төшергәч, иртәгәгә калдырырга булды. — «Курамшинны алып карыйм әле, минем «егет» нишләп ята икән анда? Бәлки бүлмәсендә дә юктыр, берәр җирдә хатын-кызлар белән типтереп ятадыр?..»

— Хәтимә, синме бу? — диде йокылы тавыш еракган. — Ни бар анда, Хәтимә? Барыгыз да исән-сау гынамы?

— Без исән, тик менә сине генә бик каты авырып киткән дип ишеттек. Йогышлы чир белән...

— Минме? Кит булмаганны, каян ишеттең?

— Без капчыкта ятмый. Кайта алмый торуларың тикмәгә түгел икән...

— Эш бит, Хәтимә, эш! Әле тагын бер айга калдырырга диләр.

— Шулайдыр шул! Бу кадәр эштән ничек аерылып китмәк кирәк, ди. Ах, син, кемне алдамак буласың?!.

— Тукта әле, Хәтимә, валлаһи дип әйтәм, эш өстенә эш өелеп кенә тора!

— Икейөзләнмә, зинһар!

— Хәтимә, ник болай сөйләшәсең әле син?

— Анысын үзең беләсең...

Азакка кадәр сөйләшергә, аңлашырга Хәтимәнең чыдамы җитмәде, холыксызланып трубканы шапылдатып куйды.

## II

Тышта гармун тавышы ишетелде.

— Минем «Хәлилем» килде, — дип авызын кыйшайтып елмайды Хәтимә.

Төгәл сәгать кичке сигездә, гадәтенчә, алар ишегалдына Шәфрун килеп баса, җәй көннәрендә домино суга торган өстәлгә менеп утыра да гармун уйнарга керешә иде. Көе элеге дә баягы «Каз канаты». Ул «Каз канаты»ннан моңлы озын көй дә, бию көе дә, марш та ясый, аны төрле вариацияләрдә, төрле темпларда уйнап, ярты төнгә, ә кай вакытларда таңга кадәр суза иде.

Курамшин барда да уйнады, ул киткәч тә тынмады Шәфрун. Курамшин да туктата алмады аны уйнавыннан, Хәтимә дә тыя алмады.

Курамшин, хатынының күңеленә бу егет вәсвәсә салыр дип курка, бераз көнләшә дә. Хәтимә исә, тузан кадәр гаебе булмаса да, ире алдында читенсенә һәм каушап кала. «Галиябану, әнә Хәлилең килеп житте»,— ди торган иде Курамшин ишегалдында гармун тавышы ишетү белән, каты төрттереп.

Хәтимәнең чыгып, Шәфрунны уклау белән кыйнап җибәрәсе килгән чаклары да күп булды, ләкин тыелып калды. Курамшин әйтә: алай ярамый, культурный кешеләр сабыр булырга тиеш, ди. Аннан, Шәфрунның төннәрен гармун кычкыртудан тыш, кешеләргә дә, Курамшиннарга да бернинди зыяны тигәне юк бит. Утызга житеп тә, ул бер гөнаһсыз сабый кебек, бичара. Сорасаң, кеше ишек төбенә нигә килгәнен дә, ни өчен гармун уйнап утыруын да әйтеп бирә алмас. Хәтимә тик кешеләрдән генә ишетеп белә: «Мин аны укыганда ук ярата идем, үзе генә белмәде, Курамшинны ташлап миңа килсә — өч баласы бар дип тә тормас идем, берсүзсез алыр идем»,— дип әйтә икән. «Бер кыз белән өч ел йөрдем, үзе генә сизмәде»,— дигән шаян җыр бар, шуның төслерәк килеп чыга инде.

Ә тышта, ишегалдындагы электр яктысында өстәлгә утырып бүген дә Шәфрун үзенең «Каз канаты»н сыздыра. Ноябрь ахыры, көзге салкын дип тә тормый егет, киләсен килә, уйныйсын уйный. Күрәсең, мәхәббәтнең мондый төрләре дә була. Ул яшькә дә, салкынга да, ачуланучыларга-янауларга да карамый, һаман үзенекен итә. Күрәсең, мәхәббәтнең йокы вакыты да, ял көннәре дә юк.

Өстенә киенде дә, Шәфрун янына чыкты Хәтимә. Тегесе моны көтмәгән иде — каушавыннан гармунын шып туктатты.

— Уйна, Шәфрун, уйна, нигә куркып калдың? — диде Хәтимә, йомшак тавыш белән. Килеп, егетнең янәшәсенә, аныңча аяк салындырып утырды.

— Юк, уйнамыйм,— диде кырт кына итеп Шәфрун. Сораганның гел киресен эшли торган гадәте бар иде аның.

— Алайса, уйнама!

— Ник тыясың син мине? Гармун кулымда, синнән сорап тормыйм! — һәм, унике телле тальян гармунын бөтен көченә сузып уйнарга кереште. Һаман да шул «Каз канаты». Аңа әкрен генә җыр белән Хәтимә дә кушылды:

Каз канатларын санадым
Тезелеп кагынганда.
Инде кемнәргә карармын
Өзелеп сагынганда.

Туктады да, егетнең колагына иелеп сорады:
— Башка көй белмисеңмени син, Шәфрун?
— Ник белмәскә, беләм.
— Белгәч, уйна башка бер көй.
— Юк, уйнамыйм!

Хәтимә инде Шәфрунны шаярта, үрти башлады:

— Я, әйт әле, Шәфрун, син бит минем сабакташ, яшермә: нигә дип син һаман безнең өй янына килеп уйныйсың?
— Уйнаса ни булган?
— Син бит мине яратасың, шулаймы?
— Яратса ни булган?
— Ник аны элегрәк әйтмәдең, Курамшинга кияүгә чыкканчы?
— Әйтәсем килмәгәнгә әйтмәдем.
— Юкка белгертмәгәнсең. Мин Курамшинга түгел, сиңа барган була идем.

— Алдама!

— Билләһи, менә!

Эче пошканнан гына чыгып, йокы килмәгәннән генә сөйләнеп утырган бу сүзеннән Хәтимә үзе дә куркып калды. «Тфу, тфу, әйттем исә кайттым»,— дип куйды үз алдына.

— Мин китәм бит, Шәфрун, хәзер кайда, кем янына килеп гармуныңны уйнарсың инде,— дип Хәтимә үзе дә сизмәстән көрсенеп алды.

— Кая китәсең? — диде Шәфрун сискәнеп.

— Еракка, Курамшин янына.

Шәфрун белән нәкъ балаларча, мәктәптә укып йөргәндәгечә шаярып, риясыз сөйләшеп утырды ул. Бераздан егетне көйләп-чөйләп өенә кайтарып җибәрде һәм үзе дә кереп китте.



## УНТУГЫЗЫНЧЫ БҮЛЕК

### I

Черек күлдә гадәти көннәрнең берсе. Җиргә авыр томан булып сугык төшсә дә, әле күл өсте ныклап туңмаган, чын. Себер салкыннары килеп җитмәгән иде. Кар да әле тирән түгел, кешеләр иркенләп, күл тирәсен тутырып эшләп йөриләр. Күлнең аръягында вышка төзүчеләр, бораулаучылар булса, бу якта алар бораулап киткән ясалма утрауларны мастер Аввакумов бригадасы басып алган.

Бу баштa, шәһәргә кайта торган юл буенда, үзенә бер авыл сыман булып утырган Черек күлнең хуҗалык базасы да көндәлек ыгы-зыгы белән яши. Моржалардан куе төтен чыгарып яткан ашханә, котельный тирәләрендә дә, кечкенә урам ясап тезелгән металл вагоннар янында да машиналар — һаман нәрсәләрдер китерәләр, бушаталар, алып китәләр.

Шул база белән беррәттән панельдән тагын нindидер зур бер бина салына. Клубмы, кызыл почмакмы булачак, диләр. Анда төзүчеләр, шау-гөр килеп, кран белән тимер-бетон өрлекләр күтәртә.

Юлның икенче ягында, булачак диспетчер пункты тирәсендә генә тынлык — кеше кара, машина-мазар күренми.

Ләкин ул тыштан гына шулай. Хәзер Черек күлнең иң тыгыз урыны да, бәлки, шушы ике катлы таш бина эчендәдер. Моңа кадәр вакыт та, кул да, теләк тә җитмәгән бу йорт эче соңгы атналарда актарылган кырмыска оясы кебек кайный, хәрәкәтләнә башлады. Курамшин әйтмешли, төбәкнең электрон мие, йөрәге һәм мускуллары булачак бу урын идарә җитәкчеләренең игътибар үзәгенә әйләнде. Алар эшнең башлануына гына түгел, барып чыгасына да ышана башладылар булса кирәк. Бигрәк тә, армиядән кайткан егетләр килеп, Черек күлдә яңа автоматлаштыру бригадасы оешкач.

Егетләрнең тормышы әле һаман солдатча бара: бергә яшиләр, бер үк вакытта сикереп йокыдан торалар, физзарядка ясыйлар, ашханәгә чабалар һәм бер автобуста эшкә киләләр. Курамшин — бу эшләрнең дә, мондагы эшчеләрнең дә башлыгы — алар өчен әллә бар, әллә юк. Үзләренең элеккеге отделение командирлары сержант Левановны гына тыңлыйлар. Курамшин заданиене Володя Левановка бирә, ә тегеләр аңардан алалар. Шунсыз эш башлау юк. Күрәсең, солдатта шулай өйрәткәннәр...

«Ярый, аларга шулай ошый икән — үзләренчә кылансыннар»,— дип Кәрам яшертен генә тик елмаеп йөри.

Хәзер инде җиһаз һәм аппаратураларны китертү, аларны комплектлау һәм монтаж эшләрен ашыктырып Курамшин түгел, киресенчә, идарә җитәкчеләре үзләре Курамшин артыннан йөриләр: «Монысын

кайчан куярга исәплисез?», «Кайчан өлгерә?», «Нәрсәләр житенкерәми?», «Нинди ярдәм кирәк!»

Кичә генә идарә начальнигы булып, эшнең барышы, кешеләрнең кәефләре, тәэминат мәсьәләләре белән кызыксынып киткән иде, бүген иртүк баш инженер Бибиков килеп житкән.

Пасарби Пшимахович, диспетчер пунктында туздырып, ачып ташланган аппаратуралар янында мең төрле чыбыкларга уралып дигәндәй, казынып ятучы егетләргә сәлам бирә-бирә, монтаж эшләрен карап чыкты. Бу кадәр күп, катлаулы һәм әкәмәт аппаратларны бары тик шушында гына күргәне булды аның. Бу системаны кайтартып, туздырып ташладылар ташлавын, ә Курамшин китсә ни эшләрләр, кеше эзләп кая барырлар?

Курамшинның өстәле янына барудан элек баш инженер, әнә шулар турында борчыла-борчыла, егетләрнең эшен карап йөрде.

— Ну, солдатлар, ничек, булдырып буламы? Армия төшегезгә керепсагындырмыймы?

— Нихәл итмәк кирәк, сагынсак та түзәбез инде!— дигән була Леванов.— Тик менә төннәрен генә кыен...

— Искә төшәме?

— Тревога белән саташып сикереп торабыз...

Егетләр күтәрелеп көлешәләр, бина эче яңгырап китә.

Авырыксынып кына, Курамшинның эш өстәле янына, түр почмакка килде Бибиков, урындык алып, Кәрам Ризванович каршына утырды. Исәнләшмәде — бүген иртән идарәдә, планеркада күрешкәннәр иде инде алар.

— Ничек соң, Кәрам Ризванович, хәлләр? Семьядан хат-хәбәрләр бармы? — дип сорады баш инженер. Моның белән, ул, эшне тикшерергә түгел, болай гына кергәнен белдертмәкче иде бугай.

Курамшин, ак кәгазь битенә ниндидер схема сызып утырган жиреннән туктап, карандашын өстәлгә куйды.

— Рәхмәт. Хатын мәсьәләсенә килгәндә — көн саен телефон шалтыратып минем кайтуны даулый. Ә эш мәсьәләсенә килгәндә... Начар,— диде ул туп-туры гына.— Авыр барабыз, Пасарби Пшимахович.

— Нәрсәсе начар?

— Сезнең беренче класста балаларны ничек хәреф язарга өйрәткәннәрен күргәнегез бардыр инде. Шуның кебегрәк. Минут саен карап торырга, кулларыннан тотып өйрәтергә кирәк.

— Солдатлар элемтә частьларыннан түгелме соң?

— Элемтә — бер, электроника һәм телемеханика икенче нәрсә.

— Соң, алайса нишлибез? Нәрсә тәкъдим итмәкче буласың?

— Укытырга кирәк егетләрне. Кичке курслар ачарга. Бер айлык булса да...

— Кем укытыр, кем өйрәтер соң? Синең дә китәр көннәрең килеп житә бугай...

Бибиковны ишеккә кадәр озата барды Курамшин.

— Миңа, Пасарби Пшимахович, тагын бер айга калмый булмас, ахры. Ташлап китә алмыйм мин аларны бу хәлдә...

Баш инженер, Курамшинга сәерсенеп карап торды да, аның жилкәсенә сугып:

— Билләһи, шулай уйлаган идем! — дип көлеп жибәрде.

Бибиковны озаткач, гафу үтенергә дип, Рафат янына килде.

— Рафат, авылдаш, син тагын ачуланырсың инде, ә? Күчтәнәчләреңне яткырган өчен дим...

Курамшинны тиз аңлап алды Рафат, мавыгып эшләгән жиреннән кулындагы отверткасын шап итеп өстәлгә куйды.

— Тагын калырга булдыгызмы? Шулай дип уйлаган идем аны.

— Мәсьәлә болай тора бит әле, егетләр,— дип мөрәжәгать итте эш-

челәргә Курамшин.— Белдегезме, баш инженер бүген безнең янга ни өчен кергән? Ул әйтә: егетләрегез болай ничего күренәләр, ләкин, ди, эшләрен белеп бетермиләр, телефон белән телемеханиканы бераз буташтыралар икән, ди. Шулай булгач, Кәрам Ризванович, сиңа, ди, аларга кичләрен бер-ике айлап сабак укытып алырга кирәк булыр, ди. Төшендегезме инде хәзер ни өчен кергәнен Пасарби Пшимаховичның?

Бина эче бераз тынып калды, аннан гөж килә башлады:

— Була, өйрәнәбез аны!

— Вакыт кына бирсеннәр, укыйбыз!

— Дәреслекләре бар микән?

Курамшин, дәртләнеп, күтәрелеп киткән егетләрне кат-кат кул күтәреп кенә туктата алды.

— Барысы да булыр, егетләр.

— Касыйм староста булсын, арада ул иң өлкәне!

— Кирәкми. Касыймны без начхоз итеп куябыз. Ул ашату мәсьәләләрен кайгыртсын!

Солдатлардан да тәкъдим керде:

— Сержант Левановны сайлыйбыз!

— Дөрес! Армиядә дә безнең командир иде, монда да булсын!

— Килештек,— диде Курамшин кандидатураны хуплап.— Алайса Володя, дүшәмбедә берсен дә калдырмый җыеп киләсең, аңладыңмы?

Бераздан, үзенең шома нарат таягына таянып, Ишәй абзый килеп керде.

— Нефть чыктымы әллә?

— Нәрсә, Ишәй абзый, әллә нефть исе киләме?

— Юк, бик тавышланганга, кычкырышканга күрә әйтүем.

Касыйм, Ишәй картка арты белән үк борылып утырды.

— Вәт инде! — дип һаман да гаҗәпләнә иде ул.— Син аңа әйтәсең, монда нефть чыкмый дип, ә ул һаман үзенекен...

— Тегендә Аввакумов әйтә: нефть чыкса шушы өй эченнән чыга инде, алар иң беренче белә, ди.

Курамшин аның сүзенә хәтта сөенеп куйды:

— Дөрес әйтә ул, Ишәй абзый. Нефть чыкса, аны иң беренче булып безнең менә бу әкәмәтләр күрсәтәчәк.

— Кайсысы күрсәтәчәк? — дип, таягын тупылдата-тупылдата Ишәй Курамшин янына килде.

— Менә бусы.— Кәрам Ризванович, һич тә ялганламыйча, Рафат кулындагы манометрга төртеп күрсәтте.— Аввакумов янында нефть чыга икән — шалт менә моның телләре уң якка!

— Кит сәнә, ничек белсен бу калай савыт нефть чыкканын?!

— Белә шул.

— Ә монысы нәстә?

— Монысы күпме нефть килгәнен күрсәтә торган прибор.

— Кит булмаганны! Бу тартма ничек нефтьне үлчи алсын ди!

— Үлчи шул.

Ишәй тагын да хәйран. Ул, ялганламыймы дип, күзләрен чекрәйтеп Кәрам Ризвановичка карый. Курамшинны монда, шушы йорт эчендә генә түгел, бөтен Черек күлдә иң саф, иң намуслы кеше дип саный ул. Шуңа күрә дә Кәрамнан күзен алмыйча аптырашта калган.

— Ә менә көлтә-көлтә чыбыклар нәмәкәйгә?

— Әнә тегендә, күл буенда Аввакумов скважинасынданиләр эшләнгәнен хәбәр итү өчен,— ди Курамшин җитди итеп. Аңа Ишәй абзыйны тагын да хәйрангарак калдыру кызык.

— Шушы чыбыкларммы? Кит булмаганны!

Ишәй абзый ышанмау гына түгел, хәтта үпкәләде дә:

— Әкият сөйлисең инде син... Карт дигәч тә, надан дигәч тә...

— Билләhи шулай, Ишәй абзый, кояштыр менә. Эшли башлагач үзең дә күреп исең китәр әле!

— Нефть чыккач, куарлар шул мине?!.

— Ник кусыннар, Ишәй абзый?

— Кеше калмый диләр ич Черек күлдә...

Сүзнең тирәнгә китәсен сизенеп алган Рафат:

— Ташла әле, Ишәй абзый,— диде.— Лутчы син безгә соңгы хәбәрләрне сөйлә.

— Үлем-китем юк, аллага шөкер,— дип тәмәке төреп башлады сүзен Ишәй.— Күптән түгел Бибиков килгән иде, шуны әйтим дигән идем. Телефон шалтырата: Курамшинны тагын бер айга калдыру турында приказ язарга куша.

Ишәй, астан гына Курамшинга карап алды.

— Ник кайтып китмисең инде син, Курамшин, өеңә?

— Җибәрмиләр бит, Ишәй абзый,— дигән булды тегесе.

— Кайт син, катының, балаларың янына кайт! Йөрмә каңгырып. Семьядан, җәмәгатеңнән башка читтә йөрү ямьсез нәрсә ул. Мин моны үземнән беләм... Бозыла ул читтә адәм баласы.

Ишәй абзый озак тормады, чыгып китте. Нигәдер кәефе юк иде картның.

Солдаттан кайткан егетләр аның турында төпченә, сораша башлагач, Кәрам Ризванович бер сүз белән:

— Яхшы карт ул Ишәй абзый, дөнья күргән,— дип кенә җавап бирде.

## II

Менә шушы дөнья күргән карт бу көнне Черек күлдә күтелмәгән, дулкынландыргыч вакыйга ясап алды.

Төш житәр-житмәс кенә чаң кактылар. Ашханә янында баганага эленгән тимер кисәген, гадәттә, нәкъ көндезге унбердә Ишәй абзый кешеләрне әбәткә чакырып суга иде — бүген иртәләде.

Рафат белән Гриша да, Кәрам Ризванович та сәгатьләренә карап алдылар. Кузгалучы булмады.

— Ишәй абзый саташа башлаган,— диде Рафат эшен дәвам итеп.— Әле ярты сәгать вакыт бар.

— Картайган инде ул, бичара,— дип җөпләде аны Гриша.— Олыгайгач әтәч тә ялгышып кычкыра бит...

Төшне житкерә алмыйча гаҗиз булган Касыйм исә, үз сәгатен тиз генә унбергә дөресләп куйды да, халатын сала башлады.

— Дөрес йөрми ул сезнең архирей сәгатьләрегез. Ишәй абзый ялгышмас, ул точный карт!

Баганадагы чаң бераздан тагын, тагын зыңгылдады.

— Әнә, әйттем бит, чакыралар,— дип ашыктырды һаман Касыйм.— Миңа сәгать кирәкми. Әбәт вакытын үз корсагымнан беләм. Унбер житте исә, менә моннан унбер тапкыр борып ала...

Курамшин кычкырып көлеп җибәрде:

— Тел белән түгел, эш белән күрсәт үзеңне, дигән ул!

Тел мәсьәләсен Рафат үзенчәгә борды:

— Эх, син, баш! Факиһә ханым бит сиңа ит урынына кыздырылган тел кирәкмиме, дип әйткән, ә син төшенмәгәнсең!

— Чыннан да, әллә шулай микән? — дип ышанып куйды Касыйм. Ә Курамшин тәрәзәгә барып карады.

— Анда, егетләр, нәрсәдер бар. Әнә, ниндидер автобуслар, легковой машиналар туктаган. Төркем-төркем кешеләр җыелган. Киттек!

Болар килгәндә ашханә алдында чиста, матур киенгән мәктәп балалары тезелеп тора иде. Яннарында укытучыларымы, пионер вожатыйла-

ымыдыр йөри. Шунда ук Вах нефть идарәсенең комсомол секретаре, майор дәрәҗәсендәге, ниндидер хәрби кеше дә бар.
Кузьма Николаевич Пичугов та биредә, нигәдер, борчылып як-ягына карана, кемнедер эзли. Курамшин, егетләрен бер читтә калдырып, Пичугов янына килде.
— Бу нинди тамаша, Кузьма Николаевич?
— Ишбулдинны эзләп килгәннәр,— дип аңлатты Пичугов. Кайда ул Ишәй абзый?
— Нәрсә булган Ишбулдинга?
— Соңыннан белерсең. Хөрмәтләү җыелышы була. Ишбулдинны хабарга кирәк безгә!
— Белмим. Моннан ике сәгатьләр элек безнең янда булып чыккан иде, шуннан соң күрмәдем.
Пичугов, этә-төртә дигәндәй, Ишәй картны эзләргә кемнедер җибәрде.
«Тапмый кайтма!» — дип кычкырып калды аның артыннан.
Мәктәп балалары, быргылар кычкыртып, барабаннар кагып, тигез сафлар белән ашханәгә килеп киттеләр.
Черек күл мәйданының төрле почмакларыннан ашханә алдына кешеләр җыелды да җыелды, ә бу тантананың төп гаепчесе — Ишәй абзый күренми иде әле.
Хәзер инде Кузьма Николаевич, аптырагач, Аввакумовка бәйләнә:
— Синдә була торган иде бит ул Ишәй, көне-төне синең тирәңдә бутала иде!..
Минем подчиненныем түгел лә ул миннән таптырырга! Әйтәм бит, булды ул иртәнге якларда. «Нефть чыкмадымы әле?» — дип сорады да, борычлап-тозлап җавап биргәч, китеп барды.
— Зря борычлап җавап биргәнсең, Виталий Иванович. Кем белән сөйләшкәнеңне белеп сөйләшергә кирәк иде, чамалап.
Әгәр ашханә алдына үз тракторы белән Фәнүзә килеп туктамаса һәм аның кабинасыннан Ишәй абзый килеп чыкмаган булса да, тантана хәсрәткә әйләнгән булыр иде.
— Әнә ич Ишбулдин!
Аны күрү белән барысы да: «Ишәй абзый» да «Ишәй абзый!» — дип ду килделәр.
— Сине эзләп килгәннәр анда, Ишәй абзый,— дип хәлне аңлатмакчы була Кузьма Николаевич, тик дулкынлануыннан сүзен кайсы башыннан башларга белми тотлыгып кала.
— Мине эзләп килгәннәр? Кемнәр?
Ишәй абзый, кинәт үзенең моннан кырык еллар элек булган гаепләрен исенә төшереп, куркып кала, агарынып китә.
Аны бу оеган хәленнән Курамшинның сүзе чыгара:
— Мәктәп пионерлары, эзтабарлар көтә сине ашханәдә, Ишәй абзый. Сугыш ветераны белән очрашуга синең янга килгәннәр...
Бер яктан Кузьма Николаевич белән Курамшин, икенче яктан идарәнең комсомол секретаре белән хәрби комиссариаттан килгән теге майор, кага-суга, Ишәй абзыйның өс-башларын аз гына булса да тәртипкә китерергә тырышалар.
Аның кыяфәте бер дә инде менә бүген пионерлар алдына китереп бастырырлык, мактанырлык сугыш ветераныныкы төсле түгел. Өстендә терсәкләре тузып, җиң очлары чукланып беткән сырма, башында ямьшәйгән иске бүрек, аягында кайрак калынлыгы итеп төпләнгән киез итек, кулларында кәкрәеп каткан брезент бияләйләр. Сакал-мыеклары да атна буе пәке күрмәгән, ахры:
Тегеләй әйләндерделәр, болай бордылар картны, ах та вах килделәр, ваемсыз йөрүе, үз-үзенә игътибарсыз булуы өчен битәрләделәр, ләкин, ни хәл итмәк кирәк, вакыт уза, балаларны көттереп булмый,

«хәзинәдә булганы белән» дип, култыклап ашханәгә очрашуга алып кереп киттеләр.

Үзләренең геройларын мондый булыр дип һич кенә дә күз алдына китермәгән балалар, алларында таушалган бөкере картны күреп каушабрак калсалар да, соңыннан кинәт батырайдылар.

Бер кыз бала алга чәчрәп чыгып басты да салют бирде,

Сәлам Сезгә, ил батыры,
Сәлам безнең геройга!
Курку белмәс Ишбулдинга,
Сугыш ветёранына!

Калганнары «Дан! Дан! Дан!» — дип бертавыштан кабатлады. Аннары икенче малай чыкты:

Бүген тыныч хезмәттә дә
Себер тайгаларында
«Кара алтын» чыгара ул
Черек күл мәйданында.

— Дан! Дан! Дан!

Сугыш ветераны Ишмөхәммәт Ишбулдин хөрмәтенә ашханә эчендәгеләр бөтенесе гөр килеп кул чапты.

«Кызыл эзтабарлар»ның җитәкчесе дә бар икән әле. Ул — ундүртунбиш яшьләрдәге сипкелле малай. Быел җәен биш иптәше белән Себер дивизиясе эзеннән — Смоленскидан алып элеккеге Көнчыгыш Пруссиягә, Кенгсберг шәһәренә кадәр барулары, күп кенә якташларының язмышларын ачыклап кайтулары турында сөйли. Аның кулында саргаеп, таушалып беткән фронт газеталары, хатлар, фотографияләр һәм башка документлар... Шулар арасында Ишмөхәммәт Ишбулдин турында да бик күп кызыклы фактлар бар икән.

Ашханәгә җыелган эшчеләр аяк очларына басып, муеннарын суза-суза рәсемнәрне карамакчы, андагы сүзләрне укымакчы булып үреләләр, ләкин бу кадәр халык арасында андый нәрсәләр берсенә дә насыйп түгел.

Аңлатма бирү өчен халык алдына Пичугов чыгып басты.

— Иптәшләр,— диде ул бик җитди итеп,— бәлки «Ишбулдин нефтьче» дигән сүз сезгә сәеррәк тә ишетелә торгандыр. Дөрес, ул моңа кадәр аучы булган. Бик төз ата торган сунарчы. Ул кардонда яши иде. Моннан биш ел элек нефтьче разведчиклар белән мин аңардан Черек күлгә юл күрсәтүне үтенеп килдем. Һәм иптәш Ишбулдин безне куе урманнар, сазлыклар аша менә шушы җиргә алып килде. Димәк, аны бу нефть мәйданын ачучыларның берсе дип атарга тулы хокукыбыз бар. Олы яшьтә булуга карамастан, күрәсез, ул бүген дә нефтьчеләр сафында!

Кузьма Николаевич, Ишәй абзыйның колагына иелеп нидер әйтте дә, залда басып торган халыкка карап:

— Бәлки, Ишбулдин мине гаеп итмәс, без күптәннән үз кешеләр,— диде акланган дай.— Ул үз әйберләрен минем квартирада саклый. Менә, ачуланмаса, сезгә күрсәтер өчен аңа бирелгән хөкүмәт бүләкләрен алып килдем...

Пичугов яулыкка төргән кечкенә төенчекне чиште, аннан берәмберәм Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденын, унлап медальне алып өскә күтәреп күрсәтте. Кешеләр ах иттеләр.

— Чынлап та герой!

— Тагып күрсәтсен! — дип кычкырдылар.

Ишәй абзыйның костюмы юк, фуфайкасын күлмәк өстеннән генә ки-

гән иде — Пичугов белән майор, аның орден һәм медальләрен кая тагарга белми аптырап, иске фуфайка түшенә каптырырга мәҗбүр булдылар. Сугыш бүләкләре иске киемнәргә дә бик килешә икән ләбаса!

Ишбулдин янына майор чыгып басты. Таныштырды: ул шәһәрнең хәрби комиссары икән.

— Ишбулдин сөйләр әле, иптәшләр,— диде ул кулын күтәреп халыкны тынычландыргач.— Без, сугыш ветераннарын җыеп, шәһәр клубында махсус бер очрашу уздырачакбыз... — Аннары, пионерлар сафына карап басты.— Кадерле пионерлар, кыю эзтабарлар! Алдыбызда моңарчы һич билгеле булмаган диярлек ветеран басып тора. Күрәбез, ул артык тыйнак, мактанып-горурланып сөйләп йөри торган кешеләрдән түгел икән. Ә бит горурланырлыгы да, мактанырлыгы да бар! Рәхмәт сезгә, Вах урта мәктәбенең кызыл эзтабарлары! Сез ул хезмәт иткән полкның сугышчан юлы буйлап йөреп, безне илебезнең иң оста мәргәне, Бөек Ватан сугышы каһарманы Ишбулдин белән таныштырдыгыз.— Майор залдагыларга карап алды да инде елмаеп: — Хәзер, иптәшләр, үз чиратымда мин дә бер сюрприз ясап алмакчы булам,— диде.— Кесәсенә жонглерларча тиз генә тыгылып, аннан кечкенә кызыл тартма чыгарды. Тартма эченнән, «Бөек Ватан сугышы» орденын алды. Хәрбиләрчә борылып, Ишәй абзыйга мөрәҗәгать итте: — Хөрмәтле иптәш Ишбулдин! Сез шушы зур бүләк — Беренче дәрәҗә «Бөек Ватан сугышы» ордены белән фронтта 1943 елның мартында бүләкләнгән булгансыз. Яраланып ерак тылга, госпитальгә китү сәбәпле, орденыгыз сезне вакытында табалмаган. Ләкин батырлар югалмыйлар да, онытылмыйлар да! Менә егерме биш елдан соң хөкүмәтнең зур бүләге эзләп тапты сезне. Котлыйбыз, иптәш Ишбулдин!

Майор, гәүдәгә кечкенә һәм чандыр гына Ишәй абзыйны, аюдай кочагына алып күтәрде, үпте һәм идәнгә бастырды. Аның күкрәгенә тагын бер орденны беркетеп куйды...

Бер сәгатькә якын дәвам итте бу тантана. Төш узып бара, тамак туйдырасы, эшкә чыгасы бар, дип берәү дә офтанмады, киресенчә, ерак кырда кителмәгән, алдан хәбәр ителмәгән бу очрашудан, үзләре арасында эшләп, көн күреп ятучы шундый батыр карт солдат булудан мондагылар хуш булып, җиңеләеп калганнар иде.

Аш вакытында да сүз гел Ишәй абзый турында гына барды. Алар борылып-борылып Ишәйне эзләделәр. Һәркемнең картны үз янына чакырасы, табынга утыртасы, бергә гәпләшәсе, аңардан фронт турында сорашасы, нәрсәләрнедер ачыклыйсы килгән иде. Тик Ишәй абзыйны тантанадан соң берәү дә күрмәде, таба алмады. Арада юк иде ул.

Эшчеләр ашханәдә сөйләнделәр.

— Ишәй абзый күптән шәһәрдә, килгән начальство белән ресторанда утыра торгандыр инде...

— Хәзер инде ул синең белән минем компаньон түгел, туган!

— Геройны аерым сыйларга дип алып киткәннәр билгеле...

### III

Ишәй карт бу вакытта балкада, үзенең сүнеп-суынып беткән калай миче янында утыра иде.

Пионерларны озаткан чакта, ыгы-зыгы вакытында китеп калды ул. Берәүгә дә әйтмәде, беркем белән дә хушлашмады — тотты да шылды. Тынычлыкта, япа-ялгыз калырга кирәк иде аңа. Башына кинәт ишелеп төшкән шатлыктан актарылып, ташып чыккан күңелен басарга, тын алырга кирәк иде.

Мичен ягып җибәрде карт. Утыннарга ут үрләп яна башлагач, үзенә дә җан кергәндәй булды. Тәмәке төреп тартты. Ләкин башы эшлә-

ми, уйлары буталчык иде. Күз алларын еракта калган туган авылы, балалары, хатыннары, Себер урманнары килеп томалады. Әйе, тормышы да, үзенең уйлары кебек, бик тә буталчык, аңлаешсыз булган икән Ишәйнең.

...Бер карагаңда, узган гомере алай зарланырлык та түгел кебек иде. Авылыннан качып Себергә килү белән аны, язу-фәләнен дә сорап тормыйча, урман кисәргә алдылар, эре нарат бүрәнәләрдән салынган торакка урнаштырдылар, киендерделәр, ашарына бирделәр. Ләкин... Аларына да түзмәде Ишәй, китте. Пычкы тавышын күтәрә алмады. Пычкы зыңлавы колакны ярып керде, еракта калган авылны, тегермән буасын, анда такта яруларын хәтерләтте. Шул тегермән буасы, комсыз Мәүлет белән дуслашу, аның кызы Мәгъмүрәне хатынлыкка алу харап итте бит Ишәйне...

Урман кисүчеләр белән янәшә генә торучы сунарчылар кооперативына күчте Ишмөхәммәт, алар белән кардонда яши башлады.

Күзе үткен иде Ишбулдинның — төз ата иде. Мушкага алынган бер генә җәнлекнең, кош-кортның да качып, очып киткәнен хәтерләми ул. Илгә тире хәзерләүдә бөтен Себердә алдынгылыкны тотты Ишбулдин «Кыек атып туры тидерәдер бу», «Моның мылтыгы сихерледер»,— дип аудан бүре, аю, яки төлке алып кайткач Ишәйнең егерменче калибрлы берданкасын әйләндерә-әйләндерә карыйлар иде сунарчылар.

Матур, тыныч еллар озак бармады — сугыш башланды. Гарасатның шомлы җиле ерак Себер авылларына да барып җитте, куе тайга урманнары аша Ишәй торган аучы кардонына үтеп керде. Халыкны айкады-чайкады, аякка бастырды сугыш. Фронтка кешеләр кирәк иде. Авырлыкларга, суыкларга чыдам, нык, таза егетләр кирәк. Бигрәк тә Ишәй кебек мылтык тота белгән, төз ата алган себерлеләр кирәк. Унсигез яшьтән башлап кырык биш яшькә кадәр булган, сугышка яраклы бөтен ир-ат гаскәри хезмәткә алына.

Ул чакта инде кырыкка җитеп килгән Ишмөхәммәт Ишбулдин Төмән шәһәрендә оештырылган атаклы Себер дивизиясенә эләкте. Чатнама суык ноябрь урталарында аларны, көнбатышка таба агылучы эшелоннарның берсенә утыртып, Мәскәүне сакларга җибәрделәр.

Солдатлар белән бер вагонда утырганда, аларга кушылып: «Вставай, страна огромная, вставай на смертный бой»,— дип җырлап барганда Ишәй үзен кешеләр белән тигез хокуклы, башкалар белән бер дәрәҗәдә бәхетле итеп тойды.

Ул фронтка бары тик бер максат белән генә барды — үзенең кемлеген күрсәтергә, кылган гөнаһларын кешеләр каршында юарга дип!

Атакаларга барырга, штык сугышларында катнашырга, дошман белән йөзгә-йөз очрашырга туры килмәде аңа. Снайперлар батальонына эләгеп, яшерен засадаларда, маскировкаланган ояларда ятты, агач башларында «күке» булып утырды, мушкага эләккән бер фашистны чәкеде дә чәкеде...

Мәскәү янында тар-мар ителгән дошман чигенеп, Смоленск тирәләрендә нык оборонага күчте. Озак яттылар анда мөртәтләр — ике кыш буена диярлек кузгалмадылар. Башка атышлардан тыш, снайперлар белән снайперлар сугышы да каты булды монда. Авызын ачып йөргәннәрне чүпләп кенә тордылар. Кем кемнекен табар, кем кемнекен күбрәк тәгәрәтер — шуңа корылган иде максат. Төз атудан, осталыктан бигрәк, хәйлә кирәк иде монда.

Снайпер Ишбулдин исә, барысыннан да битәр, түземлек кирәк дип санады. Утыз-кырык градуслы кышкы салкыннарда снайперларга бер дә селкенмичә сәгатьләр буе гына түгел, көннәр буе ятарга кирәк. Мәче тычканны сагалаган кебек. Дошман снайперы да юләр түгел — үзенә төбәлгән көпшәне күрмәсә дә яхшы сизә. Ул да, нык яшеренеп, зур түземлек саклап ята. Һәр секунд саен яшәү белән үлем көрәшә

монда. Яшьләр төз дә ата белә, әмма сабырлыклары җитми, яшеренгән урыныннан кузгалалар да шул ук секундта дошман корбаны булалар. Андыйларны сугышка кадәр, аучы вакытыннан бирле сынаганы бар Ишәйнең: җәнлекне табалар да, посып мушкага аласы урында, һай-һайлап куып китәләр. Тот син аның койрыгын!

Красноярск аучысы, өч йөз фашистның башына җиткән снайпер Иван Новоконов белән ярышты ул, ләкин уздыра алмады — Җиңү көне килде.

Кайтырга диләр. Штабка чакырып, Ишмөхәммәтовның адресын сорыйлар, билет юллыйлар. «Кайтырга, кая кайтырга, кем янына, нәрсә дип кайтырга?»

Фронтовикларны өр-яңадан киендереп, юлга азык-төлек биреп, семьяларына бүләкләр, күчтәнәчләр төяп өйләренә озаталар.

— Ишбулдин, син нәрсә телисең? — дип сорыйлар фронтовиктан. Атаклы снайперга ни сораса шуны биреп җибәрергә әзерләр.

Ә аңа бер нәрсә дә кирәкми: бирер, сөендерер кешесе юк.

Уйлап-уйлап торды да:

— Миңа мылтыгымны бирсәгез икән! — дип, командирның исенакылын алды бит.

Бу мылтык белән Ишбулдин сугышның башыннан ахырына кадәр йөрде, Смоленск урманнарыннан Балтика диңгезе ярларына кадәр барып җитте. Әйбәт иде мылтыгы, ифрат ышанычлы иде. Бер фашистны дөмектергән саен, үзенең аучы гадәте буенча, мылтык сабына бер кирт сала барды снайпер, моның өчен ачуландылар да, янадылар да, ләкин үзсүзле Ишәй барыбер теләгәнен эшләде: ике йөз егерме тамга салды мылтык сабына.

— Миңа берни дә кирәкми, кайткач, ауда йөрергә снайпер мылтыгымны гына бирегез,— дип ялынды һаман Ишәй.

— Әй, Ишбулдин, Ишбулдин! Чудак син. Кайчан инде гаскәри коралның кулга бирелгәне бар? — дип көлде командир.

Ишбулдинның, кайтырга азык та алмыйча, юләрләнеп сугыш коралын соравы мәзәк булып штабка барып ишетелгән, хәтта дивизия командиры генерал Покровскийга да җиткән.

— Бирәбез,— дигән генерал бер дә уйлап тормыйча. Һәм: «Сугышларда аеруча батырлык күрсәткәне, 220 фашистны юк иткәне өчен сержант Ишмөхәммәт Ишбулдинны шәхси коралы — снайпер винтовкасы белән бүләкләргә» дигән приказ язарга кушкан.

Шулай итеп, Ишбулдин,— кем белсен, мондый очраклар тагын булгандырмы-юкмы — үзенең аучы кардонына озын һәм авыр, оптик прицелле снайпер мылтыгы алып кайтты. Кушып бирелгән кырык биш патроны бар иде винтовканың — бары тик кырык биш тапкыр гына атарга җитте ул. Аңа тәңгәл патроннарны бүтән бер җирдә дә табарга насыйп булмады, аучыларны көнләштереп, кешеләрнең күз явын алып торган гаскәри винтовка кирәксезгә чыкты, аны стенадагы чөйгә элеп куюдан башка чара калмады.

Ишәй мичтә чия кебек кызарып күмерләнгән кисәүләргә карап утыра, тирән-тирән итеп тәмәке суыра, патронсыз иске мылтык кебек яраксызга калган, ялгыз яшәп читтә узган гомерен кызгана. Яңа гына сизгәндәй булды: ялгызлык бетергән икән аны, агач корты кебек шул кимергән әчтән, тәмам какшаткан, аяктан егар дәрәҗәгә китереп җиткергән...

Бөтен алтмыш елында ике генә тапкыр булды, дип исәпли Ишәй бәхетле чакларын. Берсе аның сугыш елларында, солдатлар белән фронтта вакытта, икенчесе менә монда — нефтьчеләр, төзүчеләр арасында. Икесе дә кешеләр белән бергә булганда, авырлыкларны бергә күтәргәндә, ил язмышын бергә хәл иткәндә!

Тиздән нефть чыгачак, кышын булмаса, язын ходка җибәрәбез дип

сөйләнәләр. Нефть дигәне чыннан да чыгып, кешеләр өйләренә тарала башласа, инде нишләрмен, кая барырмын, дип кайгыра Ишәй. Урманына кабат кайтып, үзенә йорт салып, картаймыш көннәрен япа-ялгыз шунда уздырырмы ул?

Бик борынгы, моңлы җыр килде картның күңеленә, үзе дә сизмәстән, әкрен генә сузып җырлап җибәрде:

Сәхраләрдә йөри җитез җәйран,
Аны күреп кенә кем туяр...

Ә Курамшин белән Пичугов, Ишәй абзыйны эзләп иске агач йортка кергәндә, ул кызу мич каршында елап утыра иде. Бик тә уңайсыз хәлдә калды килеп керүчеләр. Кәрам Ризвановичның түгел, Кузьма Николаевичның да, күпме еллар йөреп, күпме бергә булып Ишәй абзыйның мондый халәтен күргәне юк иде әле. Боек иде карт, йомык, күңелсез иде, әмма аның болай ук йомшап төшкәне булмады.

— Әллә нефть чыктымы? — дип сорады Ишәй, боларны күргәч куркыбрак калгандай.

— Күптән чыккан инде ул Ишәй абзый,— дип тынычландырырга теләде аны Пичугов.— Тик аны зур ташкын итеп агызып җибәрергә генә кирәк...

— Тормыш дигәнең кешеләр белән генә күңелле, алар белән генә ямьле икән,— дип саташкандай сөйләнеп китте Ишәй.— Кешеләр белән булганда син читтә калмыйсың, онытылмыйсың, онытылсаң да сине эзләп табалар, үзләренә ияртәләр, якты дөньяга алып чыгалар икән... Рәхмәт инде сезгә!

Ишәй, тагын нәрсәдер әйтергә теләп авызын кыймылдата, ләкин тавышы чыкмый, иреннәре калтырый, күзләре яшь белән томалана. Битендәге тирән җыерчыклар арасыннан күз яшьләре агып төшә. Ул аларны сөртми, ә учы белән сакал очыннан сыпырып ала да идәнгә селтәп ташлый иде...

Кәрам белән Кузьма, бер-берсенә карашып алдылар да, әкрен генә чыгып киттеләр.

Әйдә, еласын ул, комачауламагыз аңа, еласын! Табигать тарафыннан бирелгән бу изге халәтне оныткан, аның ачысын да, ләззәтен дә күптән татымаган кеше өчен елау — бәхет ул. Әйдә, үткәне, хәзергесе, кайгылары, шатлыклары — барысы өчен дә бүген берьюлы түксен ул күз яшен. Кирәкми, юатмагыз сез андый чакта кешене!

## ЕГЕРМЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Бибиков белән Аввакумов, кичке курслар өчен бирелгән бүлмәнең ишек төбенә туктап, Курамшинның дәрес биргәнен тыңлап тордылар. Алар әле генә җыелыштан чыкканнар иде.

— Дәрес башланган,— диде Бибиков тавышланмаска кушып.

Виталий Иванович колагын ишеккә куеп торды да:

— Кара син аны, тәҗрибәле укытучы мени! — дип куйды.

Икесе дә тәмәке кабыздылар.

— Укытучысын белмим, шулай да яхшы инженер,— дип үзенең соклануын белдерде баш инженер.— Автоматлаштыруны су кебек эчә, каһәр! Эшкә дә бер дә иренми...

— Ничек булса да монда, үзебездә калдырырга иде аны, Пасарби Пшимахович.

— Ничек калдырасың, Виталий Иванович, ул бит командировкадагы кеше.

Аввакумов, сакалын кашып, җиңел генә көлеп куйды:

— Командировкасын онытып җибәрде түгелме соң инде ул?

— Онытмый. Сүз тыңлап кына калды. Яңа елга китәм ди.

Аввакумовның сакал арасыннан ап-ак тешләре күренде. Ул үзенең шуклыгыннан көлә иде.

— Калдырасың килсә Курамшинның кылын табарга кирәк, Пасарби Пшимахович. Әкәмәт кеше инде менә! Үзсүзле дип әйтимме шунда, кире дипме... «Син вакытлы кеше, ташлыйсың да китәсең», дисәң кала, «кал» дисәң китеп баруы мөмкин.

— Яхшылык белән сорарга кирәк үзеннән — калсын иде. Ул китсә, безнең көймә комга терәләчәк.

Бибиков папиросын чүп савытына ташлады:

— Кереп тыңлап утырыйкмы? Турысын әйткәндә, сиңа да кирәк әле уку.

— Ул автоматларга син үзең дә сарык яңа капкага карап торгандай карыйсың бугай, Пасарби Пшимахович...

— Мөмкинме? — дип ишекне ачты Бибиков.

Курамшин, күңеленнән исәнләшеп, башын иде дә дәвам итте. Бибиков белән Аввакумов арттагы урындыкларга барып утырдылар.

Стенадагы сызымнар, схемалар, диаграммалар өстендә күрсәткеч таягын йөртә-йөртә, Кәрам Ризванович нефтьне улчәү установкаларын автомат рәвештә идарә итү системасы турында сөйли. Сөйләгәндә эшчеләре утырган өстәлләргә дә күз салырга онытмый ул — кызыксыналармы, кем дә булса йоклап китмәгәнме, дип борчыла, ахры. Бибиков та, Аввакумов та яхшы аңлыйлар: көн дә ике сәгатькә планлаштырылган укулар җиңел түгел, шулай да егетләр дәресне игътибар белән тыңларга, материалын тотып алырга, үзләштерергә тырышалар иде. Кайберләре дәресне язып та бара.

Ә Курамшин, шәкертләрен үзенчә сынап йөри: арада кем ныграк кызыксына бу яңа система белән, кем өметлерәк? Киләчәктә бригадир итеп кайсы егетне куярга була? Курамшинның үзен киләчәктә алыштырырлык кем бар?

Дәрес бирә һәм дикъкать белән Рафатны күзәтә. Авылдаш егет бит, җан тартмаса кан тарта дигәндәй, ул ничегрәк булыр икән? Тырышлыгы, тыйнаклыгы белән бригадир булырга кулай, ләкин автоматлар мәсьәләсендә белеме саерак әле. Гриша да начар малай түгел, ләкин кушканны гына эшли. Курамшин аны беренче көннәрдән бирле сынап йөри: Григорийның үз теләге белән бернәрсәгә дә башлап тотынганы юк әле. Касыйм эшкә таза егет. Тотынса бөтенесен дә булдыра ала, тик күбрәк көн узсынга гына йөри сыман күренә, күңеле урынында түгел... Солдаттан кайтканнар арасыннан Володя Леванов ошый Курамшинга. Володя армиядә дә беренче разрядлы элемтәче, радист булган,— күкрәгендә горурлык белән шуның значогын әле дә йөртә,— электроника һәм телемеханика өлкәсендә дә исе бар. Әмма бер нәрсәсе күңеленә ятмый Курамшинның: ул егет артык кырыс күренә. Үз иптәшләрен ярәтмырып түгел, куркытып, команда биреп эшләтә сыман... Шунда сагынып, Мәснәвине исенә төшереп алды Кәрам Ризванович. Менә ул шәп кеше иде! Үз эшен бетереп белү өстенә, звено житәкчесе буларак, кайсы ягы беләндер, иптәшләренә дә ярый ала иде. Бервакытта да тавышын күтәрмәс, холыксызланмас, ә тыңлата белер. Үзе дә туктаусыз эшли, кешеләрне дә эшләтә... Курамшин эштә генә түгел, шушында укытканда да еш кына Мәснәвинең сабырлыгын исенә төшерә һәм үзе дә аннан үрнәк алырга тырыша иде.

Курамшинның төпле, тыйнак кына дәрес бирүе Бибиков белән, Авва-

кумовка да ошады — кызыклы вакыйгалар белән мавыгып киткән мәктәп баласыдай тыңладылар.

— Курамшин җәнаплары рөхсәт итсә, үземнең дә йөрергә исәп бар әле,— дип пышылдады Аввакумов баш инженерның колагына.

— Минем дә теләк бар,— дип баш какты Пасарби Пшимахович. Бераздан:— Алайса, Виталий Иванович, болай итик: нефть чыгаруда турыдан-туры катнашы булган барлык инженер-техник работникларны курсларга йөрергә мәҗбүр итик! — диде.— Барыбызга да кирәк ич боларны белү. Профаннар ич без автоматлар мәсьәләсендә!

Дәрес бетеп, җыйнаулашып урамга чыккач, Бибиков белән Аввакумов Курамшинны ике яклап култыклап алдылар.

— Озата барабыз, Кәрам Ризванович.

— Озатырга мин кызлар түгел ич.

— Кара син ничек өйрәнеп беткән! — дип, белепме, белмичәме — Аввакумов көлеп җибәрде.

Курамшинның кәефе юк, ялгыз кайтасы килә иде, тик баш инженер белән участок начальнигы әрсезләнеп диярлек аңа иярделәр. Икесенең дә максаты бер, үзара сөйләшенгән — Кәрамны Себердә бөтенләйгә калырга үгетләү иде.

— Бәлки, кереп ашап чыгарбыз? — дип тәкъдим ясады Аввакумов ресторан турына килеп җиткәч. Терсәге белән әкрен генә Пасарби Пшимаховичка төртеп куйды.

— Син кич ашамагансыңдыр бит, Кәрам Ризванович? Әйдә!

— Ашадым,— дип ялганлады Курамшин.

Аввакумов һаман үзенең төртмәле гадәтен куды:

— Курыкма, син кунак кеше, заказ миннән булыр!

— Бу кунакны күптән куар вакыт инде,— дип кырт җавап бирде Кәрам.— Рәхмәт. Бүген минем телефоннан хатын белән сөйләшәсе бар... Хушыгыз...

Ул баш инженерны да, Аввакумовны да аптырашта калдырып китеп барды.

## II

Кунак йортына кайтып бүлмәсенә бикләнүгә, Курамшин күңелсезләнеп, моңаеп калды. Ялгызлыктан, кайтасы килеп сагынудан да түгел, кәефсезлектән иде.

Теге көнне төнге сәгать унберләрдә хатыны белән телефоннан сөйләшүдән башланды бу халәт. Ни булгандыр Хәтимәгә — уйламаганда-көтмәгәндә төн уртасында шалтыратып уятты да, исәнме юк, саумы юк, төрле мәгънәсез сүзләр, үпкәләр белән тутырды вакытны. Имеш, йогышлы чир белән авырый дип ишеткән Курамшинны, кайта алмый ятулар тикмәгә генә түгел... Бу ни дигән сүз? Алдама, икейөзләнмә, ди бит әле җитмәсә! Монысын нәрсә дип аңларга?

Хәтимә телефоннан сөйләшергә теләмәгәч ул ике бит тутырып хат язган иде, болай кырт та мырт килүләрнең сәбәбен сорашкан иде — менә ун көн булды инде, аңа җавап юк,— «әллә берничә көнгә булса да сорап өйгә кайтып килергәме икән?» Үзенең башкарылган һәм башкарыласы эшләрен санап, тагын уйга калды.

Ноябрь ае тынгысызлык белән үтсә дә, файдага узды дип исәпли иде Курамшин. Чөнки бу айда ул идарә итү системасының яртысыннан күбрәген диярлек кабул итеп алды, аларны җыеп, комплектлау эшләренә кереште. Бу айда армиядән кайткан егетләрне тапты, аларны үзенә алып бөтен бер бригада туплады. Ниһаять, булачак автоматчылар, киләчәктә телемеханика аппаратларына хезмәт күрсәтүчеләр өчен кичке курслар оештырып җибәрде.

Курамшин иртәдән алып кичкә кадәр Черек күлдә, ә эштән кайт-

кач яшьләргә электроника һәм телемеханика серләрен өйрәтергә китә. Авыр һәм мәшәкатьле булса да, үзен хезмәттә, файдалы эштә итеп тою күңеленә җиңеллек бирә иде аның. Шуның белән бергә, туган якларга, семьяга, үзенең участогына кайту турында да онытмый ул. Онытмый, сагына, ләкин эш җибәрми.

Үзенең кайтырга җыенуы турында моннан ике ай элек, аннан өч, дүрт ай элек сөйләнеп йөргән Кәрам Ризванович Себердә инде алтынчы аен яши. Ул киткәндә күчтәнәчләр җибәрергә йөргән Рафат инде бөтенләй кулын селтәде. Курамшин үзенең юлга җыенуы турында сүз әйтсә: «Әкият сөйләмәгез, Кәрам Ризванович!» — дип кенә җибәрә. Аның кайту турындагы хыялларыннан Пичугов та, хәтта Ишәй абзый да көлә: «Себер ул саз кебек — эчкәрәк кергән саен ныграк суыра»,— ди.

Китә алуына Курамшин үзе дә ышанмый башлады инде. Ник дисән, башында һаман бер уй: шушындагы телемеханика аппаратларны урнаштыру, көйләп җибәрү уе, торбалардан нефть агыла башлауны, читтән торып идарә итү системасының эшен, нәтиҗәсен күрәсе килү теләге.

Шунысы яхшы — монда скважиналар барысы да бергә тупланган, бер төбәктә, аларны диспетчер пункты белән тоташтыру ансатрак булачак. Ә бит Әлмәт промыселларында аралары яртышар чакрым булган скважиналардан нефтьне торбалар белән бер урынга җыю, анда группалы установка төзү, аны читтән торып идарә итү системасына тоташтыру эшләре ничә ел вакытны, күпме көчне һәм акчаны йотты.

Биредә Курамшин скважиналарны автоматлаштыру өчен байтак перспективалар күреп яши, шушындый җайлы урыннарның Әлмәттә булмавына сызлана иде. Ә бит аның күңелендә беркемгә әйтми яшереп йөри торган ике яңалыгы да бар әле. Эш белән булышып, нигәдер, ул үзенең уйлап табу белән мавыгуларын да онытып җибәрде. Системаны көйләп, нефть чыгару эшен җайга салса, бәлки, студент еллардан бирле башында йөрткән үзенең термохимик установкасы белән дә шөгыльләнә башлар әле. Нефтьне җир асты тозларыннан, күкерттән, судан һәм ком-ташлардан, ягъни, инженерлар теле белән әйткәндә, механик кушылмалардан аера торган бу установканы монда кую бик тә кулай булыр иде. Татарстанда скважиналарның бер-берсеннән ерак булуы, таралып утыруы аркасында гына яраксызга чыккан иде бит ул установка.

Вакыт шактый соң иде, Кәрам ятырга уйлады һәм үзенең чишенминитми, ут алмыйча, өс киемнәреннән утыруын шунда гына исенә төшерде. Маринадан курку галәмәте. Ут кабызды исә, теге хатын хәбәр биреп тәрәзәгә чык та чык вак таш ыргыта башлый, Курамшинны чакыра.

Фәнүзәләргә барганына түгел, баргач калуына, хәмер эчеп утыруына һәм «салметдин» баштан Марина белән танышуына үкенә хәзер Кәрам. Үкенә, ләкин соң. Дөрестерме, юктырмы, Фәнүзәнең әйтүенә караганда, Марина чын-чыннан Кәрамның «рыцарьлыгына» ышанган, муеныннан чумып гашыйк булган, имеш. Фәнүзә-елан хәзер күргән саен: Ник безгә килмисез, Кәрам Ризванович? Марина кич саен сезне көтеп тилмерә, ник газаплыйсыз — ул бит төннәрен дә сезне уйлап саташа»,— дигән була.

— Я, нәрсәмә алай саташа ул? Беткәнме Марина кебек чибәрләргә ялгыз ир-ат?— дип кычкырып куйды Кәрам төнге тын бүлмәне яңгыратып.

## III

Инде чишенеп яткан, изрәп йокыга китеп бара иде — ишек шакыдылар.

— Теге шакмак бәбәк Марина килдеме микәнни? — дип, куркып

сикереп торды Кәрам, ишеккә килде. Юк, юк, ачмаска! Теләсә нәрсә әйтсен — куып чыгарырга!

Тавышына мөмкин кадәр кырыслык бирергә тырышып сорады:

— Кем бар?

— Бу мин, Кәрам Ризванович,— диде ир-ат теге яктан татарча. Бик тә таныш тавыш, ләкин Кәрам аны кем дип тә әйтә алмый иде.

Ишекне ачуга бер кулына чемодан, икенчесенә капчык күтәргән Мәснәви килеп керде.

— Менә кайда ята икән безнең югалган кешебез!— дип сөйләнә-сөйләнә әйберләрен ишек төбенә бер кырыйга куйды.— Вәт, көт син аны кайтыр дип!— Курамшинга суыктан күшеккән кулларын сузды.— Исәнме, Кәрам Ризванович?

— Күземә күренәсеңме, әллә чыннан да Мәснәвиме син?— Бер кулын биреп, икенчесе белән Мәснәвинең салкын муеныннан кочаклап алды.— Син каян? Нишләп?..

— Соңыннан, Кәрам Ризванович. Яңа гына самолеттан төштем. Аэропортта кунарга түземлек җитмәде — менә сине эзләп килдем, гаеп итмәссең...

— Чишен соң! Мин монда ялгызым гына.

Мәснәви, исе китеп, бүлмә эченә күз йөртеп чыкты.

— Байларча яшисең,— дип кипкән иреннәрен ялап куйды.— Төрек солтаны мени, тоташ келәмгә төренгән! Кара син аны: кәнәфиләр, шифоньерлар, сервантлар... Әйтәм кайтмый ятасың.

— Үз өем алтын бишек, кеше өе тишек, дигәннәрме әле?..

Кәрам Мәснәвинең тизрәк чишенүен, утыруын, сөйли башлавын көтә иде. Аны хәзер туган илнең чыпчыкларыннан, әтәч-тавыкларыннан башлап, үзенең семьясы да, танышлары да, эшләгән җире дә, һәм, ниһаять, Мәснәвинең тора салып бу җирләргә нинди сәбәптән килеп чыгуы да — барысы, барысы да кызыксындыра иде.

— Нәрсә, син дә әллә командировкагамы? Яки болай... күрергә генәме?..— дип Мәснәвине һаман ашыктырды ул түземсезләнеп.

— Әй, сорама инде, Кәрам Ризванович!— дип кәнәфигә килеп утырды Мәснәви.— Бөтенләйгә килдем инде, ташлап...

Курамшин сагая калды:

— Тукта әле, тукта, ничек ягъни мәсәлән бөтенләйгә?

Мәснәви кулын селтәп кәнәфидә авыша төште һәм җиңел генә атына башлады.

— Шулай инде, бөтенләйгә булгач бөтенләйгә. Расчет алдым да килдем...

Кәрам Ризванович урыныннан сикереп торды.

— Ни сөйлисең син, ахмак? Ә участок? Ә автоматлар? Кешеләр?..

Мәснәви арган, талчыккан иде, исән-сау килеп аву рәхәтеннән күзләрен йомып, урынында тирбәлә бирде.

— Автоматлар да, кешеләр дә, участок та беркая качмас... Фәнүзәне күргәнең бармы? Еракмы ул моннан?

Курамшинның нервлары кузгалып,ияк чокырлары тартыша башлады. Ул, идән буенча кызу-кызу йөреп китте дә, тагын Мәснәви каршына килеп басты. Кычкырды:

— Башың бармы синең! Кемгә дип калдырып киттең участокны, нәрсә дип?!

Мәснәви кәнәфидә тирбәнеп утыру ләззәтен татый алмады, торып басарга мәҗбүр булды:

— Нәрсә, Кәрам Ризванович, әллә участогыңны договор белән килешеп алып калдыммы? Ике айга күз-колак булырга куштың — вакытлыча риза булдым, карышмадым, шулай бит? Ике ай үтте, өч ай, биш ай үтте — ә син юк! Үзең беләсең: мин инженер да, участок начальнигы да түгел — гади рабочий гына.

— Башыңны юләргә салма! Җаваплылык тойгысы юк синдә!

Бик каты кычкырышып киткәннәр икән — тавышланмаска кушып, төн икәнен, кешеләрнең ял итүен искәртеп, дежурный хатын киһәтү ясап чыкты. Шуннан соң икесе дә пышылдауга күчтеләр.

— Я, кемгә дип калдырдың инде участокны, әйт! Кем алып бара хәзер эшне?! — дип чажгорды Курамшин, бөтен усаллыгы белән Мәснәвигә ябырылып.

— Башлы инженерлар бар ул, Кәрам Ризванович, бер син генә түгел... Таптылар... — Син, Кәрам Ризванович, ачуланып утырганчы, хет чәй куяр идең,— дип әкрен генә сүз башлады Мәснәви.— Мин бит ерак юлдан...

Курамшин да исенә килде:

— Кара инде, чыннан да онытып җибәргәнмен! Бар минем самавырым! Хәзер кайнатабыз аны...

Кәрам электрлы самавар, чәшке-чынаяклар белән булышып йөрде, ә Мәснәви чишенеп, юынып керде, чемоданыннан алып чиста күлмәген киеп куйды.

— Соң, Фәнүзәне күргәнең бармы, ул ниләр бетереп ята? — дип түземсезләнеп тагын сорады Мәснәви.

— Фәнүзәнең дисеңме? Аның эшләре уңайлана хәзер... Анда, Әлмәттә, минекеләр ни бетереп яталар, киткәндә күрдеңме?

— Күрдем, исән-саулар,— дип кенә җавап бирде Мәснәви. Калганын, «Курамшин янына китәм, нинди йомышларың, әйтер сүзләрең бар»,— дип кергәч, Хәтимәнең ничек борчулы булуы, Себергә, ире янына китәргә җыенулары, квартира алмаштырырга исәп тотулары турында әлегә әйтмәскә булды. Боларның барысы да теге фотолардан икәнен Мәснәви төшенә иде.

— Хәтимә сәлам дә әйтмәдеме? — дип төпченде Курамшин, табынга чәй әзерли-әзерли.

— Ул сиңа үзе шалтыратыр әле...

— Шалтыратты инде — нигәдер миңа ачуланган. Ник ачуланганын сиңа әйтмәдеме? Озак кайтмый яткангадыр инде, билгеле. Муеннан эшкә чумдым бит...

Мәснәви туры кеше, ялганлаган кешене җене сөйми иде — түзмәде:

— Эх, Кәрам Ризванович,— дип суызды Курамшинның күзенә карап.— Ник инде әйләндереп-боргалап маташасың!

— Тукта әле, ни дигән сүзең бу?

— Оятсыз син, Курамшин! Алма кебек хатының, берсеннән-берсе чибәр өч малаең бар — ник дип рәнҗетергә аларны? Ни гаепләре бар?

Сүзнең нәрсә турында барганын аңлап, Кәрам колакларына, муенына кадәр кызарды, чәйле стаканын куеп, башын иде. «Җиткергәннәр. Менә ни өчен Хәтимә телефоннан кырт та мырт сөйләшкән... Кырын эш кырык елдан соң да беленә икән шул...»

«Ничек, кайчан, кем җиткергән?» — дигән сораулар бер-бер артлы янышнан очып узды Кәрамнең — ул берсен дә тота алмады.

Мәснәви үзе дә кыерсытылган, рәнҗегән хәлдә утыра иде:

— Безнең өчен син бит заманында чиста-саф кеше идең, Кәрам Ризванович. Бөтен бригада, участок халкы синең тормыштан үрнәк алып яшәде, сиңа охшарга тырышты. Үземнең начар кеше булуыма синең каршыда ояла идем. Ачулансаң да сүз әйтмәдем...

Курамшин, үзен кулга алырга тырышып карады, акланмакчы булды:

— Гайбәт алар бар да, Мәснәви, юк сүзләр... Әйдә чәй эчик бер тынычлап!..

Мәснәви, костюм кесәсеннән бумажнигын чыгарып, аннан даны таралган теге өч фотоны алды һәм Курамшин алдына ыргытты.

— Моны нәрсә диярсең?

Курамшин бу хәлдә үзен беренче мәртәбә күрүе иде. Ул исерек кыя-

фәтенә дә, кыланышларына, Марина белән кочаклашып утыруына да... артык исе китмәде, әмма шулай оста итеп, җаен китереп, сизмәгәндә төшереп алучы, ул фотоларны туган ягына, семьясына, Хәтимә кулына җиткерүче бәндәгә бик тә гаҗәпләнде. Берәү булса, махсус штатта тотып, акча түләп торсаң да болай шома, өлгер эшли алмас иде, билләһи!

— Я, әйт әле, Кәрам Ризванович, кем һөнәре дип уйлыйсың моны?

— Һич тә башыма китерә алмыйм.

— Шәһәрдә Җаен Җәмилне дә күргәнең юкмы?

— Бар, тик исәнләшмичә үтәбез.— Кәрам өтәләнеп урыныннан торды.— Әллә шулмы?

— Кем булсын башка? Әлмәткә кайтып, сине белгәннәргә юри таратып йөри, сволочь! Расчет алганда нефть идарәсенә кергән идем,— синең карточкаңны бүлмә саен кулдан-кулга йөртеп көләләр. Ә болары участок адресы белән килгән иде.

— Әйе...— дип сузды Курамшин күзләрен каядыр идәнгә текәгән килеш. Шул хәлендә сын кебек катып торды. Аннары йокыдан уянып киткәндәй булды:— Мин үзем гаепле,— диде.— Факт, дустым! Факт булмаса — фото да булмас иде...

Кәрам Ризвановичның хәлен, кем-кем, Мәснәви бик аңлый иде.

— Кешегә ябышкан яман тапны, Кәрам Ризванович, мең яхшылык күрсәтеп тә юып ташлавы кыен. Эшеңдә, тормышыңда, судан ак, сөттән пакь булып еллар буе йөрсәң дә әле ул озак барачак. Булмады, дөрес түгел яки очраклы хәл генә, дип кешеләр алдында лутчы акланып та маташма — барыбер ышанмаячаклар, көләчәкләр генә. Минем мисалымда син моны күрдең. Сүз күпертергә сәбәп кенә ачылачак. Иң яхшысы — булды андый хәл, ялгышканмын дияргә, гаебеңне танырга кирәк.

— Әйе, әйе...

Беркавым утыргач, Мәснәви:

— Ярый, Кәрам Ризванович, онытыйк әле бу турыда,— дип сүзне икенчегә борды.— Фәнүзә ни хәлдә соң әле, Фәнүзә? Нигә гел үз кайгыңны гына кайгыртасың?

— Фәнүзә дисеңме? Фәнүзә әйбәт... Тукта әле, син каян ишеттең Фәнүзәнең монда икәнен?

— Шул Җаен Җәмил инде! Договор белән кешеләр җыярга кайткан иде ул Әлмәткә. Вербовщик булып, ул әйтмәсә дә мин китәдер идем инде. Күңелем сизгән иде Фәнүзәнең монда икәнен...

— Малаең барын да беләсеңме?

— Малаем? — дип күзләре шар булды Мәснәвинең.— Нинди малай?

— Үз малаең, синең малай! Ишетеп килгәнсеңдер бит инде.

— Фәнүзәнең улы бармы? Ышанмыйм!

— Һе, ышанмыйм, имеш! Суйган да каплаган нәкъ син инде! Текә маңгайларына, очлы авызларына, кәкре аякларына кадәр, Мәснәви, билләһи! Чабып йөри менә шулай!..

Моннан соң инде Мәснәви бүлмәдә калырга теләмәде — очынды, талпынды, китәргә җыенды.

— Фу, камыт аяк, йокларга да бирмисең,— дип ачуланды аны Курамшин.— Каян килеп чыктың әле син төн пәрие урынына. Ят, йокла, иртүк илтеп кавыштырырмын!

Яткач та әле тиз генә йоклап китә алмадылар — сөйләшәсе сүзләре, сорашасы нәрсәләре күп, бихисап булды. Инде йоклап киттем дигәндә, Курамшин тагын торып утырды.

— Ярый, килеп яхшы иттең әле,— диде канәгатьлек белән.— Син булгач мин хәзер курыкмыйм, үз урыныма калдырыр кешем бар.

— Мин эшче,— дип кырт кисте Мәснәви — инженер булу өчен килмәдем. Булдыра да алмыйм. Әгәр телисең икән — ал монтаж эшенә.

— Ул турыда идарәдә сөйләшербез. Миңа, Мәснәви, өйгә кайтып килергә кирәк. Үзең аңлыйсың минем хәлне. Бер атнага булса да калып торырсың инде...

— Әһә! — дип сикереп торды Мәснәви.— Тагын төп башына утыртмакчы буласыңмы? Тегендә дә калып тордым инде мин синең урынга, җитәр!..

— Чынлап әйтәм: киләм! Ярый, бу турыда иртән.

## IV

Иртәнге сәгать алты да тулмас борын алар идарәнең машиналар паркы янында капка төбендә кайнашалар, Фәнүзәнең эшкә килгәнен көтәләр иде инде.

— Әнә, Себер чибәре үзе,— диде Курамшин, караңгы урам почмагыннан килеп чыккан Фәнүзәне танып.— Ярый мин сезне күрмәдем, сез мине,— диде дә, идарәгә таба китте.

Шулай да күрде Курамшин аларның ничек кавышканнарын. Фәнүзә Мәснәвине куа-нитә калса, килеп ике араны җайларга, алай да булмаса, Мәснәвине үз белән идарәгә алып китәргә, эшкә, торакка урнаштырырга дип, арырак, караңгы җирдә туктап калган иде ул. Килеп очраштылар да бер-берсенә сарылдылар. «Фәнүзәм, бәгърем!» дә «Мәснәви, җаным!»

Курамшин, кулын селтәп, тиз-тиз китеп барды.

— Муж и жена — одна сатана!— диде ул чеп-чи русча итеп.

Төне тынгысыз булган кебек, көне дә борчулар белән башланды

Идарәнең ишеген ачып керү белән Пичуговка килеп орынды Курамшин.

— Минем бүлмәгә бер генә минутка кереп чыгыйк әле,— диде бу. Үзенең кәефе күтәренке, авызы сакал-мыек арасыннан елмаеп тора.

Керделәр. Утырыштылар.

— Анда, Әлмәт шәһәрендә синең туганнарың бармы? — дип сорый бу.

— Юк,— ди Кәрам Ризванович.

— Бер фамилиядәге кешеләрне дә белмисеңме? — ди.

— Нигә алар? Бәлки бардыр, ишеткәнем юк,— ди Кәрам,— Гомумән, Әлмәттә Курамшин фамилияле кеше мин үзем генә дип йөрим, сирәк фамилия.

Шуннан сөйләп китте Пичугов: ул Әлмәт белән квартирасын алыштыру турында газетага белдерү биргән булган. Кичә берәү ризалык биреп Әлмәттән хат язган. Аның фамилиясе дә Курамшин икән — хатын-кыз.

Пичугов, сөенечен яшерә алмыйча, хатны Курамшинга укырга бирде.

Бер дә аны-моны уйламыйча гына хатны конвертыннан тартып чыгарды Кәрам, укый башлады.

«Хөрмәтле Кузьма Николаевич! Квартира алышуга мин риза,— дип язылган иде анда.— Минем дә квартира өч бүлмәле, кухнялы, ванналы, газлы һәм үзәктән җылытулы. Барлыгы 45 квадрат метр. Килегез дә тора башлагыз. Минем адрес...»

Шул урынга җиткәч Курамшин агарынып китте:

— Минем хатын ич бу!— дип кычкырып җибәрде.

Ул Хәтимәдән усал хатлар да, ямьсез сүзләр дә, үпкәләү-елаулар да, хәтта аерылышу кебек яман эшләрне дә көтә, әмма квартира алыштырып Себергә килү кадәресен башына да китерми иде.

— Шуңа барып җитте мени инде сезнең эшләр? — дип борчылып утырды Пичугов һәм битәрләргә керешә: — Әй, Кәрам, Кәрам! Мин

сиңа алдан кисәтеп әйттем: зинһар минем юлны кабатлама, дидем... Елан белән бер бит ул хатын-кызлар.

— Инде ни эшләргә?

— Ул, әлбәттә, квартираны синең рөхсәттән башка алыша алмый.

Курамшин урыныннан сикереп торды, күн перчаткаларын бер-берсенә сугып шапылдатып куйды.

— Өйгә кайтып килергә кирәк миңа, аңлашырга хатын белән.

— Үпкәләмәсәң әйтим: син, Кәрам, барыбер моннан китә алмыйсың инде — әйдә булмаса, алышабыз квартираларны. Тыңла минем хакка. Мин артык тора алмыйм бу урында. Гариза бирдем инде...

— Бер нәрсә дә әйтә алмыйм, өйгә кайтып килергә кирәк миңа!— дип кабатлады Курамшин һәм ашыгып чыгып китте.

Кичен эштән кайткач та Курамшинны хатыны турында уйлар борчыды.

Ун елдан артык яшәделәр, өч балалы булдылар, ләкин тормышыннан канәгать булмавын Кәрам бик яхшы тоя иде Хәтимәнең. Болай тату да тордылар кебек, андый-мондый каршылыклар, тавышлар да чыкмады төсле, ләкин ике арада күренер-күренмәс кенә, ниндидер бушлык ята иде. Бәлки ул бушлык түгелдер — тыгызлыктыр, ике араны аерып торган тирән катламдыр. Бу катлам яшь аермасы да, фикер каршылыклары да түгел, бары тик ун ел элек Кәрам-егетнең Хәтимәкызга биргән вәгъдәләре булырга кирәк.

«Сине укытам, дөнья күрсәтәм»,— дип әйткән иде бит Кәрам Хәтимәгә. Ул вакытта кош булып күкләргә менәргә, йолдыз булып балкырга, кояш булып янарга торган унҗиде яшьлек кызга нинди яхшылык эшләде, нинди генә изгелекләр кыла алды соң Кәрам? Юк. Булмады.

Хәтимәнең, соң булса да, иренә үпкәләргә, ачуланырга, дәгъвалар ясарга хакы бар иде.

Ут кабызып сәгатенә карады Курамшин. Кичке сигезенче киткән — укытырга барыр вакыты да җитә иде инде.

Бүгеннән, автоматчылар белән бергә, дәресләргә идарәнең барлык инженер-техник работниклары да йөри башлаячак. Баш инженер Бибиков үзе дә.

Бер айлык программа буенча, Курамшин бүген «Нефтяник» тибындагы автоматика һәм телемеханика системасының төзелеше һәм эше турында сөйләргә тиеш. Бик катлаулы һәм җаваплы тема.

Үзе теләп оештырган курслар булгач, Курамшин күңел биреп йөри, дәресләрне бик теләп, яратып уздыра иде — бүген исә, ул анда барырга да авырсына. Тормышның ямен, яшәү дәртен алды әлеге рәсемнәр...

Бер караганда игътибар бирәсе нәрсә дә түгел. Илдә иң зур булган Черек күл нефть мәйданы, андагы гигант колачлы эшләр янында Курамшинның бу хәсрәте бик кечкенә, кысыр хәсрәт кенә бит. Ләкин алай түгел икән. Кешенең шәхси тормышына чак кына күңелсезлек китерү дә кулына суга, барлык кәефен җимереп ташлый, шуның белән зур эшләренә зыян ясый. Җәмил ишеләрдән сак булырга кирәк бу дөньяда, сак булырга! Үзләренең мәкерле эшләре хакына алар вакытларын да, көчләрен дә, барлы-юклы сәләтләрен дә кызганмаслар — астан чокып карерләр, кырыйдан чалып егарлар, арттан килеп сугарлар. Алдыңны-артыңны карап йөрергә кирәк Җәмил ишеләр янында.

— Әх, ниемә дип җебеп утырам соң әле,— дип сикереп торды Кәрам.— Каш җимерелеп күз чыкмаган бит! Хәтимә Себергә килергә тели икән — бик әйбәт.

Шунда ук телефон станциясен алып Әлмәткә заказ бирде. Нәкъ төнге уникедә Кәрам Хәтимәсе белән сөйләшәчәк, «квартира алышасың икән — бик хуп, мин риза, Хәтимә хәзрәтләре, рәхим итеп кил, мин сине унөченче йортның капка төбендә түбәтәемне салып көтеп торачакмын»,— дияр.

Кузьма Пичуговның телефон номерын җыйды Курамшин.

— Кузя, бу синме?

— Мин булмыйча кем?

— Белеп булмый: син ялгыз яши торган егетләрдән түгел...

Кәрам, үз кәефен дә, дустының кәефен дә күтәрмәкче булып, көләргә тырышып карады, ләкин бер нәрсә дә чыкмады:

— Кузя, мин уйладым-уйладым да риза булдым.

— Син нәрсә турында? — диде Пичугов Курамшинның сүзенә төшенмичә.

Кәрам аның соңгы айларда, бераз сәерләнеп киткәнен сизә иде — Кузьманың авызына «чәйнәп каптырырга» мәҗбүр булды:

— Мин квартираны алыштырырга риза, яз минем хатынга: «Курамшинның каршы түгел, Әлмәткә киләм» диген.

— Чынлап әйтәсеңме?

— Чукынып күрсәтер идем, булмый! Аннан, телефоннан күренми дә.

Икесе дә тынып, бары мышнашып кына сүзсез тордылар.

— Син идарәгә, мин укыткан җиргә кил әле, шунда сөйләшербез,— диде Кәрам һәм трубканы куеп чыгып китте.

## ЕГЕРМЕ БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Менә ничәнче тапкыр инде, Фәнүзә, кар сөреп, юл чистартып барган бульдозерын туктата да, машинаның «борынына» менеп, нефтьчеләр мәш килеп эшләп йөри торган төбәкне күзәтә. «Мәснәви күренмиме шул тирәдә? Автобус белән кайтырга чыкмаганмы?»

Һич югында, Фәнүзә янына килеп кәтәргә, эше тыгыз булса да кайчанрак кайтасын әйтергә тиеш иде бит ул.

— Әллә тагын бүген дә куна калып эшләргә исәп тоталармы?

Әйе, бу Черек күлдә соңгы вакытларда көн юк, төн юк, якшәмбе юк. Ичмаса бүген, яңа квартирага күченәсе көнне җибәрергә кирәк иде Мәснәвине, өй туе уздырасы көнне.

Аннан шунысын да уйлап алды Фәнүзә: «Тизрәк кереп утырасы иде бит, тора башлыйсы иде. Квартира дигән җәннәт үзенә тизрәк оялаганны ярата. Юкса, бик тотнаксыз нәрсә ул квартира дигәннәре: кулдагы чыпчык кебек — учыңны йомарлабрак тотмасаң, оча да китә...

Күз күне нәрсә булды: «Төзүчеләр кулыннан яңа йортны кабул итү белән бер бүлмә синеке»,— диделәр Фәнүзәгә. «Борчылма, эшеңә кит, синең чиратка берәү дә керә алмас»,— дип ышандырдылар. Чыннан да, квартира алуга чиратның беренчесе Фәнүзәдә иде. Ул, тынычланып, бульдозерын кабызды да, Черек күлгә китеп барды. Кич эштән кайтып ордер алырга дип керсә — вәгъдә иткән бүлмәдән җилләр искән. Идарәдә: «Гафу ит инде, иптәш Фәнүзә, квартираңны бер яңа килгән инженерга бирергә туры килде. Ансыз эшләү мөмкин түгел, ул кешедән башка нефть чыкмый, икенче тапкырында ачкычны сиңа алдан ук биреп куярбыз»,— дип юаттылар.

Бүген-иртәгә тапшырыласы йортлар бар иде — тешен кысып, иренен чәйнәп булса да елап җибәрүдән тыелып калды Фәнүзә.

Йортлар тапшырыласы көн килеп җиткәч, чыннан да Фәнүзәне Пичугов үзе чакыртты. «Әнә теге дүртенче подъезддагы 46 нчы квартира синеке. Тик, иртәгә ордерга килергә онытма күрмә!»— дигән була начальник урынбасары. Ордерга әле печать суктырасы, кул куйдырасы бар икән.

Улын күтәреп, ул йортны карап та кайтты Фәнүзә. Тыныч урында,

урман буенда дүрт катлы шәп кенә өй. Балконнары да бар. Дүртенче подъездга керде, өченче катка күтәрелде. Өч ишекнең уртадагысы 46 нчы номерлы иде. Хәтта, өскәрәк акбур белән авыш итеп «Ризатдинова» дип язып та куйганнар. Моннан да ышанычлырак нәрсә бар инде тагын? Фәнүзә шатлыгыннан каты итеп кечкенә Фәнилен кысып алды, үбә-үбә сабыйның битләрен күз яшьләренә чылатып бетерде.

— Үзебезнең өй бит, балам, ишетәсеңме, безнең йорт, Фәнилкәем!

Алар улы белән икәүләшеп еладылар. Малае каты кысканга, ә Фәнүзә — шатлыгыннан.

Иртәгесен эш, анда сине кар каплаган юл, батып яткан машиналар көтә, кырга китмичә булмый. Инде квартирлар бүленеп беткән, ордерлары язылган, кул куйдырасы гына калган, юлны тиз генә чистартып алырга да төш вакытларына шәһәргә кайтып китәргә генә иде.

Холыксыз булса да, Аввакумов та начар кеше түгел — иртәнге сәгать уннар чамасында ук бульдозерны куып килеп житкән:— Ни дип һаман жир тырнап йөрисең? Әллә сиңа ул ордерны тәлинкәгә салып китерерләр дип көтәсеңме?! — дип акыра.

Кайтуын кайтты, тик бу йортта да торырга насыйп булмады Фәнүзәгә. Ордер алырга дип Пичугов янына барса, бүлмәдә яшь бала төреп күтәргән бер хатын утыра. Ире күптән түгел авария вакытында үлгән, үзе, Фәнүзә кебек үк, бала белән торакта калган икән.

Ихлас күңелдән кызганды аны Фәнүзә. Ни әйтсәң дә теге хатынның хәсрәте зуррак, авыррак, икеләтә...

Кузьма Николаевич та аптыраган, бер теге хатынга, бер Фәнүзәгә карап тик утыра. «Әллә тагын беразга гына түзәсеңме?» — димәкче Фәнүзәгә, әмма теле бармый, вөжданы житми. Аны аңлады Фәнүзә.

— Тагын кайчанга кадәр?! — дип куллары белән йөзен каплады да үкереп елап бүлмәдән чыгып йөгерде.

Шуннан соң ул инде квартира алырмын дип көтмәде дә, ул турыда уйларга да тырышмады — улы белән һаман кызлар бүлмәсендә яшәде.

Менә кичә инде Пичугов ордер белән ачкычны Фәнүзәгә үзе китереп бирде. Шул көнне үк кичен Мәснәви белән култыклашып, чын ир белән чын хатын, йорт хуҗалары булып, яңа квартираны карарга булдылар. Үз ачкычлары белән үз ишекләрен ачтылар, бисмилла әйтеп бусаганы атлап эчкә керделәр. Шәп! Аяк киемнәрен ишек төбендә үк салып, әле кибеп тә бетмәгән сары буяу өстендә яланаяк табаннарын шарт-шорт ябыштыра-ябыштыра бүлмәне карап чыктылар. Яхшы! Куллары белән стеналарны, тәрәзә яңакларын сыпырдылар, су, газ краннарын капшадылар. Әйбәт! Жылы су жибәреп, юыну урыннарын сынадылар. Менә диген! Моннан да яхшы квартираның булуы мөмкин түгел һәм булмас та! Ә бит боларга диген теге йортны бик-бик яманладылар. Аның түшәме тәбәнәк, коридоры тар икән. Житмәсә, бүгенге көнгә кадәр жылы суы да, газы да юк ди.

Бу йорт яхшыртылган проект белән заманча итеп салынган: түшәме биек, бүлмәсе иркен, балкон урынына — лоджи. Гомумән, түземлелегенә күрә уңды Фәнүзә.

— Әх, бу кеше дигәнеңдә нәфес! — диде дә, Фәнүзә яңадан бульдозерына утырды. Мәснәвине көтеп, шушы тирәдә генә юлны тагын бераз чистартмакчы иде ул. Үзе юл кырыенда стена булып өелгән карларны эттерә, үзе кешегә ниндидер шәйтан тарафыннан бирелгән нәфесе, комсызлыгы турында баш вата.

Әле кичә генә баш очында түбә, улы, ире белән өчәүдән-өчәү генә калып яшәрлек бер куыш булса житә иде, бүген квартира эләккәч, аның түшәме дә биек, бүлмәсе дә иркен кирәк. Юк, ул гына да житми — кайнар суы, газы, ваннасы, жылы туалеты да булсын! Алай гына да түгел, стеналары шома, анда ябыштырган обойларның төсе дә күз-

нең явын алып торсын! Бүлмәләргә ялтырап торган мебельләр дә кирәк житмәсә!..

Алар, Мәснәви белән, ике өстәл, алты урындык, кием шкафы һәм тәбак-савытлар сатып алдылар. Ял көне аларны ташу, квартирага кертү, урнаштыру белән узды. Әле тагын күп кенә нәрсәләр, төрле вак-төякләр аласы калган иде аларның.

Фәнүзә кешенең нәфесе турында уйлый да, бульдозерын артка чигереп, ачу белән тау-тау карларны актарып ташлый, гүя моңа кеше үзе түгел, ә менә өем-өем кар көртләре гаепле.

Фәнүзәнең инде кулында ачкычы, кесәсендә ордеры бар, шулай да яңа квартира алуына ышана алмый интегә. Эшли-эшли дә, бульдозерын туктатып, кесәсенә тыгыла, бер ачкычны, бер ордерны алып карый. Мәснәви белән кайтуга квартираны кем дә булса басып алыр, боларны кертмәс, куар төсле. Юк, керүче-куучы булмас, шәһәр урамында Пичугов каршы чыгар да: «Фәнүзә, гафу ит инде, ачкыч та, ордер да сиңа ялгыш бирелгән, квартира сиңа түгел, фәләнгә тиеш булган икән. Без сиңа икенче юлы бирергә карар иттек»,— дияр. Әгәр шундый хәл була калса, Фәнүзә моны күтәрә алмас, һуштан язып егылыр, ә йөрәге шартлап ярылыр...

Черек күлдә тагын кар ява башлады. Фәнүзә, бульдозерын шәһәргә таба борып, карны кыра-кыра юлны әрчи. Быел кар бигрәк тә күп, һич көрәп, актарып бетерер хәл юк. Шәһәрдән алып менә шушы төбәккә кадәр булган кырык биш чакрым араның яртысы аның карамагында. Төнме ул, көнме, иртәме, кичме — син машиналарның көпчәкләре тоткарсыз тәгәрәрлек итеп чистартып куй. Җәй көне булса, чокыр-чакырларны тигезлә, баткан машиналарны чыгарырга булыш. Шуңа күрә Фәнүзәнең эше муеннан. Бигрәк тә кар, яңгыр яуган көннәрне авыр. Ә андый көннәр монда — елның тугыз ае диярлек.

Бульдозер кар эчендә бер алга ыргыла, бер артка чигә-чигә кешене талкый гына. Рычагларны тарта-этә, педальләргә баса-баса кул-аякларның хәле калмый.

Нефтьчеләр дә кызганалар Фәнүзәне. «Тапкансың икән эш, кызый, диләр,— сиңа шушы зифа гәүдәң, бу нәфис кулларың белән, җылы, якты фабрикаларда шоколад төреп кенә утырасы иде», «Трактор йөртү хатын-кыз һөнәре түгел, әзмәвер ирләр кәсебе, ташла бу тимер тавын, еракка кач аңардан!» — дип ачуланган булалар. Мәснәви дә көннеңкөнендә: «Фәнүзә, калдыр бу эшеңне, зинһар, Фәнилне генә карап ят»,— дип теңкәгә тия, риза булмагач, башка бер җиңелрәк эшкә күчәргә куша. Ә Курамшин, күргән саен: «Тиздән Черек күл төбәгендә диспетчер штаты булачак, шунда күчәргә кирәк сиңа, Фәнүзә. Син бит инде элек тә телефонда шул ук диспетчер идең»,— ди. Менә аны үзен яраткан эшеннән — автоматларыннан аерып башка урынга куйсалар ничек җырлар иде икән?

Ә кар һаман ишеп ява да ява.

Фәнүзә үзе кар көри, үзе тәрәзәдән күзен алмыйча Мәснәвинең килүен көтә. Машинасы белән кар сөрдерә-сөрдерә генә бергә кайтырлар иде шәһәргә. Ә анда күченәсе нәрсә дә юк. Күченү дигәне авыз тутырып әйтерлек тә түгел: торактан алып кайтасы ике чемодан да, Фәнүзәнең кашык-савытлары. Кайтырга ашкынуның хикмәте шунда: ичмаса бер, өчәүдән-өчәү генә калып, үз өендә бер төн куласы иде. Караваты кирәкми, түшәк ястыгы кирәкми, баланы йоклатасы да, фатирым дип, үз идәнендә аунап, Мәснәви белән ялгыздан-ялгыз кочаклашып бер йоклыйсы иде.

Бу минутларда Фәнүзәгә бәхет әнә шул кечкенә, унсигез квадрат метрлы бер бүлмә булып тоелды. Баксаң, бәхет дигәнеңә күп тә кирәкми, ул унсигез квадрат метрлы бүлмәгә дә сыя икән ләбаса! Шушы унсигез квадрат метр үз эченә өстәл-урындыклары, караватястыклары,

савыт-сабалары һәм башка вак-төякләре белән бергә ничаклы зур мәхәббәтне, кадерле баланы, семья җылысын, иминлекне кертеп урнаштыра ала икән! Шушы унсигез квадрат метр эчендә, уйлап карасаң, кешенең күпме шатлыклары, моң-зарлары, үзеңә генә кадерле бала тавышы, бер кемгә хаҗәте — кагылышы булмаган гаилә серләре...

Шәһәргә тизрәк, көндезен үк кайтасы килүнең тагын бер сере бар, ул да булса өй котларга чакыру.

Күченгән көннәрдә мондый мәшәкатьне кузгатмый торырга исәпләгәннәр иде, тик Мәснәвинең дә, Фәнүзәнең дә дуслары тынгы бирмәде. Чакырсагыз да киләбез, чакырмасагыз да, дип яу булып ябырылдылар өскә.

Әйдә, каян килеп кая китмәгән, котларга булгач котларга, өй туен ясарга! Яшерен-батырын кавышып, өйләнешү туен да ясый алмадылар — хет икесе өчен бер туй булыр!

Шәһәр ягыннан машина күренүгә, Фәнүзә, бульдозеры белән карны ерып, юл кырыена керде.

— Курамшин килә ахры, аның машинасы. Нигәдер соңлаган бу бүген,— дип уйлап та бетермәде, әлеге өй котлау исенә төште. Әйе, аны чакырмый булмый, машинасын туктатып әйтергә кирәк үзенә...

Фәнүзәне квартиралы итү, баланы яселгә урнаштыру өчен күпме янып-көеп йөрде, идарә башлыклары белән ачуланышып-ызгышып бетә язды бит Кәрам Ризванович. Иң мөһиме — кешенең хәлен аңлый башлады, яхшырды, киң күңелле кешегә әйләнде Курамшин.

Машинаны туктау өчен юл кырыена килеп басты Фәнүзә, алгы тәрәзәдән Курамшинны танып, кул күтәрде. Кәрам Ризванович моны күрде, ләкин килгән тизлеген дә киметмичә, кызу гына Фәнүзә яныннан үтеп китте.

— Кәрам Ризванович! Курамшин! — дип кычкырып, Фәнүзә бераз машина артыннан да йөгереп караган иде — булмады, туктамады.

— Әй, шушы Курамшинны! — дип хәтере калып кул селтәде дә, кырт борылып бульдозеры янына китте Фәнүзә.— Юк, икән, эре, тупас кеше һаман тупас булып кала икән! Кабер генә төзәтә мондый кешеләрне!

Шулай да, ни булган соң әле бу Курамшинга? Себердә күрешкәннән бирле ул үзен эре тотмый башлаган иде бит. Көн саен диярлек я шәһәрдә, я монда очрашалар, туктап ярыйсы гына җылы сәламләшәләр иде. «Нихәл, авылдаш, исән-саулыкмы, бәләкәй Мәснәви үсәме? Эшләр ничек, тракторың тәгәрмәче әйләнәме?» — дигән булып торыр иде. Бүген, Фәнүзә белән Мәснәвинең яңа квартира алганын белеп тә, аларны матур итеп котлыйсы, сөенечләрен уртаклашасы урында, мәсиңа, тот та бөтен тизлектә, артыңа-алдыңа карамыйча узып кит имеш?!

— Я бу Курамшинның кәефен кырганнар, я бозылып китеп яңадан «Кәрамлана» башлаган,— дип нәтиҗә ясады ахырдан Фәнүзә.

## II

Эреләнүен эреләнмәгән иде Кәрам Ризванович, ә менә кәефен, дөрестән дә, бик каты кырганнар иде.

Күрә торып туктамады ул Фәнүзә янына, белә торып узып китте. Шулай кирәк иде. Шулай иткәндә яхшырак булыр төсле иде Курамшинга.

Скважиналар өчен икенче комплект яңа җиһазлар турында сөйләшергә дип, идарәдә калган иде ул бүген. Шунда Пичугов белән очрашты. Кузьма борчылган, йөзе каралып төшкән. «Эшләр шәптән түгел бит әле, Кәрам,— ди бу.— Мин сиңа, үземә ышанган кебек ышанып Фәнүзәгә квартира бирдердем, ах, мине подводить иттең»,— ди бу.

«Ни булды?» — дип сорый Кәрам.

«Ни булганын беләсең килсә әнә, бар кара: Мәснәвинең чын хатыны килгән анда!— ди Пичугов шактый куркынган хәлдә.— Ник миңа әйтмәдең, ник яшердең!?».

Кәрамның йөрәге жу итеп китте. Әйе, тагын бутала икән боларның дөньясы! Мәснәвинең «чын хатыны» Сара боларның яңа квартирасын табып, ишеген ничектер ачып кереп утырган, иренең кайтканын көтә, ди. Кырмыска оясын бутагандай итә инде бу саранча!

«Куарга идең аны! Якын җибәрмәскә идең!» — дип әйтеп карады Курамшин, ләкин Пичуговның үз дәлиле бар иде:

«Ә паспорты? Карадым: Мәснәвинең законный хатыны! Печате ярылып ята!»

«Булсын! Мең печать булсын! Мәснәви барыбер аның белән тормый!» дип кычкырды Кәрам, нәкъ Мәснәвичә итеп. Курамшин Черек күлгә, нефтьчеләр төбәгенә килеп Мәснәвине эзләп йөргәндә дә әле һаман эченнән генә Пичугов белән әйтешә иде.

Мәснәвине Аввакумов участогында скважиналарның коллекторларын көйләп яткан хәлдә күрде.

— Эшләр ничегрәк бара, Мәснәви?

— Болай ярыйсы. Менә, приборлар өчен оялар ясыйбыз. Ничек соң анда, автомат шкафлары кайтмаганмы?

Курамшин җавап бирмәде. Бераздан йөзен читкә борып, кемгәдер әйткәндәй:

— Син кайтып кит инде, Мәснәви,— диде.— Бүгенгә үзебез дә эшләрбез. Анда юлда сине Фәнүзә дә көтә. Чакырып калды. Тизрәк килсен, диде...

Шушы сүзләрне әйтеп бетергәнче маңгаена тир бәреп чыкты Курамшинның. Дөньяда ялганнан, икейөзлелектән дә яман нәрсә бар микән?!

Кайту турында яңа исенә төшергәндәй, Мәснәви юлга, Фәнүзә эшли торган якка карап торды.

— Хәзер иптәш Аввакумов та кайтырга рөхсәт бирде... Кәрам Ризванович, үзең соң, үзең бүген безгә өй котларга килерсеңдер бит?

— Бар әле, кайт, аннан күз күрер...— эченнән генә бу бәхетсез егетне кызганып «бичара!» дип куйды.

Бу вакытта Фәнүзә бульдозеры шәһәр ягыннан кабат монда килә иде.

— Ярый алайса, мин киттем!— диде дә Мәснәви, тунына сарган карларны кага-кага, шул якка йөгерде. Бераз баргач борылды да, кулын күтәреп:

— Килергә онытма, Кәрам Ризванович!— дип кычкырды.

Нәрсә белән генә бетәр инде аралары. Кара син аны, юньсез хатынны, дөньяны тегендә болгатуы гына җитмәгән, инде монда да килеп чыккан! Ничек белгән, каян эзләп тапкан диген? Мәснәви дөрес әйткән икән: «Әҗәлдән качып котылып була, минем саранчадан юк» дип. Дөрес икән. Тегендә булды тегендә Мәснәвигә яшәргә ирек бирмәде, инде монда да канына тоз салырга килеп җиткән! Гариза арты гариза китереп, әләк арты әләк язып Курамшинның теңкәсенә аз тимәде ул Сара дигән хатын. «Мәснәви эчә, Мәснәви өйгә кайтып керми, Мәснәви өстерәлчекләр белән йөри...» Ире шул кадәр дә начар булгач нигә аның артыннан чабарга, нигә торырга? Икесенең арасын бала да тотмый бит югыйсә! Кысыр бит ул хатын!

Җыелышлар җыеп, иптәшләр суды оештырып тикшереп, көйләпкөйләп күпме вакытын алды Курамшинның ул зәһәр җан, күпме эшен калдырды, күпме нервысын бозды. Инде тату гына яшәп яткан ике парның араларын болгатмакчы булып Себер хәтле Себергә килгән бит, пәри калдырчасы!..

Бульдозерның борылып шәһәргә табан китүен күзәтә-күзәтә, Курам-

шин әнә шул үткәндәге күңелсез, ямьсез вакыйгаларны искә төшерде.

Ә бу вакытта бер генә ай элек кавышкан Мәснәви белән Фәнүзә тар кабина эчендә бер-берсенә елышкан килеш, үзләрен гаять бәхетле санап, чөкердәшеп кайталар иде.

Фәнүзә мотор тавышын мөмкин кадәр әкренәйтергә тырышып газга баса. Шәһәргә бик ашыкса да, бульдозерын авызлыкларга мәҗбүр, чөнки аның шулай җилкәгә-җилкә куеп Мәснәви белән гәпләшеп кайтасы килә. Менә-менә буран кузгалырга торганын да сизми ул.

— И туйдырган иде дә бит торакта яшәүләр,— дип сөйләп китә Фәнүзә.— Ялгыз булсаң бер хәл иде, уйлап та бирмәс идең. Күрше торакта гына ирең була торып аерым яшәү — җәза бит ул. Утырасың — күңелең һич урынында түгел. Эштән кайтты микән, армады микән, ашады микән дип бер хафаланасың. Тегеләй-болай иптәшләренә ияреп эчәргә чыгып китмәгәе, дип ике кайгырасың. Кызлар янына гулять итәргә таймасын тагын, дигән шик тә кымырҗыта күңелне...

— Анысын арттырып җибәрәсең инде,— дип гөрелдәп куя Мәснәви.

— Аннан... Аннан, һич яшерен-батырын түгел, Мәснәви, кайчан янга керер икән, дип көтәсең... Юк, син гел шул турыда гына уйлап утырма әле. Хәл белешергә генә булса да керсен иде, дип телисең. Кергәч, аш хәзерләми, чәй куймый булмый — син буйдакның тамагын туйдырасы бар. Юкса, нәрсә инде ул столовой ашы? Ә син бит токмач яратасың, кулдан кискәнен. Өс-башыңны да салдырып юасы була — манма тир, мазут бит өстең! Гаепкә алма: эшләр беткәч нәфес дигәнең тагын да үсеп китә. Яныңа утырасы, чөкердәшәсе, онытылып кочакланышасы, аннан бергә ятып йоклыйсы килә башлый. Әлеге дә баягы: ярамый, рөхсәт ителми, вөҗдан кушмый. Сиңа чыгып китәргә вакыт, ә минем җибәрәсе килми...

— Торак дип аптырап тормадык инде анысы,— дип терсәге белән Фәнүзәнең янтыгына төртеп алды Мәснәви.— Син дә минем янга кунакка кергәли идең... Ял көннәрендә, егетләр чыгып киткән араларда, мәйтәм... Булмадымыни кочаклашкан вакытлар? Булды! Сизә идеңме, син кергәч егетләр төрле сылтаулар белән чыгып сызалар иде?

— Ә син кергәч? Кызлар йомыш белән чыгып китәләр дип уйлый идеңме? — дип трактор тавышын уздырып көлеп җибәрде Фәнүзә.— Бичаралар, ишектән синең гәүдәң күрендеме — төрлесе-төрле сәбәп таба башлый. Имеш, бүген клубта кызыклы кино була икән, шуңа билет алган идем. Имеш, магазинга бик яхшы товар кайткан, барып чиратка басарга кирәк... Бөтенесе дә безнең аркада бит, Мәснәвикәй, синең белән мин ялгыз калсын дип!

Фәнүзә көрсенеп алды да, ниндидер ялварулы тавыш белән дога укыгандай тезеп китте:

— Кызкайларым-җанкисәкләрем! Рәхмәт төшкерләре, инде миннән котылыгыз! Я раббым, инде бу квартира сезне бүтән кысмас, оялтмас, читендермәс өчен дә булсын!

— Ул кызларны обязательно бүген чакырырга кирәк.

— Соңга калдың әйтергә: бүген иртән барысына да әйттем, категорически киләбез, диделәр. Ә син соң, син, егетләреңә әйттеңме?

— Алар синнән-миннән сорап тормыйлар! Кусаң да бәреп керәчәкләр! Шайтаннар, миннән яшереп, беләсеңме, нәрсә эшләгәннәр? Кичә, чират буенча, идән юарга керештем. Хафизның караватт астын карасам — ул табак-савыт, ул чәшке-чынаяк тулган, мин сиңайтим! «Нинди тәтиләр тутырдыгыз монда? дип сорыйм. Дәшмиләр — дуңгызлар, аска карап тик утыралар. Аннан Хафиз: «Столовойда туеп булмады, ашау мәсьәләсен монда көйләп җибәрергә исәп» — дигән була, үзе иптәшләренә күз сала. Сиздем инде аны, сизмимме соң, безгә дип алганнар!— Мәснәви, тамак кырып, Фәнүзәнең колагына иелә:

— Син, чыннан да, ашны бүген күбрәк әзерлә әле, Касыйм «телгә дә йокмады» дип сөйләп йөрерлек булмасын,— ди.

— Аны барыбер туйдыра алмыйсың инде! — дип, шаркылдап көлде Фәнүзә.

Юлның яртысы диярлек үтелгәч, буран сизелерлек куерды, өермәле җил карны бер урыннан икенче урынга күчереп йөртә башлады. Җир өсте томаланды.

Фәнүзәнең хәзер күзләре юлда, куллары тыгыз һәм тынлаусыз рычакларда.

Ә буран котырганнан-котыра бара. Көчле җил карны җирдән кубарып алып һавада әйләндереп йөртә дә кочагы-кочагы белән машина өстенә, кабина ишегенә, тәрәзәләргә китереп сылый. Бульдозер гүя куе сөт диңгезе эченнән бара.

Тик бу вакытта җылытылган кабина эчендәгеләрнең буран турында түгел, ә яңа квартира, аның кечкенә бүлмәсендә бүген кич булачак өй туе, аңа чакырыласы кунаклар, дус-ишләр хакында гына уйлыйсылары килә. Туйдылар инде башларына төшкән гел ямьсез нәрсәләрдән, гарык булдылар.

Ләкин тыштагы ябышкак куе буран кәефне бозарга маташа. Тәрәзәләргә сарылган кар Фәнүзәгә бүген корган матур хыялларын, әйбәт планнарны күрергә комачаулый сыман.

— Кайчан басылыр бу буран?

Ул бульдозерын туктата, төшеп тәрәзәләрне сөртмәкче була.

— Тукта, үзем...

Мәснәви сикереп төшеп капот өстенә менә, җилкәләре белән тәрәзәдән карны сыпырып ала. Аның әле Фәнүзә белән монда да шаярып аласы килә — тәрәзәгә борынын терәп «яньчек танау» ясый.

Фәнүзә Мәснәвинең кайчандыр коммутатор тәрәзәсеннән шулай борынын яньчеп караганнарын исенә төшереп килә.

— Юлны күмеп бара торган көртләрне бульдозер пычагы белән кырдыра-кырдыра тагын китеп баралар. Ә буранның туктарга исәбе юк. Ул дулый, үкерә, карны һавада бөтереп йөри. Мәснәви борчыла, урынында утырып тора алмый, борылып әле арт, әле ян тәрәзәләргә карый. Буран болай дәвам итсә, шәһәрдән вахта машиналарының килә алмау ихтималы бар — Черек күлдән кешеләр ничек кайтыр?

— Юлның бу өлешен бераз чистартмый булмас,— диде Фәнүзә, Мәснәвинең уйларын тоткандай. Һәм бульдозерын алга-артка йөртеп, кай арададыр буран өяргә өлгергән көртләрне эттерергә кереша.

Ул арада шәһәр ягыннан да, Черек күл төбәгеннән дә машиналар күренә башлады. Фараларны кабызып, карны ерып бик әкрен, авыр киләләр иде алар. Мондый тар юлда шоферлар кара-каршы очрашса ниләр буласын Фәнүзә яхшы белә: басмада очрашкан тәкәббер тәкәләр кебек сөзешә башлыйлар...

Кай арададыр, ике яктан да машиналар җыелырга өлгерде. Ярты чакрым буена тезелгән колонна ике ягына кар өелгән тар юлга бөке булып тыгылды — алга да, артка да кузгала алмый иде.

— Әй, юл бир, читкә ал!

— Артка чиген, артка!

— Кырыйга кер, кырыйга!

Шоферлар кабина ишекләрен ачып бер-берсенә кычкыралар, үзара тиргәшәләр, тик аңардан мәгънә юк. Чыгып көрәкләр белән юл кырыйларын, көпчәк асларын казу да файда бирми. Күз ачыргысыз буран аларның тырышлыгын гына түгел, юл ярырга килгән бульдозерның да эшен минуты белән юкка чыгарып ташлый.

Юл буендагы көрт инде машиналар биеклеге булды, ә артта ашыгыч

эш белән килүче машиналар артканнан-арта, алдагыларын кар эченә тирәнгәрәк кыса бара иде.

Сигнал, кычкыру, сүгенү тавышлары күбәйгәннән-күбәя: — Артка ал, дим, артка!

— Бәрдерәм, үпкәләмә!

— Юл бир диләр сиңа, әбиеңнең кабер тактасы...

Урталыкта зур үзбушаткычлар, МАЗлар, КРАЗлар арасына кереп кысылган микроавтобуста Курамшин да бар иде. Телефоннан хәбәр иткәннәр: Черек күл скважиналары өчен җиһазлар кайткан, шуларны кабул итеп алырга шәһәр аэропортына барышы. Ул төрле маневрлар ясап алга үтәргә азаплана, ә машинасы, корсагыннан көрткә баткан да, кар туздыра.

Кәрам Ризванович машинадан сикереп төште дә бил тиңентен кар ярып бульдозер янына килде. Кул күтәреп машинаны туктатты, чылбыр өстенә сикереп менде.

— Сез мени әле? Һаман кайта алмадыгызмыни? — дип сорады кабина ишегеннән башын тыгып.

— Күрәсез бит... Кая кайту мондый чакта?

— Әйе... Янәшә эз салып булмыймы соң, Фәнүзә? Ничек тә үткәрәсе иде бит машиналарны.

— Кар асты туңмаган, кырыйда бата.

— Ничек туңмасын инде бу вакытта — яңа ел якынлаша бит! Әйдә, юкса соңга калам!

— Әх, Кәрам Ризванович! Сез монда беренче тапкыр, ә мин өченче кышымны уздырам!

— Әйдә, үзем җавап бирермен.

Курамшин сикереп төшеп калды, Фәнүзә бульдозеры белән кырыйга кереп китте дә тирән кар өемнәрен актарып юлга янәшә икенче эз сала башлады. Бу — каршыга килгән машиналарны үткәрү өчен «тупик» ясау дип атала.

Мәснәви коты очып әле җиргә, әле Фәнүзәнең йөзенә карап бара. Күп тапкырлар ишеткәне бар аның: Себер сазлыгы шундый мәкерле нәрсә икән — кышкы суыкларда да урыны-урыны белән туңмый кала, өсте чак кына каткан хәлдә кар юрганы астында ята, ди. Шуңа күрәдер инде, биредә «лежневка» дип йөртелгән юлларны агачлар, бүрәнәләр белән түшәгәннәр.

Китешли Курамшин тагын бульдозер янына килде.

— Менә рәхмәт! — диде ул кабина ишегеннән башын тыгып. — Ә син, Фәнүзә, «саз» дисең, «бата» дисең.

Курамшин Фәнүзәне үзен генә калдырып, Мәснәвине алып китәргә дип килгән иде. Әйе, Мәснәвигә Фәнүзәдән иртәрәк кайтып Сарасы белән аңлашырга кирәк. Дөресрәге, кеше-фәлән күргәләгәнче, куып чыгарырга кирәк ул хатынны өйдән.

— Әйдә, Мәснәви, утыр минем машинага, алып кайтам.

— Ә мин? — дип гаҗәпләнү катыш үпкәләп сорады Фәнүзә.

— Син каласың, Фәнүзә. Күрәсең, ничек котыра буран! Кем белә, бәлки юлда тагын машиналар тыгылгандыр. Кар ерып, баягыча тупиклар ясый-ясый кайтырга кирәк булыр...

— Ну инде, Кәрам Ризванович, вөҗданың да юк синең! — дип, Мәснәви урыныннан торды, кабина түбәсенә башын бәреп яңадан утырды. — Әйтерсең белмисең безнең хәлне! Мөмкин булса кайтармый эшләтер идең!..

— Кайту белән алмаш җибәртәм! Берне түгел икене! Сүзем сүз булсын!

— Бар инде алайса, Мәснәви,— диде Фәнүзә ризасыз гына.— Чыннан да юлны болай калдырып булмый. Анда, чакырган кешеләр дә килә башлар, каршы алырсың...

— Юк, юк! — дип кискен каршы төште Мәснәви. — Сөйләмә, ничек инде бу буранда сине калдырып китим?

— Ярый, кал алайса. Миңа да синсез күңелсез...

Курамшин нидер әйтмәкче иде — кулын селтәде дә китеп барды.

Алар ялан кырда, буранда тагын икәүдән-икәү генә калдылар.

— Җырлап утыр әле, Мәснәви.

Кәеф үтә дә кырылган чакта Фәнүзәнең шулай әйтеп куюы Мәснәвине сәерсендереп җибәрде.

— Җырлар идем дә буран эчне пошыра.

— Җырла инде. Беләсеңме нинди җырыңны яратам? Теге чакта Яңа ел кичәсендә җырлаганын. — Һәм Фәнүзә нәкъ Мәснәви җырлагандай башын чайкый-чайкый «Арча» көен сузып та җибәрде.

— Буран булсын, давыл купсын — миңа дөнья тубыктан. Ни әйтсәң дә, бүген без үз өебезгә кайтабыз. Ишетәсеңме, Мәснәви, үз оябызга!

Мәснәви, трактор тавышы шактый көчле булса да, боларны ишетә, ләкин нигәдер шатланмый кебек — җавап бирми. Ниндидер күңелсезлек сизеп, эче поша аның. Юлда утырып калудан хәвефләнү дә түгел, өй котлау мәҗлесенә вакытында кайтып җитмәүдән дә түгел бу — шулай да үтереп эче поша.

Вакыт-вакыт туктап, әле кырыйларга кереп, әле алга барып, тагын чигенеп, юлны әрчи-әрчи кайта торгач, көн тәмам кичкә авышты, караңгы төште. Инде олы юлга, бетон җәелгән туры, киң автострадага чыгарга да күп калмагандыр. Ә аннан шәһәргә егерме генә чакрым.

Ләкин буран шул кадәр азып китте — кабинадан бульдозерның борыны да, фара яктысы да күренми башлады.

Өстәвенә, машинаның ягулыгы азаеп бара. Автострададан бер туктамыйча шәһәргә кайтып җитәрлек кенә — алга-артка карамыйча.

— Чыннан да, кайда соң әле олы юл? — дип, тәрәзәгә таба йелде Мәснәви. Тик ничаклы гына күрергә тырышса да, тышта көл сыман аксыллыктан башка нәрсә шәйләмәде.

— Нигә борчыласың? Җырлап утыр әле, Мәснәви, җырлап!

Мәснәви моңа җавап итеп:

— Нигәдер бу Курамшинның вәгъдә иткән бульдозерлары да күренми, — диде.

Караңгы карны ерып тагын биш-алты минутлар бардылар.

Тәгәрмәч чылбырлары ниндидер каты нәрсә өстенә менеп басты сыман.

— Бетонга мендек түгелме?

— Әйе, олы юлга кердек ахры, — диде Фәнүзә. Бульдозерын туктатып, Мәснәвигә юлны капшап, тикшереп карарга кушты, утыргыч астыннан алып лом сыман озын бер тимер тоттырды.

Бераздан, битенә, каш-күзләренә сыланган карны бияләе белән сыпыра-сыпыра, Мәснәви кабинага менде.

— Ниндидер ауган агач өстендә без. Ботаклары тырпаеп ята. Төртеп карадым, аста саз. Менә, туңмаган. — Ул тимер таяк очындагы лайга кулын буяп күрсәтте.

— Якын тирәдә урман-фәлән күренмиме?

— Бер нәрсә дә күренми. Өстә буран да аста саз...

Бу бик яман хәбәр иде: бу — юлны югалту, адашу дигән сүз. Ничек килеп чыкты соң әле болай? Ничек шәйләми калды ул читкә тайпылганын?

Бульдозерны бераз артка таба чигерде дә, үзе дә төште Фәнүзә. Тимер таякны алып тәгәрмәч асларын төрткәләп карады — аннан пычрак саркып чыкты, аяк астын тикшерде — анда да таяк башы пычранды. Йөрәге жу итеп китте Фәнүзәнең.

— Кайда соң без, Мәснәви?!.

— Читкә кергәнбез. Килгән юлдан кире чыгыйк.

Утырып, әле генә ярып үткән тирән эз буенча артка чигенә башладылар. Шул вакытларда да әле: «Их, соңга калабыз бит! Әй туена кешеләр жыела башласа...? — дигән хәвефле уй Фәнүзәне тагын котыртып алды. — Борылырга да машинаны тизрәк шәһәргә табан куарга кирәк...»

Ул, бульдозерның пычагын күтәртеп, машинасын йөз сиксән градуска борды, тизлекне арттырды.

— Чыгарга кирәк моннан тизрәк, сизәсеңме, Мәснәви, саз чылбырларны суыра.

Шулай диюе булды — бульзодер борынын капылт түбән ия башлады. Машинаның пычагын төшерттерде Фәнүзә, тик авыр пычак җирне ертып, ак кар өстенә болганчык су гына саркытып чыгарды.

— Мәснәви, сикер, батабыз!

Мәснәви Фәнүзәнең рычаг тоткан кулларына ябышты.

— Ташла, сикерәбез!

— Җибәр рычакны, артка алам! Сикер!

Рычагны тарту белән бульдозерның арты да авыша башлады.

— Фәнүзә, ташла! — дип Мәснәви Фәнүзәне ишеккә таба этеп җибәрде.

— Син төшмичә төшмим! Калдырмыйм!

Фәнүзә үз ягыннан сикермәкче булып, бар көченә ишекне этә башлады. Инде соң, бу вакытта машина яртылаш чумган, саз ишекләрне кысып алган иде.

— Төрт ишекне, каер, Мәснәви!

Мәснәви, тимер таякны алып ишеккә бәрде, ишек калае тишелеп чыкты, тәрәзә пыялалары чылтырап коелды, аннан эчкә куе дегет кебек лай бәреп керде.

— Мәснәви!.. Саз йота!.. Бетәбез!..

Үлем ачысы белән кычкырып, Фәнүзә Мәснәвинең муенныннан кочып алды, алгы тәрәзәне тибеп ватты. Аннан, лава булып, өсләренә кара балчык ташкыны ургылды.

Мәснәви лай эченнән Фәнүзәне суырып алды да, аны кочаклаган килеш кабинаның калай түбәсен җимерергә, күтәрергә теләп башы белән бәрергә, яньчергә кереште.

— Фәнүзә!..

## III

... Килер кич, бергә эшләгән иптәшләре, дуслары, купшы киенеп, бизәнеп-ясанып, аларның түземсезлек белән көтеп алган бер бүлмәле яңа квартираларына өй котларга дип җыелырлар. Хуҗаларның кайтмый калуларына гаҗәпләнмәсләр, аларны гамьсезлектә дә гаепләмәсләр. Соңга калулар һәм эш белән бөтенләй кайтмый калулар бераүгә дә яңалык түгел биредә. Себер законнары барысына да мәгълүм, Себер законнары кешеләрдән күпне таләп итә, зурны сорый.

Бер почмакта, сәлам дә алмый, кашын җыерып, гаҗәпләнеп басып торган кара тут йөзле чибәр ханымга да артык игътибар итмәсләр кешеләр. Мәснәвинең «чын» хатыны килгән, бүген бу өйдә зил-зилә куптарырга чамалый, дип беркем дә башына китермәс. Үзләре кебек, чакырылып та хуҗасыз өйгә юлыккан гади бер кунак кына дип уйларлар аны.

«Киләселәр килеп бетте, җыеласы кешеләр җыелды», дип фараз кылгач, хатын-кызлар һәрвакыттагыча, үзләренең уңганлыкларын күрсәтү өчен, йөгерешә-йөгерешә өстәлләргә табак-савытлар, стакан-рюм-

калар тезә башлар. Кунаклар өйдә, хәзинәдә булган ризыкларны табып, үзләренең сумкаларындагы күчтәнәчләрен, кесәләрендәге шәрап-мазарларын да кушып мул табын әзерләрләр. Араларыннан сүзгә җорын, телгә остасын сайлап тамада итеп куярлар, бөтенесе берьюлы шау-гөж килеп, көлеп-шаярып мәҗлесне ачып җибәрерләр.

Бу буранлы кичтә нигезнең ныклыгы, хуҗаларның исәнлеге хакына җылы тостлар әйтелер, бер-бер артлы ифрат күп бокаллар күтәрерләр. Бинһая кызып киткән кунаклар, Фәнүзә белән Мәснәви исеменә атап, бу ике парны мактый-мактый кычкырып җырларлар, сикереп-сикереп биерләр. Һичшиксез күңелле булыр бу мәҗлес, һичкайчан күрелмәгәнчә рәхәт булыр монда...

Ә шул минутларда бәхетләреннән исереп, елмаеп-көлеп, җырлап табында утырасы хуҗаларның ерак тайгада, исеме-аты булмаган җирдә, тирән саз төбендә томаланып калуларын берәү дә белмәс...

... Алар мәңгегә югалдылар. Кешеләр хакына, эш хакына, мәхәббәт хакына киттеләр дөньядан.

## IV

Иртәгесен төбәктәге нефтьчеләр көн буена, төн буена эзләделәр аларны. Шәһәрдән алып Черек күлгә кадәр булган ярты йөз чакрым ара машиналар белән дә, атлар белән дә, җәяүләп тә үтелде. Беркайда бернинди бульдозер эзе дә, җәяүле эзе дә күренмәде. Кешеләр факельләр тотып, тавыш көчәйткечләр белән кычкырып йөрделәр, учаклар яктылар, мылтыклардан аттылар, ләкин файдасы булмады.

Шәһәрдә бу фаҗигале уңай белән, Кузьма Николаевич Пичуговны башлык итеп куеп, югалтканнарны эзләү штабы оештырылды. Моңа инде юлчылар һәм нефть чыгаручылар гына түгел, Черек күл төбәгендә эшләүче бораулаучылар да, вышка төзүчеләр дә, шәһәр салучылар да кушылган иде.

Югарыдан «Үлеме, тереме—табарга!» — дигән фәрман алынды. Һавага Төмәннән килгән самолетлар, вертолетлар күтәрелде. Тирә-як авылларга, поселокларга телефоннар шалтырады, телеграммалар сугылды. Аучы өйләренә, урманчыларга, хәтта ерак балык промыселларына кадәр хәбәр ителде.

Юлның, юл буйларының, шул тирәдәге сазлыкларның, күлләрнең, урманнарның һәр карышы тикшерелде, актарылды, капшап диярлек чыгылды, тик теге көнге дәһшәтле буран барлык эзләрне себереп күмгән, тигезләгән, гүя җир өстендәге бөтен нәрсәне йоткан иде...

Узар еллар, бу тирәләр танымаслык булып үзгәрер, матурланыр. Вах шәһәреннән илдә тиңе булмаган Черек күл нефть чыганагына сазны ярып бетон җәелгән киң автострада үтәр. Бу баганалы олы юлдан тоташ ташкын булып буровой җиһазлары, торбалар, инструментлар һәм башка кирәк-яраклар төялгән йөк машиналары, нефтьчеләр утырган вахта автобуслары, җиңел автомобильләр йөреп торыр. Шунда эшкә баручылар юл буеннан ерак түгел генә ялан саз эчендә күренеп торган маяк сыман нәрсәгә игътибар итми калмаслар. Бу — Мәснәви белән Фәнүзәгә куелган һәйкәл. Үзенә күрә кабер ташы. Кешеләр җирләнгән монда. Әйе, җирләмәгәннәр, ә җирләнгәннәр.

Белмим, ничек дип искә алырлар бу ике кешене. «Булган ди, торган ди заманында шундый бер ир белән хатын. Батыр булганнар. Утлардан-сулардан да, усал җил-давыллардан да курыкмаганнар — шушы мәкерле сазлык аша Черек күлгә юл салырга керешкәннәр...» дип легенда итеп сөйләрләрме? «Явыз булган Саз патшасы, кисәтеп әйткән болар-

га: «Әй, адәм балалары, моңа кадәр бернинди җан иясе басмаган чикләремә керә күрмәгез. Үтеп керсәгез миннән рәхим-шәфкать булмас, мин сезне йотачакмын» — дигән. Шуңа да карамастан, җөрьәт итеп кереп киткәннәр болар. Аларның икесен дә Саз патшасы йоткан, имеш»,— дип әкияткә әверелдереп сөйләрләрме?

Бәлки гап-гади итеп: «Мәснәви һәм Фәнүзә атлы ир белән хатын булган. Бик тату яшәгәннәр. Кеше ашаганны ашап, кеше кигәнне киеп көн күргәннәр. Адәм фәрештә түгел, җирдә кайбер гөнаһлары да булган, имеш. Әмма эшкә килгәндә, алардан да уңганы, алардан да булганы юк икән. Һәм киткәннәр алар Черек күл хәзинәсенә юл ачарга...»— дип дөреслеккә якын китереп сөйләрләр?!.

Ничек кенә димәсеннәр, аларның эшләгән эшләре, кылган гамәлләре һәм фаҗигале үлеме офтанып та, сагынып та, гыйбрәт итеп тә сөйләрлек...

## ЕГЕРМЕ ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Кәрамның шәһәр белән Черек күл арасын узган саен шушы урынга туктамый калганы юк.

Юл буенда, сазда ныклы терәк таба алмыйча авышып калган телефон баганасы бар — бульдозер бәлки шул тирәдә баткандыр, Мәснәви белән Фәнүзәнең гәүдәләре шунда күмелгәндер кебек тоела аңа. Нигә дисәң, теге фаҗигале көнне буранда Фәнүзәнең бульдозеры белән нәкъ шушы урында очрашканы хәтердә калган. «БелАЗ» маркалы бер үзбушаткыч, юлга тыгылган машиналар колоннасын узарга маташып, телефон баганасына килеп бәрелгән иде. Багана кыйшаеп, чак кына телефон чыбыгы өзелми калды.

Үзенә бирелгән микроавтобуста, кар-буран туздырып Черек күлгә барышлый, Кәрам бүген дә шушы урынга җитеп, шып туктап калды.

Машинасыннан төште, юлдан арырак китеп, бүреген салды. Адашкан, кыйбласын югалткан кеше кебек, кайсы якка карап басарга да белми әйләнгәләп торды да, кыйшайган телефон баганасына текәлеп катып калды.

Фәнүзә югалгач, Кәрам Әлмәткә, Ризатдиннар өенә телеграмма җибәргән иде. Ризатдин абзый белән Фәнүзәнең сеңелесе Фәния килделәр. Кайда, ничек батканлыгын берәү дә әйтеп бирә алмагач, Курамшин, машинасы белән аларны алып килеп, шушы авыш баганаы күрсәтте. Ризатдин карт та, Фәния дә, бичаралар, телефон баганасын кочаклап еладылар...

— Я, әйтегез, сезне ничек табарга? Кайда батып югалдыгыз? — дип, әкрен генә иреннәрен кыймылдатты Курамшин.

Кире кайтмас авыр югалту Кәрамның үзегенә кадәр төшеп әрнетә, үкендерә, сызландыра иде.

Бер атна гына элек менә шушы урында, Кәрам бульдозер кабинасында Фәнүзә белән Мәснәвине соңгы тапкыр бергә күрде, икесе белән дә, кырыс кына булса да, сөйләшеп алды. Бар белән юк арасындагы аерма бары тик бер атна гына!.. Фәнүзәнең үзен генә калдырып, Мәснәвине алып китмәкче булды — аера алмады. Яшәүгә нинди якты өметләр, нур белән балкый иде Мәснәвинең күзләре... Бередә үзе урынына калдырырга исәп тоткан иде бит ул Мәснәвине. Булмаса булмый икән.

— Шунда минем белән кайтып китсә, Мәснәви исән кала иде бит,— дип пышылдады Курамшин. Ләкин бу сүзе ошамады, Мәснәвине калдырып, Фәнүзәне үтерергә җибәрү булып тоелды аңа. Алар үлемендә, азмы-күпме, үзен дә гаепле санады Курамшин.

— Кайтмаска, юлны чистартырга кушып китмәсәм, бәлки икесе дә исән калырлар иде...

Уйлар, фараз итүләр, исәп-хисаплар, үкенүләр дулкын-дулкын булып килделәр, тагын чигенделәр, тагын килеп бәрелделәр. Инде Фәнүзәнең бәләкәе Фәнил исенә төште — чымырдатып тәнен өтеп алды. Ике яшендә берьюлы атасыз да, анасыз да калды сабый.

«Үлгәннәр — үлә дә котыла», диләр. Хәзер аларның баласы белән нишләргә, аны кая куярга?

Черек күлдә дә, идарәдә дә телләрдә Фәнүзә белән Мәснәви һәм бигрәк тә ятим калган бәләкәй Фәнил булды. Берәүләр сабыйны Әлмәткә, бабасы, әбисенә кайтарырга, икенчеләре балалар йортына тапшырырга кирәк, диделәр.

Бирегә Фәнүзә белән Мәснәвине якыннан белгән бердәнбер кеше, аларның якташы һәм дусты Курамшин булганга, киңәш-табыш белән күбрәк аңар киләләр иде. Нишләргә?

Бу мәсьәләне хәл итмәкче булып карады инде Курамшин. Фәнүзәнең әтисе Ризатдин абзый белән бергә Пичуговны, Ишәй абзыйны шәһәр Советына ияртеп барган иде. «Бабасы да, әбисе дә картлар, хәзер аларның үзләрен карарга да кеше кирәк»,— дип Ризатдинга баланы тәрбиягә бирүдән баш тарттылар, мәсьәләне хәл иткәнче тәүлеклек яследә тотарга куштылар.

Ә бөтенесен аптыраштa калдырганы исә соңыннанрак булды.

Баланы күрергә дип, кесәләренә конфет-пряниклар тыгып яслегә барганнар иде. «Фәнилне алып киттеләр дә китермәделәр»,— дип, тыныч кына йөриләр тәрбиячеләре.

— «Кем алып китте?» — дип сорый Кәрам.

«Кем булсын, бер хатын килеп алды. Шулай гадәтләнгән инде ул бала: әнисе эштә вакытта торактагы кызларга ияреп дә кайтып китә»,— диләр тәрбияче тиешле ханымнар.

Нәрсәдер сизенеп, кызлар торагына түгел, ә Фәнүзә мәрхүмәгә бирелгән яңа квартирага барасы иттеләр. Барып керсәләр — өйдә Сара, әчке күлмәктән генә калып, җырлый-җырлый, Фәнилне таста юындырып маташа.

Телсез калып, дүртәүләп хатынның бала коендырганын карап тордылар. Бераздан соң: «Без баланы алырга килдек»,— диде Ризатдин.

«Бала минем үлгән иремнеке, мин аны бирмим»,— диде Сара. Баланы, ак простыня белән урап, кочагына кысты.

«Кара син, моңарда да аналык хисе бар икән»,— дип гаҗәпләнде Кәрам.

«Бала минем кызымныкы!» — дип, Ризатдин кыза башлаган иде, Кәрам аның җиңеннән тотты. Сарага әйтте:

«Без аны ятимнәр йортына тапшырабыз, бирегез!»

Сара, баланы кочаклаган килеш, утырып үкси башлады: «Мин барыбер алам, аннан да алам... Бала — минеке!»

«Бала өчен түгел, беләм, квартира өчен җылыйсың!» — диде ишек төбендә үк басып торган Пичугов.

«И, ходаем! Үзегезгә булсын өегез! Минем үземнең ике бүлмәле!»

Кечкенә Фәнил дә телгә килде: «Мин бабайга бармыйм. Мин яңа апага булам!»

«Судлашам! Барыбер алам!» — дип кычкырды Ризатдин карт һәм янап чыгып китте.

Ризатдин инде Әлмәтенә күптән кайтып китте, ә Сара һаман биредә бала белән яши — шәһәр Советының карарын көтә, ди.

Курамшин, машинасына таба борылган иде, сулда ашыгып-ашыгып юлга төшеп килүче чаңгычыны күреп туктады. Бу — Ишәй абзый иде.

Атна үтте, Фәнүзә белән Мәснәвинең исән булуына гына түгел,

табыласына да өмет өзелде. Әмма Ишәй абзыйның әле моның белән килешәсе килми иде. «Кешеләр бөтенләй эзсез югалырга тиеш түгел, алар табылырга тиеш»,— дигән фикереннән кайтмады ул. Үзенең аучы булып эшләгән заманнарыннан ук калган киң табанлы чаңгыларын тагып, кулына биш-алты метр озынлыгындагы тимер шыбын тотып әле һаман кар астындагы сазлыкларны актарып йөрүе иде аның.

Курамшин янына тирләгән, сакал-мыекларына гына түгел, кашлары-керфекләренә кадәр бәс сарган хәлдә килеп житте ул. Бияләен салып, билбавына кыстырды, кулы белән авыз тирәсеннән бер уч кар сыпырып төшерде.

— Син дөрес күрсәтмәгәнсең,— дип, дәгъва белән башлап җибәрде сүзен. — Кеше уләргә булса — юл буеннан еракка китеп үлә ул. Үләсе корт та бит такыр басуга оча...

— Кайда үләселәрен әйтеп калмадылар шул,— дип куйды Кәрам.

— Ул көнне җил кайдан исә иде? Кояш батышыннан. Значит, җилгә арт белән киткәннәр алар — Черек күлгә таба... Адашып үләсе кеше җилгә арты белән китә...

— Җәяүле булса. Алар бит кабинада.

— Барыбер арт белән китә.

— Таба алмассың инде аларны, Ишәй абзый, әйдә утыр, Черек күлгә алып кайтам үзеңне.

— Эзлим әле. Тапсак хәзер табабыз. Җәй көне сазга кереп булмый.

Кәрам тагын ятим калган кечкенә Фәнилне исенә төшерде:

— Ничек уйлыйсың, Ишәй абзый, баланы Сарага бирерләрме? Аның бит бернинди хакы юк!

— Закон хатын-кыз кулында. Кабат булдым мин анда. Бала ятсынмый. Сарасы да, баласы да бер-берсен яраталар. Тимә син аларга, Курамшин. Алар бит икесе дә ятим...

Кат-кат үгетләүгә карамастан, Ишәй ачык кыр уртасында, юлда калды. Курамшин әле генә кичергән авыр тойгылары белән китеп барды. Тизрәк Черек күлгә барып җитәргә кирәк иде аңа — иртәгә үзенең туган ягына кайтып китәсен егетләре белән уртаклашасы килә иде.

— Әйтсәм дә барыбер ышанмаячаклар,— дип елмаеп алды ул. — Рафат кулын гына селтәр: «Сез, Кәрам абый, килгәннән бирле китәсез инде», дияр. Гөргери: «Иске әкият!» — дип кенә җибәрер. Касыйм туп-туры күзгә карап торыр да: «Себер ул сары май бәлеше — бик тиз үтләтә»,— дип төрттерер... Шул вакта Кәрам кесәсеннән самолет билетын чыгарып күрсәтер дә: «Сөйләшенгән, килешенгән, хәл ителгән!»— дип тегеләрнең исләрен китәрер. Инде китәчәгенә тәмам ышандырып бетердем дигәндә: «Юк шул, дуслар, берегез дә белмәдегез. Кәрам абзагыз биш көннән. Себергә бөтенләйгә күчеп киләчәк. Хәтимә апагызны алып, өч улы белән!» — дип егетләрне аптырашта калдырыр.

## II

Курамшин бүген егетләре янында басылып кына эшли алмады — китү дәрте белән ачык һавага чыгып, чатлама суыкта бер максатсыз Черек күл буенда йөрде. Һич кирәкмәгәнгә тегендә сугылды, монда кагылды.

Институт бетереп Әлмәткә эшкә килгәч тә бит ул кырларны, скважиналарны карап йөргән иде. Әйтерсең, аның эшкә калу-калмавы бары тик шуларга бәйләнгән.

Утрауларның берсенә барып, вышкачыларның ничек буровой корганнарын карап торды, бораулаучыларның җир тишкәннәрен күзәтте.

Аннан, боз өстеннән күл уртасына кереп китте. Монда бульдозер-

лар өч-дүрт метр калынлыкта каткан авыр бозларны кубарып күл төбен әрчиләр иде. Хәзер күл буендагы сазлыкларда гына түгел, юл салып күл эченә дә утраулар ясарга җыеналар. Киләчәктә бөтен күл төбен шулай акрынлап бораулый-бораулый нефть ала башлаячаклар икән. Бу — чын әкият! Ҡомнан бау ишеп, күлнең төбен күккә асудан да кызыграк.

Черек күл Бакудагы диңгез промыселена, Нефть ташлары шәһәренә охшап калачак имеш, дип сөйләгәннәр иде — биредә проблеманы башкача хәл иткәннәр.

Шәһәр белән Черек күл арасында юл салучылар, баштарак сазны төпкә кадәр сосып алып, урынына ком-таш тутырырга, аны таптап тигезләп, өстенә ансат кына асфальт җәяргә исәп тотканнар иде. Барып чыкмады — казыган урынга яңадан су, сыек лай тулды. Аннан, сазның тирәнлеге дә жиде-сигез, кайбер урыннарда унике метрга кадәр җитә. Юлны, проект буенча, тагын бер-ике метр өскә дә күтәрергә кирәк. Илле чакрымлап арага чамасыз күп материал һәм вакыт кирәклеге мәгълүм булгач, бу эшне ташладылар.

Сазлык проблемасын башкача, ансат һәм арзанрак ысуллар белән хәл итәргә кирәк иде. Бу ысул күз күнә, җир туңдыргач табылды. Кыш бабай ярдәмгә килде. Саз балчыгын алып җирне туңдырырга, җәй көннәрендә эремәсен өчен өстенә торф катламы салырга, аннан ком һәм вак таш өеп тыгызларга, тигезләргә дә бетон салырга булдылар.

Хәзер шулай бетон плитәләр җәелгән киң автострада шәһәрдән Черек күлгә кадәр генә түгел, бөҗра ясап күл тирәсен дә әйләнеп чыга. Курамшин аны Мәскәүне урап узган «Большое кольцо»га охшата иде.

Күл эчендә бозларны куптарып ятуның хикмәте дә шунда: күл төбен туңдырып, торф салып, ком-таш өеп ясалма утраулар булдыру, ул утрауларга керү өчен дамбалар күтәрү.

Килер бер көн: шушы төбәктә, күл эчендә, яр буйларында йөзләгән скважиналар эшли башлар, автоматчылар өчен хыялга да кермәгән гаять зур перспективалар ачылыр.

Ул көннәргә ерак калмаган бугай. Курамшин инде аны үзе басып торган тирән катламнар аша бүген үк күзаллый кебек...

Йөри-йөри Аввакумовның «Робинзон утравына» килеп чыкты Курамшин. Әлмәткә киткәнче Виталий Ивановичны күрәсе бар иде аның.

Аввакумов бригадасы эшли торган бу утрауга ул сирәк килә, килгәндә дә, нинди дә булса сәбәп белән аларның бәхәскә керми калганнары юк иде. Бүген аны Виталий Иванович гадәттәгедән җылырак сәламләде.

— О, телемеханика короле килгән! — дип, будкадан шәрран ярып, Курамшинның каршысына чыкты. — Әйдә, рәхим ит, Кәрам Ризванович, түрдән уз!

— Узабыз аны, Виталий Иванович, узабыз!..

Курамшин утрау эчендәге төзелешләрне, җиһазларны карап чыкты. Монда хәзер эшләр гөрләп тора. Утрау, үзенең йөзен үзгәртеп, Татарстан промыселларындагы группалы установкаларга охшап калган иде.

— Барысын да синең өчен эшлим! — дип, шелтә беләнрәк әйтеп куйды Аввакумов.

— Кем кем өчен эшлидер бит әле! Автоматлар бит миңа түгел, сиңа, нефть чыгаручылар өчен кирәк.

— Тәмам җиктең инде син мине, Кәрам Ризванович,— дип һаман зарланды Аввакумов. — Күпме тырыштым сине үз ягыма аударырга — булмады, киресенчә килеп чыкты.

— Барыбер миннән «эксплуататор» чыкмас иде, Виталий Иванович.

Тәмәке кабыздылар. Салмак кына сөйләшү бара:

— Китәсең икән дип ишеттем?

— Монда да син отылдың, Виталий Иванович. Бөтенләйгә түгел, семьяны алып килү өчен генә!

— Димәк, хәзер син дә чын сибиряк? Нигәдер, ышанып бетмим...

— Ышанмаслык нәрсә бар?

— Гадәттә хатыннар каршы төшүчән була: «Квартира шәп иде, урын яхшы иде, дус-ишләр, туган-тумачалар күп иде, этебез дә бәбәйләргә тора, мәчебез дә буаз» һәм башкалар. Хатының җибәрмәс дип куркам...

— Киресенчә, мине хатыным Себергә кыстый.

— Молодец икән хатының! Беренче ишетәм андый хатын турында, баш иям!.. — Аввакумов, артистларча кыланып, җиргә кадәр бөгелә.

— Кыскасы,— диде Курамшин үзенең ашыгуын белдереп. — Син, Виталий Иванович, минем егетләргә күз-колак була тор инде. Анда барысы да яшьләр, үзең беләсең...

— Кайгырма, эшсез тотмам! Хәерле юл сиңа! Көтәбез!

## III

Китәсе көнне иртүк Курамшинның номерына Пичугов шакып керде. Әллә бик ашыгып килгән, әллә йөгергән — тынына капланып, сүзен әйтә алмый тора.

— Хәерле көн, дустым, нигә бик иртә? — диде Кәрам. Ул юлга җыена, чемоданына әйберләрен тутыра иде.

— Уф, ашыктым, син китеп баргансың дип курыктым. — Кузьма Николаевич сулуын һаман көчкә-көчкә ала иде. — Син теге уеннан кире кайтмагансыңдыр бит?

— Нинди уемнан? — дип белмәмешкә салышты Курамшин.

— Нинди дип... квартира алмашу мәсьәләсендә.

Кәрам Ризвановичның кәефе шәп иде — дустын һаман шаяртып маташты:

— Уйлаганым да юк квартира алыштырырга!

Нинди генә сүзгә дә тиз ышанучан Пичуговка житә калды:

— Ничек инде уйлаганың юк? Кичә генә сөйләшкән идек түгелме?

— Мин татар бит. «Кичәге акыл бүгенгә ярамый», диләр татарларда.

— Бу инде егетлек түгел! — дип кычкырып әйтте Кузьма Николаевич. — Мин квартира алмашу өчен кирәкле документлар оформить итеп йөрим!..

Ул, портфеленнән кәгазьләр чыгарып, берәм-берәм өстәлгә сала барды.

— Менә договор, менә домоуправлениедән алган справка, менә квартира ордеры, менә...

— Булса соң?

Кәрам, эшләрен төгәлләп, сәгатенә карап алды да костюмын кия башлады. Кузьма Николаевич, хәлсезләнеп креслога утырды:

— Суйдың болай булгач мине,— дип, аңлашыр-аңлашмас мыгырданырга тотынды. — Үтердең син мине. Китәм диеп эшне тапшырдым, пропискадан чыктым, военкоматта учеттан төштем... Әлмәт белән төне буе хыялланып чыктым, грамм да йокламадым.

— Соң, уйлап кара, Кузьма дустым, кем соң инде салкын Себер белән Әлмәтне алыштыра? Әлмәт бит ул җәннәт!

Кәрам Кузьма Николаевичның чарасызлыгыннан көлә һәм бер үк

вакытта аның шушы кадәр югалып калуына, тупикка килеп терәлүенә борчыла, хафалана да иде.

Квартирасын алыштырып, Кәрамның Себергә килергә җөрьәт итү сәбәпләренең берсе, бәлки, Кузьманың бүгенге авыр хәленә керүдән булгандыр әле. Менә бит: кайчан гына Себер дип, шәһәрне гөлбакча ясыйм дип, ниндидер йортлар, зиннәтле сарайлар салдырырга хыялланып йөргән кешедән нәрсә калды!.. Гомер буе үзен тапмаган, юлын тапмаган кеше бик кызганыч икән. Кызганыч кына түгел, мескен. Ә бит Кузьма начар ир түгел — күңеле гел яхшылыкта. Ничек булса да ярдәм итәргә кирәк аңа, коткарырга кирәк егетне бу авыр хәлдән.

Тышта сигнал тавышы ишетеп, Курамшин тәрәзәгә килде. Тәрәзәдән төшкән ут яктысында Бибиковның кара «Волга»сын танып алды. Кичә: «Мине көт, озатырга киләм»,— дигән иде, сүзендә торган икән баш инженер.

Аптыраган, нәрсә эшләргә белми бөтенләй коелып төшкән Пичугов янына килде Кәрам.

— Спектакль тәмам! — диде дә, дустының җилкәсенә сугып куйды. — Кайчан инде син, Кузьма Николаевич, ялган белән чынны аера башларсың?!

Кузьмага җан керде:

— Чынлап ялганладыңмы? — дип сикереп торды.

— Чынлап ялганладым, дустым! Әйдә озат!

Көлешә-көлешә машинага чыктылар. Ул да булмады, Курамшинның үзе утырып йөри торган микроавтобусы килеп житте. Аңа Кәрам Ризвановичның автоматчы егетләре утырган иде.

— Кара син Курамшинны: нинди важный начальник! Бөтен бер эскорт озата бара үзен! — дип көреште Пасарби Пшимахович.

— Аның каравы, килгәндә җәяү килгән идем,— дип көлде Кәрам Ризванович. — Ник шунда шәһәрнең бер эте каршыласын!

— Килгәндә син командированный идең, киткәндә — үз кеше! Сибиряк!

Егетләр, машинадан төшеп, Курамшинны урап алдылар. Урамда караңгы булса да, Кәрам Ризванович аларның тавышларыннан танып тора: менә болары «Өч мушкетер» Рафат-Касыйм-Гриша. Тегесе Володя Леванов, әнә тегесе Виктор, арырак басып торганы — удмурт малае Семен... Бөтенесе дә Кәрам өчен якын, үз кешеләр иде.

— Ник килдегез әле монда? Кем кушты мине озатырга? — дип ачуланган булды Курамшин. Үзе аларның килүенә сөенә, игътибар итүләре өчен горурлана да иде. «Исән булса бәлки алар арасында Мәснәви дә булыр иде,— дип моңсуланып алды Кәрам. — Бәлки бергә Фәнүзә дә килер иде...»

— Сезне озатырга дип килдек, Кәрам Ризванович.

— Татарстанга сәлам җибәрергә килдек,— диештеләр егетләр.

— Без бит инде сөйләшкән идек: бернинди озату булмаячак, сез эш кешеләре, минем самолет әле тиз түгел...

— Кәрам Ризванович,— дип балаларча килеп сыенды Рафат. — Гаеп итмәгез, минем үтенечем бар иде: күчтәнәчләрне бүген үк тапшыра алмассыз микән?

— Бүген үк тапшырам! Кайтышлый ук керәм!

— Аннан: «Яңа елга кайтып житә»,— дип әйтегез Садәгә...

— Обязательно әйтермен! «Өйләнергә» дип тә өстәргәме? — дип шаяртты Кәрам Ризванович.

— Анысын белә инде ул...

Кузгалырга вакыт икәнен белдереп, баш инженер машинасы сигнал бирде. Ләкин бу вакытта да әле Курамшин китәргә ашыкмады, үзе юкта ниләр эшләргә кирәклеген аңлатып, бригадир булып калган

Левановка киңәшләр биреп торды. Тик, Пасарби Пшимахович сабырсызланып, кат-кат сигнал бирә башлагач кына, урыныннан кузгалды.

— Ярый, егетләр, хушыгыз! Рәхмәт якын итеп килүегезгә!

Курамшин үзенең каршында басып торган егетләрне төркеме белән сыпырып кочагына алмакчы булды — кулы җитмәде.

— Ярый егетләр, сынатмагыз!

Машина янында тагын кул кысышып, җылы итеп хушлаштылар, әйтерсең, эшчеләр Кәрам Ризвановичны биш көнлек юлга түгел, мәңгегә озаталар иде.

— Олы җиргә сәлам әйтегез!

Машина кузгалып киткәндә Бибиков Курамшинга таба борылып утырды.

— Кара, сине ничек яраталар! — дип сокланып куйды, тәрәзәгә күч булып ябырылган егетләргә карап.

— Әйбәт егетләр...

Чынлыкта әле Курамшин, җитәкче буларак, үз эшчеләре белән бик аз таныш иде. Шушы кыска вакыт эчендә күпме генә нәрсә белергә мөмкин? Кемнең кем икәнен, холык-гадәтләрен, уй-хыялларын бергә озак эшләгәндә генә белеп була. Ләкин шунысын ачык күрә Кәрам Ризванович: бу егетләр — Себернең киләчәге. Алар — Черек күлнең дә, шәһәрнең дә төп хуҗалары булачак.

Кәрам Ризванович барысыннан да канәгать, бөтенесенә рәхмәте зур. Тик биредә Аввакумовның юклыгы гына аның эчен тырный. Черек күлдә очрашканда Виталий Иванович озатырга киләм дип тә әйтмәде, хәтта хәерле юл да теләмәде, ләкин Курамшин әрсезлек белән аның килүен көтә. Ни өчен — үзе дә белми. Очрашып бер әйткәләшеп алырга гадәтләнгәннәр — шуңа күңелсез иде, ахры...

Кәрам Ризванович, шәһәрне соңгы тапкыр карап калырга омтылган кеше сыман, тәрәзә аша яңа төзелешләрне, үзе күрергә өлгермәгән юл һәм күперләрне, завод һәм фабрикаларны күзеннән үткәреп барды. Машина да, шәһәрне яхшырак күрсәтергә теләгәндәй, борылып-борылып төрле урамнардан, проспектлардан узды, яңа салынып яткан стадион, телецентр яннарыннан үтте. Кәрам килгәндәге белән чагыштырганда шәһәр бермә-бер диярлек үскән, үзгәргән, матурланган иде.

— Әлмәт яхшымы, безнең шәһәрме? — диде Бибиков Курамшинны сынап карамакчы булып.

Ләкин Кәрам Ризвановичның да сер бирәсе килмәде:

— О, Әлмәт — ул җәннәт!— дип, үзенең яраткан сүзен кабатлады.— Себер булмаса, мин аны гомердә дә ташламас идем!..

— Минемчә, дөньяда иң гүзәл шәһәрләрнең берсе — Вах! — дип көлдерде Пасарби Пшимахович.

Кайчандыр: «Мин шәһәрнең ветераны, мин шәһәремнең патриоты!» — дип аһ орган Кузьма Николаевич кына хәзер аның белән кызыксынмый иде. Кызыксынмый гына түгел, шәһәрне күрәсе дә килми иде бугай.

Ул инде фактта шәһәр белән дә, идарә белән дә очны өзгән, хәзер баш инженер Бибиковка үзенең соңгы үпкәләрен белдереп, бәйләнеп бара:

— Минем, Пасарби Пшимахович, шуңа гына ачуым килде: заявление күтәреп сиңа киңәшкә кергәч, ник китәсең, дип тә сорамадың, ичмасам! Идарә начальнигы да бер сүз әйтмәде.

— Анда нигә китәсең язылган ич: «Үз теләгем белән» диелгән иде.

— Калыр дип курыктың... Барыбер калмый идем, шунда юри генә булса да әйтсәң — күңел булыр иде.

— Әйтергә онытканмындыр, Кузьма Николаевич, гафу ит.

Пичугов бу сүзләрдән үзе дә сизми, көлеп җибәрде:

— Әнә, Кәрам Ризвановичны командировкада булса да онытмадыгыз, черки урынына ябыштыгыз!..

— Замнарны һәрвакыт табып була, менә син специалистны табып кара! — дип хахылдап көлде Бибиков. — Әйттерден инде ахырда!..

Машина исәпсез-хисапсыз неон утлары белән җемелдәгән иртәнге шәһәрне артта калдырып караңгы аэропорт юлына чыкты. Бу вакытта да әле Курамшин, бернинди сүзгә кушылмыйча, тәрәзәгә карап уйланып бара иде...

Әлмәттән киткәндә аңа бергә эшләгән иптәшләре юату өчен дә, шаярып та юл аягына төрле сүзләр, теләкләр, хәтта үгет-нәсихәтләр дә әйтеп калганнар иде. Шулар арасында мәрхүм Мәснәвинең: «Бар, Кәрам Ризванович, Себер җиренең тирән катламнарын бер актарып кайт әле»,— дигәне аеруча хәтерендә.

«Өстән-өстән генә сөрә алсам да таманга туры килер»,— дип җавап биргән иде Кәрам. Дөрес әйткән. Бу кыска гына арада мактанып күрсәтерлек нәрсә кырасың? Үзенең автоматлары белән җир астының, Себер нефтенең тирән серләрен ача алмады Кәрам, шулай да бу вакыт эчендә Себердә күпме гыйбрәтле нәрсәләр күрде, күпме кызык кеше белән очрашты, шатланды, ачуланышты, тапты, югалтты, кешеләр күңеленең никадәр тирән икәнен тойды, катлаулы һәм серле икәнлегенә төшенде...

Шәһәрдән унбиш чакрым ераклыктагы аэропортка килеп җиткәндә инде яктыра башлаган, радио кычкырып тора, Курамшин утырасы самолетка диктор регистрация башлануын белдерә иде.

— Әле өлгерербез!

— Вакыт күп әле! — диештеләр килүчеләр.

Курамшин регистрация ясаткан арада, Бибиков белән Пичугов буфеттан шампанский алып, шунда, биек мәрмәр өстәлдә кечкенә табын әзерләп куйдылар.

Курамшин килгәч, Пичугов мөлдерәмә тулган бокалын күтәрде дә:

— Хәерле юл сиңа! — дип эчеп тә җибәрде.

— Рәхмәт озата килүегезгә!

Кәрам, бер генә йотым шампанский эчеп, алдындагы күмәчен тешләп куйды. — Миңа җитте, юкса самолетка утыртмаслар.

Пасарби Пшихамович, аптырап, һаман бокалын күтәреп тора иде.

— Туктагыз әле, юл аягына бер генә сүз әйтим әле, иптәшләр!

— Тостмы? — дип куркып сорады Курамшин, сәгатенә карап. Ул, кавказ халыкларының мәҗлестә яртышар сәгать буена тост әйтүләрен ишеткәне бар иде.

— Тост түгел... Безнең бабайлар кешене озатканда: эчеп бетермәгән чәең, ашап бетермәгән телемең, тәмамланмаган эшең калмасын — кире әйләнеп кайтуың бар, дигәннәр. Карап-карап тордым да, Курамшинның тиздән монда киләсенә чын-чыннан ышанып куйдым. Нигә дисәң — өстәлдә аның эчеп бетмәгән шәрабе, тешләп куйган икмәге, ә Черек күлдә тәмамланмаган эше кала! Мин бу бокалны Кәрам Ризвановичның биредә бурычлы булып калуы өчен күтәрәм!

— «Кызың чибәр, бабай, ләкин тырнаша»,— дип әйткән ди бер кияү. — Бибиковның сүзләреннән тәэсирләнгән Кәрам моны җавап итеп әйтте.

Күңеле белән ул әле һаман да Аввакумовны көтә иде.

— Озатырга килмәде бит, каһәр...

— Кемне әйтәсең?

— Виталий Ивановичны.

— Киләм дигән иде ул... Димәк, эштән бушый алмаган...

Бибиков белән сөйләшеп торган арада Пичугов беразга гына югалган иде, кассага барган, билет алган икән — шуны селки-селки килеп тә җитте.

— Мин дә очам бит, Кәрам, синең белән! Ура! Әлмәткә бергә кайтабыз! — дип кычкыра.

— Ну, жилбәзәк тә кеше соң үзең! — диде Кәрам. Тагын нинди сүз әйтергә белми аптырап, иреннәрен кыймылдатып торды.

Пичугов һаман шатланып бетә алмый:

— Буш урын бар икән самолетта, әйтерсең мине генә көткәннәр!

Самолетка утырта башлаганнар, аны-моны уйлап торыр чак түгел иде:

— Әйдә, алайса!

Бибиков белән кул биреп хушлаштылар да йөгерделәр.

Самолетка менгәндә Курамшин артына әйләнеп карады һәм капка янында Аввакумовны күрде. Виталий Иванович озатучы халык арасында нәрсәдер кычкыра һәм, башкалар кул болгаганда, арада бер үзе йодрык яный иде.

Кәрам көлде һәм үзе дә йодрык күрсәтте. Бу аларның үзләренчә хушлашуы, үзләренә генә хас сәер дуслыгы иде.

## Укучының күңел дәфтәренә

**Украин мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Йөрәкләре якыннарга ерак юллар булмыйлар.*

*Ананың бер кулы сукса, икенче кулы сыйпый.*

*Баланың башы авыртса, ана йөрәге әрни.*

*Яхшы тегермән ташы барча бөртекне тарта.*

*Аягыңа баш ия дә, үкчәңнән тешләп ала.*

*Хәтта пешкән йомыркадан чебеш чыгара ала.*

*Иренеңә бал сөртәләр, ә яларга ярамый.*

*Май белән бергә үстем дип ярма мактана икән.*

*Үзеңә ярамаганны бүтәннәргә теләмә.*

*Бик өстән караган кеше бер нәрсә күрә алмый.*

*Зур болыттан яңгыр аз була.*

*Дәшми торуы куркытмый, буш сүзе эч пошыра.*

*Сарыкка каршы батыр, батыр алдында — сарык.*

*Көнчене киптергән нәрсә — бүтән кеше бәхете.*

*Ни ясыйсың, әйт әле: тарантасмы, тәртәме?*

*Агачы калын, ләкин эче куыш.*

*Ун ел инде көй уйналмый, ә ул һаман да бии.*

*Үзең ничек үлчәсәң, сине шулай үлчәрләр.*

*Акны кара итеп була, ә карадан ак булмый.*

*Саламга ут яшерә алмыйсың.*

Рөстәм Мингалим

# ИКЕ АВЫЛ АРАСЫ...

## I

Күк астында авыл тора —
Бер урамлы, төзек кенә.
Үзәнлеккә ялга кунган
Кош төркеме кебек кенә.
Бер урамы — бер кыл гына,
Бөтен көйне уйный үзе...
Чиртә, суга еллар кылга,
Юк, өзелми — әле түзә,
Әле уйный... Кызыл колын —
Кешнәп куйды кыл өстендә:
Яңа чыккан кояш булды —
Тавышы таулар җилкәсендә.

Үзгәрешләр күп булса да —
Шул ук тормыш күк астында.
Яшисе бар, күрәсе бар;
Бирәсе бар, аласы да...
Төрле холык, төрле халык,
Һәммәбезгә шатлык кирәк.
Шаян шатлык чакыра-көлә,
Посып тора, юлдан йөгерә.

Авыл карты атын җиккән,
Кай арада өлгергәндер.
Җилкән булсын, бабай, дугаң!
Карт — чөңгереп җибәрә бер.
...Таныш пәрдәләр артында
Кызлар чәчен үреп кала...
Хәтта чикләр, дәүләтләрне
Акыл күзе күреп бара:
Якалашкан илләр күрә,
Якынлашкан илләр күренә.

Менеп бара авыл карты
Гомеренең соңгы үренә.

Үрне менгәч югалыр ул,
Борынгыдан шулай инде.
Борынгыдан мирас җиргә
Һаман яңа кеше килде.

Җиргә килгән җиләк сыман
Килде кеше — туды кеше.
...Үсте кеше. Кыйтгаларга
Төркем-төркем тулды кеше.
Җирне бүлде, суны бүлде,
Күкне кисә телем-телем.
Тимер куәт алды кеше,
Эшли кулы, эшли теле.
Эшли кеше.
Авыл карты —
Кагып куйды дилбегәсен.
Һәм чайкалды хәтерендә
Бер арбалык гаиләсе:
Олы улы, уртанчысы;
Кече малай, төпчек кызы.
Хатынының чардуганы —
Миләшлектә калды посып.
...Ике улы — яуда үлде,
Үзе исән, һай, бу гомер.
Төпчегенең кызы үсә,
Ул каршыга йөгереп килер.
Тамак кырып алды бабай,
Соңгы үрен күтәрелә.
Үрнең өсте ерак та бит —
Кимеп бара егәр генә...
Өстә анда — егәрлеләр
Күкне кисә телем-телем.
Тимер куәт алды кеше
Эшли кулы, эшли теле.

II

Батыр эшли, куркак эшли;
Дөрес эшме, ялгыш эшме? —
Күрә кеше, уйлый кеше,
Яза кеше, эшли кеше...
...Сукгылар — егылды кеше,
Әллә барга, әллә юкка?
...Аттылар — коелды кошлар
Җилфердәшеп кулъяулыктай.
...Кистеләр — егылды урман,
Өнсез калып, тузып ята.

...Тимер куәт кырлар аша
Кара чокыр сузып ята. —
Ак көннәргә каберме бу?
Хәтта кояш кысылып куя.
Ә чокырдан тарих чыга,
Җилкәсеннән балчык коела,
Таш коела,
Ватык-сынык
сөяк коела, һәм ком коела.
Еллар коела,
Елтыр-елтыр
чорлар коела, алтын коела.
Коела бирсен — миңа нәрсә?!
Һәм бабайга нигә алтын?

Алтын аның дилбегәсе,
Алтын аның җиккән аты.
Менеп барган үре алтын,
Юлы алтын арасында...
Сары алтын — сагышлары,
Борчулары — сары сыман,
Һәм кызара тора сыман,
Кыза, монарлана сыман —
Күгең каплап янар сыман.
...Иран нишләр?
Кытай даулы...
Кайчан тынар бу гаугалар?
...Кызы якын булу яхшы,
Бик ерак шул кече малай.
Карт күрмәгән бәхет булып
Малайның да улы үсә.
Әгәр җитсә барыр иде,
Китәр иде — арба түзсә.

Җилкән булсын, бабай, дугаң!
Кызыңача — арбаң түзәр.
Аннан ары... Таныш хәлләр:
Сулар ага.
Яфрак йөзә.
Кер чайкыйлар.
...Иске эзне
Яңа юллар ямап бара.
Сикерә куян. Болан уза.
Ватыла заман арбалары.
...Муллык өчен дага булып
Эленә салават күпере.
...Басып тора буш чиркәүләр,
Җирдә ята шәүләләре.
..Михрабында җил йөргәнне
Буш мәчетләр сизеп тора...
Борынгылар ял итәләр,
Бүгенгеләр тормыш кора:
Фикер йөртә, исбат итә.
Талантлылар, даһилар бар.
...Колбага кайгысын салып
Бәхет ясый акыллылар.
...Тиләләр — йөри шаулашып
Бер якында, бер еракта.
Сүгәләр алар вакытны
Йодрык селкеп, туктап-туктап.
Вакыт — мәшгуль, аңлый алмый,
Сүгенүләрне тыңлый алмый.
Көчле вакыт гомерләрне
Дахауларга кертеп ялгый. —
Карт аларны күреп кайтты,
Янып кайтты — исән калды.
Илтә вакыт —
Түзәр булсаң,
Йолдызларга гомереңилтә.
...Тимер куәт су йөрәген
Җиңел генә ярып үтә.
...Яр буенда авыл карты
Чәчәк карый тып-тын гына

Үрелергә кыймый тора
Ак шомыртлар толымына.
Бер тармагы ялгыз икән,
Алсын мәллә шуны гына?
Шуны гына алсын микән
Кызына һәм оныгына?
Бер-бер киңәш көткән сыман,
Күтәрелеп карый күккә...

Әй, бабакай! Киңәшчеләр —
Күк астында яши күптән.

III

Күк астында
Шомырт үсә.
Яхшы теләк
Бөреләнә.
Күк астында
Шыбыр-шыбыр
Яңгыр ява
Бөреләргә.
...Күк астында
Кош оясы,
Оясында —
Йомыркасы:
Җиргә охшаш,
Түгәрәк тә...
Бер карасаң,
Үзгәрәк тә.
Биш карасаң,
Ун карасаң —
Мең карасаң —
Ни диярсең?
Күк астында —
Семафорлар:
Әле кызыл,
Әле яшел.
...Такси чаба,
Атлы чаба.
Поезд чаба
Максатына.
Киштәләргә
Ипи тула.
Банкларга
Акча тула.
...Ит сатыла,
Сөт сатыла.
Ир сатыла.
Ил сатыла.
Төяп-төяп
Кеше ялга...
Яуларга да озатыла.
Тимер куәт күрше илнең
Күзен ала, йөзен ерта;
Бакчаларын, балаларын,
Шәһәрләрен кабып йота.
Туфрак кала.

Яңа язда —
Чирәм чыга,— йортлар арта.
Яңа йортта — яңа тормыш
Кабынып китә —
Утлар арта.
...Чаллы балкый.
Яңгырый БАМ.
...БМО эше гүләп тора.
Төтен чыга сигареттан,
Һәр кыйтгага ис тарала —
Төтен чыга сигареттан,
Йөзә кушылып сүз һәм төтен.
Милләт хәлен күтәрәләр,
Хәл кылырдан зуррак итеп,
Яр буенда авыл карты —
Чәчәк карый тып-тын гына.
Үрелергә кыймый тора
Ак шомыртлар толымына.
Бер тармагы ялгыз икән,
Өзсен мәллә шуны гына?
Шуны гына алсын, әйдә,
Кызына һәм оныгына...
...Төтен чыга сигареттан.
Йөзә кушылып сүз һәм төтен.
Илләр хәлен сөйләшәләр,
Мәгълүматлы хәзер һәркем.

## IV

Ил башлары — сөйләшәләр.
Зур эшләрен дөнья күрә.
Дөнья — картта, карт — дөньяда,
Ул да эшли, ул да күрә,
Мин дә күрәм...

Батыр эшли, куркак эшли.
Кычкыралар эшкә өндәп:
«Коткарырга!»
«Үтерергә!»
«Катырак бу!»
Тагы өндәү...
...Үбешәләр.
Җир әйләнә.
Сулгып-сулгып елый кемдер.
Йөзен каплап гасырларга
Ничә гасыр елый кемдер,
Бәлки, ул — үлемсез карчык —
Кешелекнең әнкәседер?—
Карт шуларны уйлый әле,
Онытып атын, дилбегәсен...
Исәнләшеп аның белән
Калды казлар гаиләсе.
Чишмә тавышын тыңлап калды
Сабын кебек сары бура.
Коймак тәме йөзеп чыкты
Яңа авыл урамына.

Кәтәләрдер, өйдәләрдер,—
Карт киләсен сизгәннәрдер.
Кыз якын да...
Кече малай —
Никтер сирәк яза хәзер.
...Газетларда төрле хәлләр,
Телдә йөри төрле хәбәр...
Җилкән икән, бабай, дугаң,
Атың — дугаңа бәрабәр!

## V

Төшә бабай арбасыннан,
Кызы суга чыгып килә.
Койрык болгап көчек килә,
Аваз салып онык килә:
«Бабай килгән!»
...Әйе, килгән,
Ун чакрым ара юлдан.
Оныгына бирер өчен
Чәчәге дә юк кулында.
Бу хәл аңа бик кыен да,
Бик кыен да түгел бугай.
Кызы исән, авыл яшел;
Бакчаларга чәчәк тулган.
Чү, арбада байлык бар ич,
Тәенчеге — хәтта җылы:
Җылы, эре бәрәңгеләр —
Куян күчтәнәче булыр.
Һәм күтәрә карт оныгын,
Оныгы ла, үскән ничек!

Йортка, җиргә хуҗа сыман,
Өрә алтын-сары көчек.

*1979—80.*

## Туфан Миңнуллин

# ХӘСӘН ВӘГЫЙЗОВИЧ

ПОВЕСТЬ

### 1



Унөченче июль 1980 ел.
Көндәлегемне дәвам итәм.
Ниһаять!..
Ниһаять, килде мин көткән көн!
Менә ул! Кулымда — диплом!
Мин — Хәсән Вәгыйзович Иштирәков — фәннәр кандидаты, галим дип аталырга хакым бар.

Программа-минимум үтәлде.

Әлбәттә, алда фәннәр докторы, фәннәр академиясенең член-корреспонденты, академик дип аталган дәрәҗәле исемнәр бар. Ләкин алар киләчәк — программа-максимум. Һичшиксез, мин ул исемнәрнең хуҗасы булырга омтылачакмын. Булдыра алырмынмы, көчем, гомерем җитәрме, билгеле түгел. Әмма омтылачакмын.

Әлегә ял итеп алырга кирәк. Арыдым. Нык арыдым. Ничә ел инде бер генә көн дә онытылып, таралып ял иткәнем юк. Кайвакытларда кемнәрнеңдер күңелен күрер өчен, файдалары тимәсә дә зарарлары тимәсен, дип мәҗлесләрдә утыргалаганым булды, тик һичкайчан да контрольне югалтмадым. Һәрвакыт аек булдым. Мәҗлес халкы дөньясына төкереп күңел ачканда, җырлашып-биешкәндә, тозсыз мәзәкләр сөйләшеп кешнәп көлгәндә мин диссертациям турында уйлап утыра идем, киләчәккә план сыза идем.

Кандидатлык диссертациясен яклаган көнне, традиция таләп иткәнчә, ресторанда мәҗлес үткәрдем. Минем хисаптан ашаган ризыкларын, эчкән аракыларын аклар өчен мине мактап, күккә чөеп тостлар әйттеләр. Сүзләрен колагым тыңласа да, күңелем ишетмәде. Уемда язылачак докторлык диссертациясе иде. Чөнки кандидат булу — максатыма ирешүнең яртысы гына. Миңа ярты юлда тукталып калырга ярамый. Бу хакта мин һәр минут, һәр секунд уйлап торырга тиеш. Тиеш кенә түгел, мәҗбүр. Минем характерымның асылы — үземне мәҗбүр итә белү.

Соңыннан, мәҗлес таралгач, гайбәт ятучылар: Иштирәков банкет вакытында эченнән генә банкетка күпме акча тотылганын санап кайгырып утырды, шуңа күрә уйчан иде, дип сөйләгәннәр. Сөйләсеннәр, алар пычагым да белми. Күпләр мине саран дип уйлыйлар. Җае туры килгәндә ул хакта төрттергәләп тә куялар. Ләкин кешеләр өчен минем күңел сандыгым бикле. Актарынып мәташмасыннар, алар анда ниләр яшерелгәнлеген белмиләр һәм белмәячәкләр дә.

Акчаның ни икәнлеген бик яхшы аңлыйм мин. Чөнки мин аны хәләл көчем белән эшләп табам. Миңа бабайлардан, этидән зур мирас калмады. Урлашмадым. Читтән бер генә тиен дә кергәне юк. Кайчандыр, кемнәргәдер ияреп, өч сумга лотерея билетлары алган идем. Җиңел генә баемакчы булганмындыр. Отмадым. Үз гомеремдә беренче тапкыр һәм соңгы тапкыр мәгънәсез эш белән шөгыльләнүемнең истәлеге итеп ул билетларны һаман да саклыйм. Ләкин мин саран түгел. Мин беркайчан да акчаны дөньядагы иң бөек көчкә тиңләп, аңа табынмаячакмын, аның мескен колына әйләнмәячәкмен, һәр тиен өчен калтырап яшәмәячәкмен. Алтынны мин бакырдан аера белмим һәм шуның белән үземне бәхетле саныйм. Акча минем өчен... Кыскасы, әгәр тамагымны ач итмичә, өстемне дә бөтен итсәләр, нинди генә эш башкарсам да хезмәт хакы урынына акча сорамас идем.

Акча җыймасам да, аны юкка-барга туздырмыйм, саклап тотам. Булганын бүген туздырып бетерсәм, иртәгә кемнәндер бурычка сорарга мәҗбүрмен — тамак дип аталган бәләкәй генә комсыз нәрсә үзенекен таләп итәчәк.

Аракы эчмим. Эчмәвемнең сәбәбе аракының сәламәтлеккә зарарлы булуыннан гына да түгел. Вакытны әрәм итәсем килми. Вакыт — минем өчен иң кадерле, иң кыйммәтле нәрсә. Вакытны тәүлек, сәгатьләргә бүлеп карамыйм, минутлар, хәтта секундларны да эшкә җигәргә омтылам.

Дусларым юк. Дуслары юк кешеләрне ни өчендер бәхетсез кешегә саныйлар. Мин, киресенчә, дуслары күп кешедән дә бәхетсез кеше юктыр дип уйлыйм. Беренчедән, дусларның күңелен күрергә, алар белән еш аралашырга, кайсысының кайгысын, кайсысының шатлыгын уртаклашып торырга кирәк. Димәк, күпме вакыт бушка уза. Икенчедән, син бәйсезлегеңне, ирегеңне югалтып, мәгълүм бер рамкада яшәргә мәҗбүр буласың. Дусларың үз фикерләрен, үз гадәтләрен, үзләренә генә хас яшәеш формаларын сиңа көчләп тагалар. Янәсе, син дусларың өчен үзеңне корбан итәргә тиеш. Ни өчен? Минем корбан тәкәсе буласым килми — суеп ашауларын теләмим. Минем өчен үзләрен корбан итәргә җыенучылар да миңа кирәкми. Корбан чалыш — мәҗүсиләр йоласы. Без — цивилизация заманында яшибез. Салкын акыл, төгәл логика, аек фикер заманы. Тагын шунысы да бар: дуслар бер берсенең данга, шөһрәткә ирешкәнен җеннәре сөйми, көнләшәләр һәм нәтиҗәдә талашып, дошманлашып бетәләр. Ә дошманлыкның нәрсә икәнен беләм мин. Дошманнарны үз юлымда бик күп очраттым, дошманлыкны үз җилкәмдә татыдым. Юк, кирәкми. Дуслардан да, дошманнардан да алла сакласын. Шулай да, беркемне дә сөймәсәм дә, кирәк чагында кунак-кунак уйнашкан әшнәләрем җитәрлек санда күп була.

Ә үзем өйләнмәгән, ялгыз егетмен. Кырык биш яшемә җитеп, официаль күрешүләрне исәпләмәгәндә, хатын-кыз кулы тотып карамаган буйдак. Төс-кыяфәтем, буем-сыным белән хатын-кызлар күзе төшмәслек зат түгелмендер, кулга ияләштерергә йөрүчеләр дә булгандыр. Ләкин хатын-кызларга минем күңелем мәңгегә бикләнгән. Кемнең дә булса ачкыч ярата алуына ышанмыйм. Аларга карата нәфрәттән бүтән хисем юк. Әлбәттә, мәхәббәт дигән нәрсәнең барлыгына инанам. Аны кайчандыр үз башымнан кичерергә туры килде. Тик мәхәббәт адәм баласына бәхет китерә диючеләрне ялганчылар дип саныйм. Мәхәббәт адәм баласына бәхет китерми, мәхәббәт тозагына эләккән кеше — мәңгелек тоткын.

Мин беләм, мәхәббәттән башка гына ганлә корып яшәүчеләрне беләм. Кеше алдында култыклашып йөргән булалар, җаным-бәгърем диешәләр, берсенә-берсе елмаеп карашкан итәләр, ә күзләрендә буш-

лык, күңелләрендә боз. Ире, сиздермәскә маташкан булып, кача-поса, өркә-курка сөяркәләре артыннан сөйрәлә, хатыны теләсә кайсы ирнең кочагына аварга әзер. Мин — ир кеше, сәламәт кеше, ир кешегә хас теләкләр миндә дә бар. «Ирен яраткан» берәр хатын белән төн үткәрүе дә бәлки гөнаһ булмас иде. Һәм мин ул гөнаһтан курыкмыйм да. Әмма, беренчедән, вакытымны кызганам, икенчедән, әйтүемчә, хатын-кызны күралмыйм. Мин санга суккан бер генә хатын-кыз бар дөньяда — ул да булса мине тудырган хатын — мәрхүмә әнием. Аңардан йөз чөермәсәм дә, яратмадым. Әйе, парадокс булып яңгыраса яңгырасын, әниемне, мин хатын-кыз булганы өчен, мине өзелеп ятканы өчен яратмадым. Минем өчен үземнән дә әйбәтрәк, якынрак кеше булуы мөмкинме? Миндәйләрне ялгышмасам, эгоист диләр. Көчлеләрдән көнләшүче мескен бәндәләр уйлап чыгарган мәгънәсез сүз ул — эгоист.



Көндәлегемнең бу өлеше әлегә чаклы язылганнарына ошамаячак. Мин элек фактларны гына теркәп бардым. Теге яки бу вакыйгага, кешеләргә карата фикерләрем дә теркәлгән. Бу юлы мин үземә үзем характеристика язам. Бүгенге көнгә чаклы үзем турында уйланырга буш ара табылмагандыр, бүген уйланырга вакыт бар. Киләчәккә бару юлындагы беренче киртәне уңышлы сикереп үттем, алдагы киртәләргә ыргылыр алдыннан пауза ясап алырга үземә рөхсәт бирдем.

Миңа характеристикалар күп язылган, һәм, мөгаен, тагын күп таптырлар язылыр. Аларда мине бюрократизм кагыйдәләренә туры китереп тәти егет итеп сурәтләгәннәр һәм сурәтләячәкләр.

Гамьсез куллар белән механик рәвештә язылган һәм язылачак мондый характеристикалар архивларда сакланыр, һәм минем бәямне шул характеристикалар буенча бәяләп ялгышырлар. Монысын — үз кулым белән язганын — укучы табалмас. Әгәр көндәлегем үзем үлгәч кемнәрнеңдер кулларына эләксә, андагы шушы юлларны укысалар, бәлки язылганнарга ышанмаслар да. Фантазия җимеше, әдәби әсәргә тартым бер әйбер дип карарлар. Хәер, бу очракта кемнең ничек каравы мине аз гына да кызыксындырмый. Үзем турында, үзем өчен язам, шуңа күрә алдашуны кирәк дип санамыйм, ничек уйлыйм — шулай язам.

Әйе!

Ниһаять!..

Ниһаять, мин — фәннәр кандидаты!

Кемнәрдер өчен фәннәр кандидаты зур дәрәҗә түгел. Алар хәзер күп. Ләкин үзе ирешкәнгә кем ничек карый бит. Фәннәр кандидаты булуны мин үзем өчен олы дәрәҗә дип саныйм. Әйткәнемчә, беренче киртәне сикереп уздым. Спортта һәм, билгеле, тормышта беренче киртәне сикереп үтүе читен. Беренче психологик барьерны узганнан соң мин инде киләчәкләренә әзер!! Тренировканы гына туктатмаска кирәк. Тренировка! Тренировка! Көн саен, сәгать саен, минут саен, секунд саен...

Ничек итеп ирештем соң әле мин бүгенге дәрәҗәгә? Гап-гади авыл малае идем, югыйсә... .

Кайберәүләргә дан, шөһрәт, дәрәҗә үзеннән үзе килә. Дәрәҗәгә ирешкәннәрен алар үзләре дә сизми калалар. Болар — талантлар, тумыштан сәләтле кешеләр. Аларга әллә ни тырышырга да кирәкми. Әмма мондый вундеркиндларның шактые табигать бүләк иткән бәхетне дөрес файдалана белми, өсләренә ауган данны, мәртәбәне күтәрә алмыйча харап булып куйгалыйлар. Андыйлар, психологик әзерлекләре булмау сәбәпле, шөһрәтне, дәрәҗәне авыр кабул итәләр, язмышлары да фаҗигале тәмамлана. Бер ишләре, масаеп, борын чөеп, ходай биргәнгә ышанып кына яши бирәләр. Алар бер урында таптанган арада сәләтләре уртача булган тырыш адәм балалары өскә үрмәли. Инде

олыгая башлаган вундеркинд бу хәлне күрә, тик сәбәбен аңлый алмый интегә, бәргәләнә, өзгәләнә һәм күп очракта эчүгә сабышып юкка чыга. Кинәт ялтырап алып сүнгән мондый йолдызларны күпләр гаеп-ләп сөйлиләр. Ләкин, минем карашымча, фаҗиганең сәбәбен тирәнрәк эзләргә кирәктер. Моңа безнең әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез гаепле түгел микән? Алар безне сабый чагыбыздан ук авырлыкларга, кыенлыкларга каршы торырга, түзәргә өйрәтәләр, ә көтелмәгән зур шатлык килгәндә нишләргә икәнен өйрәтергә онытталар. Дөресрәге, ничек өйрәтергә белмиләр. Үзләре дә бит алар түзәргә генә өйрәнгән халык. Борын-борыннан шулай килгән, күнегелгән, инстинктка әйләнгән.

Кеше, олы хәсрәткә әзер булган кебек, зур шатлыкка да әзер булырга тиештер. Бәләкәй вакыттан ук әзер булырга тиештер. Мин, мәсәлән, аңа әзер идем. Кем өйрәткәндер, белмим, әзер идем. Үземнең дәрәҗәле кеше булачагымны бәләкәй чагымда ук сизә идем. Шулай тиеш дип саный идем. Нинди дер уңышка ирешсәм, очынып шатланмадым. Әле дә хәтеремдә, беренче класска укырга кергәч, өйгә «отлично» алып кайтым. Әни нишләргә белмәде, үпте, кочаклады, җылады. Минем исем дә китмәде, аның шулай кыланганына ачуым гына килде. Искитәрлек ни бар? «Отлично» икән «отлично». Шулай кирәк, шулай тиеш. «Отлично» да алмагач нигә укып йөрергә? Әйе, уңышларыма сөенмәдем, уңышсызлыкларыма гына көенеп яшәдем мин. Ләкин уңышсызлык килсә, югалып калмадым, кайгыларга баш имәдем, сыгылып төшмәдем. Кыскасы, дөньядагы бар нәрсәне дә коры факт булarak кына кабул итәргә өйрәндем.

Характеристикаларда кешенең коллективта үзен ничек тотуы турында язалар. Коллектив — ул кешеләр. Кешеләр арасында кем соң мин? Минем кешеләргә мөнәсәбәтем ничек?

Кешеләр дә минем өчен фактлар гына. Гап-гади объектлар. Алар миңа тимәсәләр, тимим, әгәр инде яшәвемә комачаулый башласалар, рәнҗетсәләр, уны белән җавап бирергә әзер. Кешеләр белән мин янәшә тыныч яшәү политикасы гына алып барам. Аларның эчкерсез ярдәменә ышанмыйм. Минем өчен беркем бернәрсә эшли алмый, барысы да үземнең тырышлыгымнан гына килә.

Әни миңа: «Эшең уңайга бармаса, кешеләргә сыен, кешеләр ышыгында яшәве җиңел була», — дип өйрәтә иде.

Ул беркатлы хатын иде, тормышны начар белгән, күрәсең. Минем юлымда сыенырлык кешеләр очрамады. Үз-үземне белә башлаганнан бирле, кешеләр мине рәнҗеттеләр генә. Олыгайгач, билгеле, рәнҗеттермәдем.

Ә сабый чагымда...

Үсмер чагымда...

Юк, сагынып искә алырлык бер генә кеше дә юк.

Туган авылга багышлап җырлар чыгаралар, шигырьләр язалар. Мин авылымны, аның кешеләрен яратмыйм. Авылдан киткән чакта мин аның урамына төкереп чыгып киттем. Бүтән әйләнеп кайтмаска дип киттем. Кайтсам да мине сабый чагымда, үсмер чагымда рәнҗеткәннәрдән үч алырга гына кайтачакмын дип киттем.

Мине кыерсытучылар, миннән мыскыллап көлүчеләр исән-сау яшәп ятасызмы әле сез?! Мин исән. Бәлки сез мине юкка чыкты, бетте бу, дип сөенәсездер, куанычыгыз кара эчегезгә сыймыйдыр. Юк, мин үземнең югалмаячагымны сез мине рәнҗеткәндә үк белә идем. Чулак Сәлимҗан каеш чыбыркы белән аркама сыдырганда: «Кыйна әйдә, кыйна, минем көн килер, ул вакытта кем кемне суктырыр икән», — дип, тешемне кысып түзә идем. Хәйдәров мине эшемнән куып чыгаргач: «Күрешербез әле, шул вакытта исәпләшербез», — дип пышылдадым. Хәйдәров, билгеле, ул вакытта ни пышылдаганымны ишетмәде.

Менә ишетер көне килеп җитте. Минем мәхәббәтемне аяк астына салып таптаган Әминә бәлки мине онытkандыр. Ә мин берсен дә онытмадым...

Онытмадым. Су кергәндә ыштан балагымны төенләп куйган Әхтәмне дә, үткән-барган саен маңгаема чиерткән Нурисламны, кышкы юлда чанасына утыртмый узып киткән Габдулланы да онытмадым. Барысы да истә. Барысына да үчем бар. Үчемне алачакмын. Ничекме? Белербез. Әлбәттә, каеш чыбыркы белән сыптырмам Сәлимҗанга, маңгаена чиертмәм Нурисламның, чалбар балагын төенләмәм Әхтәмнең. Мин бүтәнчә сыпырырмын, бүтәнчә чиертермен, бүтәнчә төенләрмен.

Кайберәүләр үч алуны кешенең начар сыйфаты диләр. Дөрес түгел! Кирәк үч алырга! Кылган явызлыкларының кайчан да булса бер үч булып кайтачагын белсеннәр кешеләр. Ни чәчсәң, шуны урырсың, дигәннәр борынгылар. Гап-гади, әйтелә-әйтелә таушалып беткән мәкальнең мәгънәсен исләренә төшереп торсыннар адәм балалары.

Чәчтеләр — урыр көннәре җитте. Мин бүген Иштирәков малае гына түгел — Хәсән Вәгыйзович Иштирәков. Минем белән шактый ук дәрәҗәле кешеләр дә кул биреп күрешәләр. Сәламәтлегем турында сорашалар. Элегрәк мин генә сорый идем, хәзер алар да сорыйлар. Метаморфоза! Тормыш законы.

Шушы дәрәҗәгә ирешү өчен күпме көч салганымны үзем генә беләм. Талант түгел мин. Ирешкәнем — тырышлык, үҗәтлек нәтиҗәсе. Олы максат белән яшим, халыкка хезмәт итәм, дип шапырынмыйм. Дөрес, башкарган эшем белән бәлки фәнгә күпмедер файда китерәмдер. Чөнки мин намус белән хезмәт итәм, вакыт уздыру өчен генә йөрмим.

Төп максатым — мине рәнҗеткәннәргә, миннән көлгәннәргә үземнең кем икәнлегемне исбатлап күрсәтү иде. Һәм мин аңа ирештем. Әгәр дә кеше бик теләсә, сәләте чамалы булганда да күп эшләр башкара алуына ышандым, ниһаять.

Этине шундый булган диләр. Теләгәнен эшләми калмый иде дип сөйлиләр.

Колхоз оешкан елларда председатель итмәкче булганнар үзен. Дөресрәге, председатель булырга үзе теләгән. Белеме юк, шыр надан дип, аны куймаганнар. Эти бер ай эчендә укырга-язарга өйрәнгән.

Соңрак, председатель булып эшли башлагач, районда ниндидер бер җыелышта чыгыш ясарга кушканнар этигә. Җыелышта рус телендә сөйләргә кирәк булган. Эти сөйләгәндә залда көлеп утырганнар — русчаны бозып-җимереп сөйләгән ул. Җыелыш беткәч, этидән: «Полевая компанияне» «половой кампание»гә алыштырып шәп әйттең, дип кычкырып көлгәннәр. Этинең ачуы чыккан. Хактырмы, ялгандырмы — һәр кич саен атын җигеп унбиш чакрымдагы Тәмте авылына китә икән. Шунда, имеш, Варвара исемле бер хатынга ияләшкән. Кайвакыт кунып та кала икән. Варвараны яратканга түгел, русча сөйләшеп телен шомартыр өчен шулай эшләгән, янәсе. Күпмедер вакыттан соң районнагы бер җыелышта эти сүз сораган. Залда мәзәк көтеп көләргә әзерләнгәннәр. Тик көткәннәре бушка киткән — минем этием, әйтүләренә караганда, саф рус телендә чартлатып сөйләп, менә дигән чыгыш ясаган.

Этине мин бик начар хәтерлим. Ул сугышка киткәндә миңа алты яшь тә тулмаган иде. Төс-кыяфәтен күз алдына китерергә ничек кенә тырышсам да — этинең тулы портреты тумый. Фотосы юк. Әнинең әйтүенчә, фотога төшәргә яратмаган. Ямьсезлегем, үлгәч, үзем белән китсен, карточкама карап битемә төкерүчеләр булмасын дип әйткән, имеш. Шулай ук, ямьсез булды микәнни минем этием. Ышанасым килми. Ни өчен, алайса, авылдагы чибәрләрнең чибәре — минем әни ямьсез кешегә кияүгә чыккан? Ул серен әни миңа әйтми үлде.

Этинең битләре кытыршы икәнен генә хәтерлим. Шадра булган ул. Әйе, бик шадра булган ул. Ләкин һәр шадра кеше дә ямьсез булмый, лабаса. Хәер, анысы әһәмиятле түгел. Нәрсәгә ул ир кешегә чибәрлек. Ир кешене бизи торган сыйфат — аның характеры. Ул мәсьәләдә эти чын-чынлап ир-егет булгандыр. Миңа әйткән кайбер сүзләре колакта калган: «Нык бул!.. Усал бул!.. Өйгә җылап кайтма!.. Берне суксалар өчне сук!..»

Эти кырык биш яшендә һәлак булган. Минем яшемдә аны фашистлар үтергәннәр. Сугыш барганда мин фашистларны кешеләрдер дип уйламый идем. Үсә төшкәч белдем — алар да кеше затыннан икән. Кешеләр... Ә үзләре кеше үтерәләр. Бу парадоксны мин озак еллар аңлый алмыйча йөрдем. Аңлагач, кешеләргә ышанмыйча, аларга нәфрәт белән карарга өйрәндем.

Әнинең этине сагынып сөйләгәнен дә хәтерләмим мин. Үлгәнен ишеткәч тә еламады шикелле. Авыр сулап, көрсенеп кенә куйды бугай. Гомумән, этине искә алмый иде әни. Яратмаган, күрәсең. Ни өчен? Ул серен дә әни миңа әйтмичә үлде.

Сизенүемчә, авыл кешеләре дә этине өнәп бетермәгәннәр. Юкса, аны искә алырга туры килгәндә исеме белән Вәгыйз диярләр иде. Коры гына итеп Иштирәков димәсләр иде. Миңа да бит Вәгыйз малае димәделәр. Иштирәков малае дия иделәр.

Авылда этине яратмауларының сәбәбе миңа аңлашыла. Ул нык характерлы, көчле кеше булган. Үзенә юл ярып максатына омтылган, үскән, күтәрелгән. Бүтәннәр шикелле бүрәнә өстендә акыл сатып утыруга вакытын әрәм итмәгән. Аның югарыга үрмәләвен күргән авыл халкы, табигый, аңа чит итебрәк караган. Авыл кешеләре шундый бит алар: үз дәрәҗәсендәге бәндәләрне генә кешегә саныйлар, кем дә булса алга чыгарга, узарга җыенса, аның чабуына асылыналар. Алга чыгучы чабуына асылындырмаса, үпкәлиләр, аны дошман күрәләр.

Шулай...

Автохарактеристикага нокта куярга да ярыйдыр. Төнге сәгать унбер туларга ун минут. Төгәл унберда мин ятып йокларга тиеш. Режим. Ул режимны бернинди сәбәп тә үзгәртә алмый.

Чишенергә ике минут. Сигез минут буш вакытым бар. Нишләргә? Дәвам итәргәме? Язылсы язылды кебек.

Характеристакаларда, гадәттә, хезмәткәрләрнең җәмәгать эшләренә мөнәсәбәте языла. Миңа калса, мин алардан баш тартмыйм, теләмичә генә булса да кушканнарын җиренә җиткереп башкарырга тырышам. Үз теләгем белән бер генә җәмәгать эшенә дә алынганым юк. Чөнки кемгәдер ярарга азаплану — куштанлану. Ә куштанлык — булдыксызлар профессиясе. Алар мөһим эш кырган булып җыелыштан җыелышка чабып йөриләр, теләсә кая барып тыкшыналар, шуңардан канәгать булалар. Минем җыелышларда чалбар төбе шомартып, төпсез чиләккә су тутырып утырырга вакытым юк.

Кабатлап әйтәм, вакыт минем өчен иң кадерле нәрсә. Менә әле дә үзем шушы юлларны язам, үзем нигә вакытны мәгънәсезгә сарыф итеп утырам дип уйлыйм. Чыннан да, ниемә бу характеристика? Кемгә кирәк? Кем аны миннән сорады! Язарга тотынганда ни уйладым?

Авылга кайтып килергә җыенуым кулга каләм алырга мәҗбүр итте, күрәсең. Иртәгә иртәнге поезд белән юлга чыгам. Егерме җиде елга беренче тапкыр. Мине кыерсытканнар белән исәп-хисапны өзәр алдыннан үземә күз салып алуымдыр бу. Тик нигә аны язып куярга? Кыланумы? Үземне үзем язмасам да беләм, ләбаса.

Тукта, нишләп әле кирәкмәгән уй башка килеп керде? Язылган икән язылган. Күңелдә, димәк, шуңа мохтаҗлык туган. Дөньяда баш, акыл

гына түгел, күңел, хис диген нәрсә дә бар бит. Рационалист булсам да адәм баласы ла мин, шайтан алгырысы. Мәхәббәттән мәхрүм икәнмен, нәфрәтем бар. Нәфрәт тә мәхәббәт кебек үк хис түгелмени?..

Буталдым, ахрысы. Җитте... Бетте... Сәгать унбер туларга өч минут.

## 2

16 сентябрь 1980 ел.

Көндәлегемне дәвам итәм.

Аны кулыма алмаганга ике ай да өч көн вакыт үткән. Минем кебек төгәл кеше өчен гафу ителмәслек хәл. Ләкин сәбәпләре булды. Шул турыда язарга кирәктер. 16 сентябрь дип куйсам да, моннан ике ай элек булган вакыйгалар турында язам. Ягъни мәсәлән, 14 июльдән башлыйм.

Нәкъ шул вакыттагыча, бүгенге халәтемне катнаштырмыйча, булганнарны төзәтмичә генә язып башкара алырмынмы? Һәрхәлдә тырышып карарга кирәк.

Көн нидән башланган иде соң?

Авылга кайтырга җыенган идем. Иртән юлга чыктым.

Поезддан төшкәндә кояш яңа күтәрелеп килә иде. Тәүлек буе вагонда аунап кайтып арылган. Кызык — ял итәсе урынга арылган. Өйрәнмәгәнлектән, эшсезлектән ул. Гомумән, мин юлда йөрергә яратмыйм. Институтта, аспирантурада укыганда каникул вакытларында беркая да бармадым. Практикага да шәһәрдән ерак китәргә туры килмәде. Эшли башлагач та туристик походлар, төрле сәяхәтләр белән мавыкмадым һәм мавыкмыйм. Йөрсеннәр җилбәзәкләр, күңел ачу алар эше. Җилбәзәкләр — минем дошманнарым. Театрларга да шуның аркасында йөрмим. Укыган чакта бер барган идем, ниндидер тозсыз комедия күрсәттеләр. Шуннан бирле аяк атлаганым булмады. Бигрәк тә ачуны китергәне — минем янда утырган олы яшьтәге ир белән хатынның сәхнәдәге җилбәзәкләрнең кыланышыннан хихылдапмы хихылдаулары. Шаккатарсың бу дөньяда кешенең ахмаклыгына.

Поездда кайтканда өч «сиртмә койрык» белән бер купега туры килдем. Студенткалар. Сөйләшкән сүзләрендә мәгънә юк, туктаусыз шаркылдап көләләр. Купега егетләр ияртеп керәләр, чыркылдыйлар-чыркылдыйлар да аларга ияреп чыгып китәләр.

Төнге унбер җиткәндә чыдамлыгым сынды. Миңа йокларга кирәк, мин абсолют тынлыкта йоклап китәргә күнеккән, ә купеда һаман тавыш, шау-шу.

— Чыгып көлешегез, йокларга комачаулыйсыз,— дидем.

— Ә сез, абый, йокларга ашыкмагыз, безнең янга төшеп утырыгыз, яшәреп китәрсез,— диде «сиртмә койрыклар»ның берсе һәм көлеп җибәрде. Аңа бүтәннәре кушылды.

— Сез үзегезнең кайда икәнлегегезне беләсезме? — дидем.

— Беләбез, абый. Поезд вагонында. Ә сез безгә унтугыз гына яшь икәнлекне беләсезме? Сез дә әллә ни карт түгел, безне аңларга тиешсез.

— Мин бары тик бер генә нәрсәне аңлыйм: сез — сөйрәлчекләр.

— Ничек?..

— Сөйрәлчекләр.

Барысы да кинәт тынып калдылар. Кызларга ияреп кергән озын яллы ике егетнең тазарагы капылт кына утырган җиреннән сикереп торды да мине өске полкадан тартып төшерде.

— Гафу үтенегез хәзер үк,— дип әтәчләнә башлаган иде, әчен тотып бөгелеп төште. Ул минем самбист икәнлегемне белми иде шул, мескен.

Институтта өйрәндем самбо алымнарына. Ярышларда катнашып чемпион булыр өчен түгел, кирәге чыкканда кайберәүләрне акылга утырту өчен. Кирәге чыккалый тора. Шуңа күрә көнегүләр ясаудан һаман да туктамыйм.

Селәгәйгә төртеп алганымны беркем дә күрмәде.

— Ни булды? Ни булды? — дип идәндә әчен тотып чүгәләп утыручы янына иелделәр.

Мин урыныма менеп яттым. Озын чәчләрнең икенчесе тавыш куптарырга маташкан иде, аны тынычландырдылар. Чүгәләүчене күтәреп торгыздылар. Ул әчен тоткан килеш миңа күтәрелеп карады да чыгып китте. Аңа иярделәр. Коридорда ниләр сөйләшкәннәрдер, белмим. Йокы вакыты җиткән иде, күзләремне йомдым.

Иртән торганда купеда үзем генә идем...

Район үзәгенә станциядән автобус йөри башлаган икән. Әле килеп җитмәгән.

Автобус көткәндә яныма бер карт килде.

— Карап-карап торам да таныган да сыман итәм. Син безнең авылның Иштирәков малае түгелме? — ди.

Сөйләшәсем килми иде:

— Юк, — дидем.

Әйе, дисәң, төпченергә, сорашырга тотыначак. Авыл картларының гадәте шундый.

Карт барыбер янымнан китмәде.

— Бик нык ошагансың, коеп куйган Иштирәков. Сугышка хәтле ул безнең председатель иде. Каты бәгырьле кеше иде, бер гаепсезгә мине төрмәгә утыртып куйды, — дип такылдады.

Йөзенә күтәрелебрәк карадым. Таныш түгел. Хәтер яхшы минем. Димәк, моны күргәнем юк.

— Кайтып барам әле авылга,— дип дәвам итте сүзен карт,— кунакка. Туганнар юк-югын да, Сәлимҗан кордаш чакыртып язган. Сагындыра туган як. Кырык өч ел авылдан киткәнгә. Сугыштан соң бер урап киткән идем, шуннан бирле кайтырга туры килмәде. Бер аерылгач шулай инде, чит җиргә дә ияләшәсең, тамыр җибәрәсең. Менә сине күргәч авылдан чыгып киткән чак искә төште. Бер уйласаң, көлке генә нәрсә өчен бит. Сәлиҗан кордаш белән ат җигеп шушы станциягә килгән идек, вокзал эченә кердек. Бер исерек адәм вокзал эскәмиясенә сузылып яткан да җырлап ята. Урысча җырлый, әллә ничек кызык итеп җырлый. Безнең урысча бик чамалы инде, җырның мәгънәсен дә белеп бетермибез. Шулай да кызык. Отып алдык бит без бу җырны. Юл буе Сәлимҗан белән урысча җырлап кайттык. Утыздан узган кешеләр үзебез, бала-чага шикелле әйттерәбез. Авылга кайткач та җырлап йөрдек. Иштирәков ишетеп алды да... җырның мәгънәсен төшендерде. Мин хурлыгымнан авылдан качтым. Семьяны үз яныма алдырдым. Шуннан сугыш башланды.

Карт сүзеннән туктады да Иштирәков малае булмавыма шикләнгән сыман миңа чекрәеп карап торды.

— Ошаган, нык ошаган... Болай үчем юк минем Иштирәковка. Бер күреп сөйләшәсем килгән иде дә, сугыштан кайтмаган булып чыкты. Авыр туфрагы җиңел булсын. Карчыгы да үлгән икән инде. Заманында авылыбызның күрке иде, бөтен егетләр аңа гашыйк иде. Ә ул Иштирәковны сайлады. Кем белә, бәлкем, ул сайламагандыр, Иштирәков үзе сайлагандыр. Үена килгәнне эшләми калмый иде. Көчле адәм иде.

Картның лыгырдавы туйдыра башлады, читкәрәк китеп бастым. Карт таныш-белешләр эзләп автобус көтүчеләр тирәсендә кайнашты.

Бәлки миңа аны тыңлап бетерергә, үземнең Иштирәков малае икәнлегемне яшермәскә кирәк булгандыр? Әти турында мин ишетмә-

гән, белмәгән мәгълүматлар әйтер иде... Ә нигә ул мәгълүматлар миңа? Аларны белүдән миңа ни файда да ни зыян? Әти юк. Юк ул. Юк кеше турында уйлап нигә баш ватарга? Минем башыма болай да эш җитәрлек.

Автобус күренми. Җәяүләп — ерак, район үзәгенә чаклы егерме өч чакрым диләр иде, хәзер дә кыскармагандыр.

Бер урында таптанып тору да алҗытты. Вакыт үтә. Мәгънәсезгә үтә.

Мәгънәсезгә?.. Чынлап та, нигә дип әле кайтып барам? Шәлперәйгән картның туган авылына ашкынуы аңлашыла — сагынган. Мин сагынып түгел бит. Мин бары тик үземне рәнҗеткәннәрне, мыскыл иткәннәрне күрергә, алардан үч алырга гына кайтам.

Үч?.. Ничек итеп алырмын икән мин ул үчне? Алдан әзерләнгән планым да юк. Үчем барын беләм, ничек итеп ул үчне кайтарырга икәнен генә белмим.

Бәлки вакланамдыр? Дәрәҗәле башым белән вак-төяк халыктан үч алып йөрү килешеп үк бетмидер? Яшәсеннәр, казынсыннар тиреслекләрендә...

Юк!.. Юк!.. Миңа мондый уйларга бирелергә ярамый. Мин гомерем буе үземне шушы көнгә әзерләдем. Әзерләнгәнмен икән, нокта куймыйча туктау үзе үк ваклык, пешмәгәнлек. Мин — биолог. Биолог өчен табигатьтә вак, эре дигән төшенчәләр булмаска тиеш. Эре кит вак планктоннар белән туклана. Планктоннар булмаса, кит үлә. Эре җанвар — аю, вак бөҗәкләр — кырмыскаларны ашый. Әгәр шул ук аюны кырмыска оясы янындагы агачка бәйләп куйсаң, кырмыскалар аны кимерәчәкләр. Кешене, әлбәттә, җанварлар белән чагыштырып карарга ярамый, дибез. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр башка, дибез. Әмма ни генә булса да, ул табигать баласы, биологик объект. Хайваннардагы инстинктлар кешедә дә яши. Һәм кеше, акылы булуына карамастан, шул инстинктларның колы, дип исбатлаучы галимнәр дә бар. Алар нигә ялгышырга тиеш тә, нигә без генә дөресен сөйләргә тиеш? Бәлки алар хаклыдыр? Бәлки кеше үзен бөек җан иясенә санап, үзенең хайванлыгын яшерергә генә маташадыр. Хайваннар яшерми, кеше яшерә — аерма шунда гына. Дөресендә исә, һәр икесе дә бер үк законга — табигать законына буйсынган җан ияләре.

— Хәсән!..

Борылып карадым. Каршыма озын буйлы, ябык, күзлекле бер кеше килә! Таныдым — Сафиуллин! Исемен оныткынмым. Бишенче класстан унны тәмамлаганчы бергә укыган идек. Күрше авылдан безнең мәктәпкә йөреп укыды.

Янýма килеп җиткәч, Сафиуллин:
— Исәнме, Хәсән... Ялгышмыймдыр бит, син ич бу? — диде.
— Әйе, — дидем, — Хәсән Иштирәков.
— Мин — Марат. Марат Сафиуллин. Онытмаган булсаң, бергә укыдык.
— Онытмадым. Исәнмесез.
— Бераз да үзгәрмәгәнсең. Нинди җилләр ташлады? Туган яклар сагындырдымы?

Тагын бер кирәкмәгән очрашу, мәгънәсез, буш сораулар. Ни дип җавап бирим мин бу адәм баласына?
— Сагындырды, — дип ялганлаудан башка чара калмады.
— Кайтып килүме, китеп баруммы?
— Кайтып килү.
— Авылгамы?
— Авылга да...
— Озаккамы?

«Анда синең ни эшең бар? Юлыңда бул», — дип әйтмәкче идем, тыелып калдым. Сөйләшәсем килмәгәнне, очрашудан очынып шатланмаганымны сизми микәнни? Хәтта күрешергә кулымны да сузмадым, нәрсә һаман янымда серәеп тора? Хәер, нидер сизенде бугай, елмаюдан туктады, як-ягына каранып алды — тизрәк минем яннан ычкынырга чамалый, күрәсең.

— Нишләп соң әле без монда басып торабыз, — диде Сафиуллин, — әйдә киттек, кайтабыз. Әнә минем машина.

Шул гына җитмәгән иде. Машинасына утыртып сораша, төпченә башлар. Бергә укыган чакларны искә төшереп, туктаусыз лыгырдар. Миңа боларның берсе дә кирәкми. Берәүнең дә янымда буталуын, сылануын теләмим.

— Рәхмәт, — дидем, — мин автобус белән...

Аның машинасына утырырга җыенмавымны Сафиуллин минем тыйнаклыгым, тарсынуым дип кабул итте, ахрысы.

— Алай булмый инде, Хәсән. Машинада берүзем утырып кайтып, кунакны автобус белән йөртү килешми ул. Автобусы да әле аның ышанычлы түгел, я килә, я юк. Килсә дә утырып буламы? Әйдә, әйдә, киттек.

Яратмыйм бәйләнчекләрне. Алар синең теләгең белән исәпләшмичә җаныңа үрмәлиләр. Мәҗлесләрдә дә шулай, эчмим дип бер әйтәсең, ике әйтәсең, юк — табыла шундый бәйләнчек — рюмкасын күтәреп килә дә баса каршыңа. Үпкәлибез дигән була, безнең хәтерне калдырасың дип, йөзенә кайгылы кыяфәт чыгаргандай итә. Сикереп торып сүгенәсе, чыраена төкерәсе килә башлый. Агу салып бир, анысын да эчәм, тик өстемдә генә торма, дип әйтерлек буласың. Һәм үзеңне эчеп куярга мәҗбүр итәсең.

Сафиуллин да җиңгә үк ябышып өстерәргә тотынгач, машинасына утырмый булдыра алмадым — мәтәлеп китсен.

Әлбәттә, нәкъ көткәндәгечә килеп чыкты. Сорашты, төпченде Сафиуллин: кайда яшим, кем булып эшлим, өйләнгәнме, фәләнме-төгәнме? Кыска-кыска гына җаваплар биреп бардым. Фәннәр кандидаты икәнлегемне белгәч, куангандай итте: — Шәп! — диде.

Аннары үзе турында сөйләргә кереште. Район мәгариф бүлегенең мөдире булып эшли икән. Педагогия институтын тәмамлагач, без укыган мәктәптә тарих укыткан. Аннан директор иткәннәр. Аннан районга алганнар. Мәктәптән китәсе килмәгән, аяк терәп каршы торган. Күндергәннәр. Ләкин һаман да мәктәпне, укытучы булган чакларын сагына икән.

— Ул вакытта мин куйган хезмәтемнең нәтиҗәсен күрә идем. Берәр укучым институтка керсә, яки тарихтан бишле алса, куана идем. Бирелә көне-төне чабарга туры килә, финишка җитеп булмый.

Зарланган кешеләрне мин яратмыйм. Зарланганнарның зарларын тыңламыйм. Мәхлүк җаннарның сукрануы — йогышлы чир. Аның бациллалары күңелгә кереп оялап күңелне йомшарталар, ихтыярны какшаталар — зарланучыга кушылып елап җибәрүең дә ихтимал.

Ләкин бу очракта Сафиуллинның зарлануын рәхәтләнеп тыңладым. Әйе, әллә кая үрмәли алмаган егет. Мәктәпне «отлично»га тәмамлаган иде, югыйсә. Сафиуллиннан бөек кеше чыгар, дип көтәләр иде укытучылар, тирәсендә бөтереләләр иде. Кызлар аңа гашыйк иде. Мин һәрвакыт аның күләгәсендә кала идем. Бишенче класстан алып унынчыны бетергәнче аның артыннан чаптым. Уздырмады. Күзе начар күргәнгә алгы партада утыра иде ул. Алты ел буе мин аның җилкә чокырына карап утырдым. Җилкә чокырындагы чәч бөртекләренә хәтле санап чыктым бугай. Партага иелеп язып утырган чагында сикереп торып муен тамырына сылыйсым килгән минутларым булгалый иде.

Үзен яратмаганлыгымны сизә иде микән Сафиуллин? Сизмәгәндер. Чөнки җай туры килеп мин аны мыскыллап көлгәндә дә: «Дөрес әйтәсең бит, малай, валлаһи, шундый кеше мин»,— дип кушылып көлә иде. Берчак шулай тәнәфес вакытында Сафиуллин кара тактага химиядән формулалар язып, янындагы кызларга индер аңлата. Кызлар аңламыйлар. Шуннан Сафиуллин миңа карады да: «Хәсән, мин арыдым, төшендереп бир әле шул тәре баганаларына», — диде. Кызлар Сафиуллин сүзеннән кызык табып көләргә тотындылар.

«Күзлекле бүкән аңлата алмаганга баганалар гаепле түгел», — дип кулыма акбур алдым. Кызлар көлүдән туктадылар. «Дөрес әйтәсең, валлаһи», — диде дә Сафиуллин көләргә кереште. Кызлар, кырт борылып, класстан чыгып киттеләр. Сафиуллин: «Кызлар, кызлар, туктагыз», — дип аларга иярде. Мин акбур тотып такта янында басып калдым.

Физик яктан Сафиуллиннан көчлерәк идем мин. Әгәр сугышырга туры килгән булса, мин аны изеп ташлый алган булыр идем. Бәхетемә каршы, маңгайга маңгай бәрелешергә җай чыкмады. Бәхеткә каршы дим. Чөнки җай чыкса, язмыш мине икенче сукмактан алып киткән булыр иде. Сафиуллинга бер-ике сугып кына калмаячак идем, имгәткәнче кыйнаячак идем.

Бер тапкыр шул Сафиуллин аркасында чак кына җинаять эшләнмәде.

Чаңгы ярышлары иде. Мәктәп беренчелегенә. Беренче, икенче урыннарны алучылар район ярышларына барачак. Биш чакрымга узышабыз. Күпмедер чапкач, мин өченче урынга чыктым. Беренче булып унынчы «Б»дан Кәримов бара. Аның белән ярышу мәгънәсез. Ул бездән өлкән. Аңа инде егерме ике яшь. Сугыш вакытында укуы бүленеп торган. Укуы начар, чаңгыда шәп йөри. Минем максат аны узу түгел. Минем максат — финишка икенче булып килү. Ләкин икенче булып Сафиуллин чаба. Аяклары озын, мин ике атлыйсыны бер атлый. Авылына ул кыш көннәре чаңгыда йөри, шуңа күрә «тренировка»сы минекеннән күбрәк. Аягында үзе ясаган чаңгылар. Өрәңге агачыннан. Авыр булсалар да шәп шуалар.

Дүрт чакрымнар узгач барыбер Сафиуллинны куып җиттем. Куып җиттем, әмма уза алмыйм — хәлем бетте. Сулыш кысылды, кату чыкты. Сафиуллинның хәле беткәнгә охшамый, нык тирләмәгән дә шикелле — өстеннән пар күтәрелми. Мин шабыр тиргә баткан.

Ара ике метр чамасы. Бөтен көчемне салып алга ыргылырга маташам. Юк, булмый. Артыннан мин килгәнне Сафиуллин сизә. «Калма, Хәсән, Кәримовны узабыз», — дип кычкыра. Үзе көлә.

Мин аның көлүен үземчә аңладым, билгеле. Минем рәт беткәнне белеп мыскыл итә дип уйладым. Бөтен гарьлегем, бар ачуым шунда ташып чыккандыр, шулар көч өстәгәндер — Сафиуллинны куып җитеп ни эшләгәнемне дә белештермичә чаңгы таягын күтәрдем... һәм аягым чалышып китеп аудым.

Ярый әле егылдым. Юкса, кадаган була идем Сафиуллинның аркасына. Чаңгы таягының очы кадаклы иде...

Финишка бармадым. Өйгә кайтып киттем. Төн буе еладым. Ни булды, дип төпченгән, мине юатырга тырышкан әнигә беренче тапкыр җикерендем һәм беренче тапкыр сүгендем.

Икенче көнне Сафиуллин мәктәпнең герое иде. Ул хәтта Кәримовны да узган. Безнең класс кызлары яламыйлар гына Сафиуллинны. Урап алганнар да үзен, чыркылдашалар гына. Сафиуллин күзлеген ялтыратып уртада басып тора, көлә.

«Кәримовны беләсезме мин ничек уздым», — ди.

«Ничек? Ничек?» — диләр кызлар.

«Куып життем дә, Кәримов, безнең класс кызларының берсе сине үлеп ярата, дип кычкырдым. Ярата, сүзен ишеткәч, Кәримовның башы әйләнеп китте, тез буыннары калтырады, ул арада мин выжт тегене...»

Ахмак кызларга шул гына кирәк, сикерешә-сикерешә көләләр, сукыр Сафиуллинны кочаклыйлар.

Әйе, классның, хәтта мәктәпнең дә алласы иде Сафиуллин. Әллә кая китә алмаган. Бәләкәй генә бер районның мәгариф бүлеге мөдире. Кулларыбызга өлгергәнлек аттестаты тапшырганда, Сафиуллинга мактау сүзләре яуганда, эчемнән генә, карарбыз әле, дигән идем, һәм менә «чебешләрне санап» кайтып барам. Сафиуллин зарлана, көлүен, елмаюын оныткан. Әйе, дөнья бу!

Уйларымны сизде, ахрысы, Сафиуллин элеккечә итеп гөрелдәп көлеп җибәрде.

— Зарлана дип уйлама тагын, Хәсән, — диде, — эшләр алай ук начар түгел. Менә әле Бишалаб авылында яңа мәктәп салып ятабыз. Шәп булачак. Колхоз үз акчасына салдыра. Шәһәрдәге мәктәпләрдән ким булмаячак. Җиһазланган кабинетлар белән. Авыл малае шәһәрнекеннән ким мени. Укысын теләсә кайсы университетта. Беләсеңме безнең малайлар нишләде үткән уку елында? Математика буенча республика олимпиадасында беренче урынны эләктерделәр. Бар ул бездә дә көч. Бер Советлар Союзы Героебыз бар, Социалистик Хезмәт Герое икәү, бер шагыйребез тишелеп чыкты — шигырьләрен өлкә газетасында мактап язалар. Болгаер мәктәбен безнең белән бер елны бетергән Исламов — фәннәр докторы, зур химик. Мәскәүдә эшли. Инде менә син. Рәхмәт. Әйдә, тырыш әле, Хәсән, доктор бул, академик бул, без мактанырлык булсын.

Дөнья кызык корылган. Кайчандыр мәктәпнең күрке булган Сафиуллин миңа рәхмәт әйтә, минем белән мактанырга җыена. Әйе, бу юлы мин аның артыннан мышкылдап чабучы түгел. Ул минем каршымда боргаланып-сыргаланып машинасына утыртып кайта. Һәм мине алып кайтканы белән кемнәрдер алдында мактаначак та әле. Телим икән, машинасыннан төшеп тә кала алам. Сафиуллин — мөдир кисәге — миңа ялыначак. Шулай ул дөнья, туганкай. Әнә, сайрый да сайрый. Мин аның сайравын тыңлар-тыңламас кына кайтып барам. Тыңламаска да хакым бар. Мин сезнең мәгънәсез сүзләрегездән ялыктым дисәм дә, Сафиуллин гафу үтенәчәк. Чөнки ул үзен минем янымда бөҗәк кебек хис итә. Бик әйбәт, Хәсән Вәгыйзович Иштирәков моңа каршы түгел...

— Фән белән шөгыльләнү вакытны күп аладыр. Шулай да өйләнергә кирәк, Хәсән... Гомер үтә бит. Нәрсә, күңелгә якын кеше очрамыймы?

Соравын җавапсыз калдыруымны үзенчә аңлап, Сафиуллин мәхәббәт, гаилә, бала-чагалар турында сөйләргә тотынды, дүрт малае, ике кызы булуы белән мактанып алды.

— Кешедән нәсел калырга тиеш, Хәсән. Беренче класска балалар елдан-ел азрак килә. Кеше бары тик үзенең шәхси мәнфәгате хакында гына уйлап, киләчәкне оныта. Табигатьтәге һәр җан иясендә нәсел калдыру инстинкты яши. Кеше шул инстинктка каршы чыга башлады...

Тагын ниләр такылдаган булыр иде Сафиуллин, ярый әле район үзәгенә кайтып җиттек.

— Туктатыгыз шунда, — дидем.

— Авылгадыр бит? Илтеп куям.

— Кирәкми, рәхмәт, шунда төшәм.

Сафиуллин машинасын туктатты. Машинасыннан чыгып минем яктан ишекне ачты.

— Илтеп куя идем, югыйсә. Эшләр бармыни? Карале, Хәсән, очрашыйк әле бүген, сөйләшеп утырыйк әле.

— Сөйләшеп утырырлык вакытым юк, — дидем дә акча калтасыннан биш сумлык чыгарып Сафиуллинга суздым.

— Нәрсә ул? — дип көлеп куйды Сафиуллин.

— Утырып кайткан өчен.

— Син нәрсә, Хәсән?

— Алыгыз, такси бәясе.

Сафиуллин югалып калды. Мин кулына тоттырган бишлеккә карап торды. Ул мыскыл итәләр дип уйлады, әлбәттә. Чөнки болай эшләү чыннан да үзенә күрә мыскыл итү. Мондый алым белән мыскыл итүне язучылар үзләренең әсәрләрендә дә күп яздылар. Әмма мин Сафиуллинны мыскыл итәргә уйламаган идем. Дөресрәге, алдан әзерләнмәгән идем. Үзеннән үзе килеп чыкты. Мин кешеләр белән исәп-хисапны өзеп яшәргә күнеккән. Бу — минем принцип. Өч тиенлек яхшылык эшләгән кешеләр соңыннан биш тиенлек файда өмет итмәсеннәр. Ара өзек булганда мөнәсәбәтләр ачык. Әлеге очракта да шулай. Сафиуллин машинасының спидометры станциядән район үзәгенә чаклы араны егерме дүрт километр итеп күрсәтте. Такси белән килгән булсам, нәкъ биш сум түләгән булыр идем. Таксист мин биргән акчага нәрсә ул дип аптырап карап тормас иде. Әзрәк булмадымы дип әйтүе бик ихтимал. Әйе, утырып килгәнмен икән, мин түләргә мәҗбүр.

— Болай килешми, — диде Сафиуллин мескеннәрчә елмаеп.

— Ничек килешә?

— Ничек инде?..

— Сезгә нәрсә, акча кирәкмиме? Кирәкмәсә, ертып ташлагыз.

Китеп бардым. Сафиуллин миңа тагылды. Нәрсәдер лепелди. Кисәк кенә борылдым да:

— Калдырыгыз мине! — дидем.

Бүтән борылып карамадым.

3

17 сентябрь 1980 ел.

Көндәлегемне дәвам итәм.

Әйе, мин Сафиуллинга борылып карамадым. Миңа Хәйдәровны эзләп табарга кирәк иде. Аның кайда яшәгәнен белә идем мин. Юк, онытылмый ул урам, онытылмый ул йорт. Зәңгәргә буялган биек коймалы, имән баганалы урыс капкалы өйдә яши иде ул. Үлмәгән булса, хәзер дә шундадыр. Хәйдәров кебек типлар күчеп йөрергә яратмыйлар. Алар бер урында мәңгелеккә төпләнәләр. Фикер йөртүләре катып калган, миләре мүкләнгән бәндәләрне фикерләреннән дә, урыннарыннан да кузгатуы авыр. Алардан бары тик пенсиягә озатып, яки алып ыргытып кына котылырга мөмкин. Әмма аларның эшләрендә алып ыргытырлык сәбәпләр табуы читен. Алар төгәл булалар, педант булалар. Аларның башлары эшләмәсә дә, үз-үзләрен саклау, куркыныч янаганны сизү инстинкты көчле була.

Хәйдәров белән мин унынчыны тәмамлаган елда очраштым. Сафиуллин институтка укырга китте. Минем дә теләк зур иде, ләкин әни аркасында калдым. Чирле иде ул, җиде-сигез ел инде туктаусыз чирли иде. Казанга китәргә җыенып йөрүемне күргәч:

«Ташлап китмә, беразга түз», — диде.

«Түз дип... Син гел чирлисең ич, синең терелгәнеңне көтсәң», — дидем.

«Озак калмагандыр», — диде әни.

«Минем укыйсым килә».

Әни бу юлы дәшмәде. Күтәрелеп йөземә карады да көрсенеп куйды. Мин белә идем, миңа сүз таба алмаганда шулай итә иде ул. Нишлисең, калырга туры килде.

Эш эзләргә кирәк иде. Колхозда эшләү турында уйлап та карамадым. Колхоз минем өчен түгел иде. Колхозда эшләп кот кунган кеше күрмәдем мин ул вакытта. Чәчүлек күтәреп ташыганда әнинең салкын тидереп чирләшкә булып калуын гына белдем.

Район үзәгенә бардым. Авылга ул якын, өч кенә чакрым. Анда да рәтле-башлы эш юк. Утырып эшли торган урыннарның берсе дә буш түгел. Чабып йөрергә минем дә исәп юк.

Кибеткә икмәк алырга дип кергән идем, татар теле укытучысын очраттым.

«Син кирәк идең, Иштирәков, ди, район газетасына җаваплы секретарь эзлиләр икән. Синең укучыларың арасында юкмы дип сорадылар. Мин сине тәкъдим иттем, син укырга китәргә уйламыйсың бугай».

«Уйлыйм да, әни чирле».

«Алайса, бар редакциягә. Фәхретдинова апа җибәрде диген. Тик кара аны, Иштирәков, холкың синең әйбәт түгел. Дорфалыгыңны, тупаслыгыңны, кирелегеңне бетер. Тырышлыгың җитәрлек, эшли алырсың...»

Мораль укырга яратуы өчен сөйми идем татар теле укытучысын. Тыңлап бетермәдем, редакциягә чаптым.

«Редактор» дип язылган ишекне ачып кердем. Өстәл артында пеләш башлы, ябалак күзле бер кеше утыра иде. Исәнләштем. Ни өчен килгәнемне, фамилиямне әйттем.

«Беләм мин синең этиеңне...— диде пеләш баш.— Бездә шундый тәртип, энекәш, эшкә кабул иткәндә кешене сынап карыйбыз. Ярты сәгатьтән райисполкомда киңәшмә башлана. Кәгазь-карандаш ал да, киттек. Шул киңәшмә турында материал хәзерләрсең».

Бардык киңәшмәгә. Хәйдәров — пеләш башлы редактор шул үзе иде инде — президиумга менеп кунаклады, мин залда, бер читтә утырып киңәшмәдә сөйләнгән сүзләрне түкми-чәчми язып барырга тырыштым.

Киңәшмә беткәч язганнарымны Хәйдәровка күрсәттем.

«Бу — әлегә чимал,— диде Хәйдәров,— әгәр без син язганнарның барысын да газетага бассак, беренчедән, урын җитмәячәк, икенчедән, мине эштән куып чыгарачаклар. Аңлашыламы? Язганнарыңны иртәгә әйбәтләп эшкәртеп китер. Төп фикерләрне генә калдыр».

Өйгә кайткач, төн буе утырып материалны эшкәрттем. Биш-алты тапкыр күчереп кенә яздым.

Икенче көн Хәйдәров кулъязмамны укып чыкты да, каләм алып мин язганнарны сызарга-бозарга кереште. Туналганнан калган материалны машинкага бирде.

«Рәт чыгуы мөмкин синнән, энекәш, тик тырышырга, бик нык тырышырга, өйрәнергә кирәк булыр»,— дип эшкә алды.

Эшли башладык. Ул чакта район газетасын ике генә кеше чыгара иде — редактор һәм җаваплы секретарь. Газета бер битле генә булып чыга иде. Бер битле генә булса да материалны күп сорый. Хәйдәров үзе редакциядә генә утыра, хәбәрләрне телефоннан шалтыратып кына ала. Барырга кирәк булган җирләргә мине чаптыра.

Чабарга мин иренми идем, шулай тиеш дип кабул ителгәндер. Ачуны китергәне, Хәйдәровның мине мыскыллавы иде. Ни генә язсам да Хәйдәровка ошамады.

«Күп сүзле, күп сүзле, күп сүзле»,— дип кабатлаганын тыңлап торганда:

«Әйтмәгез шул сүзегезне, акай күз»,— дип кычкырып җибәрәсем килгәли иде.

Хәйдәровның күп сүзле диюендә аерым мәгънә ята иде. Үзе ул татарчасын, русчасын бергә кушып исәпләгәндә дә биш йөздән артык сүз белми иде. Газетаны шул биш йөз сүз белән чыгара иде. Наданлыгын оста аклый иде Хәйдәров.

«Газета китап түгел. Китапка гына ул теләсә ни язып була. Газетаның теле кыска, аңлаешлы һәм коры булырга тиеш. Нәрсә язылган икән дип колхозчы баш ватарга тиеш түгел. Аңлашыламы?» — дия иде. Наданлыкны аңлап булмый, тешне кысып түзә идем. Наданлыгы өстенә Хәйдәров бәйләнчек тә иде. Мин язганны кулына алып, мине каршысына утыртып, юк кына нәрсәләргә дә бәйләнә иде. Мин тыңламаганны күреп, кычкырып та җибәрде бер тапкыр.

«Сине, малай актыгы, эшкә өйрәтәләр, син колагыңны колгага элеп утырасың. Үзеңнең файдаңа сөйлим бит. Мин әйтеп торам, төзәтеп торам, син һаман үзеңчә эшлисең. Кайчан редактор булырсың, шунда үзеңчә кыландырырсың. Ә хәзергә газета өчен мин җаваплы. Аңлашыламы? Мин җаваплы».

Түзмәдем:

«Нигә вак-төякләргә бәйләнәсез? — дип теләштем.— Җитәр, күп чыдадым».

«Вак-төякләр?! — дип кызып китте Хәйдәров.— Син язганнарда бер генә адәм рәтле кеше юк. Кайсы ялкау, кайсы алкоголик, кайсы шабашник... Кабәхәтләр, эт җаннар, хәшәрәтләр... Рәтле кеше очратмыйсыңмыни барган җиреңдә? Барысы да пычрак мыни? Алайса, кемнәр сукалый соң бу җирне, кем чәчә, кем үстерә, кем ура, кем суга? Син барып эшлисеңмени колхозга?»

«Тәнкыйть тә кирәк»,— дип бирешергә теләмәдем.

«Кирәкми тәнкыйть! Мин чыгарган газетага тәнкыйть кирәкми. Әйбәт кешеләр турында язарга да урын җитми. Әнә өлкә газеталары тәнкыйтьләсен, аларның урыннары җитәрлек».

Юкка кычкырды Хәйдәров. Минем кем икәнлегемне белеп бетерми иде шул. Бәхәсләшергә, талашырга туры килгәндә, сүзгә кесәгә керми идем мин.

«Сез ялагай. Сез райком секретарена ярарга тырышып кына шулай эшлисез. Сез, райкомда, райисполкомда эшләүчеләрнең аяк табаннарын ялыйсыз. Сез бервакытта да үз сүзегезне сөйләмисез»,— дидем.

Акай күзләрен тагын да шарландырып, миңа карап катты Хәйдәров. Исен җыеп өлгергәч, кычкырырга маташкан иде, тотлыгып калды.

«Син... Син, м-м-малай а-а-акты-гы!»-ннан башканы әйтә алмады. Соңыннан белдем, сугышта ул контузия алган икән. Каушаса, тотлыга башлый икән.

Бергә эшләгән арада шактый тотлыгырга туры килде аңа. Һәм барысына да үзе гаепле иде. Надан иде ул, катып калган бүкән иде. Миңа үчләшеп бәйләнгән саен, мин аңа кем икәнлеген әйтеп бара идем. Дөресен әйткәнгә курка да иде Хәйдәров. Шуңа күрә мине куып чыгарырга ашыкмады. Тик бәйләнүеннән генә туктамады.

Бу хәлнең озак дәвам итүе мөмкин түгел иде, мин, Хәйдәровның кемлеген сурәтләп, райкомга язып җибәрдем.

Берничә көннән соң Хәйдәров мине чакырып алды. Бүтән чаклардагыча, утыр димәде. Мин юри каршысына барып утырдым. Кабәхәт кешеләр белән үзләре кебек кабәхәт булырга кирәклеген бик яхшы белә идем чөнки.

Хәйдәров пеләш башын сыпырып куйды да ябалак күзләре белән сөзеп карады. Мин, әлбәттә, калтырап төшмәдем, киресенчә, аның күзләренә төбәлеп елмайдым.

«Бас,— диде Хәйдәров.— Бас! Хөкем карарын судта басып тыңлыйлар».

Мин, билгеле, басарга ашыкмадым.

Хәйдәров тотлыга-тотлыга сүзен дәвам итте.

«Я-а-арый, б-басма. Утыр. Мин синең ә-этиеңне бб-белә идем. К-к-кешеләрне яратмый иде ул».

«Тимәгез этигә!» — дип кычкырдым.

«Я-а-рый, мә-ә-әрхүмгә т-т-тимик. Кы-кы-кызганыч, син аңа ошагансың. М-м-ммин сине куып ч-ч-чыгарырга мәҗб-б-үрмен. Сау б-бу-бул. Иптәшләр б-б-белән килешенгән».

Ул башка сүз әйтмәде, борылып утырды.

Мин райкомга киттем. Анда кабул итмәделәр. Гаделсезлек җиңеп чыкты.

Өйгә кайткач туйганчы еладым. Бертуктаусыз: «Күрешербез әле, шул вакытта исәпләшербез»,— дип пышылдадым.

Әни, гадәтенчә, юатырга тотынды.

«Барысы да синең аркада»,— дип аңа җикерендем. Күңелемнең яралануына кемдер җавап бирергә тиеш иде.

Ел үтеп, икенче җәй җиткән иде инде. Булганнарны онытырга тырышып, имтиханнарга әзерләнергә керештем. Ул арада әни дә үлде. Аны җирләп, өйне саттым да Мәскәүгә киттем. Мәскәү университетына укырга кердем. Казан университеты, институтлары мине канәгатьләндерми иде. Әтиеңә ошаган дип әйтәләр икән, әтичә, Иштирәковча булсын, дидем.

Һәм менә мин, фәннәр кандидаты Хәсән Вәгыйзович Иштирәков, Хәйдәровның йорты каршында басып торам. Шул ук капка, шул ук койма. Тик инде ул яшелгә буялган. Исән микән йортның хуҗасы, теге дөньяга олагып өлгермәдеме икән? Олага алмый азапланса, мин ярдәм итәргә кайттым. Минем белән очрашканнан соң озак тора алмас.

Капканы ачып кердем. Бөкрәеп, корышып беткән бер карчык баскыч алды себереп йөри. Сәлам бирдем. Карчык, керфексез, чепи күзләрен чет-чет йомгалап, миңа күтәрелеп карады да:

— Шөкер әле,— диде.— Танып та бетермим бугай, кем буласың?

— Хәйдәров биредә яшиме?

— Хәйдәров? — Карчык, нәрсәнедер исенә төшерергә теләгәндәй, уйланып торды, кемнедер эзләгәндәй, як-ягына каранып алды.

— Әйе, Хәйдәров,— дип кабатладым.

— Нуриәхмәтне әйтәсеңдер,— диде карчык.

— Әйе.

— Шушында, шушында... Кирәк иемени?

— Кирәк иде.

— Хәзер, хәзер,— карчык, кылтыйн-мылтыйн атлап, ындыр артына — бакча ягына чыгып китте. Шактый торганнан соң Хәйдәровны ияртеп килде. Әйе, Хәйдәровны. Мин аны күрүгә таныдым. Бераз да үзгәрмәгән.

Карчык Хәйдәровның колагына үрелеп:

— Сине эзләп килгән,— дип кычкырды.

Хәйдәров биленә бәйләгән алъяпкычның итәгенә кулларын сөртте дә минем янга килде. Күрешергә кулын сузды.

— Саумысез.

Миңа да кул биреп исәнләшергә туры килде. Кытыршы, салкын кул. Димәк, тән җылысы кими башлаган Хәйдәровның. Озак яшисе калмаган.

— Бераз төсмерлим дә сыман, кем дип әйтә алмыйм. Хәтер иләге тишелгән, склероз,— дип шыңгырдап көлеп куйды Хәйдәров.

— Мин — Иштирәков.

Хәйдәров мин әйткәнне ишетмәде, гаепле кеше сыман елмаеп карап торды.

— Син аның белән кычкырып сөйләш, колагы ишетми аның,— диде карчык.

Тавышымны күтәребрәк:

— Мин — Иштирәков,— дидем.

— Иштирәков... Иштирәков...— дип кабатлап торды да,— шулаймыни!? — дип үкереп җибәрде Хәйдәров.— Шулайдыр дип уйлаган идем аны. Кара син аны. Әйдәле, әйдә. Узып җибәр әле түргәрәк. Өйдә тынчу. Кил әле, кил. Карчык, самоварыңны яңарт.

Хәйдәров кабалана-кабалана ишегалды буйлап чабып йөрде, әллә кайдан өстәл, урындыклар сөйрәп чыгарды. Аны-моны абайлаганчы, җилтерәтеп җитәкләп алып килеп, мине урындыкларның берсенә утыртты. Үзе алъяпкычын, эшләпәсен салып ташлап, минем каршыга урнашты. Пеләш баш, акай күз — нәкъ редакциядәгечә.

— Туган якка кайттым диген, ә? Күпкәме? Сагындырдымы?

— Сезне сагынып кайттым.

— Ә?..

— Сезне өзелеп сагынып кайттым.

Хәйдәров тагын елмайды.

— Колак саңгырауланды, энекәш. Контузия нәтиҗәсе диләр. Сугыш һаман искә төшереп тора. Картаела да инде. Иштирәков диген, ә? Кайларда инде хәзер? Олы кеше булдыңмы инде? Иштирәков... Әтиеңне белә идем мин. Сине дә әйбәт хәтерлим. Үзең хәтерләмисеңме соң?

— Бик яхшы хәтерлим.

— Ә?

— Бик яхшы хәтерлим.

— Син, Иштирәков, тарсынма, кычкырыбрак сөйләш. Әйе, хәтерлим. Кайсы елны эшләгән идең әле бездә?

— Сездә түгел, редакциядә эшләдем мин. Илле өченче елда.

Хәйдәров тагын шыңгырдап көлеп алды.

— Егерме җиде ел узып киткән диген. Әйтергә генә ансат. Хәтерлим мин сине. Күпләр онытылган, сине хәтерлим. Ни өчен хәтерләгәнемне дә беләм. Синең өчен бик борчылган идем мин. Әрәм булырсың кебек иде. Сорашып та тордым, Мәскәүгә укырга кергәнеңне әйттеләр, башкасын белүче булмады. Мәскәүдә укыгач, зур кеше булгансыңдыр?

— Зарланмыйм.

— Шулаймы? Яхшы. Молодец. Син безнең район малае, сер бирмә. Безнең әнә Болгаер малае Мәскәүнең үзендә зур галим. Кайткан иде, дом культурада очрашып сөйләшеп китте. Әйткән һәрбер җөмләсе бер китапка торырлык. Молодец! Менә мин картайдым инде, энекәш. Унҗиде ел пенсиядә.

— Картаймас кебек идегез.

— Ни дидең?

— Мәңге картаймас кебек идегез дим.

— Шулай инде, энекәш. Дөнья шундый хикмәтле нәрсә инде ул. Әле менә уйланып йөрим дә бер фикергә киләм. Кешегә картаерга ярамый икән. Ни генә әйтсәң дә, картайгач кеше ямьсезләнә икән.

— Искиткеч акыллы фикер,— дидем мин ирония белән.

Хәйдәров үзеннән көлеп сөйләшкәнне, иронияне сизми, әлбәттә. Хәйдәров кебек туң башлар маңгайга бәреп сөйләшкәнне генә аңлыйлар. Турыдан-туры «ахмак» дип әйтергә кирәк иде миңа. Һәм ахмаклыгын, аңгыралыгын исбатлап тиз генә чыгып китәргә иде. Хәйдәровның лыгырдавын тыңлап вакыт әрәм итү мәгънәсез эш. Минем аннардан башка да очрашасы бәндәләрем бар. Аларны күрергә дә, әйтәсен әйтеп, тынычланып, кайтыр юлга чыгарга кирәк. Монда кунып калу минем планда каралмаган.

«Беләсеңме, Хәйдәров, ни өчен синең янына килдем?» — дип әйтергә җыенганда, Хәйдәров урыныннан торды да өенә кереп китте. Аннан бер дәфтәр тотып чыкты.

— Менә картлыкның галәмәте, энекәш, хикәя яздым бит. Редакциягә илткән идем дә, ярамый диделәр. Ярамагач ярамый, алып кайтып өс-

тәл тартмасына салдым. Редакциядә барысы да яшьләр, кинәясен аңламадылар хикәянең. Менә син тыңлап карале, энекәш.

— Вакытым юк.

— Шулаймы? Ашыгасыңмы?! Алайса мин аны сиңа сөйләп кенә бирәм. Берәү малай чагында эшләпәгә гашыйк була. Эшләпә киеп йөрисе килә моның. Эшләпә киеп йөргән кешеләрне бик зур кешеләрдер дип уйлый. Чөнки ул малай чакта әле эшләпәне дәрәҗәле кешеләр генә киеп йөри. Эшләпә төшләренә керә малайның. Миңа эшләпә алып бирегез дип әти-әнисенә бәйләнә. Әти-әнисе көлеп кенә карыйлар малайның теләгенә, аңламыйлар. Малай үсә, егет була. Ләкин эшләпә аның хыялында яши бирә. Көннәрдән бер көнне бу малай кулына акча тотып шәһәргә эшләпә алырга китә. Поездга утыра. Поезд тәрәзәсеннән карап бара. Шул чакта, поезд дачалар яныннан узганда, малайның күзенә карачкы башында эленеп торган эшләпә чалына. Ныклабрак карый малай, чыннан да эшләпә, тишелеп-тетелеп беткән эшләпә. Шунда ук малайның эшләпәдән күңеле суына. Дәрәҗәле эшләпәнең карачкы башына эленеп торуы хыялын челпәрәмә китерә малайның... Я, ничек?

— Чүп,— дидем мин.

Минем сүзне Хәйдәров үзенчә ишетте.

— Билгеле, шәп... Алар төшенеп җитмәделәр.

— Шәп түгел, чүп! — дип кычкырдым.

Хәйдәров күзләрен акайтып миңа карап катты.

— Әйе, әйе, Хәйдәров, чүп, хикәяң дә синең чүп, үзең дә син чүп.— Һәр сүземне Хәйдәров ишетерлек итеп колагына әйттем. «Син» дигәнгә басым ясадым. «Сез» аңа әрәм иде.

Ул арада карчык, чынаяклар чыгарып, өстәлгә куйды.

— Нуриәхмәт, кунакка яңа балдан авыз иттер. Тулган рамнар бардыр,— диде.

Хәйдәровның селкенмичә утыруын күргәч, миңа карап:

— Шулай инде, ун әйтмичә ишетми,— дип сөйләнә-сөйләнә өйгә кереп китте.

Хәйдәров һушына килгәнче тагын өстәдем:

— Син аңгыра, томана, надан, кабәхәт бәндә, Хәйдәров. Мин сиңа шуны әйтергә кайттым.

Инде хәзер аз гына пауза ясарга да мөмкин иде. Исенә килсен, мин каптырганны йотсын. Аннан дәвам итәргә дә ярый.

Хәйдәров әкренләп һушына килде, күзләремә карап:

— Ни-ни өчен? — дип сорады.

— Оныттыңмыни?

— Н-н-нәрсәне?

— Эштән куып чыгарганыңны.

— С-с-оң бит, э-энекәш...

— Мин сиңа энекәш түгел, Хәйдәров, исеңнән чыгарма. Син бөҗәк, суалчан, кырыгаяк, таракан. Дөмеккәндә әйтеп дөмек, хәшәрәт, мин чүп диген. Чүп башым белән Иштирәковка кизәнеп маташтым диген. Синең кем икәнлегеңне исәннәр ишетеп калсыннар. Аңлашыламы?

Хәйдәров ни булганын ахырынача төшенеп җитмичә акаеп утырып калды, мин капкага юнәлдем. Капканы ачканда өеннән чыккан карчыкның:

— Нуриәхмәт, нишләп кунакны чәй эчертмичә җибәрәсең? — дигән тавышы ишетелде.

Ашыйсым килгән иде. Вакытны уздырмас өчен ашханә-фәләнгә кереп тормадым, юл уңаенда бер кибеттән печенье алып портфельгә салдым да авылга киттем.

Авылның берәр кешесе очрап танымасын, дип кара күзлек алып кидем. Берсе белән дә сөйләшәсем, хәтта исәнләшәсем дә килми иде.

Юл буе печенье кимерә-кимерә Хәйдәров белән очрашуны анализлап кайттым. Мин теләгәнчә барып чыкмады кебек. Ашыктым, кабаландым. Ул минем аягыма егылып гафу үтенергә, еларга, ялынырга тиеш иде. Һәм шул егылган җиреннән бүтән тормаска тиеш иде. Хәйдәров минем ни өчен кайтканымны аңлап та өлгермәде шикелле. Зарар юк, аңлар — аңлашылырлык сүзләр әйтелде.

Авыл читендәге чишмә янына тукталып, бит-кулларны юдым, чирәмгә ятып ял итеп алдым. Төш җитеп килә. Өлгерергә кирәк. Район үзәгеннән соңгы автобус кичке сигездә китә. Тугызда поезд. Минем карамакта, димәк, район үзәгенә җәяү баруны кырык минут дип санаганда, җиде сәгать вакыт бар. Җитә. Миңа авылда Сәлимҗан белән Әминәдән бүтән кеше кирәк түгел. Әхтәм, Нурислам, яки Габдулла очраса, әйтәсен аларга урамда гына әйтеп үтәрмен. Хәер, алар белән вакланмыйча белмәмешкә салынып китәргә дә мөмкин. Сәлимҗан белән Әминәнең өйләренә махсус керәм. Өйдә туры килмәсәләр, көтәчәкмен. Үлгән, я авылдан киткән булсалар — алар бәхете. Әмма барыбер эзләп табачакмын. Югыйсә, күңел тынычланмаячак.

Чишмә яныннан кузгалырга торганда гына машина килеп туктады. Сафиуллин машинасы. Биш тәңкәне китергәндер дип уйлап куйдым. Шулай икән, Сафиуллин машинасыннан атылып чыкты, каршыма басты.

— Мин сезне эзләдем... Сез югалдыгыз... Сез... Сез... нигә алай эшләдегез? — диде ул.

Сүзнең ни турында барганын белсәм дә, көлемсерәп:

— Нәрсәне ничек эшләдем? — дидем.

— Нигә сез?.. Сез...

— Ачыграк итеп сөйләгез, Сафиуллин.

Сафиуллин кесәсеннән бөгәрләнеп беткән биш сумлыкны тартып чыгарды.

— Нигә сез мине мыскыл иттегез?

— Мыскыл? Арттырасыз, Сафиуллин. Аңлаттым ич. Минем гадәт шундый, бушлай йөрергә күнекмәгән.

— Ничек сез?..

— Тынычланыгыз, Сафиуллин. Сезнең нервларыгыз нык булырга тиеш. Сез руль артында утырасыз.

— Менә нәрсә, Хәсән...

— Хәсән Вәгыйзович... Иштирәков...

— Әйе, әйе, Иштирәков... Мин каушадым, әйе... Алыгыз акчагызны, Иштирәков... Мин ышанмыйм, мин әле һаман да ышанмыйм...

— Нәрсәгә ышанмыйсыз, Сафиуллин?

— Мин уйладым... Мин уйлыйм...

— Син уйлама, Сафиуллин. Кайбер кешеләргә уйлау килешми.

Сафиуллин ни өчендер күзлеген салды, аны җиргә төшереп җибәрде. Капшап эзләп тапты, пыялаларын сөртеп киде, миңа төбәлеп карап торды.

— Димәк, сез чынлап... Нигә?..

— Җитте, Сафиуллин. Биш сум сезне олы хәсрәткә төшергән икән, китерегез...

Мин аның кулыннан биш тәңкәлекне алдым да ваклап турап җиргә сиптем. Сафиуллинның өстенә сипмәкче идем, ни өчендер кызгандым. Кыяфәте болай да мескен иде.

— Менә шулай. Проблема хәл ителде, иптәш мәгариф министры,— дидем дә китеп бардым.

Сафиуллин артымнан килеп тагын бәйләнә башлар дип уйлаган идем, акылы җитте — иярмәде. Югыйсә...

19 сентябрь 1980 ел.

Көндәлекне дәвам итәм. 17 сентябрьдә арып, яза алмас дәрәҗәгә җитеп туктаган идем. Кичә ял иттем. Тоташтан, туктамыйча язып чыгармын дигән идем, булмас ахры. Ләкин тизрәк бетерергә кирәк. Югыйсә...

Югыйсә?.. Шул сүздә туктап калынган икән. Ярый, анысы калсын. Шуннан ни булды?

Әйе, авыл урамына кердем. Очраган бала-чага исәнләшеп уза. Мин аларга әһәмият бирмим. Минем алда гаепләре дә юк, ләкин, беренчедән, бала-чаганы яратмыйм, икенчедән, алар шушы авылныкылар. Өлкәннәр очрамый, анысы яхшы.

Кайчандыр безнеке булган йорт турысыннан үткәндә, ул якка карамадым. Карамасам да, әти нигезендә бүтән өй торганын күңелем сизде. Тыкрыкка борылган җирдә Әминәләр өе иде. Урынында тора. Тик искергән, чүккән, тәрәзәләре кадакланган.

План буенча иң элек Сәлимҗан белән «эшне бетерергә» тиеш идем. Әминәнең чираты Сәлимҗан Чулактан соң иде.

Аяклар үзләреннән-үзе Әминәләр өе ягына атлады. Ул минутта нәрсә уйлаганмындыр, белмим. Тәрәзәләрнең такта белән аркылы-торкылы кадакланганын күрә торып шул якка борылдым.

Капкасыз, киртәсез ишегалдына кердем. Ишегалдын алабута баскан. Абзарның салам түбәсе эчкә савылып төшкән. Баз алачыгы ишелгән. Өй ишегендә күгәреп беткән йозак. Болдыр баскычлары мүкләнеп черегән.

Мин бу баскыч такталарын бик яхшы хәтерлим. Ул чакта алар сапсары итеп юылган булалар иде. Әминә чыкканын көтеп күп тапкырлар утырып тордым мин аларда. Әминә чыкмаган төннәрне шунда җәен таң аттырган, кышын бармагымны өшеткән чакларым булды. Хәзер мүкләнеп черегән такталар гына. Күрәсең, Әминәнең әнисе үлгән, Әминә үзе кияүгә чыгып башка йортка күчкән. Бәлки авылда да түгелдер. Берәрсеннән сорашырга кирәк булыр, беләләрдер.

Әгәр Әминә авылда булса? Мин барып кергәндә ире өйдә туры килсә?.. Алдан планнар корсам да Әминә белән очрашуга әзер үк түгел идем бугай. Мин мәхәббәтемне кабул итмәгән кыздан ничегрәк итеп үч алырга анык белми идем. Әлбәттә, әгәр тормышының рәте булмаса, үч алу җиңелрәк.

«Я, нигә ирештең, чибәр кызый? Борыныңны бик күтәргән идең, шушы көнгә калдыңмы?» — дип мин аның бәхетсезлегеннән көләчәкмен, ярасына тоз сибәчәкмен. Әгәр тормышы көйле булса? Бәхетле булса? Бу вариантта нишләргә икәнен төгәл белмим. Үч алам дип ахмак хәлдә калырга ярамый миңа. Мин аткан укның мин төзәгән йөрәккә тимичә, бумеранг булып үземә кайтуына һич кенә дә риза түгел.

— Абый, сез кем?

Таныш тавыш — Әминә тавышын ишетеп сискәнеп киттем, борылып карарга куркып тордым.

— Абый...

Карамыйча мөмкин түгел иде инде. Әкрен генә борылдым. Каршымда Әминә басып тора. Бераз гына да үзгәрмәгән. Мин авылдан киткәндә ничек булса шулай. Киресенчә, яшәрә төшкән бугай әле. Унөч-уналты яшьләрендә. Ничек инде алай була? Егерме җиде ел үткән ләбаса. Әллә галлюцинацияме? Юк, шикелле.

Минем аптырап карап торуымны күргән «Әминә» үзе дә аптырап артка чигенеп куйды.

— Абый, сез кем?
— Ә... Сез... Син... кем?..
— Мин шушы авылныкы. Әнә безнең өй.— Ул каршыдагы өйгә күрсәтте.
Тукта, кемнәрнеке соң ул өй? Бер ялгыз карчык яши иде сыман анда. Исемен хәтерләмим. Димәк, ул үлгәч, анда бүтәннәр күчкән. Эминәләр. Бу яшүсмер, димәк, Эминәнең кызы.
— Ә сез, абый, кемне эзлисез?
— Мин?.. Эзлим?..
— Сезнең монда кереп киткәнегезне әни тәрәзәдән күргән. Мине сорашырга җибәрде.
— Кем соң синең әниең?
— Нажия.
Нажия? Юк, ишеткәнем юк. Авылда андый исемле берәү дә юк иде шикелле. Хәер, кем белә... Каршыдагы капкадан юан гына бер хатын чыкты да үрдәк сыман атлап безнең янга килде. Таныш түгелме дигәндәй, миңа текәлеп карады. Танымагач, салкын гына итеп:
— Исәнмесез,— диде,— кемне эзлисез?
Йөзгә карап әйтелгән туры сораудан каушап калдым.
— Эзләмим,— дип мыгырдандым.
— Сез кем соң?
— Минме? Мин...
Ни дип әйтим моңа? Бәлки дөресен әйтергәдер. Нигә уйнап маташырга? Таныса ни булган? Нәрсә югалтам?
— Мин Иштирәков, исемем Хәсән.
— Шушы авылныкымы?
— Әйе.
— Күргәнем юк бер дә.
— Еракта яшим. Мин дә сезне танымыйм.
— Бу авылныкы түгел без. Күчеп кайттык. Унбиш ел инде. Без Мәрьям апаларның туганы,— (Мәрьям апа Эминәнең әнисе),— Мәрьям апа безнең әти белән бер туган. Былтыр авылдан китте ул. Эминә үз янына алдырды. Район больницасында врач булып эшли. Без аларның өен караштырып торабыз.
Яхшы булды бит әле бу. Сорашмаган килеш юан хатын миңа кирәкле мәгълүматлар бирде. Эминәне район үзәгеннән эзләргә кирәк икән. Монысы берьяктан уңайлырак та... Врач... Институт тәмамлаган дигән сүз. Бусы минем файдага ук түгел. Врач булмыйча санитар булсын иде ул. Эшеннән зарлансын иде. Шул эшне яраткан өчен түгел, ә бүтән эшкә яраксыз булганы өчен генә шунда эшләсен иде.
Урамга чыктым. Түбән очка төшеп киттем. Мин белгәндә Чулак Сәлимҗанның өе шунда иде. Тыкрыктан борылганда артыма әйләнеп карадым. Тәрәзәләре кадакланган ятим өй, алабута котырып үскән ташландык ишегалды. Юан хатын белән кызы һаман да әле шунда басып торалар. Минем турыда сөйләшәләрдер, кем булды бу сәер адәм диләрдер. Кирәк бит, охшаса да охшый икән кеше кешегә. Эминәнең коеп куйган копиясе. Барысы да табигатьнең без аңлап җиткермәгән хикмәтләре. Хәер, генетика фәне бу мәсьәләләргә күп ачыклык кертте. Теоретик яктан монда һичнинди дә сер юк. Әмма конкрет тормыш, күрәсең, теория кысаларына сыеп бетмидер. Миллион төрле әкәмәтләре белән туктаусыз гаҗәпләндереп торадыр.
Уйланып атлый-атлый кая барганымны онытып җибәргәнмен, Сәлимҗаннар йортын узып авылның икенче кырыендагы чишмә башына килеп чыкканмын. Гаҗәеп кызыклы чишмә бу. Тау сыртыннан бәреп чыга да, йөз — йөз илле метр аккач, бер чокырга барып төшә һәм шунда югала. Кая китә? Мин балачакта беркем белми иде. Бәлки хәзер серен ачканнардыр.

Чокыр янына барып, бөтерелгән суга карап, озак басып тордым. Шунда күңелемдә икеләнү хисе яңарды, күңелдә кабат шик-шөбһә туды. Нигә буталып йөрим бу авылда? Ниемә кирәк ул акай күз Хәйдәровлар. Чулак Сәлимҗаннар? Әминәсе — шайтаны ни хаҗәтемә? Мәтәлеп китсеннәр. Чокырга сикерәсе һәм чишмә белән бергә әллә кая — билгесезлеккә китеп югаласы килде.

Акылыма килеп, сүгенеп куйдым. Бу сорауларны әллә ничә кат бирдем ич инде үземә. Җавабын да тапкан идем. Нигә дип әле җебеп калдым? Чишмә гаепләме? Юктыр. Әнә ул үзе дә җир асты караңгылыгыннан, андагы ташларның кысрыклавыннан туеп, якты дөньяга чыга да яңадан шул караңгылыкка чума. Димәк, анда кыласы гамәлләре калган. Бәлки җир астындагы ташларга үзенә күрә берәр үче бардыр, аларны ашарга телидер.

Җире чигенергә ярамый. Ничә еллар буе күңелдә тырнап йөргән ташны ыргытып, аңардан котылырга кирәк. Ул таш кемнәрнеңдер башын тишәргә тиеш. Кемнәрнеңдер түгел, конкрет кешеләр бар. Үзләренең ташы үзләренә булсын. Үз чыбыркысының тәмен Чулак Сәлимҗан үзе дә татып карасын.

Мин онытмадым ул чыбыркының тәмен. Әче иде ул. Мин аның әчелеген елаганда сиздем. Күз яшьләрем авызга, ирен читләренә тәгәрәп төштеләр, авызга тулдылар, мин аларны йота бардым. Әйе, әчеләр иде.

Сугыш беткән ел иде. Урамда уйнап йөргәндә үзем белән яшьтәш бер кызый, нәрсәгәдер ачуы килеп, мине телен чыгарып үчекләде. Үчекләгәнне яратмый идем, кызыйның маңгаена чирттем. Ул тагын телен чыгарып күрсәтте дә:

«Бурсык, бурсык, бурсык»,— дип чишмә ягына йөгерде. Мин аны куып киттем. Бурсык безнең кушамат иде. Үчекләгәнне дә яратмаган малайга кушаматы белән кычкырсыннар әле, кайсы түзеп торыр икән. Чишмә башында куып тоттым да кызыйны тукмарга тотындым. Гаделҗамалмы, Гайниҗамалмы, хәзер төгәл хәтерләмим, исемле карчык чишмәдән су алып ята икән. Шул карчык:

«Нишлисең, хәерсез!»— дип килеп якамнан эләктереп алды. Мин аның кулын тырнап ычкындым.

«Иштирәк мөртәте» — дип калды карчык. Шул сүзне әйтмәсә һичнидә булмас иде, мин өйгә кайтып киткән булыр идем. Ачуым чыкты. «Иштирәк мөртәте»н күрсәтергә кирәк иде аңа.

Фуражкама юлдан тузан җыеп тутырдым да, Сәлимҗаннар өе каршында үскән каен артына посып, карчыкның үтеп киткәнен сагалап тордым. Карчык минем турыга килеп җитүгә, кинәт каршыга чыгып фуражкадагы тузанны йөзенә сиптем. Карчык көянтә-чиләкләре белән җиргә ауды. Шул чакта үзем дә куырылып җиргә чүгәләдем.

Күтәрелеп карасам, янымда Чулак Сәлимҗан. Кулында каеш чыбыркы. Шуның белән ярды гына мине.

Өйгә үкереп елап кайтып кердем.

«Ни булды тагын?» — дип сорады әни.

«Кыйнады...»

«Кем?»

«Чулак...»

«Кайсы Чулак?»

«Сәлимҗан».

«Ни өчен?»

Дәшмәдем. Тагын да кычкырыбрак еларга керештем. Авыртудан еламадым, гарьлегемнән еладым. Мине кыйнарга Чулак Сәлимҗанның хакы юк иде.

Әни, һәрвакыттагыча, мине кочагына алып юатты. Аннан чоланга урын җәеп шунда яткырды.

Йокымнан Чулак Сәлимҗан тавышы уятты. Чолан ишеге ачык иде. Сәлимҗанның тавышы ишегалдыннан килә. Куркуымнан юрган астына чумдым. «Әни!» — дип кычкырмакчы идем дә, әни тавышын ишетеп, тыелып калдым. Әни белән Сәлимҗанның ни сөйләшкәннәре хәтергә нык уелып калганнар. Ялгышсам да күпкә ялгышмыймдыр.

Ә н и. Вәгыйз ачуын малаеннан аласың инде, беләм.

С ә л и м җ а н. Юкны сөйләмә, Маһинур. Үлгәннән үч алырга башка тай типмәгән. Сугышта үлгәннән бигрәк тә. Сугышның ни икәнен беләм мин — кулымны калдырып кайттым.

Ә н и. Тел белән әйткәнне дә аңлар иде.

С ә л и м җ а н. Ачуланма, Маһинур, тел белән әйткәнне аңлаудан узган ул малаең. Карап-карап йөрим дә күпләр зарлана малаеңнан. Ир малай ул — аңа бераз эләктергәләп торырга кирәк.

Ә н и. Үз балаң булмагач шулай инде.

С ә л и м җ а н. Син минем ярама кагылма, Маһинур. Аны Иштирәк малаеннан тапканга минем гаебем юк. Миңа чыккан булсаң, минеке булыр иде.

Ә н и. Шуның да үчен алуыңдыр.

С ә л и м җ а н. Мин үч алмадым. Кайчандыр сине яратканыма Иштирәков үч алды — анысы хак. Ә малаеңны кара, соңыннан үзеңә читен булыр. Малаеңда этисенең каны. Миһербансыз, явыз.

Ә н и. Явыз булып нишләгән...

С ә л и м җ а н. Сөйләдем ләбаса.

Дәшми тордылар. Сәлимҗан:

«Ярый, әйткәнемә ачуланма, Маһинур, йөрәгем әрнегәнгә әйттем. Сау бул»,— дигәч кенә, әни:

«Нишләпләр генә бетәрбез инде»,— дип көрсенеп куйды.

Олыгайгач бу сөйләшүне күп тапкырлар анализлап карадым мин. Сәлимҗанны гафу итәргә дә маташтым шикелле. Ләкин барыбер юрган астында биргән антым җиңеп чыга килде. Ул эти үчен миннән алган, мин ул үчне кайтарырга тиеш идем. Өстәвенә, без Сәлимҗан белән тагын бер тапкыр бәрелештек.

Анысын да үзем башладым. Тугызынчы класста укыганда мәктәптән кайтып килә идем, урам чатында әни белән Сәлимҗанның сөйләшеп торганнарын күреп туктадым.

«Кит аның яныннан!» — дидем әнигә.

«Нигә әниеңә җикеренәсең»,— диде Сәлимҗан.

«Анда синең эшең булмасын, Чулак тәре».

«Улым...»

«Өйгә кайт. Ә син әни янына якын киләсе булма. Актык кулыңны сындырырмын».

Сәлимҗан кызарынды, бүртенде.

«Сындырып кара»,— диде.

Мин аны этеп җибәрдем. Сәлимҗан шуны гына көткәндәй сыңар кулы белән изүемнән эләктереп алды. Буыла башладым. Арага әни килеп кермәсә, бу бәрелешү ни белән беткән булыр иде, билгесез.

Менә тагын бер кат — соңгы тапкыр очрашырга барам Сәлимҗан янына. Бу юлы инде изүемнән эләктерергә ирек бирмәм. Мин дә аның бугазына ябышмам. Бер-ике сүз генә әйтермен. Ул сүзләр каеш-чыбыкдан әчерәк булыр, куырылып килер Сәлимҗан. Әгәр дә инде сыңар кулын уйнатырга җыенса, якасыннан умырып тотармын да башын аска иеп йөзе белән ботинкамның тузанын сөртермен.

Исән микән әле? Исән булсын, миңа дөмеккән Сәлимҗанның кирәге юк.

Җил капканы аягым белән ачып ишегалдына кердем. Җан иясе күренми. Чолан, өй ишекләре ачык иде, эчкә үттем.

Түрдәге караватта, таныдым, Сәлимҗан ята. Карават янында бер карчык (хатыны булса кирәк) һәм мин станциядә очраткан карт басып тора. Күргәнемне сизмәделәр, ахрысы, борылып караучы булмады.

— Кичә ару иде, бүген иртән авырайды,— диде карчык.

Карт, Сәлимҗан өстенә иелә төшеп:

— Кордаш, таныйсыңмы мине. Я, әйбәтләбрәк карале, мин бу — Галиулла кордашың,— диде.

— Сине бик көтте инде,— дип, карчык яулык чите белән күзен сөртеп куйды.

Сәлимҗан хәрәкәтсез ята. Йөзе ап-ак. Чөй сакалы тырпаеп тора. Димәк...

— Доктор чакыртырга кирәк,— диде карт.

— Үзебезнең авылныкы килеп карады. Укол да кадаган булды, файдасы тимәде. Районнан чакыртырга китте.

Мин ничектер югалып калдым. Мондый очракта нишләргә тиешлеген уйланылмаган иде. Бәлки әкрен генә чыгып китәргәдер? Әзерләнгән сүзләремне Сәлимҗан йөзенә бәреп әйтсәм дә, язмыш минем өчен үч алган түгелме соң: Сәлимҗан мин кайткан көнне аягын сузачак. Һәм мин үзем шул тантананың шаһиты. Мин исән, ул җан биреп ята.

Шулай да чыгып китә алмадым. Нindидер көч карават янына тартып китерде. Дошманымның җаны чыкканын үз күзләремә күрсәтергә теләгәндер.

Кара күзлекле таныш түгел берәүнең карават янына тавыш-тынсыз килеп басуын күргәч, карчык сәерсенеп миңа текәлде.

Чулак Сәлимҗанның агарып калган йөзенә бер төбәп карадым да, эчемнән генә: «Мин исән, син — мәет»,— дип кабатлап чыгып киттем. Карт арттан иярде. Капка төбендә куып җитеп җиңемә ябышты.

— Шул үзең бит. Син Иштирәков малае бит. Нигә инде яшергән булдың? Авылга кайтасыңны ник әйтмәдең? — дип төпченә башлады.

— Юлда торма! — дип картны читкә этеп китеп бардым. Сәгать өч тулып килә иде. Район үзәгенә барып өлгереп, Әминәне эзләп табарга кирәк иде миңа.

## 5

20 сентябрь 1980.

Поликлиникага кереп регистратурадан врач Әминә Садриеваны сорадым.

— Әминә Фатыйховнамы? — диде регистратурада утыручы кыз. Әминәнең этисен мин белмим. Сугыштан кайтмады. Исеме Фатыйх булды микәнни? Әминәне Мәрьям кызы дип кенә йөртәләр иде. Шулайдыр. Фатыйх исемле булгандыр Әминәнең әтисе.

— Әйе,— дидем.

— Ләкин аның фамилиясе Газизуллина,— диде кыз.

Димәк, иренең фамилиясен йөртә Әминә Садриева.

— Чакырыгыз.

Кыз елмаеп куйды.

— Мөмкин булса, чакырыгыз, дип әйтергә кирәк, гражданин, бәлки ул биредә юктыр.

Кызның чытыклануы ошамады.

— Биредәме, юкмы икәнен сез белергә тиеш.

Кыз гаҗәпләнеп миңа карап алды да шапылдатып регистратура тәрәзәсен япты. Каядыр китеп югалды. Бераздан килеп:

— Әминә Фатыйховна стационарда, авыру кабул итә, озакламый монда керәчәк,— диде.

Болдырга чыгып култыксага сөялдем дә Әминәне көтә башладым.

Әминә... Үзгәргәндер инде... Юанайгандыр, ямьсезләнгәндер. Анысы яхшы, миңа аның юанаюы, ямьсезләнүе кирәк. Каршыма авылда очраган теге кыз кебек килеп чыкса, нишләрсең. Болай да, әллә ничек, ул кызны күргәч, күңел какшады сыман. Каушабрак калдым шикелле.

Әминә... Гомерем буе мине эзәрлекләгән исем. Йөрәгемнең иң тирән ярасы. Бәгырьләрне өзеп туктаусыз сызлаучы яра. Онытырга тырышып карадым, булдыра алмадым. Аны искә төшергән саен җенләнеп эшкә тотына идем. Кулымнан килмәслек эшләр эшләнеп ташланды. Дәрәҗәгә ирештем. Ничә тапкыр хат язарга тырышып карадым үзенә, тыелып калдым. Аның белән сөйләшә алырлык биеклеккә житмәгәнемне сизә килдем. Минем белән очрашканнан соң үкенергә, өзгәләнергә, гафу үтенергә тиеш иде ул. Юк, миңа хәзер аның мәхәббәте дә, яратам дию дә кирәкми инде. Бары тик үкенсен генә, ялгышканмын, Хәсән, дип кенә әйтсен. Һәм мин аның күзләренә карап хахалап көлим. Шунда җаным тынычланачак.

Әминә... кайчан, ничә яшемдә гашыйк булдым икән мин аңа? Хәтерләмим. Үз-үземне белә башлаганда мин аны ярата идем инде. Ә ул?

Ул көлә иде. Бәләкәй чагында телен чыгарып үчекли иде, мине кушаматым белән үрти иде. Сәлимҗан кыйнаган көнне дә мине үчекләүче, бурсык, бурсык, бурсык дип үртәүче ул иде. Әгәр дә ул мине үчекләмәгән, үртәмәгән булса, мин аны инеш башында куып тотып тукмамас идем, «Иштирәк мөртәте» дигән сүз ишетмәс идем, шул сүз өчен судан кайтып килүче карчыкның йөзенә тузан сипмәс идем. Кыйналмаган булыр идем. Һәм бәлки Чулак Сәлимҗаннан үч алам дип, вакланмаган булыр идем. Алдыммы инде үч? Караватта хәрәкәтсез яткан картка эчемнән генә: «Син — мәет»,— дип киттем. Шулмы үч алу?

Култыксага таянып Әминәне көткәндә кәеф кырылганнан кырыла барды. Күңелдә Сафиуллиннан, Хәйдәровтан көлгән вакыттагы тантана юк иде инде. Искә төшерергә теләмәсәм дә үткәннәр ихтыярыма буйсынмыйча уемны биләп алдылар.

Менә мин беренче тапкыр Әминәгә мәхәббәтемне аңлаттым. Сигезенчедә укый башлаган идек. Борчак йолкырга алып бардылар. Караңгы капканчы йолкыттылар. Әминә өйләренә бакча артлатып кына кайтып китте. Мин аңа тагылдым. Әминә читән аша бакчаларына сикереп төшәм дигәндә, эләктереп алдым. Чарылдап кычкырыр дип уйлап, авызын томаларга ук әзерләнгән идем, кычкырмады.

«Нишлисең, ә?» — дип кенә читкә тайпылды.

«Сөясеңме мине?» — дидем.

«Кит, җүләр» — дип көлеп җибәрде Әминә.

«Син көлмә, яме».

«Көлсәм нишләтерсең?»

«Нишләтә белермен».

«Мин синнән курыкмыйм».

Курыкмыйм дию дөрес иде Әминәнең. Күпме тукмагандырмын мин аны, ләкин ул беркайчан да мине үчекләвеннән туктамады. Мин аның күз яше чыгарып елаганын күрмәдем. Мин суккан саен бурсык дип тора иде. Күп вакыт шул «бурсык»ны ишетмәс өчен генә кыйнаудан туктый идем.

«Мин сине куркытырга җыенмыйм да»,— дидем.

«Нишләтергә җыенасың соң?»

«Белермен».

«Ха-ха... Бик исем китте. Үтереп ташласалар да мин синең белән йөрмәячәкмен».

«Кем белән йөрергә уйлыйсың?»

«Үзем белермен».

«Мин сине берәү белән дә йөртмим».

«Нәрсә-ә-ә?»..

«Тозлаган кыяр-кәбестә».

«Син үзең кәбестә» — Әминә читәнгә үрмәләде.

Мин аны сөйрәп төшердем. Төшергәндә читән казыгына эләгеп күлмәк итәге ертылды.

«Бурсык тәре!» — дип кычкырды Әминә, өстемә ташланып, тырнакларын битемә батырды. Бу юлы мин аны рәхәтләнеп кыйный алмадым. Минем белән тигез сугышты ул — өйгә кызыл канга батып кайтып кердем.

Шунысы бар: безнең ике арадагы мөнәсәбәтләрне икебез генә бела идек. Әминә бүтәннәр янында мине хурлап яки миннән зарланып сүз әйтми иде. Кешеләр янында күрми генә иде ул мине. Һәм, анысын да әйтергә кирәк, беркем белән дә «йөрмәде».

Күпме генә азаплансам да, нинди генә планнар корсам да мин аны ялгызын очрата алмый интектем. Очратканда да оста ычкына иде. Ялынып та, куркытып та хатлар яздым. Хатларны сумкасына сала идем, ул хатлар һәрвакыт укылмыйча үземә кайттылар.

Унынчыда укыганда Әминә кинәт үзгәрде — миннән качмый башлады. Икәү генә калган чакларыбыз еш була иде. Мин аңа туктаусыз үземнең яратуым турында сөйләдем, ул «яратам» сүзен ялгыш кына да, шаярып та ычкындырмады.

«Әллә синең бүтән сүзләрең юкмы?» — дия иде. Юк иде минем бүтән сүзләрем. Әгәр дә Әминәнең мине яратуын сизсәм, шул хакта үзеннән ишетсәм, бәлки сүзләрнең башкалары да табылган булыр иде. Әмма ул салкын килеш кала бирде. Мине тыңлаганда да миңа туры карап түгел, башын читкә борып тыңлый иде. Бер тапкыр:

«Минем белән сөйләшкәндә нигә һәрвакыт читкә карыйсың?» — дигән идем.

«Мәхәббәтең турында сөйли башласаң, борын очың тирли синең, көләсем килә», — диде.

Үзем дә сизмәстән җиңем белән борынымны сөртеп алдым. Әминә елмаеп куйды.

«Беләсеңме, Иштирәков, ачуың чыкканны борыныңа карап беләм мин. Борының тирләсә, син берәрсенә әшәкелек эшләмичә калмыйсың», — диде. Чыннан да шулай иде. Хәзер дә ачуым килсә, борыным тирли. Ул чирдән һич кенә дә котыла алмыйм. Каһәр суккан борынны куптарып алып ыргытырдай булам.

Шул көннән соң Әминә белән очрашканда кулымда һәрчак кульяулык йөрде. Әминәгә күрсәтмәскә тырышып борын очын сөртеп тора идем. Әминә минем азапланганны күрә иде, әлбәттә. Аның күргәнен сизеп мин уңайсызлана идем. Уңайсызланган саен борын ныграк тирли иде.

Ахырда Әминә түзмәде:

«Нигә интегәсең? Борының барыбер сиңа буйсынмый», — дип үзенең кульяулыгы белән борын очымны сөртте.

Ни уйлап шулай эшләгәндер, аңламадым. Аңларлык түгел идем. Соңрак шушы вакыйганы искә төшереп анализлаганда, Әминәнең кыланышы мине мыскыллавы булган дип нәтиҗә ясадым. Ләкин ул чакта бу минем өчен зур җиңү иде.

Икенче җиңүем өлгергәнлек аттестаты алган көнне булды. Әминә бигрәк шат иде ул көнне, көлеп кенә торды. Без аның белән төн озыны чишмә, әрәмәлек буйларында йөреп таң аттырдык. Сөйләшмәгән сүз

калмады. Тик ике арадагы мәхәббәткә кагылган сүзләр генә әйтелмәде. Кирәкләре дә юк иде бугай аларның. Миңа болай да рәхәт иде.
Аерылышыр, өйләргә кайтышыр алдыннан Әминә:
«Иштирәков, син мине чынлап та яратасыңмы?» — диде.
Шаккаттым. Ярату турында Әминәнең сүз башлавы гаҗәпкә калдырды. Мин инде әллә ничә кат такылдаган, хәтта үземнең дә эчне пошыра, туйдыра, ялыктыра башлаган сүзләрне яңадан кабатларга керештем. Әминә дикъкать белән тыңлады да:
«Мин сине яратам микән, Иштирәков? — диде. Йөзе житди, уйчан иде аның,— яратамдыр, яратмасам, сине кызганмас идем».
«Ни өчен кызганасың?»
«Белмим».
«Мин кызганыч түгел, Әминә... Мин...»
«Беләм, син Иштирәков».
«Минем исемем дә бар».
«Карале, чыннан да,— дип көлеп җибәрде Әминә.— Нигә бөтенесе дә сиңа Иштирәков диләр. Исемең белән берәү дә әйтми. Хә-сән... Юк, Иштирәков сиңа килешәрәк төшә».
Батыраеп китеп мин дә:
«Миңа синең фамилияң ошамый,— дидем,— Садриева... Әллә ничек».
Әминә тагын көлде:
— Кызларның фамилиясе кияүгә чыккач үзгәрә ул,— диде. Һәм мине тагын да аптыраштa калдырып: — әйдә, Иштирәков, үбешәбез,— дип өстәде.
Кулына кагылырга да рөхсәт итмәгән Әминәнең «үбешәбез» диюенә, билгеле, ышанмадым. Ләкин ул үзе мине кочаклап үпте. Ни булганын абайлап өлгергәнче көлә-көлә өйләренә кереп китте. Җиңү шатлыгыннан тантана иткән күңел җиде кат күктә очып йөрде.
Хәзер беләм, аңлыйм — бу минем җиңүем түгел, җиңелүем, тар-мар ителүем иде. Чөнки шуннан соң минем иреннәремә бер генә хатын-кыз ирененең дә тигәне булмады. Беренче һәм соңгы тапкыр. Минем белән үбешергә теләгәннәр булмагандыр димим, ләкин берсен дә якын җибәрмәдем һәм җибәрмәячәкмен. Шул үбү белән Әминә хатын-кыз затына булган хөрмәтне үтерде. Чөнки ул үбүнең дәвамы булмады. Икенче кат якын җибәрмәде Әминә. Әгәр үпмәгән булса, йөрәктә яра гына калган булыр иде, һәм ул бәлки вакыт узу белән төзәлер дә иде, ә болай күңелем тулы нәфрәт, ачу, үч.
Әйе, Әминә белән ике арада бүтән мондый якынлык булмады. Мин редакциядә эшли башладым, Әминә медицина институтына керә алмый авылга кайтып колхозда эшләде. Көн саен кайтып йөрдем. Әминә белән күрешеп тора идек. Әмма очрашкан саен аралар ерагая, суына барды. Мин гаепле түгел идем. Әминә читләште. Дөресрәге, якынаймады.
Соңгы күрешү мин редакциядән куылган көнгә туры килде. Нервларның өзелердәй булып тартылган чагы иде. Әминә белән очрашкач, еладым, Хәйдәровны сүктем.
«Күрсәтермен әле мин аңа»,— дип Хәйдәровка янадым.
Әминә минем хәсрәтемне уртаклашмады, сабыр, тыныч, салкын иде.
«Әминә, чык миңа кияүгә, өйләнешик»,— дип ялындым ул көнне.
«Юк, Иштирәков,— диде Әминә,— без бәхетсез булачакбыз».
«Нигә?.. Ни өчен?!»
«Мин куркам синнән».
«Ник?»
«Белмим. Ләкин сизәм, без бәхетсез булачакбыз».
Башка күрешмәдек, сөйләшмәдек. Әнине җирләгән көнне генә:
«Кайгыңны уртаклашам, Хәсән»,— диде ул.
Мин укырга киттем, Әминә авылда калды. Димәк, ул да укырга кергән. Бәхетсез булачакбыз дигән иде. Карап карыйк, бәхетле микән хә-

зер? Дөнья тоташ бәхеттән генә тормый, тормышының чатнаган, кителгән ягы бардыр әле. Булсын иде, ходаем! Зарлансын, сукрансын иде.

Поликлиника белән янәшә бинаның ишегеннән ак халатлы бер хатын чыгып, ашыга-ашыга миңа таба килә башлады. Әминә! Аның йөреше — биегән сыманрак атлый. Гәүдәсе элеккечә сылу, аз гына да юанаймаган.

Килеп житте. Йөгереп диярлек баскычтан менде.

— Исәнмесез,— дидем.

— Исәнмесез,— диде Әминә. Миңа күтәрелеп тә карамады, кереп китте. Ул ачкан ишектән мин дә кердем.

— Мин сезне көтә идем, Әминә Фатыйховна,— дидем.

— Гафу итегез, ашыгам,— дип юлын дәвам итте Әминә, һәм кинәт тукталып калды. Борылып яныма килде, төбәлеп карады.

— Әллә танымыйсызмы? — дидем.

— Ай, Хәсән ич...

— Әйе, Иштирәков. Тагын бер тапкыр исәнмесез.

— Исәнме, Хәсән. Кайдан болай? — һәм җавабымны да көтмичә,— Хәсән, зинһар, гафу ит, вакытың булса, көт бераз,— дип бер бүлмәгә кереп югалды.

Яңадан болдырга чыгып култыксага таяндым. Бераздан Әминә ишектән атылып чыгып баскычтан төшеп китте. Миңа әйләнеп карады да:

— Көт, Хәсән, мин озакламам,— дип стационар бинасы ягына йөгерде.

Кызыклы очрашу. Мин аны болай күз алдына китермәгән идем. Әминә аптырап, каушап, югалып калыр сыман иде. Ул, киресенчә, шатланды булса кирәк. Хәтта «Исәнмесез», «Мин сезне көтә идем, Әминә Фатыйховна» дигән сүзләремдәге иронияне дә сизмәде.

Юанаймаган, ямьсезләнмәгән, картаймаган. Бәлки ак халәт кына зифа итеп, матур итеп, яшь итеп күрсәтәдер? Эчтән генә сүгенеп куйдым — әллә ахмаклана башладым инде.

Әминә мине күрүгә үк танымады. Димәк, шактый картаелган. Картаелсын, мин аңа яшьлегем белән мактанырга кайтмадым. Әйтәсен әйтәм дә... Ләкин нәрсә әйтергә?

Бәлки көтмәскәдер? Китеп барыргадыр. Ул чыкканда мин булмасам, барысын да аңлар. Аңлар? Ничек аңлый бит. Мине сагынып, бер күреп китәр өчен генә кайткан, мескен,— дип аңласа? Ире тиешле кешесенә сөйләп көлсә?..

Шактый көттем Әминәне. Поликлиника каршындагы бакчага кереп, утыргычка утырып көттем.

Ниһаять, ул күренде. Бу юлы чапмый, әкрен генә килә. Каршысына чыктым.

— Хәзер, Хәсән, өстемне генә алыштырам,— дип поликлиникага кереп китте. Һәм озак тормыйча чыкты да.

Мин хатын-кызның өс-башына, бизәнүенә игътибар итмим. Минем белән эшләүче, мода артыннан куучы кайбер чикерткәләр моның өчен миңа үпкәләгән булып та кыланалар. Төкерәм мин аларның үпкәләүләренә.

Ләкин Әминә өстендәге куе кызыл күлмәкнең Әминәне тагын да матурлатканын күреп шаккаттым. Кирәк бит, шайтан алгырысы.

Әминә яныма елмаеп килде.

— Я, исәнме, иптәш Иштирәков,— диде,— сиңа хәзер шулай дип кенә эндәшәләрдер инде.

Мин дә үземчә шаяргандай иттем:

— Сезгә житеп булмый — сез Әминә Фатыйховна.

Шулай диюем булды, борыным очына тир бәреп чыгуын тойдым. Шаяртып маташмаска дип ничә тапкырлар сүз биргәнем бар. Кулым-

нан килми ул эш, юк миндә юмор хисе, ә шаярткан булам. Ярый әле Әминә йөземә карамады. Арыган иде ул, арыганлыгы йөзенә чыккан иде.

— Эшегез тыгыз булган ахры,— дидем.

— Бер абзыйны китерделәр. Инфаркт. Хәле шәптән түгел, көчкә саклап калдык шикелле. Син аны беләсеңдер дә әле. Озак еллар газетада редактор булган, син дә анда эшләдең бугай.

Хәйдәровта инфаркт? Минем белән очрашу нәтиҗәсеме? Картлыкмы? Әгәр дә Хәйдәров инфарктының сәбәпчесе мин булсам, бу начар түгел. Кайтуым бушка китмәгән. Тик мин аның үлемен теләмим. Ашыкмасын үләргә. Сәламәтләнә төшкәч үзе белән больницада ятучыларга безнең очрашуыбыз хакында сөйләсен, кешеләрне рәнҗетергә ярамый икән, җәмәгать, дисен, кайчан да булса бер үзенә әйләнеп кайта икән ул рәнҗү дисен. Әлбәттә, аның сөйләве үз файдасынарак булыр, миңа эшләгән этлеген акларга тырышыр. Ләкин барыбер фактны яшереп калдыра алмаячак ул. Вөҗдан газабы дигән нәрсә бар дөньяда.

Әминә янәшәсендә атлаганда мин шул турыда уйлап бардым. Күңелдә канәгатьлек хисе иде. Янымда Әминә икәнлеген дә онытып җибәргәнмен хәтта.

— Я, ничек кайтасы иттең, Хәсән? — диде.

Кактырып-суктырып сөйләүнең мәгънәсе юк иде, турыдан сыптырдым.

— Кайтмадым, килдем.

— Килдем?..

— Килдем. Сезне күреп китәргә дип килдем.

«Сез» сүзенә махсус басым ясап әйттем.

— Кызык,— диде Әминә, ирен чите белән генә елмаеп алды.— ничә ел инде очрашмаганга?

— Төгәл егерме җиде. Көне дә шушы көн.

— Кызык,— дип кабатлады Әминә.— Тормышлар ничек соң?

— Яхшы. Бик яхшы.

— Шулайдыр. Шулай булырга тиеш иде.

— Ничек тиеш иде?

— Синең... Гафу ит, Хәсән, мин сиңа син дип дәшәрмен инде. Сез дисәм көлке килеп чыгар төсле... Синең характерыңда үҗәтлек бар иде. Үҗәт кешеләр максатларына ирешәләр.

Хәйдәров яшәгән урамга килеп җиткән идек. Шикләнеп туктадым.

— Кая барабыз? — дидем.

— Безгә. Мине күрергә килгәнсең ич. Бездә кереп сөйләшеп утырырлык ресторан-фәләннәр юк, авыл җире. Кунакка чәй эчертеп җибәрә торган гадәт тә әлегә онытылмаган.

Әминәнең үзен шулай гади тотуы, минем белән бер дәрәҗәдән торып сөйләшүе, хәтта астыртын гына миннән көләргә маташуы чыгырымнан чыгара язды.

— Юк,— дидем,— мин сезгә бармыйм.

— Нигә?

— Барасым килми.

Әминә минем ни уйлаганымны белә иде шикелле.

— Курыкма, ирем өйдә юк. Ул әнине кайналарыма алып китте. Иртәгә генә кайтачак.

— Мин курыкмыйм,— дип мыгырдандым,— ләкин...

— Ярый, алайса, шушында хушлашыйк. Мин арыдым, ашыйсым да килә.

Шушы минутта үземә читтән карап торсам, йөземә төкерер идем. Кызганыч, мескен идем. Әллә ничә еллар мондый җебегән хәлдә калганым юк иде инде. Борыным гына түгел, бөтен тәнем шабыр тиргә батты.

Әминә Джоконда елмаюы белән миңа карап торды да:

— Киттек,— дип култыклап алды,— синең миңа әйтәсе сүзләрең бар. Нигә үзең белән алып китәргә. Үземнең дә сине болай гына җибәрәсем килми. Күреп каласым килә. Тагын кайчан күрешәбез. Бәлки инде күрешеп тә булмас.

Иярдем. Суярга алып барган мал кебек сөйрәлеп бардым кебек.

Хәйдәровлардан биш-алты йорт аркылы гына яшиләр икән. Ишегалдына кердек. Ишегалды тулы чәчәк — күзләр камашырлык. Чәчәкләр арасындагы таш түшәлгән сукмактан баскыч төбенә килдек.

Әминә сумкасыннан ачкыч алып ишектәге йозакны ачты. Миңа карап елмайды.

— Күрәсеңме, аулак бездә. Ә син куркасың.

Балалары юк микәнни? Хет алары булмасын иде. Кысыр калган Әминә белән сөйләшү миңа җиңелрәк булачак. Нихәтле бәхетле булып күренергә тырышса да, баласыз хатын-кыз язмыш тарафыннан кыерсытылган җан иясе ул.

Әминә мине шаккаттырып тагын уйларымны укып өлгерде.

— Өй тулы бала-чага иде, атлап үтеп булмый иде, хәзер бикле өйгә кайта башладым. Үсеп җиттеләр дә, берәмләп таралалар. Олы кызыбыз институтта — студ-отряд дип, каникулга кайтмады, ике игезәк армиядә. Бер кыз гына үзебезнең янда калды. Ул да бүген әтисенә тагылып бабайларына китте.

Нигә саный ул балаларын? Юриме? Һәрхәлдә, сүз юктан сүз булсын өчен генә түгел, нindидер мәгънә ята.

Дәресен белмәгән бала такта алдында таптанып торган кебек, ни уйларга, ни әйтергә белми бер урында таптанып тордым. Әминә чоланнан киез башмаклар алып чыгып каршыма куйды.

— Сал ботинкаларыңны, ки боларны, аякларың ял итсен. Курыкма, иремнекеләр түгел.

Тибеп очырырга иде аларны. Туктаусыз елмаеп йөрүче хатынга иң әшәке сүзләр белән сүгенеп чыгып чабарга иде. Юк, берни эшли алмадым. Сихерләде ул мине, гипнозлады. Елан авызына суырылып кереп барган куян хәлендә идем. Йотачагын сизәм, беләм, күреп торам, ычкынырга көч таба алмыйм.

Өйгә үттек. Әминә алгы бүлмәгә алып кереп миңа диваннан урын күрсәтте:

— Утырып тор аз гына, теләсәң таянып тор. Эчең поша башласа, менә бүгенге газеталар. Мин — хәзер...

Бүлмәдә салкынча иде. Диванга утырдым да чуалган уйларымны, планнарымны тәртипкә китерергә тырыштым. Болай ярамый иде, болай булырга тиеш түгел. Мин һөҗүм итәсе урынга мине кысрыклыйлар. Хәтта мин адәм рәтле итеп саклана да алмыйм. Мине эләктереп алалар да келәмгә чәпиләр, мин авыз ачып торам. Самбист имеш...

Тактиканы тизрәк үзгәртергә кирәк, юкса харап булам.

Әминә бүлмәдән бүлмәгә тыз-быз чабып йөреп өстәл хәзерләде. Мине ныграк үртәр өчен булса кирәк, авыз эченнән нindидер көй көйләде. Әмма мин үземне кулга алып өлгергән идем инде. Сөйләшүнең теләсә нindиенә әзер идем.

— Булды, чәйнек кайнады. Юынып аласыңмы?

Мөмкин хәтле тыныч һәм салкын булырга тырышып:

— Әлбәттә,— дидем.

— Әйдә, алайса. Безнең монда шәһәрдәгечә үк түгел инде, җәй көннәре тышта юынабыз.

Кабаланмыйча гына ишегалдына чыктым, баганага элеп куелган умывальникны күреп янына бардым.

— Телисеңме, мин синең кулыңа үзем су салып торам.

— Кирәкми, мин аңа өйрәнмәгән.
— Өйрәнерсең. Син дә бит авыл малае. Әй, нигә дип сорап торам, кунак хуҗаның ишәге.
Ул чоланнан чүмеч белән су алып чыкты.
— Ал сабынны, кил бирегә.
Тагын ул әйткәнчә булды — мин ул кушканнарны эшләдем.
Чәй эчәргә утыргач, Әминәнең хәйләкәр, серле елмаюы югалды, йөзе житдиләнде, күзләре моңсуланды. Кыз чагын хәтерләтеп, күзгә туры карамый башлады. Ашыкмый гына бер чынаяк чәй эчте. Тагын ясады. Күрәсең, ул минем сүз башлавымны көтә иде. Мин дә ашыкмаска уйладым. Беренче ул һөҗүм итсен. Мин сабыр гына сакланырмын. Аннан һөҗүмгә күчәрмен.
Ниһаять, Әминә түзмәде:
— Я?
— Нәрсә я?
— Сөйлә.
— Ни сөйлим?
— Нигә кайттың?
— Әйттем.
— Шуннан?
— Шул.
Сөйләшү өчен мондый форма сайлавым диванда утырганда башыма килгән яңа тактика иде. Беренчедән, ул миңа кыюрак, әрсезрәк, өстенрәк булырга мөмкинлек бирә, икенчедән, үз өендәге, өстәле артындагы «кунак»ның үзен шулай тотуы Әминәнең ачуын китерәчәк. Ачуы килгән кеше сүзләрен үлчәп бетерми, җиңелгәнен сизеп кычкырырга тотына, истерикага бирелә. Истерикага бирелгән хатын-кыз тадәттә елап җибәрә. Миңа бу очракта шул гына кирәк. Күрәм, ул, кызганычка каршы, мин көткәнчә бәхетсез түгел, тормышы көйләгә охшый. Һич югында, кәефен кырып, мөмкин булса, елатып китим. Минем каршымда Джоконда булып кыланмасын.
Әминә каш астыннан гына миңа сөзеп карап алды да яңадан башлады.
— Нигә кайттың син?
— Әйттем.
— Я, менә күрдең инде мине. Шуннан?
— Шул.
Әминә кинәт мине сискәндереп шаркылдап көлеп җибәрде. Минем этләшүемне шаярту, кылану дип кабул итте ахры.
— Әйдә, яңабаштан башлыйбыз,— диде ул көлә-көлә.
Үзенә кушылып көлүемне көтсә дә, мин житди идем. Бик житди идем.
— Башлыйк,— дидем.
— Нигә кайттың?
— Әйттем.
— Егерме җиде елдан соңмы?
Әһә, үзгәртте. Карап карыйк, ничек дәвам итәр.
— Соң булса да уң булсын.
— Сагынып кайттым димәкче буласыңмы?
— Димим.
— Димәк, болай гына, күрергә генә?
— Күрергә генә.
— Күргәчтен дә нигә китеп бармадың? Нигә көттең?
— Көтәсем килде.
— Әйтер сүзең бар идеме?
— Юк иде.

Әминә нидер сизенә башлады. Озак итеп сынап күземә карап торды. Мин дә күзләремне яшермәдем. Аның хәйләкәр елмаюын үземә алып, мыскыллы елмаю өстәдем. Әминәнең күзләре тагын моңсуланды.

— Нигә кайттың син?

Бу инде сорау түгел иде. Тавышы да калтыранып чыкты. Сынды тәкәббер хатын. Хәзер ул кычкырырга тотынып, мине куа башлар. Куысын, тыныч кына көлеп чыгып китәрмен.

— Нигә кайттың син? Ни калган сиңа монда? Мине күрер өченме? Нигә элегрәк күрергә теләмәдең? Нигә егерме жиде ел көттең? Мин беләм, Хәсән... Мин сине бик яхшы беләм. Синең миңа әйтер сүзең бар. Шуны әйтер өчен кайтканыңны сизәм. Хәерле сүз түгел ул. Син миннән үч алырга кайткансың. Ни өчен?.. Я, ничек алмакчы буласың үчеңне? Мин синең кайчан да бер кайтачагыңны тоеп йөрдем. Мин эгоист сүзен белми идем әле, синнән курка гына идем. Син шатлана аласың, мин кияүгә шашып яратып чыкмадым. Ни өчендер, сине көттем, алты ел көттем, син күренмәдең. Димәк, син үзгәрмәгәнсең. Тамчы да үзгәрмәгәнсең. Яратам дия идең бит. Яраткан кешең белән әз генә булса да кызыксынырга була иде. Мин синең белән кызыксынып тордым. Өйләнмәгәнеңне, беркемгә карамаганыңны да беләм. Мине раткангамы? Ялган. Мин риза булып сиңа кияүгә чыксам да син барыбер миннән үч алачак идең. Ташлый идең. Синең яратуың мәхәббәт түгел иде, синең алдыңда җебеп төшмәгән бер кызыйны буйсындыру теләге генә иде. Мин ишетеп тора идем, син һәрвакыт берәр кеше ачуыңны китерсә, күрсәтермен әле дия идең. Күрсәтергә кайттыңмы? Сизәм, син үзеңә күрә дәрәҗәле кешедер, синең турыда мактап күп сөйлиләрдер. Шуннан ни? Мин дә синнән ким түгел. Берәү дә беркемнән дә ким түгел бу дөньяда. Сине эшеңдә яраталармыдыр белмим, мине яраталар. Ирем дә, балаларым да ярата. Я, ни әйтмәкче буласың миңа? Зарланганымны көтмә, Хәсән, мин мескен түгел.

Бу юлларны укучыларның, Әминә өзгәләнә-өзгәләнә кычкыргандыр, күз яшьләренә тыгылып сөйләгәндер, дип уйлаулары мөмкин. Юк, Әминә тыныч иде. Гаҗәп дәрәҗәдә тыныч иде. Һәр сүзен, һәр җөмләсен уйлап әйтте. Һәм үзенең шул тынычлыгы белән, ни өчен кайтканымны дөрес сизеп, аны йөземә бәреп әйтеп мине янәдән каушатты. Мин үзем аңа кычкырырга әзер идем. Көчкә тыелып тордым.

Әминә моны да сизде, сүзне икенчегә күчереп:

— Чәй ясыйммы, Хәсән? — диде.

— Чәй?..

— Син тынычлан... Артыгын әйтеп ташладым бугай, гафу ит. Мондый сүзләрне бәлки беренче ишетүеңдер. Ачуланма миңа, уйла гына. Син акыллы кеше бит. Эгоизм — ул чир, Хәсән, аңардан котылырга кирәк сиңа. Яшәвеңнең тәме юктыр синең. Зур эшләр эшлисеңдер, шул хезмәтләреңә тиң бул. Ә син, минемчә, вакланасыңдыр. Эгоист кеше тормышта бик вакчыл була. Ул юнәлешен югалта. Ишетәсеңдер, хәтта олы галимнәр дә вакланып бетәләр... Кызганам мин сезне, Иштирәков... Сез кызганыч кеше.

Йөрәгем урынынннан атылып чыгарлык булып тибәргә тотынды, хәлем бетеп урындык артына сөялдем. Күзләрем томаланды. Шул томан аша Әминәнең күзләрендә мөлдерәмә тулы яшь сиздем. Өзеп әйтә алмыйм, бәлки үземнең күз яшьләрем булгандыр. Бу коточкыч халәттән ычкынырга, котылырга кирәк иде миңа. Ничек? Китәргә кирәк, ахмаклык эшләмичә генә китәргә кирәк.

Әкрен генә урынымнан күтәрелдем. Шунда Әминәнең:

— Мә, Хәсән, сөлге, борыныңны сөрт,— дигән тавышы бөтен тормозларны берьюлы ычкындырып ташлады.

Калганын бик начар хәтерлим.

— Житте, кабәхәт!!! — дип кычкырдым бугай. Янгына да суктым шикелле. Гафу да үтендем, еладым да сыман. Әминә мине тынычландырырга тырышты. Үзе дә елады, озата чыкты, ботинкаларымны киндерле кебек. Барысы да төштә булган сыман, төштә күргән шикелле...

## 6

21 сентябрь 1980 ел.

Көндәлекне дәвам итәргә кирәк. Ләкин ничек — белмим. Юк, язасы сүзләр беткәннән түгел, авылга кайтып килү вакыйгасы да ахырына чаклы язылмаган. Сүзләр күп, әмма нервлар какшаган — һәрбер җөмлә гаять зур авырлык белән языла. Һәр сүзне язган саен йөрәгемә каләм белән кадап-кадап алам сыман. Авыртуга чыдый алмый тешләремне кысам, күздән яшь атылып чыга. Бәлки ул авырту да түгелдер, гарьлектер. Тәкәббер җанның мескен хәлдә калуыннан туган газаптыр. Кайсы тәкәббер үзенең хурлыгы хакында бүтәннәргә сөйли? Ә мин сөйләп маташам. Ни өчен? Кемгә? Үземә булса, нигә кирәге бар? Бушану өченме? Шулайдыр. Җинаять кылганнар да, хөкем карары укылганнан соң җиңел сулап куялар ди ич. Бушанып калгач, җиңел була, имеш. Мин дә бәлки үземә үзем хөкем карары язамдыр?.. Димәк, мин җинаятьче?

Юк... Юк!.. Юк!.. Мин җинаять эшләргә теләмәдем. Теләмәдем. Җинаятьче җинаятьне салкын кан белән эшли. Мин хәтта ни эшләгәнемне дә белештермәдем. Барысы да төштә күргән сыман...

Көндәлекне дәвам итәргә кирәк. Кайда тукталган идем? Әйе, Әминә мине тынычландырырга тырышты. Үзе дә елады, озата чыкты...

Исемә килгәндә юл кырыенда утыра идем. Яныма автобус туктаган. Кычкыра. Борылып карадым.

— Әй, кая барасың? — ди шофер.

— Ә?

— Кая барасың диләр сиңа.

Станциягә дип әйтергә телим, телем әйләнми.

— Станциягәме? — дип сорый шофер.

Башымны селкеп кенә җавап бирәм.

— Әйдә утыр, алайса.

Кузгала алмыйм.

Тавышлар ишетелә:

— Исеректер ул...

— Шофер, әйдә, соңга калабыз. Бетмәс монда...

— Туктагыз, бәлки авырудыр.

Бер-ике кеше автобустан төшеп яныма килделәр.

— Кирәкми,— дидем. Әкрен генә тордым. Хәл юк, баш әйләнә, чак егылмадым. Автобустан төшүчеләр култыклап алдылар, автобуска керергә булыштылар. Кемдер урын бирде.

Автобус кузгалып китте. Исерек түгеллегемне белгәч, сораштыра башладылар.

— Кай җирең авырта?..

— Үзең кайсы як кешесе?..

— Нишләп анда утыра идең?..

Берсенә дә җавап бирмәдем. Җавап бирергә теләсәм дә, рәтем юк иде. Нервлар какшаган иде минем. Артык арысам, борчылсам, дулкынлансам, шулай була — хәлем бетә минем. Ләкин бу чаклы ук булганы юк иде әле. Тынычланырга кирәк дип күзләремне йомдым. Андый чакта шулай эшлим, йокыга китәм, һәм әйнәк әкренләп үтә.

Тик йокы алмады бу юлы. Станциягә җиткәч, автобустан үзем төштем төшүен, әмма барыбер хәл юк иде.

Поездга утыргач та хәл яхшырмады. Анда да йоклый алмадым.

Квартирымның ишеген көчкә ачып кердем, бармаклар тыңламый, ачкычлар кулдан төшеп китә.

Стенага таяна-таяна бүлмәгә уздым һәм, үз гомеремдә беренче тапкырдыр, чишенеп тә тормыйча диванга аудым.

Бөтен ихтыярымны җыеп үземне йоклап китәргә мәҗбүр иттем... Йоклап кителгән. Ләкин йокы булды микән ул? Саташу гына булгандыр. Куркыныч саташу. Кайдандыр Сафиуллин килеп чыкты. Үзе кычкырып көлә, үзенең күзләреннән мөлдерәп яшь ага. Кочагында бер кочак кәгазь акчалар һәм минем кандидатлык диссертациясе. Шуларны бергә буташтырып бөгәрли-бөгәрли дә авызыма тутыра. Тыным кысыла, кычкырмакчы булам, тавышым чыкмый. Ул да түгел, култыклашып Хәйдәров белән Сәлимҗан килеп керәләр. Икесе дә кәфенгә уралганнар.

«Менә ул, менә ул!» — дип Сафиуллин миңа төртеп күрсәтә. Хәйдәров белән Сәлимҗан икесе берьюлы өстемә авалар. Үзләре туктаусыз ыңгырашалар. Этеп төшермәкче булам үзләрен, Сафиуллин кулларыма асылына. Поездда очраган егетләр-кызлар да шунда икән, җыйнаулашып башымны тәпиләр. Кинәт барысы да югала. Янымда Әминә генә. Кысып кочаклаган. Туктаусыз үбә. Үпми — иреннәремне тешли. Ниһаять, аңардан ычкынам. Оча башлыйм. Әминә мине куып тота да кыпкызыл күлмәгенең итәге белән тирләгән борынымны сөртә. Ышкыпышкып сөртә...

Уянып киттем. Шабыр тиргә батканмын. Өянәгем, күрәсең, узган. Бүлмә эче караңгы. Баш инде әйләнми, гүләп кенә тора. Селкенмичә шактый озак яттым. Саташуымны анализлап карарга тырыштым. Берни дә килеп чыкмады. Төшме ул, өнме икәнен аера алмадым.

Чишенеп ятарга кирәк иде — торып утырдым. Анысы яхшы, куллар, аяклар, көчләре булмаса да, мине тыңлыйлар.

Ут кабыздым. Сәгатькә карадым. Ун тулып узган. Алгы бүлмәгә чыгып кухняга, ваннийга кереп, бөтен җирдә дә утларны кабыздым.

Өч тәүлеккә якын рәтле-юньле ашамавым искә төште. Ашыйсы килми, авызның тәме юк, шулай да ни дә булса капкалап алырга кирәк. Югыйсә, ныклап торып егылуым мөмкин. Бәлки режимнан чыгуым да хәлсезләнүемә ярдәм иткәндер.

Ашарга кирәк дип кухняга керәм дә, нигә кергәнемне онытып чыгып китәм. Бәрелеп-сугылып квартира буйлап йөрим. Бушлык, бушлык, бушлык...

Ни өчендер китап шкафы янына килеп, китапларга карап тордым. Күзем шкафның бер бүлегендәге — пыяла артындагы шешәгә төште. Нинди шешә соң әле ул?..

Шешәне кулыма алып озак итеп этикеткасын укыдым. Коньяк икән ич. Әллә кайчан, бер кирәге чыгар дип алган идем бугай. Торган да торган. Үзем эчмим, квартирага кеше-фәлән килеп йөрми — торган да торган.

Туктале... Нервлар какшаганда, депрессия вакытында ярдәме тия дип сөйлиләр. Эчеп исерәсең дә, имеш, кәеф күтәрелә, аннан онытылып йоклыйсың. Иртәгесен, имеш, сау-сәламәт килеш уянасың. Миңа бу депрессиядән котылырга кирәк. Юкса харап булачакмын, күңелем сизә. Өянәк озакка сузылды, хәерлегә түгел.

Кухняга кереп, коньякны чәй эчә торган касәгә тутырып салып эчтем. Үңәчләремне яндырып төшеп китте. Тагын салып эчтем... Тагын... Тагын...

Кәеф күтәрелмәде. Киресенчә, ниндидер сагыш басты. Кара сагыш. Дөнья тагын да буш, мәгънәсез булып тоелды. Үткән гомер мираж гына булган, киләчәк — юк. Әгәр дә үлеп китсәм, кем елар? Яшәп кемнәрне шатландырам? Нигә кирәк бу тормыш? Менә бу касә өстәлдән төшеп

ватылса, аны хет мин кызганачакмын. Чөнки ул ничә еллар миңа бердәнбер киңәшче, бердәнбер иптәш булды. Мин аңа ияләшкән, чәйне бүтән савыттан эчсәм, тәмсез. Әйе, ул төшеп ватылса, миңа күңелсез булачак. Ә мин төшеп ватылсам?..

Касәне идәнгә атып бәрдем. Чәлпәрәмә килеп ватылды. Аннан өстәл өстендәге ваза, коньяк шешәсе идәнгә очты. Холодильник гөрселдәп ауды, алгы бүлмәдәге трюмо егылды, хрусталь люстра коелып төште... Тагын ниләрдер кырылды. Нигә кирәк? Ни юаныч миңа алардан?! Шулармы минем бәхетем?!!

Кырдым, җимердем. Бу квартирада нишлиләр икән дип күршеләрдән берәү дә кереп карамады. Чөнки белмиләр алар мине, мин дә аларны белмим. Хәтта исәнләшмим дә.

Урамга атылып чыкканым хәтеремдә. Каядыр йөгергәнем хәтеремдә. Нигә чыкканымны, нигә йөгергәнемне белмим.

Бер урам чатында басып торучы егетләргә очравым исемдә. Йөгереп килгән уңайга берсенә нык кына суктым шикелле. Шуннан арысын хәтерләмим.

Һәм менә мин ике ай инде больницада. Ярым үлгән хәлдә милиция машинасына салып китергәннәр. Исән калырыма ышанмаганнар. Ямый, тегә, ялгый торгач, адәм кыяфәтенә керттеләр. Хәзер инде үз аягым белән туалетка бара алам.

Милициядән килеп сораштылар. Хәтерләмим, исерек идем дидем. Башлап үзем сукканымны әйтмәдем.

Эшләгән урынымнан сирәк булса да килеп хәлне беләләр. Бүтән беркем юк. Бер кемем юк.

Уйланырга вакыт күп бирелә. Ләкин уйларның берсе дә шатлык китерми. Үземне рәнҗеткәннәрдән үч алырга кайтам дип, үземнең шактый ук вак, түбән җанлы мескен бәндә икәнлегемә төшендем. Мине рәнҗеткәннәр диюем, минем тарафтан рәнҗетелгәннәр икән ләбаса. Янә мин ялгыз икәнлегемне, япа-ялгыз икәнлегемне аңладым. Ялгызлыкның куркынычлыгы, үзәк өзгеч нәрсә икәнлегенә төшенеп барам кебек. Әмма ул ялгызлыктан чыгу юлын белмим. Миңа кырык биш яшь... бит инде. Кырык биш яшь! Нәрсәгә ирештем соң әле мин? Фәннәр кандидаты? Шул гына. Шуннан ни? Палатада утыз яшьлек бер егет ятып чыкты. Ул инде ике ел фәннәр кандидаты. Ләкин аның ул дәрәҗәгә исе дә китми. Шаярта, көлә. Аның янына керергә дуслары, туганнары чират тора. Ә минем? Кемгә үз серләремне сөйлим?

Ярый әле шушы көндәлек бар. Язуы авыр, бик авыр булса да язам. Адәм баласы ни чаклы көчле булмасын, аңа бушанырга кирәктер. Кайгы, шатлыкларыңны кем беләндер уртаклашырга, бүлешергә кирәктер. Кем беләндер дигәнем — минем шушы көндәлегем. Киләчәктә ниләр буласын, ничек яшәячәгемне ачык итеп төсмерли алмыйм. Киләчәгемә өметем аз.

Соңгы сүз итеп шуны гына әйтәм, көндәлегемнең бу өлешен үзем өчен генә язмадым, кемдер табып укып, мине акламаса да — аклау өмет итәргә хакым да юк — бәлки кызганып куяр дип яздым. Бәлки гыйбрәт алучылар да булыр дип яздым.

*1980* *Крутушка — Казан*

## Марсель Галиев

### Яңгыр шавы

Яңгыр шавы уятты да куйды
җанда күптән сүнгән учакны.
Елау хәтта оят түгел иде
моңнан авырайган ул чакны.

Елау хәтта оят түгел иде...
Бу мизгелнең беләм бәясен:
тамчыларга бүлдем дөньялыкның
әкиятләрдән калган хәйләсен.

Вакыт белән авырып яткан чакта
кайтарасы килеп үткәнне,
яңгыр шавы тәрәз аша кереп
пышылдады... яшим икәнне.

Мин кузгалып күкрәгемне баскан
кабер ташларыннан арындым.
Тавышлары истә, исемнәре...
Мин бит сезне шундый сагындым.

«Кайтарыгыз мине!» дигән әрнү
килә икән
йолдыз аша баккан күзләрдән,
кичерегез, әгәр ишетмәсәк,
без бит инде шундый үзгәргән.

...Вакыт белән авырып яткан чакта,
дәва алмаганда бу тәнне,
яңгыр шавы, син искәрттең миңа
киләчәктән килер үткәнне.

### Ераклык һәм вакыт ярыннан

Томан катыш салкын яңгыр керде
ачылгач та поезд ишеге.
Каршылавы көзнең — хушлашуы —
авырып яткан Тукай шикелле.

Кереп килә поезд шәһәремә.
җилпеп ачып яңгыр пәрдәсен.
Сагынылган шәһәр манзарасын
ачыграк килә күрәсе.
Алтын җәтмә булып күзгә төшә
урам утларының шәүләсе.

Кайткан саен неон хәрефләрдән
була иде: «каза», я «азан».
Бүген әнә бөтенесе төзек,
яшел булып балкый ул — «Казан».

Иске вокзал, саумы! Башланышы,
тукталышы синдә юлларның.
Язмыш кәрваннарын һәр тарафтан
кабул итсен яшел утларың.
Поезд туктый. Бар да төшә гүя
ераклык һәм вакыт ярыннан.
Ул бит мине каршыларга тиеш:
түзмим, күзлим, эзлим перроннан.
Арттан килеп кемдер күзне каплый:
«Онытмаган булсаң, кулдан бел...»
Күңелемне били кайнар дулкын —
сихәтле чәй кебек туган тел.

●

Мин тагын синең ярыңда,
мин тагын синең якта.
Күзләрең белән көлсәң дә
күңелең белән якла.

Уйнале язмышым белән,
карамыйк артыбызга.
Ясалма ягымлылык та
килешә хатын-кызга.

Гүзәл булып тууыңа
гаепле түгелсеңдер.
Сиңа сарылган карашлар
чайпалып түгелсен бер,

уйнале, башны әйләндер,
тезләнгәнем юк күптән.
Оялсын тыйнак күңелем
гөнаһлы гүзәллектән.

## Исәнбәт тәрәзәсе

Урам тын. Шәһәр йоклаган.
Мең тәрәз арасыннан
бер якты сызылып төшә
тыныч төн карасына.

Йокламый, бер ул йокламый,
булсынга дип, булсынга:
ап-ак чәчле вакыт булып
иелгән дөньясына.

Үткәннең көлен аралап,
уятып тавышларын,
тыңлый ул халык бәгырен,
киләчәк язмышларын.

Тыныч төн... Йолдыз коела
чиксез күк иләгеннән —
гасырлар төшеп калгандай
бу тарих итәгеннән.

...Таң беленә. Ә ул уяу —
чал чәчле күрәзәче.
Соңгы йолдыз кебек якты
Исәнбәт тәрәзәсе.

## Кичке шәфәкъ

*Очты дөнья читлегеннән*
*тарсынып күңлем кошы.*

**Габдулла Тукай**

Кичке шәфәкъ. Утыргычта картлар,
мин әтине читтән күзәтәм.
Мин беренче кабат белгән чактан
вакыт аны ничек үзгәрткән.

Чәчләрендә каен яктылары,
күзләрендә күңел моңнары.
Тезләрендә авыр булып ята
тал тамыры кебек куллары.

Тәмугъ-оҗмах капкаларын җирдә
шушы куллар ачып кергәндер.
Кайгы-шатлыкларга чама белгән
туган ягым гына бирдәнбер.

Кара толым кебек буразналар
аның гомереннән узгандыр.
Дөнья гизеп кайткан күңел кошы
тал-тирәккә килеп кунгандыр.

Кичке шәфәкъ. Мин әтигә карыйм,
колак салам һәрбер сүзенә.
Дөнья читлегенең шәүләләре —
җыерчыклар аның йөзендә.

●

*Салих Сәйдәшев турында уйлану*

Соңгы аккорд, акчарлаклар булып,
дулкыннарга ятты мәллә?
Соңгы аккорд, сандугачлар булып,
юкәләргә басты мәллә?
Кем ишетте
соңгы аваз кайсы кылдан сирпелгәнен?
Кемнәр күрде
ул авазның нинди төскә әверелгәнен?
Яфракларның яшел кан тибешен тыңла,
яңгыр шавын,
болытларның күкрәүләрен тыңлап кара,
бураннарның җебен-җепкә аерып кара...
Кем ишетте?..
(Язылачак бөек симфония
шул аваздан башланырга тиеш иде...)

Пәрәвездәй тирбәлә күк
көйдән артып калган шул авазлар!
Ялгыз булмә:
соңгы дигәнне ишеткәнгә мәллә
стенада сөенеп көлә,
тураймакчы булып, бөкере шәүлә?!

## Тын иртәсе кышның

*Мостай ага Кәримгә*

Башын кыңгыр салып атлап бара,
Йөз яшәрлек чыршы асларыннан.
Карлы таңда туган шигырь юлы
Башлангандыр шәрыкъ дастаныннан.

Чигенмәле, тынлык, иркенлек бир
Әрнүләрдән торган уйларына.
Чыршыларның кызыл энәләре
Янып төшә әнә юлларына.

Кулын артка куеп атлап килә...
Таң уянган яшь кар җылысыннан.
Тиен булып күчә җитез Вакыт
Карлар коеп чыршы ылысыннан.

Кулын куеп артка салмак кына
килә заман белән бәхәсләшеп.
Йөрәгендә утлар дөрли микән,
Учларына ала кар тәлгәшен.

Көн яктысы төшкән эзләр карда.
Уйланыр ла чагы бу дөньяның.
Ни дип җавап бирер җирем әгәр,
Күкләр дәшсә изге шагыйрь җанын?..

## Нурия Измайлова

### Ракеталар, нервлар һәм акыл

Ракеталар төбәп, корып куелган,
Ә нервлар җәя кебек киерелгән.
Тартылыр да сынар җәя, ук атып! —
Шуны көтә ракеталар ни вакыт!

Бу нервлар чыдамлыгын югалтса,
Тик бер җәя тик бер генә ук атса,
Әй, нәни Җир, әй газиз Җир, нишләрсең?
Утта янып, көлгә калып очарсың!..

Мин ышанмыйм андый хәтәр минутка.
Акыл-алла! Җир нәселен корытма!
Үзең дә син — Җир җимеше, онытма.
Ракеталар — синең җимеш, курыкма.

Һәм курыкма җәяләрдән — нервлар
Син кушмасаң, тартылмыйлар, сынмыйлар.
Берүк безгә Җиребезне коткарыш!
Синдә генә, синдә генә ышаныч.

### Син гармунчы булсын өчен...

Их, сыздырасың, гармунчы!
Мин дә сыздырам сыман:
Ун бармагым биеп тора,
Бөгеләм дә сыгылам.

Гармуныңны мин алсам да,
Уйнап җибәрер кебек.
Бир әле! Сузып карыйм бер! —
Булыйм гармунчы егет!

Юк шул... Синең гармуннарың
Синдә генә әйттерә.
Миңа дәрман бирмәгән шул,
Биргән бары дәрт кенә...

Ә шулай да син «Берүзем
Уйныйм» диеп уйлама —
Миңа дигән дәрманны да
Биргән синең кулларга!

Ун бармагым биеп тора,
Бөгеләм дә сыгылам.
Син гармунчы булсын өчен,
Мин шулай хисле туган.

Минем дәртем-хисләрем дә
Гармуннарыңа тулган.
Их! Сыздырасың, гармунчы!
Мин дә сыздырам сыман...

## Март кояшы астында

Әй, җылыта кояш кышны,
Әй, балкыйлар офыклар!
«Уф авыр!.. Тыным бетә...» дип
Изрәп ята күпрек кар.
Авыр булса да, түз инде!
Җиңеллек килер тиздән:
Арчылырсың, ачылырсың,
Бәхет түгелер синнән —
Кояш белән икегездән
Туар тәти малайлар.
Елтыр-елтыр йөгереп китәр
Гөрләвек булып алар!
Котлап кояш малайларын,
Шук тамчылар биерләр,
Бәби туена бүләккә
Яшелләнер бөреләр,
Бәбиләргә җыр җырларга
Матур кошлар килерләр,
Елтыр күзле улларыгыз
Чылтырашып йөрерләр,
Терелтеп Җир-әбиләрен
Яңа тормыш бирерләр!

## Күптәнгечә... яз

Сергә төренеп, нурга коенып,
Сихри көннәр килделәр.
Көйгә салсаң, җыр булырлык
Шигъри көннәр килделәр.
Аералмыйм бу көннәрдә
Вакыт белән вакытны:
Үткән белән бүгенгене,
Яшьлек белән картлыкны.

Күптәнгечә очып йөрим —
Элеккеге төш керә.
Дөньялардан күптәнгечә
Нечкә-татлы ис килә!
Үткәннәрдән көмеш тама —
Тамчы-тамчы хис килә...
И нәфис хис! Атыйм сине
Бары «шигъри» дип кенә.
Аңлаталмыйм — сүзләр җитмәс,
Җырламыйм — көй табылмас.
Синең көең — күптәнгечә —
Тагы яшьлек, тагы яз!
Күптән йоклаган бөрене
Уята ул күңелдә.
...Үткән гомер кала икән
Әверелеп шигырьгә.
Яз саен бер — шул шигырьләр —
Тамчы-тамчы түгелә...

## Беренче мәхәббәт

Алсуланып офык яна
    Язгы таңнарда.
Без бергә кайтабыз язга,
    Офык янганда.
Үзебез дә алсу гына,
    Оялчан гына.
Бездән шундый сафлык сибелә! —
    Күзләр чагыла.
Безнең хәтта тәннәр дә юк,
    Бар тик җан гына.
Сүзләр дә юк. Сүзләр һаман
    Әйтми калына...
Хәер, үзебез дә юкбыз
    Фани дөньяда:
Дөнья тар тәүге сөюгә —
    Калмый ул анда.
Без — таңда күргән төшләрдә
    Һәм без хыялда.
Алсу офыкка төренеп
    Йөрибез язда...

# И ГҮЗӘЛ ҖИР, И ГАЗИЗ БАЛА!

Җәй җитте. Ишегалдында балалар чыр-чуы. Кайсы сызыклы уйный, кайсы велосипедта оча, кайсылары тагын нидер эшли. Мин ачык тәрәзәдән аларга карап торам. Шундый матурлар, сәламәт, шат йөзле алар. Күңелләрендә бер генә болыт та юк, бер генә борчулары да юк аларның. Әти-әниләре сөеп-назлап үстерә, ашау-эчү, кием-салым турында уйлыйсы юк, йомшак җылы урыны әзер. Бик бәхетле безнең балалар.

Әлеге балаларга караган саен, йөрәгемне телеп үткән, вакыт үтсә дә һич онытылмый торган бер вәхшилек искә төшә. Бервакыт телевизордан Кампучияне күрсәттеләр. Иенг Сари һәм Пол Пот башкисәрләре, Кытай җитәкчеләре өстерүе белән Кампучиянең гади халкын кырып бетерергә исәп иткәннәр иде. Солдатлар, йөкле хатыннарны үтереп, карынындагы бала башларын бөти итеп тагып йөри торган булганнар. Кемнең күпме бөтие бар, шул «батырлыгы» белән дан ала икән. Я, әйтегез, моннан да артык вәхшилекнең булуы мөмкинме? Ап-ак сөтен, изге сөтен имезеп ана үстергәнме аны? Без, Бөек Ватан сугышы чоры балалары, фашистларның ерткычлыгын күп ишеттек, китаплардан укып, кинолардан күреп җаннарыбыз тетрәнде. Әмма минем, балалар үстергән, инде олыгаеп барган гади бер ананың күңелен айкаган бу вакыйга әле хәзер, соңгы елларда гына булган хәл.

Чыңгыз Айтматовның бер әсәрендәге манкуртлар сыман ата-анасын, туган илен, кардәш-ыруын, танымый, белми торган адәм кыяфәтле җанварлар эшләгәндер мондый вәхшилекне. Ана сөте белән кермәс андый әшәкелек, капитализмның бүре законнары кешеләрне шундый ерткычка әйләндерә, ерткыч та эшләмәс эшләргә өйрәтә. Чик куярга, чик куярга кирәк моңа! Кичекмәстән бөтен чаңнарны кагарга. Күңелендә кара уй йөрткән, илнең, җирнең тынычлыгына кул күтәргән, ут белән янаган дошманнарга каршы чыгарга кирәк! Балаларыбыз иминлеге өчен, җиребез тынычлыгы өчен көрәшергә кирәк.

Шагыйрь Илдар Юзеевның бик матур бер җыры бар, «Бөркет турында җыр».

> Ә баласы — күз карасы —
> Сизмәде дә яшенне.
> Ике канат, канап-канап
> Зур давылдан яшерде...

Бөркет булып бөркет тә баласы өчен ничек җан ата, ничек көрәшә! Аналар турындагы җыр, балаларына җил-яңгыр, ут-давыл тидерми торган ана күңеле турындагы җыр!

Ана күңеле... Кайсы гына ана нарасыеның күз яшен күрүгә чыдап тора ала икән?! Кем генә баласының бәхетле булуын теләми икән! Балалар елы уңае белән үткәрелгән Бөтендөнья конференциясен искә төшерәм мин.

Мәскәүдә ак төнле, сары, кара төнле аналар җыелган иде. Бөтен дөньядагы прогрессив хатын-кызлар вәкилләре, үз балалары өчен генә түгел, җир шарындагы бөтен балаларның да бәхетле булуы өчен көрәшкә баскан аналар җыелган иде.

1979 ел Берләшкән Милләтләр Оешмасы тарафыннан Халыкара Балалар елы дип игълан ителгән иде. Планетабыздагы балаларның тормышын җиңеләйтү өчен бөтен балалар да тыныч, шат, бәхетле булсын өчен игълан ителде бу ел... «Балаларның тыныч һәм бәхетле киләчәге өчен» дип аталган әлеге конференциянең төп максаты — җир йөзендәге балаларны сугыш афәтеннән, ачлык-ялангачлыктан саклау, аларның киләчәген якты, бәхетле итү өчен бөтен мөмкинлекләрне файдалану булды.

1959 нчы елда ук инде Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генеральный Ассамблеясы тарафыннан балалар хокукы Декларациясе кабул ителгән иде. Ун принциптан торган бу Декларация җир йөзендәге бөтен балаларның да хокуклардан тигез файдалануын таләп итә. Менә ул хокуклар: баланың туган көненнән үк үз исеме һәм үз иленең гражданы булырга хакы бар; бала социаль тәэминат шартларыннан файдаланырга тиеш, ягъни сәламәт булып үсүе өчен балага бөтен шартлар булдырылырга тиеш. Ашарга ризыгы, яшәргә җылы куышы, уйнарга уенчыгы булу һәм авырса медицина ярдәме алу хокукы Декларациядә аерып күрсәтелгән. Сәламәтлеге начар балалар махсус кайгыртучанлык тоярга тиешләр. Баланың бөтен яктан да җитлеккән булып үсүе өчен аның кечкенәдән үк әти-әнисе тәрбиясендә назланып, сөелеп яшәве шарт. Ачлыкны, ялангачлыкны, күз яшен күрмәсен бала!

Бала белем алырга, җәмгыятькә файдалы кеше булып үсәргә хокуклы. Бала белән сату итәргә, аны авыр эшләрдә файдаланырга, аны кимсетергә һәм кагарга ярамый. Бала үзара дуслык һәм теләктәшлек шартларында үсәргә, үзенең иле һәм халкы өчен кирәкле кеше булып үсүен аңларга тиеш.

Безнең өчен бик табигый булган, Конституциябез тарафыннан закон белән беркетелгән бу хокукларның берсе дә үтәлмәгән илләр күпме әле?!

Хәзерге вакытта җир йөзендә 1 миллиард 600 миллион бала бар. Халык санының өчтән береннән артыграк дигән сүз бу. Балаларның күпчелеге планетабызның экономик яктан артта калган районнарында яши. Аларны ашатырга, киендерергә, торак бирергә, укытырга һәм медицина ярдәме күрсәтергә, үсмч эш бирергә ул хөкүмәтләрнең көче дә, теләге дә җитми. Менә саннар: дөньяда 600 миллион бала хәерчелектә яши, 200 миллион бала көн саен ач кала, 1 миллиард баланың торак шартлары канәгатьләнерлек түгел, өчтән бер өлеше хәрабәләрдә яши. Планетада ел саен 100 миллион бала туа, шуның 70 миллионына туганда медицина ярдәме күрсәтелми. Авыл җирләрендә яшәүче балаларның 85 проценты чиста суга тилмерә. Ризыкларында «А» витамины җитмәү сәбәпле, ел саен 100 мең бала сукырая, 100 миллион баланың укырга мөмкинлеге юк, алар хәтта саный да белмиләр, хәреф тә танымыйлар. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның бары бер проценты гына ясле һәм бакчаларга йөри.

Минем «Балалар гаепли» дигән документаль фильм караганым бар.

Экранда күзләр. Бер йотым суга тилмергән нәни кызчык күзе. Ажгырып төшкән бомбалардан коты алынган йөкле хатын күзләре... Тамагы туярына инде өмете өзелгән буш караш ул күзләрдә. Ятимлектән сакларга үтенгән ялварулы караш ул күзләрдә, яратуны, назны көткән сабыйлар карашы. Бу картинаны тетрәнми карый алмыйсың. Күзләрдән яшь ага, йөрәккә кан сава аны караганда.

... Һәр анага үз баласы бик газиз. Ул аны җил дә тидерми үстерергә тели, бәхетле итәсе килә. Әмма...

Менә Испания, фашизмның үлем куркынычын беренчеләр булып испан балалары татый. Икенче бөтендөнья сугышы Көнбатыш Европаның уннарча илендә кабынды. Фашизм балаларга үлем алып килде. Экранда нәни баласын күкрәгенә кыскан ана. Ул коты очып күккә карый. Свастикалы самолеттан бомба яңгыры ява. Фашизмның бу вәхшәтен без онытa алмыйбыз! Юк, тагын бер кат юк! Экранда Польшадагы Майданек лагере. Балалар юк, миллионлаган пар аяк киеме генә калган. Балаларны крематорий мичләрендә яндырып үтергәннәр. Освенцим лагере. Чәнечкеле тимер чыбык артына балалар тезелеп баскан. Сары сапкан ябык йөзләрендә, зур булып калган моңсу күзләрендә тау да күтәрә алмас кайгы чагыла. Кулларына келәймә сугылган, алар хәзер кеше түгел, әйбер булып санга теркәлгәннәр. Янган, җимерелгән авыл-шәһәрләр, йортсыз-җирсез калган ятимнәр. Балаларны яклап гомерләрен биргән совет солдатлары. Бронзага төренгән, гранитка баскан солдат һәйкәлләре. Һәй-

коллар сугышны хәтерләтәләр, сабыйларны мондый фаҗигадан сакларга кирәкле-гән искә төшерәләр.

Экранда күпме күргән Вьетнам җире. Вьетнамга каршы, аның балаларына каршы агрессия көннәр генә, айлар гына бармады, еллар буена сузылды. Еллар буе аналарның күзенә йокы кермәде, балалар тыныч көн күрмәделәр. Безнең алда коточкыч кинодокументлар. Аяксыз, кулсыз, сукыр балалар. Өс-башлары теткәләнеп беткән, ач күзләре өметсез карый. Кадрлар алышына. Менә Чили. Пиночетның канлы кулы 69 мең баланы ата-анасыз калдырды, меңләгән балалар төрмәләрдә җәза күрәләр. Көньяк Африка Республикасы, Намибия балалары ата-аналары белән резервацияләргә ябылган. Коры җирдә, чүп-пычрак арасында балалар төн куна. Этләр дә шунда. Корсаклары күпкән, аяк-куллары чыбыкка калган балалар эттән җылылык алалар, кеше түгел, этләр миһербанлы аларга. Болар хәзерге кинокадрлар, безнең еллар документлары. Экраннарда тагы бомба шартлый, йортлар җимерелә, ут-төтен арасыннан нәни йодрыклары белән күзләрен уа-уа тетенгә тончыгып нәни кыз елап чыга. Кем баласы ул, аны алда ни көтә? Израильнең гарәп халыкларына каршы торган политикасы нәтиҗәсе бу. Меңләгән Палестина балалары беркайчан да туган илләрен күргәннәре юк, ата-аналарын күбесе белми аларның. Никарагуа, Кампучия балалары. Азатлык алган бу илләрдә балаларның хәле әле бик авыр. Балаларын югалткан аналарның кайгысын әйтеп-сөйләп бетерерлек кенә түгел, сугышка каршы нәфрәтләре дә шундый ук көчле аларның!

Бер баруымда миңа Мәскәүдә Кампучиянең халык революцион совет вәкиле, мәгариф министры Чан Вен сөйләгәннәрне тыңларга туры килде.

«Пекин нярчәннәре булган Пол Пот һәм Иенг Сари режимы берничә ел эчендә генә дә борынгы кхмер халкын, аның культурасын юкка чыгара язды. Балалар, картлар, йөкле хатыннар кайда күренсә шунда үтерелделәр. Бер генә мәктәп тә, бер генә балалар бакчасы да, бер генә вуз да калмады. Мәктәп биналарын җимерделәр, яндырдылар. Янмый калганнарын төрмә, җәза бүлмәләре иттеләр, чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алдылар. Һәр провинциядә Пол Пот режимына кадәр 180—200 мәктәп бар иде, хәзер берәр генә мәктәп калды. Дәреслекләр, китапханәләр яндырылды. Укытучыларны үтерделәр. 1968 нче елда башлангыч мәктәпләрдә 21 300 укытучы булса, хәзер 3 мең укытучы калды, элек урта мәктәпләрдә 100 мең укучы булса, хәзер 400 бала укый; элекке 11 мең студенттан 400 ләп студент исән калган. Вузларда эшләгән 725 укытучыдан хәзер 58 кеше бар.

Пекин кушуын үтәп, Пол Пот һәм Иенг Сари кликасы илнең интеллигенциясен — артистларын, композиторларын, рәссамнарын, галимнәрен дә үтереп бетерергә тырышты. Хыянәтчел планнарына каршы төшәрләр дип уйладылар, алар хәтта борын-борыннан килгән авыл исемнәрен юкка чыгарып, алар урынына, номер суктылар.

Мондый хәлләргә халык түзеп тора алмады. Хыянәтчеләрне җиңеп чыкты. Вьетнам һәм социалистик илләр, шулай ук Советлар Союзы ярдәмендә хәзер илне җимереклердән торгызу, халыкны ачлыктан, наданлыктан коткару эшләре бара. Хәзер мәктәпләр эшли башлады. Мәктәп дигәне дә без белгән, без йөргән мәктәпләргә охшамаган, я агач төбендә, я берәр тигезлектә җиргә тезелеп утыралар да, алларындагы туфракны тигезләп, шунда язарга, мисал чишәргә өйрәнәләр. Китап-дәфтәрләр, каләм-каралар юк. Укытучы дигәннәребез дә бераз гына укый-яза белгән яшүсмерләр.

Әлегә Кампучия балаларының хәле бик авыр: алар ач, ялангач, авырыйлар. Ләкин без читтән ярдәм килгәнне көтеп тормыйбыз, балаларның хәлен җиңеләйтергә тырышабыз. Әгәр безгә эчкерсез ярдәм кулын сузсалар, рәхмәтебез чиксез зур булыр. Без бөтен дөньядагы балалар да Кампучия балаларына теләктәшлек күрсәтерләр дип ышанабыз».

Халыкара хатын-кызлар федерациясе президенты, тынычлык өчен халыкара Ленин премиясе лауреаты Фрида Браун балалар елы уңае белән үткәрелгән конференциядә балаларның мондый бәхетсезлеге капиталистик даирәләрнең кыргый политикасыннан килә, диде. Җир шарының әле бер урынында, әле икенчесендә сугыш уты кабыну, ашкынып кораллану, әледән-әле яңа төр кораллар уйлап табу — боларның

авырлыгы иң башлап балалар җилкәсенә төшә. Коралланугa һәр көн саен 1 миллиардтан артык доллар акча китә, бер елга — 400 миллиард! Ә һәр елны 10 миллион бала ачтан үлә! Бу саннарны истә тотарга кирәк. Ашкынып кораллану, сугыш афәте бүген дә яңый. Бөек Ватан сугышының хәсрәтле яралары әле һаман әрни, кинолардан без бүген дә ятим калган Вьетнам балаларын, үксез нәни негрларны, йортсыз-җирсез Палестина яшьләрен күрәбез.

Безнең төп бурычыбыз — балаларны атом-төш катастрофасыннан коткару. Ашкынып коралллану сугыш куркынычы тудыра. Киләчәк буыннарның һәлакәтенә этәрә. Моннан өч дистә ел гына элек Хиросима белән Нагасаки өстенә ташланган ике атом бомбасы йөз меңләгән кешенең гомерен киссә, хәзерге атом-төш арсеналы шундый 1 миллион 800 мең бомбадан артык. Хәзер бер Европада булган атом-төш коралының гына да шартлау көче икенче бөтендөнья сугышында алты ел буе атылган шартлаткычлар көченнән берничә дистә тапкырга артыграк. Кешелеккә, гомумән планетабызга бигрәк тә куркынычлы булган нейтрон бомбаларын ясау, ашкынып коралллану барганда җир шарының әле бер, әле икенче җирендә сугыш уты кабынып торган шартларда балалар бәхетле була аламыни?!

Кешеләр сугышка каршы көрәшергә, тынычлык өчен көрәшергә тиешләр. Беркайчан да, беркайда да балаларның куркып, әрнеп, офтанып елаганнары ишетелмәсен өчен без, өлкәннәр, бөтен көчебезне куярга тиешбез. Балаларның бәхете бездән, өлкәннәрдән тора. Алар безгә өмет белән карыйлар, алар Җир планетасында безнең тынычлык булдыруыбызга ышаналар.

Бөтендөнья Тынычлык Советы президенты Ромеш Чандра, Мәскәү балаларының Зур театрда үткәрелгән бер бәйрәмендә болай сөйләде.

«Без бүген сезгә, совет халкына, сезнең балаларыгызга һәм оныкларыгызга сәлам юллыйбыз. Мин сезгә бүген тынычлык турында сөйлим. Җир йөзендәге бөтен балалар өчен тынычлык нәрсә ул? Әле күптән түгел генә без икенче бөтендөнья сугышы башлануга 40 ел тулуны искә алдык. Күпме хәсрәт, күпме күз яше, күпме кара кан сауды ул сугыш! Күпме гомерләрне, күпме байлыкны әрәм итте ул сугыш! Тынычлык ул моннан соң беркайчан да сугыш кабатланмасын, фашизмның баш күтәрмәве, напалм бомбаларының шартламавы дигән сүз.

Бомба ялкынына уралган нәни кызчыкның куркудан, газаптан шашынган күзләрен күргәнегез бармы сезнең? Тынычлык ул безнең балаларыбызның рәхәт тормышы, дигән сүз, сабыйлар күзеннән канлы яшь түгел, нур түгелсен, дигән сүз. Соуэтоның, Ливанның, Палестинаның утта янган, канга баткан балаларын күргәнегез бармы сезнең? Тынычлык ул балаларның йомшак тәнен беркайчан да напалм ядрәләре җәрәхәтләмәсен, дигән сүз. Кара, сары тәнле балаларның ачтан шешенгән олы корсакларын, шыр сөяккә калган аяк-кулларын күргәнегез бармы сезнең? Тынычлык ул балалар ач булмасын, дигән сүз. Менә ни өчен Тынычлык сүзе Бала сүзеннән аерылгысыз. Өченче сүз бар — Ленин. Ленин дөньядагы бөтен балаларның бәхет символы. Ленин — СССРда яшәүче сабыйларның елмаюы ул. Еш кына, Советлар Союзында балалар иң өстен сыйныф, диләр. Әйе, иң өстен сыйныф, Советлар илендә Коммунистлар партиясе, хөкүмәт яшь буынның киләчәге бәхетле булсын өчен бөтен шартлар тудырган. Сезнең ил — Ленин иле. Шушы өч сүз — Тынычлык, Бала, Ленин сүзләре Советлар илендә иң кадерле сүзләр. Бөтен дөньядагы прогрессив кешелеккә дә кадерле ул сүзләр».

Тынычлык иң башлап балаларга кирәк. Балалар турында кайгырткангa да Советлар Союзының Ленин кул куйган иң беренче декреты Тынычлык турында булды. СССР Ленин политикасын дәвам иттерә, тынычлык өчен көрәшнең иң алгы сафында тора.

Леонид Ильич Брежнев балалар турында өч бик мөһим төшенчә бирде: балалар безнең мәхәббәтебез, безнең өметебез, безнең киләчәгебез, диде, җир шарындагы миллионлаган балаларга безнең ярдәмебез, безнең мәхәббәтебез, безнең яклавыбыз кирәк. Балаларның тормышын җиңеләйтү, шуңа төрле юллар табу, Советлар Союзының, аңа теләктәш илләрнең максаты шунда. Балаларны без өметебез дибез, алар — безнең киләчәгебез. Йокыга киткәндә бер телем икмәк турында үйламаска, бомба шартлауларыннан курыкмаска тиеш ул. Планетадагы бөтен балаларның да бәхете тигез булсын!

«Жир шарындагы балаларның барысына да өч теләгемне әйтәсем килә,— диде Ромеш Чандра;

Бала күзен күтәреп күккә карарга курыкмасын — бомба шартлаулары, ядрә зыңлавы ишетелмәсен!

Бала күзен төшереп алдындагы буш тәлинкәсенә карарга курыкмасын! Тәлинкәләр ризыклы булсын!

Планетабызның һәр баласы сезнең илдәге балалар кебек бәхетле булсын! Киләчәккә Ленин иле балалары кебек ышанып карасыннар!

Без — миллионнар! Бөек Ленин сүзләрен байрак итеп балалар бәхете өчен көрәшүче миллионнар! Дошманнар безнең изге теләкләребезгә каршы тора алмаячак. Без җиңәрбез!

Балаларыгызга әйтегез, аларның бәхетле елмаюларын без үзебез белән алып китәбез. Балаларны яклагыз, тынычлык өчен көрәшегез, Ленин идеяләрен саклагыз!

Бәхетле булыгыз!»

Бөтен балаларның да бәхетле булуы өчен көрәшергә кирәк. Тынычлык өчен көрәшергә! Тигезлек өчен көрәшергә! Дуслык өчен көрәшергә! Капиталистик даирәләрнең ашкынып кораллану политикасына, расачылык политикасына каршы торырга кирәк.

... Җәй җитте. Табигатьнең иң матур вакытында, 1 июньдә Халыкара бәйрәм, балаларны яклау бәйрәме үткәрелә. Шәһәрләрдән авылларга үтеп, далаларны, тауларны кичеп, диңгез-океаннарны үтеп илләрдән илләргә, телләрдән телләргә күчеп җыр яңгырый:

Һәрвакыт булсын кояш!
Һәрвакыт булсын һава!
Һәрвакыт булсын әни!
Һәрвакыт булыйм мин!

ВЕНЕРА ИХСАНОВА.

# Шәүкәт Галиев

## Безнең йорт малайлары

Өч сикереп, бер атлап
Чыктык ишегалдына:
Сагынышкан Сашалар,
Азат, Фәрит бар монда.

Фәрит кайткан — Кубадан,
Азат кайткан — Алжирдан,
Әтиләре эшләгән
Дөньядагы бар җирдән!

Океан-диңгезләр кичкән
Гитара чирттерәләр,
Испанча да французча
Җырларны сиптерәләр!

Открыткалар — әкәмәт,
Карыйбыз өелешеп,
Сувенирлар — галәмәт,
Бүләбез сөенешеп.

Хосе, Әхмәтләр белән
Төшкән фотолар да күп,
Кочаклашып басканнар
Менә шулай, безнең күк.

Безнең йорт малайлары,
Сынатмый торганнары,
Дуска ярдәм кирәктә
Соратмый торганнары!

Онытмас дуслар булгач,
Хатлар килер кайдан да:
Чыкты ишегалдыбыз
Халыкара мәйданга!

## Халыкара хәлләр

Мәдир клубка
Юлны киртәләп:
— Мондый тема, ди,
Сезгә иртәрәк!

Монда буталып
Йөрмәгез кичен,
Кайтып әйтегез —
Өлкәннәр килсен!

Иртә дә түгел
Һәм соң да түгел —
Миңа белергә
Кирәк нәкъ бүген!

... «Яшь ленинчы»да
Язганга өстәп,
Казан лекторы
Сөйләде бик шәп.

Бомбалар үрчи —
Әллә шашына —
Ничәшәр тонна
Кеше башына...

Еллар тынычсыз,
Хәвефле заман —
Гөртли дә сугыш
Кабына һаман.

Экранда түгел,
Чынлап үләләр,
Меңнәрне көн дә
Җиргә күмәләр...

Җанга шом төште,
Уйга шик керде —
Сугышлы уйнау
Гаеп шикелле...

Әмма шулай да
Туктамыйк мәллә —
Кая карама
Хәтәр бит хәлләр;

Теге якта да
Малайлар уйный,
Безгә төбәгән
Мылтыгын куймый...

Иртә дә түгел
Һәм соң да түгел,
Аңларга кирәк
Миңа нәкъ бүген!.

## Куркыныч хәбәр

Кот алынып балалар
Чабышып кайтты өйгә:
— Сарбай кайда?
— Аталар!
— Эт атучылар килә!

Ә Сарбай берни белми,
Йөгереп уйнамакчы,
Яшел чирәм өстендә
Хәзер үк аунамакчы!

Тавышлары калтырап
Сөйләшәләр балалар:
— Нишләргә соң?
— Бирмибез! —
Киңәш тоталар алар.

Шундый куркыныч хәбәр!
Шундый коточкыч хәлләр!
— Тезелешеп басабыз,
Килеп чыксалар әгәр!

Ни булгандыр, ничектер,
Килмәде мылтыклылар.
... Ә балалар тормышта
Бик зур сынау тоттылар!

## Батыр булам

Мин үскәч һәйкәл булам,
Батыр булам,
Муса Җәлил янында
Басып торам!

## Ленин рәсемен ясыйм

Елмаюын, күз карашын
Күңелемнән кичерәм,
Яратуымны кәгазьгә
Рәсем итеп күчерәм.

## Канәфер чәчәге

Янып тора
Кызыл төсе,
Балкып тора
Йолдыз төсле!

Чакыра ул
Бик ерактан —
Аны Ленин
Бик яраткан!

## Эссе рәшә

Ерактa трактор күрәм —
Офыкны сөреп йөри.
Тузаннан чыгып китә дә,
Рәшәгә кереп йөри.

Тирләп-пешәр, иген чәчәр,
Тырышып әти эшләр.
Аннары эссе рәшәдә
Тирбәлеп әпи пешәр!

## Туган җир сөте

Чү, монда якын килмә,
Колынның ашын бүлмә —
Колын ап-ак сөт имә...

Биягә дә син тимә,
Колын имезгән көйгә
Ул яшел болын имә!

Болын иммидер димә,
Бик тәмле сүлләр килә —
Ул туган җирне имә!

## «Миңа! Миңа! Үземә!»

Шундый малай Әптекәш —
Ни чалынса күзенә,
Ике куллап ябыша:
— Миңа! Миңа! Үземә!

Конфет алып кайтсалар
Тавышына түз генә;
Апасына да бирмәс:
— Миңа! Миңа! Үземә!

Курчак аюны да ул
Утыртты да тезенә:
— Килмәгез, ди, тимәгез,
Миңа! Миңа! Үземә!

Урманга баргач та ул
Читкә киткән тиз генә.

Зуррак аю күргән шул:
— Миңа! Миңа! Үземә!

Әмма аю үзе дә
Әптекәш кебек икән:
«Миңа! Миңа! Үземә!» — дип,
Малайны алып киткән...

## Бала сөю

Аю әйтте:
«Аппагым!»
Керпе әйтте:
«Йомшагым!»
Куян әйтте:
«Батырым!»
Бака әйтте:
«Матурым!»

«Ә кешегә
Ни кала?»
«Шәфкатьле бул
Син, бала!»

## Зәки Нури

# КҮПНЕ БЕЛӘСЕ КИЛӘ...

«НӘНИЛӘР КИТАБЫ»ННАН

*Саный беләм, таный беләм*
*Бәб-бәләкәй булсам да:*
*Мин биш яшьтә! дип куанам*
*Берне дүрткә кушам да.*

*Көлмәгез миннән, олылар,*
*«Әйтсә — егып сала» дип.*
*Тик күргән-белгәнне сөйлим,—*
*Чөнки мин бит... бала бит.*

### Ник кечкенә?

— Бу йомырка, нигә бик кечкенә?
— Аны, бәбкәм, тавык шулай салган.
— Кире куйыйк оясына,— үссен,
Син, әбекәй, аны иртә алган?!

## Көтелмәгән сорау

— Төн буе кар яуды кичә.
Хәтта төшкә керде кар!..
Ә кая явасын төнлә
Ничек икән күрде кар?

## Бәйрәм алдыннан

— Ник бик иртә тордың әле болай?
— Чөнки төнлә бик тиз йокладым.
Һәм төш күрдем: никтер урамга мин
Шар күтәреп, имеш, чыкмадым.

## Кран бозылгач, яңгыр яуганда

— Әйттең, әни: «Ай-яй пычрангансың...
Өйдә су юк — кран бирми»,— дидең.
Әйдә юыйк инде! Әнә күктән
Нихәтле су агып тора бүген.

## Кая китте?

— Йом күзеңне! Йокла! Әнә вакыт
Ике тулып өченчегә китте...
Ә шук малай сүзне читкә бора:
— Нәрсә китте? Кая? Нигә китте?

## Әкият сөйлә

— Минем хакта әкият сөйлә әле!
— Мин бит аны сөйли белмим, балам...
— Ә син, әни, башлап кына җибәр,
Калганын мин үзем сөйли алам

## Бабай белән онык гәбе

— Сиңа ничә тула, бабай? —
— Сиксәнем быел, улым.
— Туйдырып бетермәдеме
Көн саен юынуың?..

## Теш төшкәндә сөйләшү

— Инде тәүге теш тә төште...
Шәп бара бит эшләрең!
— Ә тиздәнме икән чыгар
Минем алтын тешләрем?..

## Аңлатканнан соң

«Бу — моторлы велосипед!» диеп
Аңлатканнан соң да бер аңа,
Тагын сорый малай: «Ник ул шулай
Мотоцикл булып кылана?»

## Ник йөзә белми?

— Бик соңгарды бүген кичке поезд...
Кояш батмый әллә килмиме?
— Ник бата ул, апам, әллә кояш
Суга төшсә йөзә белмиме?

## Каян белдегез? Ничек килдегез?

... Минем Хәйдәр икәнемне
Мин тугач ничек белдегез?
... Мине алырга кибеткә
Такси беләнме килдегез?..

## Бер уч көнбагыш

— Көнбагыш чиртәсем килә!
— Чоланга кер дә ал, кызым.
— Синең учка күбрәк керә,
Кесәмә, әни, сал үзең!

## Үгетли

— Атаңасың тузан суыргыч дип,
Ә үзеңә күпме тузан кунган?! —
Сөйли кызый шуны сөртә-сөртә...
— Чиста бул син, бул син эштә уңган.

## Кибеттә адашкач

— Миңа охшаган малайсыз
Бер әнине,
Ул мине эзләп йөргәндә,
Күрмәдеңме?

## Дәү булганчы

— Дәү булганчы нинди идең, әни?
— Гап-гади бер бала идем.
— Ә син мәктәпкә киткәндә
Мин кем белән кала идем?

## Чыныгыр өчен

— Үскәч, әти, мин котыпчы булам!
— Каршы килмәс, улым, кем дә моңа.
— Хәзердән үк чыныгырга кирәк.
Мороженый ашат көн дә миңа!

## Аучысы кайда?

«Аучы белән Куян ясадым, әти» дип,
Дәфтәр битен бала бик куанып ачты.
— Куяның шәп! Ә соң аучың кайда монда?
— Куян күргәч, Бүре диеп куркып качты.

### Чын курчак

— Бу — чын курчак, кызым! Тирбәтерсең
Кирәк чакта аны йоклатырга.
— Ә кибет соң, әни, аңлаттымы:
Еласа ул ничек туктатырга?

## ТАПКЫРЛАРГА — ТАБЫШМАК

### Күп күзле

Бармакбаш хәтле нәрсә ул.
Ләкин баш түгел үзе.
Берүзенең ким дигәндә
Йөзләптер нәни күзе.

(Уймак)

### Җеп түгел — сузыла

Аның озын-озын буен
Йомгакка урый алмыйсың.
Аны мактап, аны таптап
Кайларга гына бармыйсың?!

(Юл)

### Аяксыз, канатсыз юлчы

Армый-талмый йөри көн-төн
Һәр адымын төгәл санап.
Кирәк түгел аңа сукмак,
Кирәк түгел аяк, канат.

(Сәгать)

### Акты-акты да... катты

Язын, җәен, көзен акты —
Һәм бер көн... Күксел пыяла
Астына кереп ятты —
Көзгедәй булып катты.

(Елга)

## Җирдә йөри, күктә оча

Оча — канат какмый,
Суга керсә — батмый.
Ул күн күлмәк кия,
Аны куллар чөя.

(Туп)

## Ике юлдан йөри

Ике юлдан йөри: шуның берсен
Көпчәкләре белән яра ул.
Өстәгесен исә — икенчесен —
Ике кулга тотып бара ул.

(Троллейбус)

Шамил Рәкыйпов

# САУБУЛЛАШУ ҖЫРЫ

«КАЙДАН СИН, ЖАН?» ПОВЕСТЕНЬЫҢ ИКЕНЧЕ КИСӘГЕННӘН

Жан фронт сызыгының теге ягында булып кайтты. Киткәндә, шактый вакыт юкка чыгып торуы белән кызыксынучыга авылда дәваланып яттым дип әйтергә кушкан иделәр. Ләкин җавап тотарга туры килмәде: доктор Ярашовичның әле күптән түгел генә гүр иясе булганлыгын хәбәр иттеләр. Аны гауляйтер фон Кубе үзе икенче дәрәҗә бронза медаль белән бүләкләгән. Башы күккә тигән Ярашовичның. Бу тантананы немец офицерлары белән атна буе билгеләп үткәннәр. Эшенә килмәгән. Больницадагылар белмәмешкә салынганнар. Һәм бер иртәдә аяз көнне яшен суккан шикелле, газетада некролог басылып чыга. Билгеле инде, немец ялчысын күмәргә баручы да табылмый...

Жан Викториягә ачуланды:

— Менә монысы юкка инде! — диде.

— Ничек инде юкка булсын!

— Барырга, күрергә кирәк иде.

— Әле дә соң түгел. Кабере немецлар күмелгән аллеяда, диделәр.

Жан зиратка китте. Каберне тиз тапты. Баш очындагы купшы һәйкәлгә: «Надежда Абрамова-Ярашович» — дип язылган иде. Ак беләгенә таянып төшкән рәсемен дә рам эченә куйганнар. Елмаеп тора. Нәкъ исән кеше кебек... Һәм шушы фикер, күзгә чебен сыман, аны

бимазалап-йөдәтеп тора башлады. «Нәкъ исән кеше кебек... Нәкъ исән кеше кебек...» Ни хикмәттер, сурәтне кубарып аласы килә иде. Жан итек кунычыннан чабактай ялтыраган нәфис хәнҗәрен алды. Үткен йөзенә «Барысы да Германия өчен!» — дип язылган бу нәмәрсәне аңа әнә шул йомшак кулы белән Ярашович тапшырган иде. Гади хәнҗәр түгел, тылсымлы булып чыкты ул.

...Жанга Колодище старостасы, элеккеге танышы Николай Борщевский ышанычлы кәгазьләр әзерләп куярга тиеш иде. Ул ниндидер эш белән Водопой авылына киткән икән. Жан старостаның ямь-яшел бәпкә үләне үскән иркен ишегалдында яланаяк калып, балаклары сызганып утын ярды. Аннары, хуҗаның дүрт яшьлек улына әкият сөйләде. Үзенең сабый чагын исенә төшереп, Харисны, Тамараны юксынды. Беләкләрендә көч тибеп торган һәр ир уртасы кеше, дөнья мәшәкатьләреннән беразга арынып, кемнендер нарасые белән икәүдән-икәү гаплашкан чагында, әлбәттә, үзе турында да уйламый калмый инде. Әх, Тамара да аңа менә шундый егет бүләк иткән булса!.. Кем белә бәлки... Димәк, аңа хәзер икенче яшь китте ич инде! Моның чаклы ук түгелдер инде анысы, әмма атасына охшаса, кәрлә булмас...

Күктә кояш елмая, җирдә сабый тешләрен балкытып көлә. Әнә ул ниндидер кыска көй уңаена кәҗә бәтиедәй уйнаклый. Кара син почык борынны, нинди такмаклар белә! Билгеле инде, күрше кызлары өйрәткәндер....

Жан рәхәтләнеп көлде, малайны муенына атландырып йөрде. Аннары, борын тишекләреннән ут бөркеп ак болытларга чаклы очкан канатлы атка әверелгән, тылсымлы таяк юнырга керештеләр...

Шулай кич житте. Кояш баер алдыннан Водопойдан Николай бер немецны ияртеп кайтты. Икесе дә кызмача. Жан майкадан килеш, малайга һаман әкият сөйли-сөйли, әлеге тылсымлы таякны юна иде. Сабыйны куандырыйм дип мавыгып киткән бит. Тәмам дөньясын оныткан. Лапаска гына ычкынасы, югыйсә.

Немец, чит кешене күрүгә, капкадан кере-керешкә:

— Мандат! — дип бәйләнде.

Жан, эчке майкадан гына икәнлегенә ишарәләп, хәнҗәрле кулын артка яшергән килеш:

— Папиер нахаузе,— дигән булды. Янәсе, кәгазь өй эчендәге киеме кесәсендә. Үзенең күзләре Николайда: алып китсәңче бу нарасыйны тизрәк, күрмәсен иде ул фашистны чәнчегәнне.

Николай кирәкми, җүләрләнмә, дигәндәй ым какты. Немец сизмәде димсең? Кабалана-кабалана кобурасын чишә башлады.

— Тулы тәртиптә аның кәгазьләре, обер-лейтенант әфәнде,— диде староста. — Абзам ич бу минем. Кәгазьләрен үзем тикшердем. Теләсәгез, өйгә кергәч карарбыз. Әллә алып кына чыгыйммы?

Пистолетлы кул өйгә изәде:

— Алып чык... Шнель! [1]

Шушы мизгел бик житкән иде дә, Николай борчылмый гына йөгереп өйгә кереп киткәч, Жан тик кенә тора бирде. «Кәгазьләрне укыганда эшен бетерермен»,— дип уйлады ул.

— Куда ехаль? — диде обер-лейтенант, һаман сынаулы төстә карап.

— Сюда ехаль,— диде Жан, үртәгән кебек итеп.

Такмак әйтешү уенын хәтерләп булса кирәк, сабый көлеп җибәрде. Баскычта өйдән кәгазьләр тотып чыккан Николай да елмайды:

— Орша поехал — сюда заехал, обер-лейтенант әфәнде.

---

[1] Шнель — тизрәк (Нем.)

— Зашем Орша поехаль?
Николай аңа кәгазьләр сузды:
— Кызлар жыя минем абзый. Германиягә жибәрер өчен. Менә белешмәсенә генерал Заукель әфәнде үзе кул куйган.
— Гут, гут,— диде немец.
— Зур коммерсант — вербовщик минем абзый,— диде Николай.— Отто әфәнде, бу хәнжәрне аңа Минскида гауляйтер әфәнде бүләк иткән.
Жан төче елмаерга тырышып:
— Гауляйтер Вильгельм фон Кубе әфәнде,— дип төзәтү кертүне кирәк тапты.
— Салкын корал түгел, чын-чынлап сәнгать әсәре! — диде обер-лейтенант, сокланып карап.— «Аллес фюр Деутшланд!» Германиядә генә шундый затлы әйберләр ясый алалар.
— Әйе, әйе...
— Әлбәттә, шулай... Бездә, әйтерсең, борча дагаламыйлар!..
— Нәрсә ул бор-ча? — диде немец.
— Борча бет — мужик каныи эчә торган жанвар...
— А-а, мужик! Ошень понятно.
— Әфәнделәр, өйгә рәхим итмәссезме? Тыйнак абзыкай алып килгән күчтәнәч коньяктан авыз итсәк, ә?
Жан мәгънәле төстә Николайга карап алды. Әмма хужа хәстәрсез тормыйдыр дип тынычланып, обер-лейтенантны култыклады.
— Шкурниклар! — диде урамда кемдер, жирәнеп.
Аңа игътибар итмәделәр.
Өстәл янында Колодище станциясенең коменданты Оттоны күбрәк сыйладылар. Ярыйсы ук кәефләнгән обер-лейтенант бөек Германия өчен гаять тырышып йөрүче коммерсант Назаровка Оршага чаклы пропуск язып бирәчәген әйтте. Бу юлы немец офицерларының юмартлыгы өчен эчтеләр.
Ачык тәрәзәдән өйгә кичке жиләс һава керә. Поселокны икегә бүлгән тимер юлдан әледән-әле хәрби эшелоннар үтеп тора. Озынча платформаларда — брезент белән томаланган йөк. Анда нәрсә икәнлеген чамалау әллә ни кыен түгел. Элек фронтка агылучы мондый йөкләрне немецлар дүрт почмаклы итеп калыплап томалыйлар иде. Хәзер ныклап яшермиләр — поезд кызулаган шәпкә жил брезентны танкларның, тупларның көпшәләренә сылап, менә монда алар, күрегез дигәндәй, юл буе гүя кисәтеп бара. Ә игътибар итүче юк. Дөресрәге, мөмкинлек юк хәзергә. Царюк хаклы: тимер юлны параличлау өчен берәгәйле шартлаткыч кирәк. Аны табу ансат түгел. Зур жирдән самолетлар килүе соңгы айларда нигәдер азайды. Мөгаен, фронтлардагы хәлнең кыенлыгы сәбәпчедер моңа. Әнә обер-лейтенант ничек мактана: Кырымда фюрерның шанлы гаскәрләре хужа, Харьковта, Донбасста немец коралы искиткеч жиңү яулаган, Воронеж янында, Донда киң фронт буйлап һөжүм алып барыла, 25 июльдә Ростов тез чүккән, Кавказ таулары түбәсендә свастикалы байрак жилферди...
Вагоннар үткәндә тәрәзә пыялалары зыңгылдый, өстәлдәге ризыклардан кандай саркып, шәраб ташып чыга; тәлинкә кырыена очы белән куелган затлы хәнжәр әкрен-әкрен читкә шуа; чәнечкеләр чылтырый; почмакта путаллы Мәрьям-ана сыны дер калтырый. Түрнең яртысын биләгән, сәндерәсендә өй хужасының төпчеге борынын жылы тунга төртеп яткан, аскы өлешендә жирдә кышын тавыклар ябып тотылган, хәзер сандыклы радиотапшыргыч күмеп куелган зур рус миче генә селкенми дә, калтырамый да. Ул, сабыраеп, ут көтә, чуен тирәсендәге коры-сарыга, утыннарга элдертер өчен күршедә көйрәгән ут кайтуын көтә. Күмерләр тизрәк дөрләп янып китсен дип, хужабикә кәгазь йомарламын да алдан ук хәстәрләгән. Бу йомарлам гауляйтер Кубеның

«Җирдән файдаланунының яңа тәртипләренә аңлатма»сы басылган газетадан ертылган икәнлеген Жан бая ук абайлап өлгергән иде.

Мактанчык комендант урыныннан кузгалды. Тибеп җибәрелгән ишек контузияләнгәндәй шыгырдады да ачык калды. Өйдәгеләр, лапаска чыгып, эш турында пышылдаштылар. Жан үзендәге яңа документларга кинрәк итеп аңлатма бирүне үтенде.

— Бу — ышанычлы кәгазьләр, — диде Николай. — Берлиннан җибәрелгән яшерен боерыкка нигезләнгән ул. Күчермәсе болай: «Эшче көчләрне файдалану буенча империя Баш вәкиленең программасы: немец крестьяннарының эшен җиңеләйтү өчен, фюрер миңа көнчыгыш өлкәләрдән 400—500 мең таза, нык кызлар сайлап Германиягә китерергә кушты. Заукель». Менә сез, Назаров, Баш вәкилнең агенты. Поезддан төшкәч — үз транспортыгыз. Акчагыз җитәрлек. Шартлар мәҗбүр итмәсә, идарә органнарына күренәсе түгел. Сезне Темный лес станциясендә «Саша» партизан отряды элемтәчесе Аркаша Козырев көтеп торыр. Ул сезне отряд командиры Бикбаев белән очраштырыр... Бикбаев үзе ясаган мина белән беренче немец эшелонын шартлаткан командир...

— Кем? Кем дидегез?..

— Бикбаев дидем.

— Исеме ничек аның?

— Монысын инде белмим, хөрмәтле иптәш.

— Кайсы якныкы?

— Татарстаннан микән...

Язмыш дигәнең алда күңелле очрашу әзерләп куйды микәнни? Әнигә, аның балачак дусты Харис Бикбаев полковник Зашибалов җитәкләгән Казан дивизиясендә иде ич. Майор Кадерметовның шушы тирәләрдә партизан отряды оештырып йөрүен һәм ничек һәлак булуын теге чакта Вафин сөйләгән иде. Димәк, Бикбаев үлмәгән. Барлык сугышчыларга да үләргә дигән мени?! Кара син аны кара чутырны! Отряд командиры! Малай чакта аклар-кызыллар булып уйнауның файдасы тигән икән үзенә!

— Отряд командирына үзегезне танытыр өчен пароль — өч йөз. Ягъни ул, сүз арасында өч йөзгә чаклы нинди генә сан әйтсә дә, сез аңа тиешлесен кушарга һәм аларның суммасын өч йөзне тәшкил итәргә тиеш.

Жан балачак истәлекләренә чумган иде. Ул шат елмаеп:

— О-о, Бикбаевка үземне танытыр өчен нәрсә әйтергә белермен мин, агай-эне! — диде.

Аннары фронт сызыгының теге ягына чыккач тапшырылырга тиешле кәгазьләрне күздән кичерделәр. Ул ике биттән торган сызым — дошманның Минск тирәсендәге һәм шәһәрдәге оборона ныгытмаларын тәгаенләгән план иде.

— Бу кирәгеннән артык кыйммәтле нәрсә икән шул, — диде Николай. — Карт атакай әйткәнчә, без аның күчермәсен алып калыйк. Шулай ышанычлырак булыр. Юкса, сугыш вакыты бит, ни кылмас шайтан...

— Барысы тәртиптә булыр, — диде Жан.

— Сакланганны саклармын дигән... Төп нөсхәне тапшырырга икәнлеген Бикбаев әйтер. «Капкадан» ул озатачак.

— Кем ул? Званиесе нинди?

— Белмим.

Жан киная белән төртеп ерми түзмәде:

— Сугыш вакыты бит... Ни кылмас шайтан, ходай йокыга талгач! Әгәр Бикбаев безгә сәлам әйтергә дә өлгерми калган булса?..

— Мин аның Кызыл Армиянең Генеральный штаб кешесе икәнен

генә беләм. Махсус группа командиры. И — Все!.. Бүтән мәсьәләләрне дә аның белән хәл итәсез.

— Бу инде ярый. Рәхмәт, агай-эне.

— Хәерле юл сезгә, Жан! Ни генә әйтмә, фронт сызыгы... Сак булыгыз.

— Васыять әйтештән киткән икән, карт атакайга тапшырыгыз алайса: Сувалкадагы хәрби лагерьда «Беренче рус милли СС полкы» төзелеп ята. Командиры — 229 нчы укчы дивизиянең элеккеге штаб начальнигы подполковник Гиль, контрразведка начальнигы — Богданов. Полкны эчтән таркату эшен кичекмәстән башларга кирәк!...

— Яхшы, әйтермен.

— Тагын шул, Николай... «Х — 41» акциясе, аңлыйсызмы, «Х—41» акциясе мин кайтканчы үтәлми торсын. Кайткач, үзем карармын. Кайтам мин, барыбер кайтам!..

Алар кочаклашып аерылыштылар.

*

* *

Жан Оршага хәтле поездда түләүсез барды. Юлда бер тапкыр документлар тикшерделәр. Икенче тикшерү Коханово станциясендә булды. Жан перронга төшкән иде. Янәшә юлда паровозы су алырга киткәнлектән хәрәкәтсез калган агач вагоннар каралып күренә. Элек аларда мал ташыганнар. Хәзер ни икән? Аркылы такта кадакланган ишекләр янына автоматлы сакчылар баскан. Димәк, эчтә дүрт аяклы мал түгел... Шуны раслагандай, вагон эчендә бер кыз җыр башлады. Аңа үзе кебек бәхетсез иптәшләре кушылдылар.

Моңлы җырны әсәрләнеп тыңлап торганда, ике полицай иярткән әзмәвер күк немец офицеры сары йоннары тырпаешкан көрәктәй кулын Жанның иңбашына шапылдатып:

— Мандат! — диде.

Пропускны, белешмә кәгазен җиз иләктән үткәргән кебек карады һәм, аларны бар дип тә белмичә, төпчена башлады:

— Кая? Кемгә? Ни өчен?

— Мин кылган гамәл күз алдында! — диде Жан эшем кешеседәй.— Менә Германиягә без ни чаклы эшче кул озатабыз. — Жан кызлар төялгән эшелонга ымлады.— И тагын да озатырбыз, боерган булса. Көн дими, төн дими шуның өчен чабабыз. Хәзер юл Кричевны узып Журбинга. Анда инде ул кызларның кәттәсе!

— Коралыгыз бармы?

— Ник булмасын! Гауляйтер Вильгельм фон Кубе әфәнде үзе бүләк иткән салкын коралым бар!

Жанны тоткарламадылар.

## Адъютант Аркашка

Оршада билет юнәтү җиңелдән булмады. Бәла шунда: Кричевка да, Журбинга да пассажир поездлары йөрми, ә хәрби эшелоннарның койрыгына анда-санда тагылган ике-өч вагонда гади халыкка урын булмый икән. Жан, вокзалга кереп, сугышка чаклы ук касса янына эленгән схеманы караштыра башлады. Темный леска хәтле зур-зур дүрт станция үтәсе бар. Димәк, йөз илле чакрымнар ара. Җәяү чыгып китсәң, бер атна барырга кирәк. Билгеләнгән очрашу көне — иртәгә... Поездан калырга һич ярамый.

Жан комендант янына килүчеләрнең азайган чагын көтәргә булды.

һәм ике хәрби чыгып китүгә, Колодищеда Отто язып биргән пропуск кәгазе арасына егерме биш марканы кыстырды да тәрәзә шакыды:

— Кричевка чаклы, хөрмәтлем! — диде.

— Урын юк!

— Миңа табылырга тиеш, хөрмәтлем. Рәхим итеп кәгазьләремне карасагыз иде. Монда җыелган халык кебек вак алыш-биреш белән йөрмибез. Бөек Германия өчен... — Жан, алтын тешләре күренсен дип, тимер рәшәткәле касса тәрәзәсенә иелеп елмаюын кирәксенде. — Анда барысы әйтелгән, хөрмәтлем...

Җиңенә свастикалы чүпрәк бәйләгән авыру чырайлы зат:

— Посмотрим, — диде. Тәрәзә капкачы шапылдап ябылды. Вокзал эчендә халык гөж килә. Тир исе, дегет исе. Юан гәүдәле хатыннар, ябык карт-коры бирегә азык-төлекне тозга алмаштырыр өчен килгән. Кайчан кайтулары билгесез. Хәер, Жанның да бу поездга эләгүе билгеле түгел әле. Бар өмет — маркаларда. Алар әлегә чаклы үз бурычларын шома үтәделәр. Шаять бу юлы да көчсезлек күрсәтмәсләр.

Киек читлегенең ишеген хәтерләткән, шомарып беткән керле тәрәзә капкачы, ниһаять, ачылды.

— Битте, герр коммерсант, — диде эчтә ягымлы тавыш. Аннары, көзәнгә охшап, муенын сузды, иснәнде.

Жан кәгазьләрен тикшереп тормады. Хезмәт күрсәткән төстә эндәшкәч, үтәлгән булуы билгеле инде.

— Данке шен [1], — диде Жан эре кыяфәттә һәм юкара төшкән юл кәгазьләрен күк саквояжына салып куйды. Диванга җәелеп утырып (халык, пыш-пыш килеп, аңа урын биреп өлгергән иде), сигара кабызып җибәрде. Күрегез, янәсе, чын коммерсант менә шундый була! Сөрсегән һавалы, корымлы залга гавай сигарасының хуш исе бөркелде.

Ачкычларын чылтыратып тар бүлмәсеннән чыккан өлкән яшьтәге күзлекле немец түзмәде, баш ия-ия килде дә Жаннан бер сигара бирүен итәгатьле генә итеп үтенде.

Мактанчыклыгы хур итә язды Жанны. Тартмада бер генә сигара калган иде бит! Аны Жан килеп җитеп поездан төшкәч кабызырга тиеш. Шул сигарага карап Аркаша танырга тиеш... Итәгатьле немец исә кулын сузып тора. Коммерсант кеше саранлык күрсәтмәс бит инде! Кем белә, бәлки сынап кына соравыдыр... Әнә шулай Жан соңгы сигарасы белән саубуллашты. Җүләрлек эшләве өчен үз-үзен эчтән тиргәп, ашыгып вокзалдан чыкты да инде шактый яныр кыскарган сигарасын тизрәк сүндерергә кереште. Сүнми генә бит. Аннары, җен төкергән нәрсә, тәмам таралып китә язды. Тапканнар пароль ясар нәрсә — сигара! Имеш, кызлар вербовщигы коммерсант бай күренергә тиеш. Оккупациядә халык ачлыктан кырылганда болай кылану ни пычагыма кирәк булгандыр. Әнә бит вокзал тирәсендә алҗып йөргән кешеләр нинди ябык, сәләмә! Бай күренденме, син аларның дошманы инде. Көчкә-көчкә аякларын сөйрәсәләр дә, сәлам бирми үтеп китәләр. Бай белән кемнеңавыз чайкыйсы килсен! Искелеккә — тишекле бер тиен! Янача яшәү һәммәсенең канына сеңгән. Шуңа күрә немец властьларының игъланборык ише нәрсәләрен күрмәмешкә салыналар. Бармы-юкмы мондый кәгазь чүбе — керфекләре дә селкенми.

Жан перронга чыккан җирдә коймага ябыштырылган зур белдерүгә күз салды. Анда эре-эре хәрефләр белән:

«Гражданнар, кем дә кем үз эшен һәм вазифасын тыныч башкара һәм герман гаскәрләренә һәртөрле каршылык күрсәтүләргә катнашмый икән, ул иркен тормыш, мал-мөлкәт, иминлек һәм тәртип белән тәэмин ителәчәк.

---

[1] Рәхмәт (Нем.)

Фронт тылы начальнигы генерал Бернгард» диелгән иде.

Димәк, тылда бик үк тыныч түгел икән шул дип нәтижә ясады Жан. Арырак китте. Биредәге кәгазьләрдә партизаннарга булышлык иткән, корал яшереп саклаган адәмнәргә үлем җәзасы биреләчәге әйтелгән иде.

Рөхсәтсез авылдан чыксаң — атылу...

Уңышны вакытында җыеп тапшырмасаң — асылу...

Милекне бозсаң — үлем лагеры...

Үгетләү, янау, куркыту барыбер уңай нәтиҗә бирми. Менә Кричевтан поезд ике сәгатькә соңга калып килде — «урман бандитлары» (фашистлар партизаннарны шулай атыйлар) юлны сүтеп киткәннәр. Поездда йөрүләр хәтәр. Паровозың-вагоннарың белән чокырга мәтәлүең бик ихтимал. Николайның сугыш вакытында ни кылмас шайтан дип искәртүе урынлы шул. Жан махсус задание белән бара, сез, егетләр, ике-өч көн хәрәкәт итми торыгыз әле дип әйтә алмыйсың аларга. Тимер юлга «күчтәнәч» куйган чакларына туры килсәң, җәһәннәмнең үзенә тукталышсыз очасың да очасың инде.

Ә поезд тукталып-тукталып, керпедән ялгыш кына ычкынган, теткәләнгән карт елан сыман, хәл җыя-җыя бара, менә, нипаять, Темный лес станциясе. Тезенә чаклы ак тула оеклы, чабата киндерәләрен аркылы-торкылы кысып бәйләгән, кыска соры чикмәнле, аркасына юкә бау белән тагылган кечкенә биштәр аскан, картузлы егет баганага сөялгән дә тәмәке пыскытып тора. «Мине көтә!» дип уйлап Жан, жеп белән урап булса да менә-менә таралып китәргә торган гавай сигарасын авызына капты, шырпы сызды. Әммә нәләт төшкән төпчек кабынырга һич теләмәде. Ахыр чиктә кабынды. Ләкин бу тамашаны мыек астыннан гына елмаеп күзәткән теге егет бер сүз эшдәшсәче! Черт иттереп төкерде дә үз юлына китеп барды.

Янып бетмәгәе дип, бу җен күркәсен янә сүндерергә туры килде — станциядә кеше заты калмады.

Кая барырга? Коммерсант кеше баганага сөялгән килеш тормас бит инде! Ресторанына кереп тамак ялгаргадыр, бәлки? Китәрсең генә — элемтәче килсә? Димәк, станциядән ераклашырга ярамый. Чалбар каешын кыса төшми чарам юк. Олау көткән булып, нарат күләгәсендә ятарга кирәк. Кырмыска оясыдай кайнаган станция күренеп торсын. Шул фикерне бизмәнгә салып, уңай һәм кире якларын тәгаенләгәндә, станциядә тагын берәү күренде. Сигара белән янә җәфа чигәргә туры килде. Һәм янә бушка. Болай янып бетә ич бу. Ни дип әле янып пыскып торырга тиеш ул? Англия премьеры Черчиль янмаган чагында да сигарасын авызыннан төшерми икән әнә.

Тимер юлда хәрәкәт бер генә сәгатькә дә тукталып тормый. Паровозы алдында ике-өч вагон вак таш этеп, юлларны сыгылдырып узган хәрби эшелоннар фронтка ашыга, аннан күбесенчә буш вагоннар һәм яралылар белән дыңгычлап тутырылганнары кайта. Зыңгылдап-чылтырап, кайнап-тетенләп тора дөнья. Кичә Колодищега бер-бер артлы үткән сәер бронепоездлар кайда тукталдылар икән? Комендант Отто телен шартлатып: «Болар — Литер — цвай!» — дип шундук семафорны ачтырды. Николай да, Жан да берни аңламаган булып җилкә сикерткәч, көлеп: «Берлин приказаль: партизан пух-пух!.. Заслонов капут. Минай капут!..» — диде. Димәк, фашистлар бу төбәккә куәтле җәза отрядлары җибәрәләр. Үзләренә нинди куркыныч янавын партизаннар беләләрме икән?

Жанның кул сыртына кызыл тунында кара тәрткеләре булган түгәрәк камка төшеп кунды һәм, канат сүрүен дә җыймыйча, әрле-бирле йөренә башлады. Жан аның юлына киртә итеп бармагын куя торды, камка бармакка менә торды. Бала чакта алар Харис белән:

Камка-тәтәй, туныңны сал да оч та кит!
Камка-тәтәй, безгә кунак килүен хәбәр ит!

— дип такмаклап, камканы очыра торганнар иде.

Тизрәк хәбәр иттерәсе иде урманга нинди кунаклар килүен. Танклар, артиллерия, бронемашиналар, кимендә ике мең солдат. Тыгыз, бик тыгыз булачак партизаннарга! Колодищедан чыгып киткәч, юлда туктап тагын ике бронепоезд уздырып җибәрделәр. Болары да Минай белән Заслоновка баралармы икән?

Ә камка-тәтәй очмый гына. Элемтәче юк та юк кына.

Көне буена кояш нурларын үзенә мул сеңдергән җир, анаң яккан мич җылысын искә төшереп, тәнне рәхәтләндерә. Карл Маркс урамындагы өйнең яртысы биләп торган мич. Чытырдый-чытырдый янган утыннар. Ягымлы чырай. Мөлаем тавыш. Әнкәсе тавышы: «... Мичтәге утыннар янып бетүгә, хуш исле нарат ылыслары белән ахактай күмерләрне, ипи йөзе уң булсын, кияү бәхете мул булсын дип салмак кына көй көйләп бер читкә себереп өярбез дә ипине мичкә тыгарбыз... Белоруссия синең туган җирең. Исән булып бер шунда кайтсаң, китәсең килмәс. Җире — гөл-бакча, кешеләре — билбирмәс пәһлеван...».

Дөньяны дер селкетергә теләгәндәй, паровоз кычкыртты. Фронтка таба үкереп тагын бер эшелон шаулап үтә иде. Җан ирексездән: «Менә Белоруссиягә кайттым мин, әни!» — дип уйлады һәм каты итеп кулын йодрыклады.

Элемтәче Аркаша Козырев кичке якта гына килде. Җан, эчке бер сизенү белән аңа каршы атлады. Көлле төпчеге генә калган сигараны үсмер егет күргәндерме-юкмы, әллә ул да сизенеп кенәме:

— Кызлар җыючы вербовщик сезме, абый? — дип сорады.

Җан сорауга сорау белән җавап кайтарырга тиеш иде:

— Тазалармы, чибәрләрме? — диде.

Бөдрә чәчле егетнең зәңгәр күзләре кысылды:

— Андыйларны бүтән җирдән тапмассыз. Безнең Темный леста гына алар.

— Киттек алайса, Аркаша!

— Киттек...

Үзәнлеккә төштеләр. Җан, түземсезләнеп, Аркашадан отряд командиры турында сораштыра башлады.

— Татармы ул?

— Шулай бугай.

— Исеме ничек?

— Без аны дядя Саша дип йөртәбез.

— Уртача буйлымы?

— Әйе.

— Шофер түгелме?

— Аның белмәгәне юк.

— Кара чутырмы?

— Әйе...

— Аркаша, син мине, энекәем, «Әйе-юк» белән генә туендырма. Күп итеп сөйлә.

— Күп сүз — юк сүз...

— Барыбер сөйлә! — дип үҗәтләнде Җан.

— Сүзең көмеш, тик торуың алтын дигәннәр.

— Сиңа ни? Юл кыскарыр иде.

— Хәсрәткә баткан — теленнән тапкан!

— Җитте, Аркаша!.. Мондый буш тегермән тарттыручыны рәтле кыз яратмаячак!

Җан туры тидерде: егетнең озын керфекләре түбәнгә сирпелделәр. Ул:

— Ярата инде, — диде. Аркаша, азгынлык кылгандай кызарып, барган җайга чәчәкләр өзә башлады. Җан да аңа булышты. Оялчан төстә аска карап торган сылуны хәтерләткән ромашка чәчкәсен егеткә биргәндә үсенеп, сер саклый белгән кешедәй сорап куйды:

— Василиса — гүзәл кебек ак чырайлымы?

— Әйе.

— Җете зәңгәр күзлеме?

— Әйе.

— Ә менә минем Тамара чем кара күзле. Чиб-бәр!..

— Командир кәләше дә шундый.

— Нинди?

— Чиб-бәр.

— Танышулары күптәнме?

— Күптән. Ул чакта отряд юк, без нибары җиде кеше идек әле. Ә хәзер җиде йөз. Менә көч!.. Фашистның унтугыз эшелонын откоска мәтәлдердек инде. Анда кимендә ун мең фриц. Йөздән артык танк булгандыр. Честное пио... партизанское!..

Җан елмайды:

— Ышанам, Аркаша. Ә командирыгыз ул кызны кайда очратты?

— Болтутино авылында. Моннан ерак түгел ул. Башта Монастырьщино, аннары Краснин районы. Һәм ике генә адымда Болтутино. Без җидәү: подполковник Пасюков, политрук Цирбунов, командирның якташы хәзер безнең штаб начальнигы Хазат Мифтахович Садров, мин һәм тагын ике кызылармеец — Заводский белән Цыганков — авылга килдек. Камалышта бит. Күбесе яралы. Ничә тәүлек ашамаган-эчмәгән... Безгә ял итәргә, хәл җыярга кирәк. Ә кайда нәрсә барын белмичә ятып торсаң, фашист үзеңне күзе ачылмаган песи балаларын тоткандай — һап! Һәм, билгеле инде, сиңа бүләк — бау-элмәк... Бикбаев йорт хуҗасының кызы Тамара Шантылеваны разведкага барырга күндерде. Мине җибәрмәде. Чит авылныкы икәнлегең күренеп тора, диде. Аннары минем аяк та авырта иде әле.... Тамара икенче көнне генә кайтты. Аны тыңлагач, исән-сау чакта хәзер үк моннан ычкынырга дигән карар кабул иттек. Подполковник та, политрук та Бикбаевны тыңладылар. Шуннан ул безнең законлы командирыбызга әйләнде. Ә Тамара — разведчик. Партизан отрядының исемен дә Бикбаев исеме белән «Саша» дип атадык. Мин элеккегечә аның адъютанты. Командир миңа иң куркыныч эшләрне генә куша...

— Бүгенге задание дә шундыймы?

— Бүгенгесе керми, — диде Аркаша. — Бу нәрсә, ике төкердең — бетте. — Шунда ук Җанга карап, шаулама дигәндәй, иреннәренә бармагын тидерде һәм сандугач булып сайрый башлады.

Алда хәсрәтле моңаеп тынып калган урман тора иде.

«Сандугач» өздереп, чут-чут итеп сайрый да сайрый. Күп тә үтмәде, әкиятләрдә сөйләнә торган зәңгәр аланны хәтерләткән әрфия томан эченнән ярсып чапкан өч аргамак килеп чыкты. Икесе җайдаксыз иде аларның.

Артта — Темный лес станциясеннән арырак, көчле шартлаулар гөрселдәде, күккә утлы чәчкәләр сибелде, офык тоташтан кызгылт төскә манчылды.

— Безнекеләр, — диде Аркаша. — Егерменче откоска очты. Их!.. — Кабыргаларына шпор тигән ат, арт аякларында тыпырдады да, текә борылып, җан-фәрманга чабып китте. Яшь егет күкрәгеннән ургылып чыккан бу авазда исә Җан горурлык һәм офтану галәмәте сизде. Горурлыгы партизан иптәшләренең батырлыгы өчен булса, офтануы аның менә хәзер шул егетләр сафында атлый алмавы өчен иде, ахры.

Ничә яшь аңа? Күп булса, унҗидедер дип нәтиҗә ясады Җан. Бая «Честное пионерское!» дия язды. Хәер, бәлки ул өлкән пионервожатый

булгандыр?.. Сугыш тиз җитлектерә. Ул үзе Аркаша кебек чагында ниләр майтарды соң? Ак кәҗәне урлап суючылар шайкасына эләгә иде, агасы белән Харис коткарды. Трампарктагы бер өйдә чак-чак кына янгын чыгармады. Аның каравы алар Арча кырындагы туганнар кабере янында кызыл командирлар булырга сүз бирделәр... Менә Харис вәгъдәсенә тугрылыклы калган. Ул хәзер — партизан отряды командиры. Кабер янындагы вәгъдә турында ике сүз әйтүгә Бикбаев балачак дустын танып алачак. Тукта, тануын таныр... Пароль... пароль нәрсә иде соң? Парольне дөрес атамаган кешегә, ул кемнең генә булса да, ышанырга ярамавын Бикбаев белмимени? Ышанырга хакы юк аның! Юк! Элеккеге танышың, дустың, туганың бүген кем? Бәлки ул дошман агентыдыр? Сугыш вакыты бит...

Кайтып җиттеләр бугай. Әнә Аркаша, егәтләрчә сикереп төште дә, камчысы белән итек кунычына суга-суга, землянкага юнәлде һәм эчтә әле тиешенчә калынаерга өлгермәгән яшүсмер тавышы яңгырады:

— Иптәш командир! Боерыгыгыз үтәлде: сигаралы вербовщикны алып кайттык. Юлда бернинди тоткарлык булмады...

— Мең яшә, Аркаша! Молодец!..

Җан шикләнмәде: Харис Бикбаев тавышы түгел иде бу.

## Аңа ышанмадылар

Тегеләй итеп, болай итеп сораштырып карадылар да тиешле җавапны ала алмагач, иртәгә аңлашырбыз дип икенче землянкага яптылар. Ишек төбенә автоматлы сакчы куйдылар.

Җан төнне йокысыз үткәрде. Ышанмаулары өчен партизаннарга һич үпкәләми иде ул. Үзен генә тиргәде. Шушы дүрт-биш сәгать эчендә кимендә биш-алты яшькә картайгандыр. Билгеле, отряд белән отряд үзара элемтәгә кереп, мәсьәләне ачыкламый калмаслар. Ләкин ничаклы кадерле вакыт әрәмгә узган була инде. Юк, моңа юл куярга ярамый! Шартла, ярыл, ә Бикбаевны үзеңә ышандыр. Беренче чиратта Минай белән Заслоновка хәбәр салырга кирәк. Юкса, йөзләрчә партизан һәлак ителәчәк!.. Ничек ышандырырга соң? Мин сине, кадерле иптәш, балачак дустым Харис Бикбаев дип уйлап, Колодищеда парольне рәтләп тыңламаганмын дипме? Николайны дикъкать белән тыңламавы да хак бит. Шуның әҗере — миллион газаплар. Ярый ла иртәгә һәммәсе уңай хәл ителсә! Ничә тапкыр, ничә тапкыр үз тойгыларыңа таянып кына бәя бирмә — берьяклы килеп чыга дип җан атып үкенгәне, каһәрләнгәне бар!? Һәм менә тагын... Болай ук идиот хәленә калганы юк иде әле. Ярар, ни чара бар хәзер бу тупиктан чыгу өчен, ни? Кино тасмасын янә сүткән кебек, һәммәсен хәтердән үткәрергә кирәк. Немец Отто... Хәнҗәр...) (аны менә бирелә алып калдылар), лапаста Минск планын күчереп сыздылар... (аны ул Бикбаевка үзе бирде). Бирелә булганнарны искә алу белән мавыкмаска! Алар күз алдында. Бу Бикбаев бәгырьгә үтәрлек итеп текәлеп карый. Карасын... Әһәмияте юк. Ни дип әле ул ике тапкыр: «Арымадыгызмы, Оршадан безгә чаклы йөз илле чакрымнан артык ара бит!» — диде. Ни өчен? Соң, вокзалда чакта Җан иске схемадан бу аерманы тәгаенләмәде мени? Кричевка хәтле шулай. Ә Кричевтан соң күпме әле? Сан!!! Әйе, Николай пароль иттереп сан билгеләнүен әйтте ич. Бикбаев син тишек хәтерле Балдадан шуны суырып чыгармак була. Точно шулай!.. «Сүз арасында әйтелгән... теләсә нинди санга үзеңнән өстәп кушасың да... аларның суммасы...? ...Күпме булырга тиеш аларның суммасы? Күпме?.. Өч йөз!?! Точно шулай!.. Бикбаев сиңа ышанып, миеңне тизрәк чистартырга теләп, йөз илле

чакрымны ике рәт кабатлаган. Шулай. Нәкъ шулай. Әх-ма, Иванушка-җүләркәй, тәки чиштең бит серле башваткычны!

Янәшәдәге курадамы икән — әтәч кычкырды. Өчне кычкырса, табышмакның җавабы дөрес табылган була. ... Ике, өч! Мең яшә, әтәч җаным... Дөрес кычкырасың!

Жан, землянка ишеген шакып, сакчыдан үзен командир янына илтүне сорады.

Урманда сызылып таң атып килә иде. Партизан лагере уяна башлады.

Отряд командиры Бикбаевка парольне әйткәч, тиз аңлаштылар. Бикбаев, уртача буйлы, кара тут чырайлы, чем кара чәчле, шундый ук кара күзле һәм кую кара кашлы, күп булса 24-25 яшьлек егет иде. Борыны туры, иреннәре юка. Димәк, юаш адәм түгел бу. Тарап куйгач, махсус сыекча ярдәмендә катыргандай кую чәче дә шуны раслый. Кыю, тәвәккәл карашы тагын... Кешедән таләп итеп кенә калмый, үзе дә дөрләп янган ут эченә атылып керәдер бу...

Ачык ишектән төшкән көн яктысында шулай бер-берсен күздән кичергәч, командир:

— Гафу итегез, җайсызрак килеп чыкты, — диде.

Жан ым кагып тәкъдим ителгән сәкегә утырды:

— Үзем гаепле. Балачак истәлекләренә бирелеп... Харис Бикбаев дигән бик якын дустым бар иде. Сезне шул дип уйлап... — Жан, кул селтәп, беразга тынып калды.

Бикбаев исә эчкерсез елмайды да:

— Ул да барыбер пароль сорар иде, — диде. — Вакыты шундый. Сугышта бернинди ваклык юк...

— Әлбәттә, әлбәттә...

— Ну, иптәш Назаров, эшкә якын килик. — Бикбаев өстәлгә карта җәеп салды.— Сезнең игътибарга ике төрле вариант әзерләнде...

Жан, түземсезләнеп, урыныннан кузгалып куйды һәм:

— Гафу итегез, иптәш командир, — диде. — Маршрутларны тикшерергә керешкәнче, күршеләрегезгә кагылышлы кичектергесез бер мәсьәләне хәл кылыйк әле.

— Нәрсә ул?

— Дядя Костя белән Минай атакайга каршы немецлар көчле җәза отрядлары туплап юлга чыгарганнар.

— Бу бик мөһим. Кайда соң безнең штаб начальнигы? — Бикбаев, сузылып, почмактагы бауны тартты һәм тышта кайдадыр тимер-томыр чылтырады. «Нәкъ трамвай кыңгыравы кебек», — дип уйлады Жан. Шул арада командиры шикелле үк ыспай гәүдәле, кара-кучкыл чырайлы, житез, пөхтә киемле, ләкин Бикбаевтан берничә яшькә олырак берәү килеп керде дә честь бирел:

— Штаб начальнигы кече лейтенант Садров! — диде.

Исәнләштеләр. Бикбаев землянка ишеген япты, аннары, дәвам ит дигәндәй, Жанга кул изәде.

Жан Колодищеда һәм юлда күргәннәрен сөйләде.

Күршедәге отрядларга хәзер үк элемтәчеләр җибәрергә боерык бирелде.

Ниһаять, карта өстенә иелделәр. Бикбаев аңлатма бирергә керешге:

— Беренче маршрут,— диде ул,— Вихра һәм Каспля елгалары буйлап, халык яши торган урыннарга кермичә, Архиповка станциясе янынннан тимер юлны үтеп, аннары Днепрны кичеп... Замошье-Жичицы һәм — «Сураж капкасы». Барлыгы өч йөз чакрымнан артыграк юл. Атлар белән биш-алты көн. Озын юл, ләкин чагыштырмача куркынычсызрак юл.

Жан тимер юлга күрсәтеп:

— Икенче вариант Орша — Витебск — Осинторф аркылымы? — дип сорады.

— Юк.

— Ни өчен «юк?» Мине Оршада ук каршылап, шуннан туры киткән булсак, без хәзер үзебезнең гаскәрләр штабында утырыр идек.

— Ихтимал, — Бикбаев тәмәке кабызды, — бик ихтимал... Ә бәлки, немец комендатурасында утырыр идек!..

— Бүредән курыккач, урманга барырга кирәкми!

— Ә бездә: «Бүре дә тук булсын, сарык та бөтен булсын!» — дигән мәкаль дә бар. Кызганычка каршы, хәзергә шуңа йөз тотарга туры килә.

Жан сикереп торуын сизмичә үк калды:

— Сез... сез мине сарыкка тиңлисезме? Гафу итегез! Кайда минем хәнҗәр? Куркыныч дигән җирегезгә ялгызым китәм! Кара төндә сигез бәдбәхетнең йөрәген айкаганда кулым калтырамады минем!

— Кызмагыз, Назаров! Башта эшне тиешенчә эшлик. Аннары үпкәләшербез. Алыгыз хәнҗәрегезне... Сүз дә юк, әйбәт нәрсәкәй...

— Так, Орша — Витебск — Осинторф маршруты ничек?

— Аннан һич ярамый.

— Эш нәрсәдә?

— Ул зона гаять куркыныч: Осинторфта РНА төзелеп ята!

— Ни ул тагы?

— Рус халык армиясе, имеш. Эмигрант ак офицерлар, Чека муенын борырга өлгермәгән графлар, СС һәм СД койрыклары...

Жан бу кадәресен үк көтмәгән иде. Сувалкида милли полклар, Слонимда милли үзәк, бригадалар, биредә — армия...

— Карагыз әле, иптәшләр, сез әйткән ак офицерлар, барон, графлардан армия төзеп була мени?! Өч мыскалга дүрт кадак җитми дигәндәй, адәм мәсхәрәсе ич бу!

Штаб начальнигы, планшетын ачып, бер бит кәгазь алды:

— Бездәге мәгълүматлар буенча, анда хәзер өч меңнән артык кеше бар. Төгәл әйткәндә: кичәге хәрби әсирләр. Мобилизация дәвам итә. Граф Санин, эмигрант Иванов, Сахаров, эре алпавыт Соболевский һәм башка шундый «титуллы әфәнделәр» — Берлиннан китерелгән җитәкче состав. СС һәм СД гаскәрләре исә тәртип саклаучылар.

«Баш җитәкче» Иванов болай дип белдергән:

— Мәскәүне немецлар да, японнар да түгел, без, руслар алачакбыз. Без үк анда тәртип урнаштырырбыз. Шуңа күрә армиябез оештырылып беткәч тә, фронт участогының берсендә без совет гаскәрләренең каршына басарга тиеш.

Штаб начальнигы тамак кырды һәм, тагын да кызыграгы бар дигәндәй елмаеп, дәвам итте:

— Граф Санин рус офицерлары гына җыелган бер мәҗлестә болай дигән: «Безгә ике миллионлы армия төзеп, аны тулысынча коралландырырга кирәк. Бу сугыштан соң немецлар хәлсезләнәчәк, һәм без шул чак аларга китереп бирербез. Властьны үз кулыбызга алырбыз, Россиядә монархияне торгызырбыз!»

Нәтиҗә: анда хәзер һәртөрле өйрәнүләр үткәрелә, тирә-як зоналарга бүленгән, тәүлек буе атлы һәм җәяүле патрульләр йөри. Сиздермичә үтү һич мөмкин түгел.

— Рәхмәт, аңлашылды, — диде Жан. — Фронт сызыгын узуның икенче вариантын тыңлап карыйк инде алайса.

— Ул моннан гыйбарәт, — отряд командиры аягүрә басты, — биредән 1 нче Смоленск партизан дивизиясенә, аннан самолет белән «Сураж капкасына». Өч көнлек юл, ләкин ярыйсы ук хәтәр, куркыныч юл.

— Бу — мин дигәнчә! — диде Жан. — Мин шушы минутта ук юлга чыгарга әзер!

## Роберт Миңнуллин

### Энекәш кирәк миңа

Сезгә рәхәт! Берегез дә
Минем хәлдә түгел сез.
Беләсезме? Өйдә миңа
Кызык түгел, күңелсез.

Елыйсы да килә кайчак,
Уйлап ятам-ятам да:
Юк шул минем абыем да,
Юк шул минем апам да.

Сеңелем дә, энем дә.
Бергә-бергә уйныйсым
Бик тә килә минем дә.

Ә күршеләр гөр килә:
Уйныйлар, шаяралар.
Алар күп шул, күмәк шул —
Шуңа да шаян алар.

Бер иптәш кирәк миңа,
Энекәш кирәк миңа!
Яратыр идем мин аны,
Хәтта елак булса да,
Бакчага да илтер идем,
Хәтта ерак булса да.

Энем белән мин урамга
Уйнарга чыгар идем.
Әгәр мине тыңламаса,
Ничек тә чыдар идем.

Әтиләр бит, ничә кабат
Алабыз дип алдыйлар.
Берләнбер малайларына
Бер энекәш алмыйлар.

Күңелсез өйдә миңа,
Уенчык нигә миңа?!

Бергәләшеп уйнарга
Бер иптәш кирәк миңа.
Бераү генә булса да,
Ямьсез генә булса да,
Елак кына булса да,
Энекәш кирәк миңа!

### Тырышам

«Иген игү,— ди әтием,—
Мактаулы да, авыр да».
Нәкъ тырышлар, мактаулылар
Яши безнең авылда.

Алар басуда кышын да,
Язын, җәен, көзен дә.
Каникулда абыема
Булышкалыйм үзем дә.

И тырыша минем абый,
Үзем дә тырышкалыйм.
Шөрепләрне бик тырышып-
Тырышып борышкалыйм.

Мин тырышкач, комбайн да
Бик тырышып ура шул.
Тырышабыз — ипикәе
Бигрәк тәмле була шул!

### Кайтыйк ла үзебезгә!

Диңгез — матур,
Сүз дә юк.
Мондый диңгез
Бездә юк.

Йөзеп тә чыгып булмый,
Төбенә чумып булмый.

Тотып булмый балык та.
Юк биредә таллык та.

Ләкин теге ягына,
Ләкин теге ярына

Тозлы икән суы да —
Чистартмыйлар шуны да.

Эчкә үк кереп булмый,
Иркенләп йөреп булмый.

«Кермә!» — диеп торалар,
Керсәң, кире боралар.

Кайтыйк ла
Үзебезгә —
Кечкенә
Сөнебезгә!

## Безнең як крокодиллары

Булат бүген берүзе
Сөндә су кереп калган.
Таллык төбендә ике
Крокодил күреп калган.

һәм чабарга тотынган.
Көчкә качып котылган.

Чапкан чакта, җитмәсә,
Ул бер талга абынган.
Икенче тал Булатның
Аягына кагылган.
Крокодил дип, Булатның
Тагын коты алынган.
Куркуыннан, ахрысы,
Тагын бер кат абынган.

Булатның шул хәлдән соң
Бер генә сүз телендә:
— Ул крокодиллар,— ди ул,—

Әнә... әнә тегендә,
Әнә теге таллыкның
Әнә теге төбендә.

Ә малайлар көләләр.
Чөнки алар Булатның
Ни күргәнен беләләр.

Ләкин Булат сер бирми:
— Сез юкка көләсез,— ди,—
Белмисез бит сез берни.

Барыгыз да карагыз —
Таллыкта ята алар.
Бездәге крокодиллар
К ә л т ә дип аталалар.
Белдегезме!

## «Ми-8А»

Самолетларда очмаган
Малайлар әздер бездә.
Нинди генә самолетлар
Эшләнми хәзер бездә.

Самолетларның «Ил»ларын,
«Ил-18», «Ан»нарын,
«Ту-154»ләрен,
Я «Як-40 А»ларын —
Беләсездер аларын.

Ә менә сез «Ми-8 А»
Дигәнен беләсезме?
Күрәсезме?
Андый самолетны бер дә
Ишеткән юк дисезме?
Чыннан да белмисезме?
Шаяртусыз-нисезме?

Шулайдыр шул.
Аның әле
Буявы да кипмәгән.
Ул әле оста очарга
Өйрәнеп тә җитмәгән.

Аның әле пропеллерен
Алыштырырга кирәк,
Бер-ике җиргә кадак та
Кагыштырырга кирәк.

Ул өр-яңа самолетның
Конструкторы мин булам.
Ә мин үзем «8» яшьлек
«А»лмаз «Ми»ңнуллин булам!

## Кызганыгыз бүрене!

Көн дә мульти карыйбыз,
Берне түгел, унберне.
«Ну, погоди!» дигән мульти
Барыбызны көлдерде.

Белмим, ник көләбездер? —
Мәзәк дип беләбездер...

Ә мультидә бүрене
Көлкегә
Калдыралар,
Утта да
Яндыралар,
Суга да
Батыралар,
Цементка
Катыралар,
Кагалар да сугалар,
Сугалар да кагалар.
Сугар сәбәп табалар.

Улый бүре, елый бүре,
Йөри бүре сызланып.
Мин дә утырам сызланып,
Шул бүрене кызганып.

Ул — ямьсез, юньсез, янәсе,
Ул — әшәке, ул — тиле.
Бер дә андый түгелдер ул,
Туктатыгыз мультине!

# Разил Вәлиев

## Кайтаваз кайда яши

Урамга чыгып кычкырдым:
— Әй, кайтаваз!
Син кайдау?
Ишеттем бары бер аваз:
— һау-һау, һау-һау,
һау-һау-һау.

Көтү көткәндә кычкырдым:
— Син кайда?
Хәбәр җибәр!
Ишеттем бары бер аваз:
— Бә-бә, бә-бә,
Бә-бә-бә-бә-бә.

Урманга барып кычкырдым.
Җавабын озак көттем.
Яңгырады моңлы аваз:
— Күк-күк, күк-күк,
Күк-күк-күк.

Төнлә төшемдә сорадым:
— Әйт, кайтаваз!
Син кайда?
Бик ерактан аваз килде:
А-а-а-а-а-ай-да-а...

## Курыкмыйм

Сыртына капчыклап
Маймыллар төягән, —
Шулай да барыбер
Курыкмыйм дөядән.

Курыкмыйм жирафтан,
Курыкмыйм филләрдән.
Фил борын күтәрсә,
Мин көлеп җибәрәм.

Әнием куркыта:
«Әгәр, — ди, — карышсаң,
Тотар да йотар, — ди, —
Менә бу арыслан».

Тамчы да курыкмыйм!
Әйтегез: кем курка?
Бергәләп барырбыз
Иртәгә циркка.

## Күпне күргән бүрек

— Бүрек, бүрек, кая бардың?
— Кая булсын, кинога.
— Бүрек, бүрек, сөйлә әле
Ниләр күрдең син анда?
— Әй-лә, шунда, күрсәтәләр
Әллә нинди юк-барны.
Хуҗамның тезе өстендә
Рәхәтләнеп йокладым.

— Бүрек, бүрек, кая бардың?
— Кая булсын, кунакка.
— Бүрек, бүрек, кемне күрдең,
Сөйлә әле шул хакта.
— Әй-лә, шунда, чакырганнар
Әллә нинди юк-барны:
Кәпәч, таяк, эшләпә һәм
Чәчәкле зонтикларны.

## Тегермән

Әбинең туган көненә
Бүләк иттек тегермән.

«Хәзер кофе тарттырырга
Кибеткә барып йөрмәм, —
Дип сөенә әбиебез, —
Мәшәкатьтән котылдым».

Әби күршегә кергә,
Тегермәнгә тотындым.

Әй, тарттырам чикләвекне
Кабыгы-ние белән.
Әйләнеп тора тегермән,
Мин шатлыгымнан көләм.

Тарттырдым мин бәрәңге дә,
Тарттырдым кишер, кыяр.
Мин тарттырган нәрсәләрне
Ашаса, фил дә туяр.

Тарттырдым мин борыч, суган,
Тарттырдым мин алманы.
Өебездә тарттырмаган
Бер нәрсә дә калмады.

— Син тарттыңмы? — диеп, әби,
Аһ-уһ килде, шаккатты...
... Әйе, әйе, үзем тарттым,
Колакны әби тартты.

## Кемгә сукты?

— Фәрит кемгә сукты дисез?
Кара аны, юньсезне.
Нигә сукты? Нык суктымы?
Тегесе ничек түзде?

Туп-туры... эшләпәсенә?
Ә син тордыңмы карап?
— Утлар чыгарып сукты ул, —
Керде дә китте кадак.

## Минеке

Кычкыралар, сугышалар —
Әйтерсең, мәхшәр купты.
Ике малай бүлә алмый
Түп-түгәрәк бер тупны.

Берсе әйтә: «Минеке!» — ди,
Икенчесе: «Минеке!»

Шулай тарткалаша торгач,
Ярты көннәре үтте.

Әтиләре чыккан иде —
Әтәчлекләре очты.
«Минеке» дә «минеке», дип,
Тарталар хәзер пычкы.

## Мәҗлес

Әтәч коймага кунган,
Мәҗлес җыймакчы булган.

Утыра кунак көтеп,
Тәлинкәдә — бер бөртек.

Җыелганнар тавыклар,
Караганнар савытка.

Ә савытта — бер ярма...
Кикрикләре кабара.

Тавык явы башлана,
Әтәч алга ташлана
Узып унбиш өтекне,
Чукып ала бөртекне.

Үзе шундый сөенә,
Җырлый «Сарман» көенә.

Тәлинкәсе бушын буш,
Тик чыкмады, ди, сугыш.

## Песи төш күргән

Мич башында йоклаганда
Песи гаҗәп төш күргән.
Төшендә ул Африкада
Арыслан булып йөргән.

Теләсә-кемнең өенә
Шакымый гына кергән.
Кемгә керсә дә, урынны
Биргәннәр аңа түрдән.

Арыслан караватында
Кичен йокларга яткан.
Төшендә ул мич башына
Кире әйләнеп кайткан.

Шул чагында песиебез
Куркып уянып киткән.
Песиме ул, арысланмы —
Әле дә белми икән.

Адлер Тимергалин

## КҮРЕШҮ

ФАНТАСТИК ХИКӘЯ



ш көне башланырга бер сәгатьләп бар иде әле. Иңенә үтүк астыннан гына чыккан ап-ак халат элгән администратор ханым борынгыча илтифат белән кат-кат гафу үтенде дә:

— Телисез икән, ял итеп алыгыз. Уку залын ачарга да мөмкин. Кирәксә, автобуфет эшли,— дип төрле кызыктыргыч тәкъдимнәр ясап карады.

— Уку залында «Математика хәбәрләре»нең ахыргы саны юкмы?— дип белеште Анри Томмазо.

— Юктыр, бу бүлеккә без гыйльми-теоретик журналлар алдырмыйбыз, — дип башын чайкады администратор. — Бездә балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты гына...

Томмазо урыныннан кузгалды.

— Алайса, мин бакчагызны күрим әле.

— Рәхим итегез,— диде ханым һәм Томмазоны дендрарийга чыгарган пыяла ишеккә кадәр озата килде.

Иртәнге һава җиләс, үлән яфракларында чык та кибеп җитмәгән иде. Томмазо күләгәле ышык җирдә эленгән даганга килеп утырды. Утырган гына иде, даган үзлегеннән җай гына тирбәлә дә башлады. Очыш тойгысына бирелеп берничә минутлар атынгач, Томмазо култыксадагы кнопкага басып даганны туктатты. Утыргычтан төште, челтерәп яткан фонтан янына килеп, судагы җанлы болыт шәүләләрен күзәтеп торды. Аннан соң түгәрәк чәчәклек тирәсендәге пластмасса скәмияләрнең берсенә сузылып ятты...

Һава баш әйләндергеч зәңгәр. Күптән онытылган икән бу зәңгәрлекләр. Җирдә туып үскән булса да, Анри менә ун ел инде Айда яши һәм шунда төпләнгән иде. (Астрофизика обсерваториясенең математик тәэминат бүлеге мөдире — егерме җиде яшьлек кеше өчен кечкенә дәрәҗә түгел!). Ул Айдагы ясалма төсләргә, кискен күләгәләргә, караләым күк йөзенә, җансыз йолдызларга күнегеп беткән. Гәүдәсе дә, атлап йөрешләре генә түгел, кул хәрәкәтләре дә шундагы авырлыкка (дөресрәге — җиңеллеккә) ияләшкән һәм мондә Томмазо үзен аркасына потлы рюкзак аскан альпинист кебегрәк хис итә.

Шулай да зәңгәр күккә карап хозурланып яту рәхәт икән.

Җирдәге төсләр дә йомшак, назлы, күзне иркәлиләр. Хәер, туктале, менә бу чәчәкләр артык ачык төстә түгелме соң? Сабаклары да чамасыз яшел. Зәһәр яшел... Чәчәкләрдә ник бер тимгел, я күгәрек булсын. Һәммәсе — бөреләре дә, яңа ачылган чәчәк таҗлары да, зурлары да һичбер кимчелексез. Артыкка китсә, матурлык әдәпсез тоела, чөнки ул табигыйлеген җуя. Әлеге чәчәкләр дә шулай күңелгә тия иде. Хәер, Томмазо бу чәчәкләрнең үзенә нигә ошамаганлыгын аңлап бетермәде бугай. Ул, математик кеше, аларның ифрат төзек, циркуль белән сызган кебек симметрияле булуына гына игътибар итте.

Баш өстеннән җуылдап бал корты очып үтте. Юкә балы Айда «әҗәл даруы» кебек кыйммәтле нәрсә санала, ә бал кортын, тәмам изгеләштереп, Җир-ананың һәм тырыш кешелек дөньясының символы итеп йөртәләр иде. Томмазо, кызыксынып, торып утырды.

Бал корты гөлләр өстендә әйләнде дә, бер мизгел һавада туктап торгач, күңеленә хуш килгән чәчәккә төште. Томмазо, аягына басып клумбага якынрак килде. Ләкин аңа бал кортының татлы ширбәт эчкәнен тамаша кылырга насыйп булмады. Бөҗәк, чәчәккә орыныр-орынмас, чиртеп җибәргәндәй өскә атылды һәм, югарыда тагы бер әйләнә сызды да, баягы юлын дәвам итте.

— Китте, — диде Томмазо, иңнәрен җыерып, — бакчы нинди нәзберек.

Математик ялгыша иде. Иелебрәк карагач, моңа ул үзе дә төшенде. Клумбага чын чәчәкләр түгел, бәлки ярымбиологик табигатьле үсемлекләр утыртылган иде. Алар үзләре үсә, яфрак яра, чәчәккә бөреләнә, хәтта орлык бирә, ләкин аларның чын үсемлеккә охшашлыгы шуның белән чикләнә дә. Башка төрле биохимик реакцияләргә нигезләнгән булганга, аларның исе дә, тәме дә үзгә. Кырау да, чир дә алмый торган бу чәчәкләр тере түгел, бәлки чын тереклекне имитацияләү генә. Ифрат оста кул ясаган ялган акча шикелле...

Томмазо иренеп кенә чәчәкләргә кулын селтәде дә, аллея буйлап китеп барды. Агачлар чын, хәтта утырган килеш чери башлаган карт юкәләр дә бар. Аларыннан әчкелтем-төчкелтем җылымса ис килеп, борынны кытыклый. «Аягүрә үләләр»..., — дип уйлады Томмазо, саргылт агач череген уч төбендә уа-уа. — Үләннәр һәм башка тормышка — яшьрәккә һәм көчлерәккә урын бирәләр. Яшәеш һәм тәрәккыять шундый булырга тиеш. Үлемнән башка тәрәккыять юк...»

Бу сүзләрне аңа юлдашы — Ай ракетопланында очраган бер карт әйткән иде. Ул үзен шагыйрь дигән иде бугай. Шагыйрь... Сүзләрне һәм авазларны билгеле бер тәртип белән төзеп, мәгънәсе бик томанлы бул-

ган — һәрхәлдә аңлашылып җитми торган — яңгыравык җөмләләр уйлап чыгаручы кеше. Уйлап чыгаручымы, әллә уйламыйча гына серле хиссият даирәсендә тудыручымы?

— Безнең гөнаһлы җиребезгә ник баруыгыз, егетем? — дип сорады ул урта Европа телендә.

Тәкәллефсез... «Үзенең өлкән булуыннан файдалана» — дип уйлап алды Анри, ләкин үпкәләп тормады. Ачык йөзле бу чибәр картка үпкәләү мөмкин дә түгел иде.

— Евгеника институтына чакырганнар иде, — диде Анри урта Европа телен исенә төшереп. — Ничек әле? Рандеву?

— Көрәшүме?

— Йес. Әйе. Көрәшү.

Картның йөзе караңгыланып киткәндәй булды.

— Евгеника... Евгеника... — дип кабатлады ул авыз эченнән. — Табигатеңне яхшыртам дип ымсындырып, кешене кешелектән мәхрүм итә торган фән,— дип өстәде ул, ишетелерлек итеп.

— Бу фән безгә мәңгелек тормыш вәгъдә итә, — дип каршы төште егет. — Һәрхәлдә актив гомерне ике-өч тапкыр озайта. Кешенең күптәнге хыялы тормышка аша!

Шагыйрь көлемсерәде генә:

— Ә нигә кирәк ул мәңгелек тормыш? — диде. — Искелек яңага урын бирергә тиеш. Үлемнән башка тәрәккъыять юк. Кеше яши дә, үлә дә белсен.

Томмазо башын чайкады. Юк, яшьлек үлемне аңлый да, аның белән исәпләшә дә белми. Хисләре генә түгел, егетнең аналитик гакылы да иҗаттан туктау, башлаган эшеңне тәгалләмичә ташлап калдыру белән килешә алмый иде.

— Кешенең биологиясе яхшырганнан-яхшыра барса начармыни? — диде ул, бирешәсе килмичә.

— Әгәр кешенең биологиясе үзгәрсә, ул инде кеше булмаячак! — диде шагыйрь кайнарланып.— Нәрсә, ул кеше авырмаячак та мени? Ә минем авырып тереләсем килә. Терелү ләззәтен кичерәсем килә!

— Әгәр утызынчы гасыр тарихчысы: «Безнең борынгы бабабызны кеше дип атаганнар» — диячәк икән, миңа — егерме беренче гасыр кешесенә — шуннан да аянычрак хакыйкать юк, — дип өстәде ул. — Әгәр киләчәк кешесе шигырьне дә аңламаса? Шигырь яза белмәсә?

— Шигырь язарга автоматлар өйрәнер, — диде Томмазо битараф кыяфәттә.

— Автоматлар?! Беләсезме, егетем, бер шагыйрь: «Машина чын шигырь язган көнне мин үз-үземне үтерәм»,— дигән. Ә икенчесе: «Машина чын шигырь язган көнне мин ул машинаны үтерәчәкмен!» — дигән ди.

Анри сүзне борып җибәрү ягын карап, шагыйрьдән Айга ник килүе турында сорады. Шагыйрь көрсенеп куйды да: «Зиярат кылырга... — диде. — Мәхәббәтемнең каберен күрергә бардым».

Анри бу сүзләрне аңлап җиткермәде.

Ә менә хәзер Томмазо Җирнең үзе кебек үк карт агачлар янында басып тора, берьюлы черек исен дә, үлеп баручы агач төпләреннән шытып чыккан яшь үсентеләр сулышын да тоя. Аңа карт агачлар кызганыч, ләкин якты дөньяга гаҗәпсенеп караган яшь бөреләр күңелгә якынрак. Аларның иртәгесе көне, киләчәге бар...

Кайдадыр ерактә бик аһәңле тавыш белән борынгы сәгать сукканы ишетелде.

Вестибюльгә әйләнеп кергәч, Томмазоны баягы ханым каршылады.

— Иң элек каныгызга анализ үткәрәсе, — диде ул, кәгазьгә карап.

— Рәхим итегез. Кая барасы?

Ханым, эчке телефон аша сөйләшеп, санитар чакырды. Санитар кыз

Томмазога артык төбәп караган шикелле тоелды. Ләкин бер кат күздән кичергәч, ул, канәгатьләнеп, Томмазога ул кадәр игътибар итмәгән кебек күренергә тырышты.

Канны кадими бер ысул белән — сул кулның атсыз бармагы очын чак кына кисеп алалар икән. Авырту-мазар сизелмәсә дә, бер тамчы кан күренгәч, Томмазо йөрәгенең көчлерәк тибә башлавын тойды. Бу хәлгә ул үзе дә аптырады, ләкин моның куркудан түгеллеген Томмазо яхшы белә иде. Бәлки, психиканың иң аулак почмагында йоклаган хайвани һәм вәхши тойгыларның — борынгы сунарчы инстинктларының кинәт кабынуы гынадыр?

Аннары санитар кыз аны педагог янына алып керде.

Урта яшьләрдәге ир кеше иде бусы. Гадәттән тыш нык зурайта торган калын күзлек пыяласы аша аның зәңгәре уңган күзләре — барысын аңлый торган күзләр — текәлеп карый һәм син үзеңне микроскоп астына килеп эләккәндәй хис итеп, борсалана башлыйсың.

Танышу бик кыска булды: Һашим Һелиос. Педагог һәм психолог.

— Анри, сез соңгы тапкыр кайчан җылаган идегез? — дип сорады ул кинәт.

Томмазо әле урындыкка җайлап утырырга да өлгермәгән иде, сәерсенеп китте.

— Әллә кайчан... — диде ул. — Җирдә үк, башлангыч белем мәктәбендә чакта...

— Һмм... Сугышыпмы?

— Йес. Әйе. Сугышып.

— Нык эләктеме? — дип күз кысты педагог һәм шундук ике арадагы еллар эреп югалдылар, ике күңел якынаеп киткәндәй булды.

— Ул малай миннән көчлерәк иде, ләкин аягы таеп егылды да, кулы каймыкты. Без икебез дә җыладык. Ул — җиңә алмаган ачудан, ә мин аны кызганып.

Педагог хисап машинасына кертелә торган перфокартага берничә тишек тишеп, яктыга тотып карады. Аның йөзе җитди, канәгатьмә түгелме икәне аңлашылмый иде.

— Психогенотип ягыннан Дәрьял сезгә ныграк тарткан алайса,— диде ул.

— Чынлапмы? Бик елак түгелдер бит?

— Елак түгел, ләкин йомшак. Иптәшләренә артык ирек куя. Гафу итә. Ни сорасалар — шуны бирә. Беләсезме, борынгы Сервантесның Дон-Кихоты кебегрәк.

— Ә бу әйбәт түгелмени? — дип гаҗәпсенде Томмазо, чөнки ул саф күңелне, ачыклыкны барысыннан өстен дип санарга күнеккән иде.

— Хәзергә юк, — диде педагог. — Тормышта һәм җәмгыятьтә тискәре моментлар бетеп җитмәгән, хәтта вак җинаятьләр дә очрый әле. Алар белән көрәшә белергә кирәк, ә кайчагында үзеңне генә түгел, башка берәүне дә аямаска туры килә. Шуңа күрә без пансионатта балаларга көрәш тәрбиясе дә бирәбез. Кеше көрәшче булып үсәргә тиеш. Ләкин нәселдән килгән сыйфат — хасиятләр зур әһәмияткә ия: психогенотип йомшак булса, корычтай нык кеше тәрбияләү... үзегез беләсез.

— Әйе, — диде Томмазо, кеше табигатенең һәм тәрбия мәсьәләсенең нечкәлекләрен белеп бетермәвенә дә карамастан,— аңлыйм шикелле.

— Тагы бер сорау. Турысын әйтегез әле, Анри: дөньяда Дәрьял барлыгы уегызга керәме? Исегезгә төшкәлиме? Аңа карата хис-тойгыларыгыз нинди?

Томмазо уңайсызланып кына елмайгандай итте (чөнки соңгы биш ел эчендә космология мәсьәләләреннән башка нәрсә турында уйлаганы бер дә хәтерләми иде):

— Уйлаганым да юк диярлек. Гади кызыксыну гына. Якынлык тойгысы? Белмим,— диде.

— Ә бит биологик яктан, Дәрьял сезгә туган гына түгел, тагын да якынрак. Улыгыз тиешле! Аңа мөнәсәбәтегез җылырак булып, рухи контакт урнаштыра алсагыз, Дәрьялны тәрбияләү уңышлырак барыр иде. Ул гадәттән тыш сәләтле, Анри. Гадәттән тыш! Һәм мондый сәләтне үстермәү, иҗтимагый күзлектән караганда, гафу ителмәслек хата булыр иде.

Уңайсыз тынлык чак кына озаккарак сузылды.

— Бу хакта сөйләү иртәрәк түгелме? — дип сорады кунак, башын күтәрмичә генә. Аның бит очлары кызыша башлады.

— Юк, иртә түгел. Биш яшьлек бала Эвклидның параллель турылар хакындагы постулатыннан канәгать булмыйча, Лобачевский һәм Больяи юлына баскан икән, бу инде...

Карт педагог кунакның уңайсызлануын күреп тора, ләкин нәзакатьлек саклау кагыйдәләрен читкә тибәреп, аңа басым ясавын дәвам итә иде. Нигә микән?

— Анри... — диде педагог, кунакның күзләренә үк карап. — Анри... Балага карата җаваплылык хисе тою... сезнең үз тормышыгызга да ямь өстәр, аны тагы да мәгънәлерәк итәр иде. Ата булуыңны тою искиткеч тойгы ул!

Педагог кабинетыннан чыгып килгәндә Анри Томмазо коридорда баягы санитар туташны очратты. Кызга ифрат озын күлмәк кигән бер ханым ияргән иде. Тәрәзәдән төшкән кояш яктысында ханымның алсу колак яфракларына эленгән эре бриллиантлар җемелдәде.

Ханым Томмазога игътибар итмәде шикелле, ә Томмазо аны таныган кебек булды. Кинофильмда күргәндер, ахрысы. Берәр атаклы җырчы дисәң инде? Әллә биючеме?

Педагог Томмазоны уен залына алып керде.

Бу бүлмә гадәттән тыш зур булып чыкты. Дөресен әйткәндә, Ай кешесе Анри биналарның һәр квадрат сантиметры исәптә булуына күнеккән иде.

Монда шакмак өеп уйнаудан алып автоматлаштырылган өстәл футболына кадәр төрледән-төрле уеннар бар. Өстәл янында ике дистәдән артык малай кайнаша. Кулларында кечкенә генә идарә панеле, шуның ярдәмендә алар өстәлдәге курчак футболчыларны «йөгертәләр». Бер малай тынычрак күренә, анысының кулында гади сызгы гына: арбитр.

Шахмат почмагы кемнән дә исен китәрерлек. Шахматның йөз шакмаклысы гына түгел, цилиндр һәм бөҗра рәвешендәгесе, стереошахмат дигәне, берьюлы дүрт кеше уйный торганы да бар. Биредә, әлбәттә, өлкәнрәк балалар. Хәер, шахмат белән мавыккан бер малайга биш-алты яшьләрдән артык түгелдер. Ул берничә иптәшенә каршы уйный: тегеләре пышылдашып алгач кына йөреш ясыйлар.

— Дәрьялмы? — дип сорады Томмазо.

— Шул үзе, — диде педагог һәм шахматчы малайга дәште:

— Дәрьял! Тактага карамыйча уйнарга синең иртәрәк әле!

— Хәзер бетә, маэстро, — диде малай һәм каршы якка мат игълан итте.

Борыннары салынган малайларны күргәч, Томмазо күкрәгенә горурлыкка тартым бер хис тулганын тоеп, елмаеп җибәрде.

Педагог малайның кыска итеп алдырган кара чәченнән сыйпады һәм үзенә иярергә кушып ым какты.

Алар — Анри Томмазо, педагог Һашим һәм бәләкәй шахматчы — залның иң аргы почмагына барып утырдылар.

Педагог малайны математика фәннәре докторы Анри Томмазо белән таныштырды. Дәрьял бөек математика әһелен беренче тапкыр күрә иде һәм малайның күзләрендә шатлык чаткылары кабынды:

— О! — диде ул, дәртләнеп.

— Параллель турылар ни хәлдә? — дип шаяртты педагог.

— Бишенче постулатны исбат итү мөмкин түгел, — диде малай һәм аның йөзенә җитди төс чыкты. — Ләкин...

Томмазо үзенең: «Ләкин?» — дип сораганын сизми дә калды.

— Ләкинме? — диде бала, күзләрен хәйләле кысып. — Аннары мин параллель турылардан башка яңа геометрия төзеп карадым.

Педагог җәһәт кенә Анри Томмазога күз төшереп алды.

Анри сорау бирергә авызын ачкан гына иде, Дәрьял үзе үк җавабын әйтеп бирде.

— О, Лобачевский белән Больяины беләм мин! Безнең фильмотекада алар турында диафильм бар... Тик, маэстро, тагы да киңрәк... тагы да...

Малай сүз таба алмыйча, кулларын җәеп, нәрсәнедер кочарга тырышкандай хәрәкәт ясады.

— Тагы да гомумирәк дип әйтергә телисеңме?

— Әйе! Тагы да гомумирәк геометрия төзергә мөмкин!

«Риман геометриясен әйтә...» дип уйлап алды Анри Томмазо, малайның шома маңгаена карап.— Бу бәләкәч унтугызынчы гасырда даһи Риман ачкан нәрсәләргә килеп җиткән инде... Искиткеч! Әгәр тәрбиячеләре тыеп тормаган булсалар, бу малайның интеллекты кайларга барып җитмәс иде...»

Томмазо малайның кечкенә һәм йомшак кулын кысты.

Ниһаять, педагог Һашим, башта ук килешеп куелганча, урыныннан кузгалып:

— Мин сезне беразга калдырып торам, — диде. — Әйбәтләп танышыгыз, ярыймы, Дәрьял?

Икәү генә калгач, Анри беркавым малайның йөзенә карап утырды. Озынча матур йөз. Кыйгачрак утырган күзләреннән үк аның канына шәрыкъ катнашканлыгын чамалап була иде.

«Борыны гына минем борынга ошаган бугай,— дип уйлады Анри.— Ләкин бәләкәй чакта мин болай матур булмаганмын...»

Кинәт малай туп-туры сорау бирмәсенме:

— Сез... сез минем кардәшемме?

Бу самими сораудан Томмазо каушап калды.

— Әйе, Дәрьял... Ләкин, беләсеңме...

— Бая сезне күрү белән әллә ничек булып китте. Әтием түгелме икән дип тә уйладым.

Моңсу күзләреннән аның моңа ышанып бетә алмавы күренә иде.

Бераз дәшми утырганнан соң, Томмазо бик авырлык белән генә:

— Мин синең әтиең, Дәрьял, — диде.

Шатлыклы күз яшьләре дә, кочаклашулар да булмады. Ләкин малайның йөзенә горурлык хисе ташып чыкты: аның әтисе — атаклы математик бит!

— Син мине Айга алып китәрсеңме? — дип сорады Дәрьял. Сорады гына түгел, күзләре белән, Томмазога елышкан гәүдәсе белән үтенде.

Дәрьялны алып китү Томмазоның уена да килмәгән иде, чөнки «Улым бар» дигән яңалык аның үзе өчен дә сәер иде әле. Ул үзенең берничә ел ял алмыйча эшләгәнлеген исенә төшерде дә:

— Берәр айдан алырга килермен. Менә ашыгыч эшләремнән бушыйм да... Ярыймы? — диде.

— Ярый.

— Башта Җирдә сәяхәт итәрбез. Тайганы да, саванналарны да күрербез, Батискофта иң тирән океан чоңгылына төшәрбез, Көньяк полюстагы Амундсен-Скотт станциясенә барырбыз.

— Минем иң биек тауга менәсем килә,— диде малай.— Җомалуңмага.

— Менәрбез.

— Айга да!

— Әлбәттә. Әгәр администрация һәм тәрбиячеләрең рөхсәт итсә — озакка җибәрсәләр дию ем. — Айның карамаган җирен калдырмабыз. Мәшһүр «Туры стена»ны да, төпсез упкыннарны да, Тихо кратерыннан чәчелгән нурларны да күрербез.

— Кояш тотылганны да!

— Җае чыкса монысы... Ә Айда кояш тотылу ифрат матур. Җир шары түп-түгәрәк салават күперед әй бөҗра белән әйләндереп алына...

— Ә без нитсәк... — качсак? —дип пышылдады Дәрьял, хыялга бирелеп һәм аның кайнар сулышы Анриның көйдереп алды.

— Сиңа монда күңелсезме әллә? Ямансуmы?

— Күңелсез түгел лә... — диде малай теләр-теләмәс кенә. — Минем монда иптәшләрем күп.

— Ә аларның... әтиләре килеп йөриме соң?

— Рәшадның гына әнисе килә. Ә башкаларның — юк. Безгә унөч яшь тулгач — «Гакыл һәм хис көне»ндә — ата-аналар белән очрашу булачак. Ә аңа кадәр әниләр... үлеп китсә? — дип пышылдады малай үтә җитди кыяфәттә.

Евгеника институтында фән хакына законлаштырылган мондый ятимлек математик кешенең дә кәефен китәрде, китәреп кенә калмады — йөрәгенә килеп кадалды. Анри үзен хиссияттән ерак кешегә санап йөри иде. Баксаң, аның хисләре йоклап кына яталар икән ләбаса. Менә алар — кеше хисләре — уяндылар. Уяндылар да: «Син бу гуманСЫЗ экспериментка риза булмаска тиеш идең! Синдә бер тамчы да җаваплылык тойгысы булмаган!» — дип вөҗданын газапладылар.

Ул Дәрьялның юка иңбашыннан тотып үз каршына бастырды һәм аны бинибһая яратуын тойды.

Башын күтәреп караса, Анри янәшәдә генә басып торган икенче бер малайны күрде. Малайның елтыр күзләрендә түм-түгәрәк соклану һәм, әлбәттә, көнләшү дә бар иде төсле. Әйе, көнләшү.

— Рәшад ул, — диде Дәрьял, Анрига туры карап. — Әйткән идем ич — аның әнисе килгәли.

Берәр минут үткә, Дәрьял Анри Томмазоның сул тезенә, Рәшад исә уң тезенә менеп кунаклаганнар иде. Анри аларның укудагы уңышлары турында сорашты.

Психолог Һашим кереп, аларның җанлы әңгәмәсен бүлдерде. Ул, юк кына сәбәп табып, Рәшадны иптәшләре янына озатты. Психолог нәрсәдәндер канәгать түгел иде шикелле. Анри шиккә калды: «Педагогика кануннары белән сыешмаган ялгыш җибәрдемме әллә? Бәлки, хискә бирелеп, артык сентиментальлек күрсәткәнмендер?» — дип уйлады.

Аерылышканда Анри Дәрьялга тиз арада әйләнеп кайтырга сүз бирде.

— Мин көтәрмен, — диде малай, күзләрен мөлдерәтеп.

Психолог кабинетындагы сөйләшү бик җитди булды.

— Ата булу белән сез үз өстегезгә гаять зур җаваплылык аласыз, — диде психолог. — Әлегә Дәрьялның күңелендә ата-ана биләргә тиешле урын буш иде. Буш иде, аңлыйсызмы?

Анри дәшмәде.

— Ягъни ата һәм ана кешене башка берәү дә алмаштыра алмый, бала психикасы дөньяда үзенә тормыш бүләк иткән кешеләрне көтә. Бу аның геннарына ук язылган. Импринтинг: мин синең әтиең дип әйткән кешене ул ата дип кабул итәчәк тә.

— Кыскасы, нормаль үссен өчен балага ата һәм ана булуы кирәк, — дип бик гади нәтиҗә ясады математик. — Элементар хакыйкать бу. Ә нигә соң бирәдә...?

Педагог туры җавап бирмәде. Үзе хезмәт иткән институтның бөтен эшен бер селтәнүдә сызып ташлый алмый ич ул. Хәер, аның бу инсти-

тутка тискәре карашы тел төбеннән сизелде инде. Ул, кеше буларак, монда ятимнәр тәрбияләгәнен күрмимени?

— Без Дәрьялга сезнең фоторәсемнәрне бирербез. Рәсми биографиягезне укытырбыз.

— Әйе.

— Дәрьял өчен махсус уку программасы төзергә кирәк. Математика укыту юнәлешен билгеләүдә ярдәм итәрсез дип уйлыйм, ә гуманитар фәннәр буенча программаны мин үзем төзермен. Күргәнсездер, бу яктан Дәрьял гадәти балалардан арттарак... Монда сезнең геннарның өстенлек итүе аермачык.

— Өстенлек итүе? Ә аңарда тагы ниндн геннар бар соң? Димәк...

— Әйе, Анри... Дәрьялның генотибы сезнекенә тәңгәл үк түгел. Югыйсә, ул төскә-биткә дә, психик яктан да коеп куйган Анри Томмазо булыр иде бит! Аның эмбрионында сезнең колак йомшагыннан алынган ярымкүзәнәк һәм... тагы бер ярымкүзәнәк була.

Педагог Һашим Анри Томмазоның күзләрендә кабынган сорауларга бер-бер артлы җавап бирде:

— Табигый, икенче ярымкүзәнәк хатын-кызныкы иде, Анри... Ни өчен колак йомшагыннанмы? Колак йомшагы тышкы тәэсирләргә чыдам булганга. Әйтик, температура үзгәрешләрен ул җиңел күтәрә. Ә эмбрион үсеше өчен бу бик мөһим, чөнки пыяла колбада ана карынындагы константаларны саклау мөмкин дә түгел.

— Кем? — дип сорады Анри ят бер тавыш белән.

— Әйдәгез, монысын хәзергә калдырып торыйк, Анри. Һәрхәлдә шуны белегез: әгәр ата буларак, Дәрьялга сезнең хакыгыз бар икән, ана кеше дә шундый ук хокукка ия...

Психолог Анри Томмазоның иреннәре кысылганын күреп, сизелерсизелмәс кенә елмаеп куйды:

— Шунысына ышаныгыз: евгениклар гадәттән тыш уңышлы комбинация сайлаганнар. Хәер, моны электрон-хисап машинасы ярдәмендә хәл иткәннәр дип беләм.

Байтак кына тын утырдылар. Психолог Анриның уйларын бүлдермәде. Уйласын. Ай хакына туган Җирен оныткан кешегә тормыш турында уйлау бик кирәк. Әлбәттә, аңа әзер фикер бирергә дә мөмкин булыр иде. Ләкин галим кеше үзенең логик нәтиҗәләренә ныграк ышана. Уйласын.

Психолог ялгыша иде.

Бу минутларда Анри Томмазо уй-фикер йөртү сәләтеннән мәхрүм калган кебек иде.

Аның каравы Анри Томмазоның күзләре ачылган кебек булды.

Әнә тәрәзә. Кояш күтәрелгән саен тоныклана бара торган пыялалар. Тавыш дулкыннарын йота торган биокеләмнәр һәм биопаласлар. Аларның тузган җепселләре урынына яңалары үсә. Әнә, гәүдәңә карап җайлаша торган ялагай урындыклар...

Ниһаять, шушы өзек-өзек тәэсоратлар арасыннан зәһәр уйлар, сораулар калкып чыкты. Ә табигать кайда соң? Имеш, битеңнән сыйпап иркәли торган чын кояш нуры кайда? Хәрәкәт шатлыгыннан мәхрүм иткән мондый йоклаткыч кәнәфиләр картларга да, зәгыйфьләргә генә кирәк. Болар кешелек дөньясының картаю галәмәте микәнни? Ә картаюның чиге... әйе, чиге бармы?

Мондый уй Анри Томмазоны сискәндереп җибәрде.

Адәмнәр шулай картая — үзгәрә барып, кеше дигән биологик төрнең сыйфатларын югалтып бетермәсләрме? Ә Анри үзе? Ул ата-бабаларын, канлы һәм шанлы тарих сәхифәләрен, борынгы кыйммәтләрне онытып бара. Челтерәп яткан кизләүләр, шау усаклар, исерткеч бал һәм әче әрем исләре... ул боларның берсен бер белми!

Дәрьяллар буыны табигатьнең җылы күкрәгеннән тәмам аерылыр, ахрысы. Әйе, табигатьнең ямьле һәм гүзәл чагы — йөгәнсез һәм кыргый яшьлеген күрмәгән буыннар килә. һәм алар үзләре килгән дөньяны табигый бер норма дип кабул итәләр. Димәк, табигатьнең берәр почмагы кителгән булуын киләчәк буын сизмәячәк. Иң яманы шул!

Матурлык деградациясе түгелме бу?

Анриның күз алдына пассажир ракетасында очраган карт шагыйрь килеп басты. Ул нәкъ шушыны әйткән иде түгелме соң? Шагыйрь исенә төшкәч, Томмазо иркен сулу алды һәм үзе дә сизмәстән елмаеп җибәрде. Шул мизгелдә ул каршындагы психологка күз төшергән иде, аның да дустанә елмайганын күрде.

Шагыйрь Томмазога җиргә кайткач «Өч грация» скульптурасын күрергә киңәш иткән иде шикелле. Өч грация... Нәрсә микән ул?

Математикның күңеле әллә нишләп китте. Ул наданлыгыннан, үз-үзеннән оялды.

Психологик һашим белән алар бик җылы хушлаштылар.

...Институт шәһәрдән читтә, нарат урманы буенда урнашкан, ләкин магистраль юллар аңа ерак түгел, җиңел очкычлар станциясе дә якын гына иде.

Томмазо бирегә бер урынлы орнитонтерда килгән һәм, кайчан кирәк буласын белмәгәнгә, очкычны автомат идарәгә куеп кире станциягә җибәргән иде. Аны хәзер чакыртырга да булыр иде булуын. «Юк, тәпитәпи генә барып карыйм әле,— диде үз-үзенә Томмазо егетләнеп. — Биш километрны дә җәяүләп үтә алмаган кешедән әүвәлгеләр ничек көлерләр иде», — дип уйлады ул.

Ләкин ай кешесенә җир чакрымнарын узу чыннан да җиңел түгел икән. Турыдан бармакчы булып, ул тыюлык урман аша киткән иде, куелыкта адашып, чирәмле сукмакларда байтак әйләнеп-тулганып йөрде. Урман авызына килеп чыкканда егет шабыр тиргә батып, тәмам алҗыган иде. Ул гына да түгел, урман-чытырманда аның чалбары тезбашыннан ертылды, җитмәсә башмагы кыра башлаган иде. һәм аңа, ирексездән, бер агач төбенә утырып, чалбарының үзеннән-үзе ямалганын көтәргә туры килде. Ул кыскан башмагын гына түгел, икенчесен дә, оекбашларын да салып ташлады. Аяк табаннарын җанлы үләннәр кытыкланды. Томмазоны ниндидер яңа хисләр, яңа уйлар, яңа тойгылар биләп алды. Шушында көтеп утырган чирек сәгать эчендә ул җир табигатендәге күп нәрсәләргә игътибар итеп, балалар кебек гаҗәпләнде, куанды, ләззәтләнде.

Усак яфраклары ничек сизгер, ничек иркә икән! Чак кына җил кагылды исә, алар леперләп сөйләшергә, пышылдашырга тотыналар, ә башка агачлар әлегә тып-тын, сер саклыйлар... Нигә шулай икән? Томмазо берничә яфрак өзеп алып, аларның рәвешен тикшерде, сабакларын күздән үткәрде. Каен яфрагының сабагы йомры, ә усакныкы яссыланып тора икән. Шуның аркасында ул, әлбәттә, бик сыгылмалы. Ләкин табигатькә бу ник кирәк булган соң? Усак агачының тереклеге өчен моның ни әһәмияте бар? Анри Томмазоның аналитик гакылы бу мәсьәләне бик тиз чиште, агач ябалдашындагы тышкы яфраклар шулай бөтерелгәләп, тирбәлеп торганда, эчкеләре дә кояш яктысыннан мәхрүм калмыйлар. Агач бит бүлмә гөле түгел, аны боргалап, яктыга күчереп куючы юк. Кыскасы, кояш энергиясеннән мөмкин кадәр тулырак файдалану өчен, усак яфракларына менә шушындый хәрәкәтчәллек кирәк булган.

Томмазо бер ботакны җилпәзә итеп селкеп, муеннарын җилләтеп алды.

Ул үзенең рухи халәтен аңламый иде. Ни өчен соң әле кәефе бу чаклы шәп, күңел күтәренке? Җир тартымын җиңгән мускулларына кан йөгереп, көч-гайрәт тулгангамы әллә? Бер шуңа гынамы?

Кул сузымында гына бер кочак чыбык-чабык ята иде: кайчандыр урманны җыештырганда яндырырга онытканнар, күрәсең. Томмазо тәвәккәл кыяфәттә өем янына чүгәләде дә, кесәсеннән Дәрьял ясаган лупаны чыгарды. Башын югары күтәреп, аяз күккә һәм Кояшка карап алды. Кояш аңа елмайган төсле тоелды.

Берничә минуттан аланда, күңелле чытырдап һәм төтәсләп, учак яна иде. Томмазо ут янына утырды.

Утка карап торганда кеше бар дөньясын оныта. Һәр мизгелдә яңа рәвеш алган ялкын телләрендә шәхесең эреп югала да, фәкать бер уй— дөньяның мәңге үзгәреп, алмашынып торуы турындагы уй гына кала. Табигатьтә шуннан да югары, шуннан да бөек хакыйкать юк, ахрысы. Мәңге хәрәкәттәге болытларга да карап туймыйсың, шарлавыкка, алкын Иделгә һәм диңгез дулкыннарына да... Алар да бер хакыйкатьне тәкърарлыйлар: «Аһ, син, кеше. Табигатьтән өстен түгел син. Син олуг табигатьнең бер кисәкчеге. Син дә һәр даим үзгәрештә. Синдә шушы мизгелдә нәрсәдер туды, нәрсәдер үлде...», — диләр.

Шул чакны аяк очына шап итеп бер коңгыз килеп төште. Юк, кунмады. Нәкъ чуерташ кисәгедәй атылып төште! Төште дә төзәтенә башлады: җиз калканнарын ачкалап, элпә канатларын җыештырды, аяк селкетеп, язгглап карады. Исән! Тәртип.

Анри коңгызны учына алып салган иде — авырлыгына исе китте. «Ничек һавага күтәрелә дә, ничек оча икән бу әкәмәт?» дип уйлады галим. Чыннан да, кургашын ядрә кебек авыр бөҗәкнең кечкенә генә канат ярдәмендә очуы аэродинамика кануннарына сыеп бетми кебек. Гаҗәп! Томмазо бу мәсьәләне математик яктан ныклап тикшерергә ниятләп, куен дәфтәреннән бер бит ертып алды да, коңгызны кәгазь конуска төреп кесәсенә салды. Күкрәк турысында коңгызның кыштыр-кыштыр кыймылдавы, ә кул белән кагылгач тагы үлгән булып кылануы аңа кызык тоелды.

Анри оекбашларын киеп, аягына башмагын элде дә, учак көлен әйбәтләп таптады. Аннары баягы сукмак буйлап көньякка таба юл тотты. Чирек сәгатьләп атлагач, ул урман авызына килеп чыкты һәм орнитоптер станциясенең җилдә җилфердәгән аклы-каралы җиңсә-флюгерын күрде.

Космопортка бару өчен аңа кечкенә орнитоптер тәкъдим иттеләр, ләкин, яшен якынлашу сәбәпле, бер-ике сәгать күтәргә туры киләчәк иде. Шуңа күрә Томмазо җил-яңгырга исе китми торган транзит аэробуска утырырга булды. Һавадагы аэробуска аны орнитоптерда меңгереп куйдылар.

Меңгә якын турист утырган аэробус урман-кырлар, таулар-елгалар өстеннән очты.

Монда һәр утыргыч каршында телеэкран бар һәм теләгән кеше түбәндә яткан төбәкләрнең табигате һәм тарихы турында фильм карый ала иде.

Ярты сәгать саен тапшырыла торган телехәбәрләрнең берсе үзенең музыкаль кереше белән игътибарны җәлеп итте. Йөрәкне җилкендерә торган, шатлыклы, тантаналы музыка иде ул.

Анри Томмазо тезенә куйган кәгазьләрдән аерылып, экранга күтәрелеп карады. Кәгазьдәге формулаларда ул терекөмеш тамчысыдай авыр бер коңгызны һавага күтәрә алмыйча гаҗиз иде, экранда да табигать кануннарына каршы килгән шундый ук могҗизаны күрде.

Балерина, җир тартуын җиңеп, югары атылды да, канат кулларын җилпеп, салмак кына түбән төшә башлады... Томмазо, әсәрләнеп, эчке калтырану белән, аның аяклары сәхнә идәненә орынганны көтте. Бәллүр пыяладан койган бу аяклар артык нәфис һәм менә-менә уалып китәрләр кебек тоелды аңа. Томмазо юкка курыккан икән: биюче җансыз

чәчкә өеменә түгел, бәлки мәһабәт аккошка әйләнде дә күзгә күренмәс йомшак дулкыннарга таяна-таяна йөзеп китте.

Кем бу? Бөтен Җир-Ай системасында атказанган биюче Очкын Карагез шушы микәнни?

Чиксезлекне берәү дә күз алдына китерә алмый. Очсыз-кырыйсыз дөньяны тик биниһая көчле сәнгать кенә колачлый ала. Табигатьнең чиге булмаган шикелле, сәнгатьнең дә чиге юк. Томмазо кинәт менә шул хакыйкатьне аңлады. Ул дөньяны хисапка гына буйсына дип белә иде, ә сәнгатьтән ягъни хыял белән шигъриятттән башка, дөнья буш һәм җансыз икән... Табигать һәм чынбарлык алтын йөзек булса, сәнгать аның асыл кашыдыр.

Биюченең йөзен күргәч, Анри сискәнеп китте. Ул ифрат таныш һәм якын булып күренде аңа. Әйтерсең лә, Очкын Карагез моңарчы да аның хыялында яшәгән һәм төшләренә кереп йөдәткән бер зат иде. Очкынның чаткылар чәчкән күз карашы, очынкы кашлары, шулар арасындагы күк йолдызыдай миңе, чак кына һавалырак чөелгән борыны, очлы иркә ияге — барысы да коеп куйган Дәрьялныкы иделәр!

Анри Томмазо Евгеника институтының коридорында очраган озын күлмәкле чибәр ханымны исенә төшерде. Ул аңа актрисадыр кебек тоелган иде. Ә бит ул мәшһүр балерина — Очкын Карагез булган!

Очкын һәм Дәрьял, Очкын, Дәрьял һәм... Анри.

Математикның әле беркайчан да болай ук дулкынланганы булмагандыр. Ул кесәсендә кыштыр-кыштыр килгән бөҗәк барлыгын да, кулындагы карандашын да онытты, ә блокноты тезеннән шуып төшеп китте...

Ул хәзер үзенә нишләргә кирәклекне белә!

Анри бер минут та көтмәстән Айга телеграмма сугачак, ике айлык, хәтта бер кварталлык ял сораячак. Ул бит инде биш ел буена ял итмәгән иде, чөнки ял дигән нәрсә аны үзенең бөек максатыннан ераклаштырган булыр иде. Анри Томмазо үзенең бөтен тормышын стереовакыт дигән богауны өзеп, кешелекне иреккә чыгару эшенә багышлаган иде. Бөек максат! Кеше гакылы өчен йолдыздан йолдызга гизеп йөрү генә аз. Анриның мондый сәяхәтләр генә канәгатьләндерми. Аның вакыт-заманнар буйлап та сәяхәт итәсе, үткән заманнарга барып чыгып, борынгы дөньяга күз саласы килә. Әйтик, Җирдә борынгы тереклек ничек яралганны күзәтү нинди әһәмиятле булачак.

Дөрес, Анриның стереовакыт буйлап сәяхәт итүгә тулы ышанычы юк. Үткән заманнарга барып чыгу бүгенге көнгә мең төрле юллар белән зарури рәвештә тәэсир итеп, әллә нинди үзгәрешләр китереп чыгарачак һәм, кызганычка каршы, ул үзгәрешләрне алдан күреп тә, көтеп тә булмый. Әйтик, мезозой дәверенә барып, юк кына бер бөҗәкне ялгыш һәлак итүең аркасында кайнозой дәверендә боланнар кырылып бетүе бар. Чөнки әлеге хәшәрәт бөҗәк кылыч теш юлбарысларга үрчергә ирек бирмәгән, ә алар болан аулаганнар. Сәбәп-нәтиҗә чылбыры әнә шулай чебеннән фил ясый.

Анри Томмазо үткән заманга йомык стереовакыт аппаратында үтеп керү теориясен эшли иде. Ул бүгенге көн белән әллә ни кызыксынмый, фәкать аның табигый агыш белән агуын гына тели иде...

Әйе, ул көндәлек тормыштан бик ерак, бик ерак кеше шул.

Аэропортта багана башларындагы, стеналардагы радиодинамиклар дөнья бетереп турист Анри Томмазоны эзлиләр иде: «Доктор Томмазо. Доктор Томмазо, хәзер үк почта бүлегенә керүегезне сорыйбыз...»

Почта бүлегендә Анриның ике ашыгыч телеграмма көтә иде.

«Кадерле Анри, без Дәрьял белән Фил сөяге яры буена ялга киттек. Килерсез бит?

Очкын Карагез».

Икенче телеграмма педагог Һашимнан иде. Бусы кыска, өч сүздән генә тора: «Бәхет-сәгадәт телим».

Анри телеграммаларны бөкләп кесәсенә салды һәм, хыялый елмаеп, Африкага чираттагы рейсның кайчан булачагын белешергә китте. Шул чагында аның кесәсеннән, линолеум идәнгә бер коңгыз төшеп калды. Коңгыз канатларын ачкалап та япкалап маташты, ахырда рәткә китерде дә, җир тартымын җиңеп, һавага күтәрелде, һәм туп-туры ачык тәрәзәгә юл тотты.

## Укучының күңел дәфтәренә

**Украин мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Олаудагы күзлене сукыр ат тартып бара.*
*Алтын читлеккә япсаң да очар кош тоткын була.*
*Башта син кунакка чакыр, аннары мин килермен.*
*Ленин хакыйкатьтәй гади, Ленин халыктай зирәк.*
*Бөртегең башакта чакта басуга кызу атла.*
*Хезмәт чәчсәң — дан үсәр.*
*Күккә коедан карасаң — бик аз нәрсә күрерсең.*
*Һәр кешегә яхшы кеше беркемгә дә ярамый.*
*Җырламыйча йөргән солдат — патронсыз мылтык кебек.*
*Атаң улы гына булма, ватаның улы да бул.*
*Дошманга ут ашы ашат, кургашын суы эчерт,*
*кайнар пуля каптыр да минага салып йоклат.*

**Хакас мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Югалткан кеше — мең языклы, алган кеше — бер языклы.*
*Ике яхшы кешенең арасыннан су үтми,*
*ике яман очрашса — арада кан коела.*
*Ялганчы кеше куркак та була.*
*Елга башы таулар булса, партия көче — халык.*
*Бүре сарык саклый алмый.*
*Үзең ничек кычкырсаң кайтавазың шул булыр.*
*Тамагы артык тук булган эт үз хуҗасына өрә.*
*Ятим колын тизрәк ат була.*
*Шыгырдыкияр — атка комачау, исерек кеше — халыкка газап.*

*ОЧЕРКЛАР*

# ИДЕЛ БӨРКЕТЕ



Сабыр холыклы Дмитрий Рогачев озак вакыт Зеленодольск шәһәрендә яшәде. Ул Татарстандагы бик күп политик һәм иҗтимагый вакыйгаларга актив катнаша торган кеше иде. Ул, вафат булгач, Зеленодольскида күмелде. Республика кешеләре, Амур, Днепр, Идел флотилиясе моряклары аны зур ихтирам белән искә ала.

...Сталинград төнге караңгылыкка чумган. Шәһәр өстендә шомлы сентябрь җиле уйный. Урамнарда һәм мәйданнарда дары, нефть, тимер һәм мәетләр исе. Караңгы һәм салкын Идел буена суднолар кәрваны сузылган.

Флотилия командующие Дмитрий Рогачев штаб корабы палубасына чыгып басты. Уртача буйлы, пәһлеван кебек киң җилкәле бу кешенең йөзе бүген бик җитди. Контр-адмирал инде кырык җидене тутырган, ә үзе яшь егетләрчә таза, нык.

— Салкын түгелме? — диде ул вахтадагы кызыл флотчыга.

— Һич юк, иптәш адмирал!

Командующий матросны яңадан бер кат күздән кичерә.

— Әйе, бик кызу чак шул, туңарга вакыт юк.

Октябрь революциясенең егерме биш еллыгы якынлашып килә. Хатирәләр яңартырга кайчак вакыт та тия. Хәлләр анда да кискен иде...

1917 елның дәһшәтле октябрь төнендә Балтик флотының «Слава» линкоры матросы Дмитрий Рогачев революцион переворотта катнаша. Таврис сараен революция дошманнарыннан саклый. Аннан кызылларның Беренче фронты, Петроградка ыргылган кадетлар белән сугышлар. Ревель янындагы штык сугышында ул яралана. Җәрәхәте төзәлгәч, ак финнар десантына каршы көрәшкә китә. Контузия, тагын госпиталь. Унтугызынчы елда Рогачев матросларның икенче экспедициясе отряды составында «Красная Горка»ны штурмлый.

Озак та үтми, аны Байкал күлендәге Себер отрядына җибәрәләр. Монда ул беренче командирлык дәрәҗәсе ала — элемтә начальнигы ярдәмчесе итеп билгеләнә. Яңа эшкә алыныр алдыннан командирларга икеләнүе турында сөйли. «Кулымнан килерме? Белемем юк. Бала чакта мәктәпкә дә тулыр-тулмас дүрт кыш кына йөрдем. Белемне тормыш мәктәбендә генә алдым: ялланып эшләдем, корабльләрдә хезмәт иттем, дошманнарга каршы сугыштым. Дөрес, слесарь-электрик эшен беләм. Һөнәргә Царицында туп заводында өйрәнгән идем»,— ди ул командирларга.

— Һөнәреңнең ярдәме тими калмас. Хәзер Кызыл Флотка ко-

мандирлар кирәк. Син — коммунист.— Отряд командиры Н. П. Орловның җавабы Рогачевның икеләнүләрен киметеп калдырды.

1929 елда Көнчыгышта хезмәт итә, мониторда капитанның өлкән ярдәмчесе булып эшли, ак кытайларны тар-мар итүдә катнаша.

Бөек Ватан сугышы башланган көннәрдә ул флотилия командиры була. Матрослар мониторларда, туплар белән коралланган хәрби көймәләрдә, бронекатерларда фашистларга каршы соңгы мөмкинлекләренә хәтле сугышалар. Көчләр тигез булмый. Каты бәрелешләрдә судноларның күбесе бата, исән калганнарын Днепр моряклары үзләре шартлата, экипажлар коры җир гаскәрләренә кушыла. Командующий үзе Киев оборонасында каты яралана. Авыр хәлдә Рогачевны «У-2» самолетында фронт сызыгы аша алып чыгалар. Сул кулы йөрмәс хәлдә булса да, ул тагын сугышчан постына баса.

Язмыш исән калган сугышчан дусларны яңадан очраштыра. Алар күп булмый: 3 нче ранг капитаннары Всеволод Кринов белән Степан Лысенко, капитан-лейтенантлар Климентий Максименко белән Яков Небольсин...

Хәрби флотилия турыдан-туры кырыс Сталинград фронты командующиена буйсына. Аның алдында шәһәрне саклаучы коры җир гаскәрләренә ярдәм итү, Камышин — Астрахань арасында су юлы элемтәсен саклау, Идел аша безнең гаскәрләр янына чыгып йөрүне булдыру, фашистларның елганы кичүенә юл куймау бурычы тора.

Төн уртасы үтеп баруга да карамастан, флотилия командирларының күзләренә йокы керми. Югары чинлы офицерлар, штаб корабленә җыелып, суднолар хәрәкәте турында фикер алышалар. Көтмәгәндә телефон шылтырый.

— Дмитрий Дмитриевич, фронт командующие Еременко сезне сорый,— дип, флотилия штабы начальнигы Федоров телефон трубкасын Рогачевка суза.

Рогачев фронт командующиен игътибар белән тыңлый һәм аның җавабы да кыска һәм төгәл:

— Барысы да үтәлер!

Дмитрий Дмитриевич каютадагы диңгез офицерларына күз йөртеп ала да, Федоров һәм флотилия комиссары Бондаренкога мөрәҗәгать итә:

— Фронт командующие ашыгыч төстә елганың сул ягыннан шәһәр үзәгенә тулы бер дивизия чыгару бурычы куя һәм аны корабльләрнең артиллерия уты белән сакларга куша.

— Җиңел эш түгел, ничек башкарырга икәнен уйлашырга кирәк,— дип куя иптәшләренең берсе.

— Бу кичү түгел, дөресрәге, десант,— дип өсти икенче берәү.— Немецлар уң ярга якын килделәр, артиллерия утлары һәм минометлары Иделгә төбәлгән.

— Десант икән, десант, һич кичекмәстән кичү операциясен башларга кирәк!— ди җитди тавыш белән Рогачев.

Шәһәр үзәге районында һәм Мамай кургане итәгендә дошман зур көчләрен туплаган. Ул безнең частьларыбызны Иделгә бәреп төшерергә ниятләнә. Кыен хәлдән безнең гаскәрләрнең һәм флотилиянең яшендәй тиз һәм тәвәккәл хәрәкәтләре белән генә чыгарга мөмкин.

Елганың сул як яры урман белән капланган. Кызыл Бистә тирәсенә унөченче гвардия дивизия частьлары җыела. Бронекатерлар тупланган җиргә флотилия командующие катеры да килеп җитә. Дивизион командирлары капитан-лейтенантлар Степан Лысенко белән Александр Песков хәл итәсе мәсьәләләр җитәрлек.

— Корабльгә ничәшәр кеше алырга?

— Сез хәл иткәнсездер дип уйлаган идем.

— Исәпләвен исәпләдек, әмма нормадагыдан биш мәртәбә артык туры килә шул,— ди Лысенко.

— Мондый хәлнең булганы юк иде әле — дип өсти Песков.

Командующийның җавабы кыска һәм ачык:

— Сугышта күп нәрсә белән беренче тапкыр очрашырга туры килүен сез яхшы беләсез. Сугышчыларны бик тиз уң ярга чыгарырга кирәк. Подразделениеләрне бүлмәс өчен җидешәр норма да алырга туры килер. Корабль командирларына гаскәрне урнаштыруда ярдәм итегез. Кечү операциясен дошманга белгертмичә һәм котмәгәндә үткәрергә кирәк.

Һәм башлана...

Күк күкрәгәндәй гөрселдәгән артиллерия утыннан тирә-як дер килә, һава чыңлап тора. Прожекторлар уты астында калган Идел дулкыннары ярсып шаулый. Меңәр ат көченә тиң двигательләрен җиргеп, хәрби корабльләр уң якка юл яра. Беренче эшелон артыннан тральщиклар кәрваны кузгала, аннан баркаслар, баржалар таккан буксирлар китә.

Дошман безнең корабльләрне туктатырга тырыша. Аның снарядлары һәм миналары Идел суын фонтан итеп чөя. Ләкин уң ярга ашкынучы матросларны туктатырлык бернинди дә көч юк!

Командующий тыныч булып күренергә тырыша, ярдәмчеләре аркылы бер-бер артлы кыска-кыска күрсәтмәләр биреп тора. Аңа кичү операциясенең барышы турында хәбәр итәләр.

— Корабльләр сафтан чыкты,— дип аларның саннарын атый штаб начальнигы ярдәмчесе.

Командующийның боерыгы ачык:

— Тральщикларга ярдәм күрсәтергә! Бронекатерларны тоткарламаска! Артиллерия утын көчәйтергә! Мине генерал Чуйков белән тоташтырыгыз...

Уң як ярда кургашын пуляләр яңгыры ява, гранаталар уты көлтә булып күтәрелә. Ут өермәсенең ярдан ераккарак күчә баруы бинокль аша аерым-ачык күренеп тора.

Икенче төн дә, беренчесе кебек үк, киеренке һәм авыр үтте. Матрослар аргы якка яхшы коралланган дивизияне бөтенләе белән чыгарып бетерделәр. Дивизия фашистларны яр буеннан кубарып ташлады да оборонага урнашты. Родимцев дивизиясе артыннан Сары-су елгасының уң ягы һәм элеватор арасындагы районга 92 нче укчы бригада төшерелде. Бу бригада Төньяк һәм Балтик флотларыннан килгән моряклардан тора иде.

Август ахырында фашистлар, Донны кичеп, Сталинградка күп кенә танкларын, мотопехоталарын ташлыйлар. Дошман авиация ярдәмендә фронт сызыгын өзә дә шәһәрнең төньяк читеннән Идел ярына килеп җитә. Флотилия штабы немецларны елгага үткәрмәү өчен ашыгыч һәм эшлекле чаралар күрә. Алга ыргылган дошман гаскәрләренә каршы диңгез пехотасы батальоны күтәрелә. Ул, Сталинград эшчеләре отрядлары һәм гарнизон частьлары белән берләшеп, гитлерчыларның завод районына ыргылган омтылышын сүрелдерә. Аларга ярдәм итү өчен бронекатерлардан һәм артиллерия орудиеләре белән коралланган көймәләрдән флотилиянең төньяк отряды оештырыла. Флотилия командованиесе батальон һәм корабльләр отряды алдына тәгәл бурыч куя һәм аларның сугышчан бурычны үтәүләрен күзәтеп тора.

— Михаил Иванович, 3 нче ранг капитаны Телевнойдан нинди мәгълүматлар бар?— дип мөрәҗәгать итә Рогачев штаб начальнигы Федоровка.

— Орловка янында сугышалар. Телевной яраланды. Батальонга лейтенант Горшков командалык итә. Полковник Горохов батальонны башкаларга үрнәк итеп куя. Бик аз калдылар, күбесе батырларча һәлак булды.

— Кызганыч. Корабльләрдә белгечләр болай да җитешми. Судноларны тулыландыру турында уйларга кирәк.

Сталинград оборонасы чорында флотилия корабльләре дошман көчен күпләп юк итмәгән бер генә көн дә булмый.

— Танклар өере килә. Артиллериядән ут ачыгыз,— дип ярдәм сорый, 422 нче дивизия командиры полковник Морозов.

Корабль туплары дошманны ут белән каршылый. Немецларның 4 нче армиясе Котельниково һәм Абганерово районнарына көчле һөҗүм башлый. Фронтның бу участокларында безнең 64 нче һәм 57 нче армияләр оборона тота. Дошман көчле. Ул, елга ярына чыга калса, Иделне кичү мөмкинлеге дә ала. Аны туктату өчен флотилиянең ашыгыч ярдәме кирәк. Командующий Рогачев армияләрнең удар көчен корабльләрнең махсус бригадалары белән ныгыта. Бу бригадаларга контр-адмираллар С. М. Воробьев һәм Т. А. Новиков командалык итә. Флотилия артиллериясе немецларны унбиш километрдан ук көчле ут белән каршылый. Сугыштан соң генерал-майор И. К. Морозов бу дәһшәтле көннәр турында болай дип язачак: «1942 елның августы белән сентябрендә — коры җир гаскәрләре өчен иң авыр көннәрдә — безнең артиллерия утыбыз көчле түгел иде. Ярдәм вакытында килде. Дошман авиациясе бомбага тотуга да карамастан, контр-адмирал Рогачев командалыгындагы флотилия матрослары каһарманнарча сугышты. 64 нче армиянең команда пунктында флотилия командующие, коры җир гаскәрләре командованиесе белән бергә, дошманның ут һәм төп көче тупланган нокталарын дөрес билгеләде. Иртә таңнан корабльләрнең артиллериясе аларны юк итәргә тотынды. Диңгез орудиеләренең тиз һәм төз атуы безне таңга калдыра иде».

Сентябрьнең бу көне ап-аяз иде. Күктә бер генә болыт кисәге дә күренми. Кояш җәйнең эссе көннәрендәге кебек кыздыра. Идел өсте тып-тын. Мондый чакта бомбалар һәм снарядларның гөрселдәп ярылуы куркыныч түгел төсле. Шулай да теге яктагы хәрабәләр күзгә ташланып, дары һәм кан катнаш ис борынга бәрелеп, сугышны искәртеп тора.

Шундый матур көнне моряклар делегациясен партиянең Сталинград өлкә комитеты секретаре А. С. Чуянов үзенең пунктында якты йөз белән кабул итте.

— Без сезгә, Алексей Семенович, ярдәм сорап килдек,— дип башлады сүзен Рогачев.— Судноларны төзәтәсе бар. Ягулык һәм майлар белән дә эш әйбәттән тормый.

Чуянов, телефоннан предприятие җитәкчеләре белән элемтәгә кереп, хәлне ачыклады да матросларга кулдан килгән ярдәм күрсәтүне сорады.

— Тагын нинди үтенечләрегез бар?

Бондаренко үз күңелендә күптәннән бер фикер йөртә иде.

— Газета чыгару һәм листовкалар басу өчен кәгазь кирәк.

— Газетаны кайда басарга уйлыйсыз?

— Үзебездә. Кайбер җиһазларны таптык, белгечләребез юк.

— Бик кирәкле эш, газетасыз мөмкин түгел. Газетагызны шәһәр типографиясендә басарсыз.

— Минем дә сезгә үтенечем бар,— диде секретарь.— Кара Ярда Ленинградтан эвакуацияләнгән биш йөз бала җыелды. Тизрәк Идел аша чыгарып, тимер юл станциясенә якынрак илтәсе иде. Аларны Уралга озатырга кирәк.

Рогачев эсселе-суыклы булып китте. Шул балалар арасында ул үз кызы Наташаны күргәндәй булды. Кайда икән соң аның Наташасы? Кайда гына булмасын, янында әнисе бар ич. Ә бу ятимнәрнең беркемнәре дә юк. Рогачевның белүенчә, Чуянов һәм Бондаренко балалары да шундый ук хәлдә.

Тынлыкны Чуянов бозды.

— Иделдә фронт өчен кыйммәтле йөкләр һәм азык-төлек төяләгән баржалар батырылды. Аларны да бушатасы бар...

Үзенең команда пунктына кайтканда Рогачев командующий итеп билгеләнгән беренче көннәрен исенә төшерде. Ул корабльләрне һәм частьларны карап йөри. Флотилиянең оешкан чагы гына. Моряклар төрле частьлардан җыелган. Күбесе госпитальдән яңа гына чыккан, хәрби хезмәтләрен күптән үткән кешеләр. Алар гаять авыр шартларда эшлиләр. Шуңа күрә командующий штаб офицерларына матросларның тормыш шартлары белән кызыксынырга, кулдан килгән ярдәмне күрсәтергә куша. Үзе гел штабтан ерак корабльләрдә йөри, экипажларны атакага күтәрә.

Кырык икенче елның беренче яртысында Иделдә навигация бик кыен шартларда барды. Немецлар елганы туктаусыз бомбага тоттылар. Коралланмаган күп кенә судноларыбыз батып калды.

Бөтенләй көтмәгәндә нефть кәрванына фашистлар авиациясе һөҗүм итә. Бу турыда Рогачевка хәбәр итәләр. Ул ярымглиссерда бомбага тотылган урынга китә. Аерым баржалар гына түгел, бөтен Идел суы януын күреп йөрәгә әрни аның. Ут, еландай уклы телләрен сузып, судагы бөтен нефтьне ялап бара. Фашист козгыннарының яндыргыч бомбалары шартлавыннан капкан ут баржаларны учак иткән. «Нефть кәрванын коткару өчен мөмкин булмаганны да эшләргә кирәк»,— дигән карарга килә контр-адмирал.

Коралланмаган судноларга зенит туплары, пулеметлар куялар, корабльләргә өстәмә көч итеп флотилия резервыннан кызыл флотчылар һәм старшиналар җибәрелә, яр буенда зениткалар саны арттырыла. Йөк судноларына зенит туплары куелып, алар һава һөҗүменә каршы көрәш корабльләре вазифаларын үтәрлек хәлгә килә. Кәрван судноларын бронекатерлар озатып йөри. Әмма авыр йөкле судноларның агымга каршы йөзү тизлеге зур түгел — сәгатенә 4-5 чакрым гына. Флотилия җитәкчелеге моннан чыгу юлын эзләрчә уйлап таба. Бронекатерлар дошманның һава һөҗүменнән саклап кына калмыйлар, йөк судноларын этеп тә баралар. Һавада кара төреле козгыннар күренүгә, кәрваннан аерылып, аларга ут ачалар. Бу нәрсә навигациядәге судноларга фашист авиациясе һөҗүмен киметә. Мәкерле дошман, һава һөҗүме барып чыкмагач, суны миналарга керешә. Моны ул тәнлә эшли. Баштарак безнең транспорт флотына шактый зыян китерергә өлгерә. Фашистлар беренче мәртәбә Иделдә күп импульслы магнитлы миналар куллана башлыйлар. Ләкин аларның сере тиз ачыла. Сталинградның суднолар ремонтлау заводлары эшчеләре андый миналарны зарарсызландыру өчен махсус траллар ясыйлар. Миналарны юк итүгә бронекатерлар да кушыла. Бронекатерларның миналы суга беренче рейдында Рогачев үзе катнаша.

Флотилия корабльләре, снарядлар яңгырын үтеп һәм үлемне җиңеп, Сталинград ярына кабат-кабат чыгалар, шәһәрне саклаучыларга сугыш кирәк-ярагы, азык-төлек ташыйлар, яралыларны алып кайталар.

138 нче укчы дивизия командиры генерал И. И. Людников шундый рейсларның берсе турында болай дип яза: «...Идел өстендә төнге караңгылыкта, парашютларда яктырткыч фонарьлар асып, «Фокке-вульфлар» бөтерелә. Ракеталар балкуыннан елга өсте көзгедәй ялтырап тора. Дошман безнең корабльләрне һәм паромнарны күреп, тук-

таусыз ата да ата. Сугышчылар җиргә басу өчен ашкынып тора. Пехотачы җирдә үзен өендәге кебек хис итә: ул анда яшеренә, сыена ала. Дошман уты яуган су өстендә кыен, әлбәттә. Синда аталар, ә син, винтовкаңны күкрәгеңә кысып, баржада утырасың. Берни эшләп булмый. Яшьрәкләрнең нервлары түзми. Мин моны аларның бер-берсенә әйткән сүзләреннән сизәм.

— Ник акрын?

— Бер урында торабызмыни!

— Шыңшыма. Идел дигәннәр аны!..

Октябрьның икенче яртысында флотилиянең команда пунктына Сталинград фронты командующие генерал Еременко белән аның урынбасары генерал Попов килде. Рогачев командующийга флотилия кораблльләре һәм частьларының 62 нче армия гаскәрләренә ярдәме турында сөйләде. Еременконың бу хакта яхшы ук хәбәрдар булуы күренеп тора иде. Контр-адмиралны игътибар белән тыңлагач, ул урынбасарыннан:

— Идел матросларының хәрәкәтләрен ничек бәялибез?— дип сорап куйды.

— Верховный Башкомандующий Сталинга: «Идел хәрби флотилиясе коры җир гаскәрләрен шәһәргә һөҗүм итүче дошман көчләрен юк итүдә зур ярдәм күрсәтә» дип хәбәр иттек,— диде генерал Попов.

— Коры җир гаскәрләре командованиесе сезнең тырышлыгыгызны белми дип уйлый күрмәгез, Дмитрий Дмитриевич. Ярдәмегезне тоябыз, сезгә дә җиңел түгел.

— Хәзер берәүгә дә җиңел түгел. Һәркем Ватан алдындагы изге бурычын үти.

Кичен Ахтүбә бугазыннан «Красный Октябрь» заводына таба ике бронекатер китеп барды. Фронт командующие үзен озата бармауларын сораса да, Рогачев, бу тирә суларның хуҗасы буларак, өлкән хәрби начальникның куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен бронекатерга утырды.

«Елга, шәһәрдәге кебек, яп-якты иде. Немецлар һавага яктырткыч бомбалар яки ракеталар «асып куялар». Причалларга һәм култыкларга атып торалар. Идел ярлары җимерек-ватык әйберләр белән чуарланып беткән. Шулай да ул ярлар фронтны тулыландыру, яралыларны эвакуацияләү өчен бердәнбер юл иде»,— дип искә ала бу рейсны үзенең мемуарларында маршал Еременко.

Ноябрь салкын, ләкин көчле җил исә, әле кар, әле яңгыр ява. Сирәк-сирәк кенә кара-кучкыл болытлар арасыннан кояш та карап алгалый. Иделнең пыяладай юка бозларын вата-җимерә суднолар йөзә.

Фронт штабына ашыгыч рәвештә флотилия командующие Рогачев белән штаб начальнигы Федоровны чакырып алдылар. Штабта эш бик кызу, һәркем үз вазифасы белән мәшгуль. Матросларга аларның килүенә берәү дә игътибар итмәгән төсле тоелды. Дежур офицер кунакларны турыдан-туры фронт командующие янына алып китте. Бүлмәдә фронт штабы начальнигы генерал И. С. Варенников та бар иде. Еременко морякларны үзенә хас кунакчыллык белән каршылады. Флотилиядәге эшләрнең торышы белән кызыксынды. Федоров доклад язылган папканы ачкан иде, командующий аны туктатып торды.

— Сабыр итегез, хәзергә мөһимрәк эшләр бар.

Өстәл башында утырган штаб начальнигы урыныннан торып басты. Ул һәрвакыттагыча аз сүзле һәм рәсми иде.

— Һөҗүм операциясен тормышка ашыру өчен флотилия алдына түбәндәге бурычлар куела,— дип Рогачевка директива тоттырды.

— Димәк, һөҗүм! — дип аптырашта калды Рогачев.

Фронт командующие кәгазьләрдән күзен алмыйча гына:

— Әйе, һөҗүм!— диде.

Командование Рогачев өчен моның көтелмәгән хәл булачагын алдан ук белә иде, әлбәттә.

Рогачев директиваларда язылган кыска җөмләләр һәм конкрет саннар эченә кереп чумды. Алар контр-адмиралга корыч хәрефләр белән кергән саен, аның дулкынлануы арта төште.

— Бу бит искиткеч зур һөҗүм!..

Еременко аны алдан ук кисәтеп куйды:

— Хәрәкәтләрегезне яшерергә тырышыгыз. Гади көннәрдәге кебек эшләгез...

Флотилия алдында торган беренче мөһим бурыч 62 нче армия берләшмәләрен кешеләр резервы, сугыш техникасы белән тулыландырудан гыйбарәт иде. Бу берләшмәләр Сталинград тирәсендәге фашист гаскәрләрен чолгап алуда һәм юк итүдә катнашырга тиеш. Боз белән капланган елга аша 62 нче, 57 нче һәм 66 нчы армияләр районына меңнәрчә кеше, йөзләрчә тонна сугыш кирәк-яраклары чыгарырга кирәк.

Әзерләнә торган операциянең күләмен күз алдына китерү өчен Советлар Союзы Маршалы Жуков истәлекләренә мөрәҗәгать итик. «...Гаскәрләрне һәм сугыш йөкләрен ташуда 27 мең машина эшләде. Иделнең уң ярына чыгару өчен тимер юлдан көн саен 1300 вагон йөк килә иде. Сталинград фронтына гаскәрләр һәм йөкләр гаять катлаулы шартларда Иделдә көзге боз катканда ташылды. 1 нче ноябрьдән 19 ына кадәр елга аша 160 мең солдат, 10 мең ат, 430 танк, 600 орудие, 14 мең автомашина, 7 мең тоннага якын сугыш кирәк-ярагы чыгарылды».

Әле телгә алынганнарның күбесен Идел хәрби флотилиясе корабльләре һәм йөзү средстволары ташыды. Матрослар сул яр госпитальләренә уннарча мең яралы солдатны һәм офицерны күчерделәр.

СССР Хәрби Диңгез флоты халык комиссары Н. Г. Кузнецов болай яза: «...Идел флотилиясе командованиесе флот көчен тральщиклар һәм траллар белән тулыландыру һәм арттыруны, елга суднолалрына зенит расчетлары җибәрүне үтенеп сорый иде. Әмма без бу өлкәдә күп ярдәм итә алмадык».

...Флотилия штабы начальнигы 1 нче ранг капитаны Федоров Баш диңгез штабына доклад яза: «1942 нче елның 2 нче июленнән 1943 нче елның 2 нче февраленә кадәр флотилия артиллериясе дошманның 47 танкысын, 118 орудиесен һәм минометын, гаскәрләр утырган 133 автомашинасын, 7 ягулык складын юк итте, 32 артбатарея уты бастырылды, 16 самолет бәреп төшерелде, 5000 солдат һәм офицер юк ителде...»

— Фашистларның югалтулары сизелерлек бит иптәш контр-адмирал?— диде бер таңда комиссар Бондаренко.

Рогачев сугышчан дустына күзләрен күтәреп карады:

— Бөек полководец Суворов дошманны санамыйлар, бәлки юк итәләр дип өйрәткән.

— Дошманның үлгәннәрен санарга кирәк,— дип каршы төште штаб начальнигы.

Алар икесе дә чын күңелдән көлеп куйдылар.

ЛАВРЕНТИЙ СЫРКИН,
отставкадагы 2 нче ранг капитаны

*Волгоград*

# КЫРЫС ЯЗМЫШЛАР



Кырык икенче елның февралендә мине, Мәскәүгә, кече политруклар әзерли торган округ курсларына җибәрделәр.

Башкала кырыс сугыш шартларында яши иде. Ул кышның күренешләре хәтеремдә мәңгегә саклана. Урамнарда һәм мәйданнарда танкларга каршы корылмалар: өчпочмаклап җиргә утыртылган рельслар һәм юан-юан бүрәнәләр тырпаеп тора, рельс кисәкләреннән эшләнгән «керпе»ләр утыра. Комлы капчыклардан баррикадалар корылган. Өй түбәләрендә һәм чарлакларда — зенит туплары һәм пулеметлар, күктә көмешсыман аэростатлар. Болар барысы да әле күптән түгел генә булган хәлләрне искә төшерә иде. Кырык беренче елның октябрендә немец фашистлары Мәскәүгә бәреп керергә ябырылды. Башкала аларны кире кагарга әзерләнде. Без килгән көннәрдә дошман инде Мәскәү тирәсендәге сугышларда мөгезен сындырган иде, шулай да кала сугышчан-хәрби шартларга яраклашкан килеш яши бирә иде әле. Тревогалар игълан ителә, шәһәр тирәсендә һава сугышлары булып тора. Төннәрен караңгы күк киңлеген прожекторлар нуры телгәли, зениткалар гөрселдәве ишетелә.

Кыскасы, Мәскәү сугышчан тормыш белән яши иде. Трамвайлар һәм электр поездлары йөри, метро эшли. Кинотеатрлар янында чиратлар. Төрле фильмнар күрсәтелә: «Дуңгыз караучы һәм көтүче», «Мәскәү янында немец гаскәрләрен тар-мар итү», «Машенька»...

Без укырга килгән округ курслары элекке хәрби-политик училищеда урнашты. Монда тизләтелгән программа буенча рота политруклары әзерлиләр һәм аларны хәрәкәттәге армиягә озатып торалар иде. Көннәр киеренке хезмәт белән уза. Безгә вакыт аз бирелгән, ә өйрәнәсе нәрсәләр күп. Булачак политруклар подразделениеләрдә политик эш алып бару сәләтенә өйрәнергә дә, сугыш шартларында, кирәк булган чакта аларга командалык итәргә әзерләнергә дә тиешләр иде. Тактика дәресләре шәһәрдән читтә уздырыла. Без укчы частьларда була торган барлык төр кораллардан атарга өйрәнәбез. Төн уртасында тревога белән торулар, ун-унбиш чакрымга маршлар — болар барысы да безнең өчен гадәти хәлләр булды. Шулар өстенә, каравыл тордык, патруль хезмәтен дә башкардык.

Курсларда төрле милләт кешеләре укыды. Безнең взводта, мәсәлән, руслар, украинлылар, татарлар, чувашлар, грузиннар, казакълар бар иде. Барысы да партия членнары яки ВКП(б) членлыгына кандидатлар, нигездә, элекке партия, совет, комсомол хезмәткәрләре, укытучылар.

Яз якынлашты. Кояш инде яктырак балкый, көчлерәк җылыта башлады. Мәскәү елгасында боз кузгалды. Бозлар, гранит ярларга бәрелә-сугыла, агалар да агалар. Мәскәүлеләр өмәләргә чыга — урамнарны чистарта. Кояш җылыткан тротуарларда бала-чага уйный. Скверларда кулларына газета-журнал тоткан картлар, төрле кул эшләре белән шөгыльләнүче карчыклар утыра.

Без ике сәгатьлек гаскәри әзерлек дәресендә. Дәрес урамда, хәрби шәһәрчеккә илтә торган асфальт юлда үткәрелә торган иде. Мин бүген сөйләргә теләгән хәл, ул чагында онытылмаслык булып хәтергә уелган вакыйга нәкъ менә шушы дәресләр барган вакытта булды.

Апрель иртәсе иде. Строевой әзерлек дәресен алып баручы рота командиры «тәнәфес» игълан итте. Тартучыларның эше мәгълүм

инде — тәмәке тәрергә керештек. Шул вакыт курсант Григорян, якында гына торган ике катлы таш бина ягына ымлап:

— Әнә тегендә, почмакта басып торучыны күрәсезме, егетләр!.. Бер малай. Әнә ул, әнә... Күптән шунда тора инде ул. Бая мин почтага газеталар алырга барганда да шунда иде, хәзер дә кузгалмаган. Гел безнең якка карый, күрәсезме? — диде.

Без барыбыз да ул күрсәткән якка әйләнеп карадык. Чыннан да: таш йортның зур, соры капкасы янында басып торган кечкенә малайны күреп алдык.

— Тәрбиячесез балага охшаган,— диде Григорян моңсу тавыш белән.— Кигәне — кырык корама, үзе юынмаган, ачтыр, мөгаен... Яныннан узганда сорашасы калган да бит, сорашмадым. Кем ул? Нишләп монда йөри?..

Сафка тезелергә команда булды, һәм без янә үз эшебезгә керештек. Ләкин без әледән-әле ул басып торган якка күз ташлыйбыз. Фикер таркаулануданмы, нигәдер, кайбер командаларны да төгәл үтәми башладык. Рота командиры моны шундук сизеп алды.

— Ни булды, курсант иптәшләр? — дип сорады ул.

Мин янымда басып торган Сережа Григорянга терсәгем белән төртеп алдым: аңлатып бир, янәсе. Григорян кыска гына итеп хәлне сөйләп бирде. Аны тыңлап бетергәч, өлкән лейтенант та малайга карап куйды.

— Сугыш! — диде ул тын гына. Аннары Григорянга: — Нинди малай икән ул, белешегез, миңа әйтерсез,— дип боерды.

— Есть! — Курсант йөгереп китте. Без эшебездә булдык, ләкин Григорянның ниләр эшләвен күреп тордык. Ул малай янына чүгәләп, аның башындагы бүреген тәзәтте, үзенең кесәләрен актарып, нидер тапты, ахрысы, малайга бирде. Ниһаять, ул торып басты, малайны кулыннан алды да, безнең якка килә башлады.

— Тәнәфес! — диде рота командиры.

Мондый чакларда була торган шаян сүзләр дә онытылды, тәмәке янчыклары да кесәдән чыкмады... Барыбыз да сүзсез баскан килеш тордык. Нииндидер дулкынлану кичереп, аларны көттек. Григорян белән малай безгә якынлашып киләләр. Курсант аны шундый саклык белән китерә, әйтерсең бераз гына кискенрәк хәрәкәт ясаса да, малай егылып китәр һәм кабат тора алмас.

...Ул көннән соң күпме вакыт үтте, әмма бу хәлне һич оныта алмыйм. Күңелне әрнетерлек, тетрәткеч күренеш иде бу. Күз алдыгызга дүрт-биш яшьлек малайны китерегез әле. Сабыйның йөзен сагыш баскан, күзләренең нуры сүнгән, ябык битләрендә корым да тузан. Өстендәге киемен аңлап та, аңлатып та булмаслык. Кызгылтсары бүреге зәңгәр одеал кисәге белән ямалган, асылынып торган зур пинжәге өстеннән тутык тимер чыбык белән билен буган, пинжәгенең җиңнәре җиргә тиеп тора, сул аягында сукнодан тегелгән хатын-кыз итеге, ә уңында — балалар туфлие.

— Иптәш өлкән лейтенант, малай әйтә, әтиемне әзлим, ди. Үзенең кайдан булуын белми. Кыскасы, аңлаешсыз тарих,— диде Григорян.

Офицер дәшми-тынмый гына малайны күздән кичерде. Сугыш утларын кичкән командирның җитди йөзе кырыслана төште. Ул тораташка әверелде сыман. Өлкән лейтенантның сул яңагындагы пуля ярасы әзе кызарып чыкты. Мәскәү янындагы канлы сугышларда катнашкан командирның бу минутларда ниләр кичерүен әйтүе кыен. Бәлки аның да улы бардыр, аңа да шулай ук дүрт-биш яшьтер?

Курсантлар бәләкәй бу кешене уратып алдылар. Бер нәрсә ачык: малайны аяусыз сугыш ата-анасыннан аерган, шәфкатьсез язмыш кочагына ташлаган. Моны уйлап, безнең йөрәкләргә кан сауды.

— Каһәр төшкән нәрсә бу сугыш!— диде урта яшьләрдәге казакъ Макжҗанов.— Кошчыкны туган оясыннан аерган.

Макжҗановның биш баласы бар, ул элек партия райкомының инструкторы булып эшләгән. Бала кадерен, кеше кадерен белә торган адәм ул.

Рота командиры, малайга иелеп һәм елмаерга тырышып, йомшак тавыш белән:

— Исемең кем синең, балам?— дип сорады.

Малай үз чиратында аңа гамьсез генә карап, командирның петлицаларын, ялтырап торган каешларын күздән кичерде дә, карлыккан тавыш белән җавап бирде:

— Ви-тя.

— Синең өең кайда! Кайда яшисең син?

— Белмим.

— Әниең кайда?

Малай кинәт тетрәнеп куйды. Аның күзе зур булып ачылды — ул күздә курку да, җан газабы да бар иде. Малай хәзер елап җибәрер төсле тоелды, ләкин яше чыкмады. Күрәсең, яше дә кипкәндер инде.

— Әни... тегендә... Әби дә... Миңа әтине табарга кирәк...

— Синең әтиең солдатмы?

— Әйе... Миңа әтием кирәк...

Минем күзләремә яшь тыгылды. Сүз әйтүче булмады, бер мәлгә авыр тынлык урнашты.

— Ни булды, иптәшләр?— тынлыкны ярып, хатын-кыз тавышы яңгырады. Тротуарда Фәридә басып тора иде. Ул безнең ашханәдә эшли, татар кызы. Тик исемен русчалатып аны Фая дип йөртәләр. Фәридә дә малайны күреп алды, ашыга-ашыга аның янына килде. Без аңа юл бирдек.

— Нинди малай бу? Кайдан килеп чыкты?— дип сорады Фәридә, малай янына иелеп.— Я, ходаем, бөтенләй бала кыяфәте дә калмаган!

Григорян берничә сүз белән хәлне аңлатып бирде.

— Нинди әйбәт малай! — дип куйды Фәридә. — Эх син, оясыннан давыл бәреп төшергән кошчыгым!..

Шул минутта барыбызны да тетрәндергән хәл булды. Малай җирдән сөйрәлгән пинжәк җиңнәре эчендәге кулларын күтәреп, таныш булмаган хатын-кызның тезләрен кочаклап алды да, башын тез өстенә куеп, кычкырып еларга тотынды. Фәридәнең күзләре дә яшьләнде. Без дә — күбебез фронтта үлем белән күзгә-күз очрашкан кешеләр — түзмәдек, керфекләребезне күз яшьләре чылатты.

— Әйдә, өйгә кайтабыз, улым!

Фәридә шулай диде. Без ни уйларга да белмәдек. Фәридә үзе ни уйлагандыр — анысын да аңларлык хәлдә түгел идек. Алар урам буйлап киттеләр һәм, почмактан борылып, күздән югалдылар.

Билгесез бу малай белән очрашу безнең барыбызны да уйландырды, барыбызны борчуга салды. Курсантларның күбесе ул төнне йокысыз үткәрде. Минем күзләремә дә йокы кермәде. Төрлесен уйладым. Күзләргә яшь килә, мин аларны ак җәймә почмагы белән сөртеп алам.

Мин балаларны яратам. Үземнекеләрне дә, читләрне дә. Туган якларымны — еракта калган Башкортстанымны искә төшердем. Авылда энеләрем һәм сеңелләрем яши. Без җидәү идек, арада иң өлкәне — мин. Кечкенәләрне караштыргаларга туры килә иде, билгеле. Балаларны яратуым да шуннандыр, мөгаен. Кечкенәләргә булган мәхәббәт минем тормыш юлымны билгеләүдә дә роль уйнады. Алар белән эшләргә мөмкин булсын дип мин Троицкидагы татар-башкорт училищесына укырга кердем. Аны тәмамлагач, балалар укыттым. Бу

хезмәтемнән, яраткан балалардан мине сугыш аерды. Күпне күрдем, төрлесен күрдем, ләкин мондый бәхетсез баланы күрергә туры килгәне юк иде. Моңарчы кайда, ничек яшәгән ул? Әти-әнисен кайда җуйган? Шундый сораулар миңа тынгылык бирмәде. Курсантларның да күбесе шуны ук уйлый иде, мин моны бөтен йөрәгем белән тойдым. Барыбыз да таң атуын көттек. Тизрәк тусын иде ул таң! Фәридә безгә малайның хәлен сөйләр. Берәр нәрсә ачыкламый калмас. Безне тагын бер сорау барчый иде: ул малайны Фәридә киләчәктә кая куяр?

Безнең эчке тәртип кагыйдәләре буенча иртәнге ашка унбиш минут вакыт бирелә. Бу арада әллә ни күп нәрсә белә алмадык. Шулай да Фәридә малайны үз квартирасына алып кайтуын, бик әйбәтләп юындыруын, күрше-күлән биргән киемнәрне кидерүен сөйләп өлгерде. Кыз аны табында бары белән сыйлаган, малай шунда, утырган җирендә үк, йокыга киткән.

— Мин эшкә киткәндә йоклап калды, мескенкәй,— диде Фәридә.— Күршеләргә әйттем инде, күз-колак булыгыз дип. Барысы да Витяны бик кызгана. Кием-салым бирделәр, хәтта паек та китерделәр...

Ашханәдән чыгып барганда, беравыкка туктап, мин Фәридәгә сорау бирми түзмәдем:

— Нишләтмәкче буласың инде син хәзер ул малайны, Фәридә?

Бу сорауга, күрәсең, ул инде үзе өчен җавап биргән булгандыр, бер дә икеләнеп тормады:

— Үземдә яшәр... Әти-әнисен эзләрмен. Тапсам, әлбәттә, кайтарырмын, таба алмасам... үзем үстерермен.

Фәридәне беренче мәртәбә күргәндәй, аңа текәлеп карадым. Ул инде кичәге оялчан, аз сүзле кыз түгел. Кечкенә малай язмышын үз җилкәсенә алу аны бөтенләй үзгәртеп җибәргән. Ул үз фикерен өзеп әйтә, сүзендә торачагына ышанычы зур. Күңелендә ниндидер эчке ялкын кабынган һәм ул ут аның бөтен тормышын яктыртып җибәргән сыман иде.

Фәридә белән булган бу сөйләшүем турында курсантларга әйттем. Алар малайның ышанычлы кулга эләгүенә сөенәләр, язмышы якты буласына ышаналар иде.

Сугыш елларын үз башыннан кичергән кешеләр яхшы белә: ул чор батырлыклар заманы иде. Ул елларда сугышчан һәм хезмәт батырлыклары аз булмады. Аларның бер ишеләре бөтен илгә билгеле булган батырлыклар, бер ишеләре артык зур булмаган батырлыклар. Ләкин аларны эшләү өчен рухи көч кирәк иде. Батырлык эшләүче кешеләр көчле рухлы, саф намуслы, Ватанга чын күңелдән бирелгән гади кешеләр булды.

Фәридәнең ятим малайны тәрбиягә алуы да батырлыкка тиң адым иде.

Ул көнне мин солдат ашханәсендә эшләүче татар кызы Фәридә турында күп уйладым. Аны бик аз беләм икән. Мәскәүдә яшәүче татар гаиләсендә туган. Әти-әнисе сугыш алдыннан гына үлеп киткәннәр. Фәридә урта мәктәпне тәмамлаган. Педагогия институтына укырга керергә ниятли — конкурстан узмый. Сугыш башлану белән, хәрби шәһәрчектә эшли башлый.

...Курсантлар Фәридә белән Витяны гел кайгыртып тордылар. Без үзебезнең паектан аларга шикәр һәм ипи бүлеп бирә торган идек. Дөрес, Фәридәнең аларны һич аласы килми. Ул безгә, малайның бөтен нәрсәсе җитешле дип аңлатырга тырыша. «Безгә күршеләр дә булыша», ди.

Барыбызны да бер сорау кызыксындырды: мондый кырыс язмыш кочагына малайны нинди хәтәр җилләр ташлаган соң? Төрле кеше төрлечә уйлый, ә дөресен белергә мөмкинлек юк. Штаб хезмәткәрләре Фәридәгә зур булышлык күрсәттеләр: төрле милиция бүлекләренә һәм

комендатураларга малай турында сораулар язып җибәрделәр. Дөресен әйткәндә, ул хатларга җавап алыныр дигән ышаныч юк иде. Шундый зур сугыш барганда, кайдадыр, кемнеңдер, нindидер җитди оешманың игътибарын бер малай язмышы җәлеп итә алырмы икән? Печән кибәненнән инә эзләү белән бер ич инде бу!

Витя Мәскәү малае түгел. Ул авыл җирендә туган. Моны Фәридә бик тиз ачыклады. Малайга ул күршеләрдә сакланып калган «Букварь»ны күрсәтә. Витя, аның рәсемнәрен күреп, җанланып китә, елмаеп җибәрә һәм таныш рәсемнәрнең исемнәрен әйтеп бара: урман, елга, сыер, эт, кәбестә, кишер, трактор... Малайның буталчык хикәясеннән Фәридә шуны да аңлап ала: Витя әти-әнисе белән агач йортта яшәгән, аның әбисе дә булган. Әтисе тракторда эшләгән, ә әнисе «сыерлар күп булган урында» булган. Әтисенең исеме Василий, әнисенеке Нина икән. Фамилиясен малай хәтерләми.

Вакыты-вакыты белән Витя үзен бик сәер тота.

— Төн уртасында куркып уяна, кычкыра, елый башлый: бөтен тәне дер-дер килә,— дип сөйли иде Фәридә.— Елый-елый да тынып кала. Күзен бер ноктага төбәп, нидер уйлый. Әти-әнисен күз алдына китерә торгандыр, бик газаплана, мескенкәем...

Малайның кичергәннәре эзсез калмаган, күрәсең.

Безнең уку тәмамланып чаклар да җитеп килә. Барыбыз да, онытылып, булачак имтиханнарга, зачетларга хәзерләнәбез. Янымызга Витя да килгәли. Ул инде мескен малай түгел: юынган-чистарынган, өстендә матроска, битләре алсу. Ләкин күзләре... Юк, ул күзләрне оныту мөмкин түгел. Ничәмә-ничә ел үтсә дә, ул күзләр һаман хәтердә. Алар шундый зәңгәр, шундый тирән! Ә бу төпсез тирәнлектә нindидер әчке сагыш, әрнү ята. Безнең беребез дә аңа ата-анасы турында сорау бирми, элекке тормышы белән кызыксынып казынмый. Киресенчә, аның белән булганда без юк нәрсәне бар итеп шаяртырга тырышабыз, аңа вак-төяк бүләкләр бирәбез. Ул безнең барыбызны да якын итә. Бигрәк тә Сережа Григорянга күнекте. Аерылулары авыр булыр инде, ул рәхимсез көн якынлашып килә.

Чыгарылыш кичәсендә безгә «кече политрук» исеме бирү турындагы боерык укылды. Шул минуттан башлап, без инде Кызыл Армия политработниклары.

Шул көнне үзешчән сәнгать концерты булды. Минем урыным Фәридә янәшәсендә иде, сөйләшеп утырдык. Бөтен сүзебез Витя турында булды.

— Аңа инде азык-төлек карточкасы да бирделәр,— диде Фәридә.— Хәзер ул минем фамилиямдә: Вахитов. Виктор Васильевич Вахитов. Бу — вакытлыча гына,— дип аңлатырга ашыкты Фәридә.— Әти-әнисе табылгач, үз фамилиясенә күчерербез.

Фәридә малайны яратып өлгерүен, үз итүен дә әйтте:

— Үз балам шикелле ул миңа хәзер. Ата-анасы табылмаса, ул бөтенләйгә миндә калачак. Мин аны үстерермен, үз балам итеп...

Без частьларга китәргә юнәлешләр алып, хәрби шәһәрчектән трамвай тукталышына таба киттек. Тротуарда Фәридә белән Витя басып тора, алар безне кул изәп озатып калды.

Төп-төгәл бер ел үткәч, 1943 елның июль аенда йомыш белән яңадан Мәскәүгә килеп чыктым.

Мөмкинлек булу белән, мин Фәридә янына ашыктым. Ул эштә булып чыкты. Ишекне Витя ачты. Малай шактый үскән ачык йөзле һәм көләч иде. Мине ул әйткән бер сүз гаҗәпләндерде һәм сөендерде — Фәридәне ул «әни» дип атый иде.

Икенче килүемдә Фәридәне өйдә туры китердем. Кыз әллә ни үзгәрмәгән. Җитдилеге арткан да маңгаенда нечкә генә бер сызык хасил булган.

— Дусларның күп булуы да яхшы,— дип елмайды Фәридә. — Элекке курсантлар безне онытмыйлар, җае килгән саен кереп чыгалар.— Аннары сагышлы тавыш белән өстәп куйды:— Күпләре сугышта башларын салды инде...

Без кичнең-кич буе сөйләшеп утырдык.

— Витяның ата-анасын табып булмый — диде ул.— Сугыш бетмичә торып, моны эшләп тә булмас, шәт. Таба алмасам, үз исемемә яздырам инде.

— Шәхси бәхетеңә комачау булмасмы соң? — дип сорадым мин. — Сез бит әле яшь, үз тиңегезне очратмый калмассыз.

Фәриданең моңа җавабы гади булды:

— Мине яраткан кеше Витеньканы да яратырга тиеш булачак.— Шундук кызарынып китте һәм серен дә ачып салды?— Сережа Григорян безгә хатны яудырып кына тора. Хисләрен дә яшерми. Миңа — иптәш, Витяга әти булырга әзер. Акча аттестатын да безгә җибәргән. Витяны ярата. Хәзер ул капитан инде. Яраланды...

Канлы фашизмны тар-мар итеп, илнең бөйсезлеген, азатлыгын саклап калдык. Дәһшәтле елларның авырлыгына түздек, җиңеп чыктык.

Ул чорның авырлыкларын кырыгынчы ел балалары да җиңеп чыкты. Алар да кырыс язмыш сынауларына түзделәр. Безнең кечкенә героебыз Витя да түзде.

Фәридә Мәгруфовна Вахитова, Сергей Георгиевич Григорян һәм Виктор белән элемтәбез күп еллар буена өзелмәде. Юраганыбыз юш килде дигәндәй, алар тату гаилә төзеп яшәделәр. Элеккеге комсомол хезмәткәре, булдыклы политработник Сергей Григорян үзенең сугышчан юлын Берлинда тәмамлады, пенсиягә чыкканчы, армия сафларында хезмәт итте. Сугыш яралары үзенекен итте — Григорян шактый яшьләй вафат булды. Ләкин бу вакытта инде Виктор Васильевич Вахитов-Тюрин, хәрби училище тәмамлап, командир булырга өлгергән иде. Аның инде үз гаиләсе бар. Балаларын әни һәм әби булган шул Фәридә Вахитова карап үстерде. Моннан биш ел элек ул да дөнья куйды.

Игътибар итккәнсездер: Викторның фамилиясендә Тюрин дигән кушымта да бар. Моның сәбәбен аңлатып китик.

Күп еллар буена сузылган эзләнүләр безнең геройның эзләрен, ниһаять, Калинин өлкәсенә алып килә. 1941 елның көзендә фашистлар тарафыннан күмер-көл ителгән Выселки дигән авылда колхоз-механизаторы Василий Тюрин гаиләсе яшәгән. Сугыш башланганда Витяга дүрт яшь була: Танкист әтисе үзе теләп сугышка китә, Ленинград фронтында һәлак була.

Немецлар Мәскәү янынннан чигенгәндә бөтен нәрсәне җимереп, яндырып, көл итеп китәләр. Выселки авылы урынында да көл генә кала. Бик күп балалар, хатын-кызлар һәм картлар һәлак була. Витяны баздан табып алалар. Әбисе белән әнисе, аны шунда урнаштырып, иң кирәкле әйберләрне алырга дип йортка кайтканнар булса кирәк. Нәкъ шул чагында фашист бомбасы шартлый... Соңыннан малай землянкада яши, бик нык авырый. Аны коткарырга теләп, хәрби машиналарның берсенә утыртып, Мәскәүгә җибәрәләр. Ул монда балалар йортына эләгә. Кырык икенче елның язында балалар йортын Чиләбе өлкәсендәге Миасс шәһәренә күчерәләр. Витя вокзалдан читкә чыгып китә дә поездга әләкмичә кала.

Офицер Вахитов-Тюрин үзенең бала чагында кичергән ачы язмышын яхшы хәтерли. Ул аны беркайчан да онытмас. Шуны истә тотып, ул тынычлык сагында, сиксәненче ел балаларының бәхете сагында тора.

**КӘРИМ ШАКИРОВ,**
отставкадагы капитан

Тәлгат Галиуллин

# БИЗӘКЛӘР ТӨРЛЕЛЕГЕ

I

Хәзерге татар поэзиясе жанр һәм стильләргә, сурәтләү һәм тасвирлау чараларына, ритмика һәм рифмага гаять байлыгы һәм төрлелеге белән үзенә җәлеп итеп тора. Чынбарлыкның төп үзәненнән алынган һәм сәнгатьчә мөмкинлекләрен елдан-ел киңрәк ача барган иҗат методының бердәмлеге, уртаклыгы шигъри палитрада бертөслелек тудырмый. Аның чынбарлыкка үтеп керү, танып-белү һәм сурәтләү ысуллары гаять бай һәм төрле.

С. Хәкимнең уйчан, тирән мәгънәле, реалистик поэзиясен Р. Фәйзуллин белән Р. Харисның шартлы алымнарга бай, дәртле, көтелмәгән борылышлы, хыял ачышына киң таянган романтик лирасы тулыландыра, Н. Арслановның тыгыз хисле, салмак агышлы стиле Г. Афзалның хикмәтле, Ш. Галиевнең итәгатьле, тыйнак иҗат чишмәләренә килеп кушыла. Поэзиягә хатын-кызның уйлану рәвешен, моң-зарын һәм мәгүрлыгын алып кергән С. Сөләйманова, К. Булатова, Э. Мөәминова, С. Гәрәева иҗатлары Р. Гатауллин, Р. Мингалимовларның романтик, тарихи-интеллектуаль эзләнүләрен тулыландыра... Шул бай шигърияткә яңа шытып чыккан көчләр кушыла, өстәлә тора.

«Бүгенге шигырьнең төп характерын берничә сүз белән генә аңлатуы, әлбәттә, кыен — ди Н. Юзиев.— Әмма шунысын ачык итеп әйтеп була: ул заман һәм заман кешесе белән бергә үзгәрә бара: аның аһәңе һәм структурасы яңара, төрләнә һәм катлаулана, шигъри сүзнең җегәрлеге, энергиясе һәм нюанслары арта, күренеш-детальләрнең мәгънәләре көчәя... Лирик башлангыч тирәнәя».

Хәзерге тәнкыйтьтә поэзиянең тематикасы һәм предметы турында сүз алып бару әле эш, фәнни методикадан читләшү, хәтта күпмедер күләмдә яман аты чыккан вульгар социологизм тегермәненә су кою кебегрәк бәяләнә. Шуңа күрә без еш кына бу төшенчәләрне катлаулырак категорияләр, чит телләрдән иңгән авыр терминнар белән алыштырабыз, мәсьәләгә әйләнеч юллар белән килергә мәҗбүр булабыз. Ә чынлыкта бит бериш шагыйрьләрнең иҗат юлын тематик сферадан, аның профессиясеннән, ахыр чиктә яшәешенең мәгънәсен, эчтәлеген билгеләгән гадәти һәм табигый хакыйкатьләрдән башка күз алдына китерүе кыен. Конкретлыктан читләшү, вакыты белән абстракциягә һәм буш сафсата сатуга алып килә.

Әдәбиятның эчтәлеге белән сурәтле фикерләү чараларының, объектив һәм субъектив факторларның тыгыз элемтәдә үсүен дә онытырга ярамый. Тематик ачыклык кеше образын конкретлаштыруга ярдәм итә.

Туган ил, туган җир темасы халыкның иң матур хисләренә уралып, шуннан көч, ямь алып, фольклорда да, поэзиядә дә күптәннән яши. Бу олы тема Тукай, Такташ, Җәлилләрнең илһамына канат бирде. Х. Туфан, С. Хәкимнәрне поэзиянең олы юлына

алып чыкты. Хәзерге шигърияттә дә тормышчан, уйланучан һәм формасы яңача бик күп шигырьләрнең үзәгендә туып-үскән җирнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында уйлану ята. Төрле буын шагыйрьләре иҗат иткән һәм халык рухына, зәвыгына якын буяулар белән бизәлгән бу төр әсәрләрдән туган якка, аның кешеләренә олы мәхәббәт бөркелеп тора. Х. Камаловның «Туган җирем — Идел йорт» шигырендә лирик затның ватанына мәхәббәте үтә шәхси, кабатланмас булып һәм шул ук вакытта олы тарих фонында ачыла:

**Туган җирем — Идел йорт,**
**Җаным дөнья күргән җир,**
**Туфрагына бабамнарның**
**Хәләл каны кергән җир.**

Ф. Яруллинның «Мәңгелек мирас»ында туган илнең нәфислеге, күркәмлеге лирик «мин»нең хисләренә уралып ачыла:

**Иң кадерле, иң зур байлык**
**Булуын беләм аның.**
**Ул — минем азат, ирекле**
**Җирем — Татарстаным.**

Еш кына туган җиргә, авылга багышланып язылган шигырьләргә гражданлык пафосы, заман билгесе җитми, алар буенча чорыбыз алымнарын тануы кыен диген фикерләр ишетергә туры килә. Бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаган һәм гомумән җир, гомумән игенче турында язылган шигырьләр әле дә басылып тора. Яхшы шигырьдә туган як кетелмәгән детальләре, күзгә чалынмаган матурлыклары, ахыр чиктә интернациональ, гуманистик эчтәлекне ачуга хезмәт итәрдәй милли бизәкләре, моңнары аша гәүдәләнә.

**Рәсүлнең артында таулар,**
**Биек-биек таулар ич...**
**Таяныч кирәк язганда,**
**Кайда минем таяныч!**

— ди С. Хәким бер шигырендә.

Р. Гамзатов Дагыстанның биек тауларын, борылмалы-сыгылмалы юлларын, халкының хикмәтләрен җырлап шөһрәт казанды, олы шигъри мәйданга чыкты. Безнең шагыйрь язарына азыкны каян ала? Мактанырлык нәрсәсе бар аның? Уйланып утыра торгач, ул «кайдадыр яланда» баш калкыткан, әлегә үзе күрмәгән дә, белмәгән дә әремне шәйли:

**Ышаныч биреп шул әрем**
**Күз алдыма элена.**

Көтелмәгән һәм гыйбрәтле янәшәлек. Р. Харис С. Хәкимнең «Казан өсте, читтә аэродром...» шигыре турында «бөтнек исен аэропорт исе белән куша белгән шигырь» дип бәяләгән иде[1]. Бер карауда сәер күренгән бу янәшәлектә сүз остасының дөньяны, гүзәллекне кабул итү, сурәтләү үзенчәлеге, туган җиренә чиксез мәхәббәте һәм ахыр чиктә милли үзенчәлеге чагыла. Шагыйрь табигатьнең теләсә кайсы чагылышында илһам чыганагы таба, туган җиренең сынын таный, халык язмышын, тарихын укый.

Без романтиканы күктән эзләргә яратабыз. С. Хәким романтик биеклекне җирдән, әремнән, алабутадан, кыскасы, китаптан түгел, тормыштан таба. Шагыйрьнең соңгы елларда иҗат ителгән шигырьләренең зур күпчелеге туган ягына багышланган. Үзәктә лирасына сугышка чаклы илһам, дәрт биреп торган арыш, чык, чәчәк, урман... Ләкин шагыйрь аларны күзәтүче буларак сурәтләми, туган як билгеләрен хисләренә урап алып керә, шулар ярдәмендә егерменче гасырның икенче яртысында яшәгән һәм үз иленә хезмәт иткән шәхеснең кичерешләрен, омтылышларын, уйларын җырлый.

---

[1] «Казан утлары» 1978, 12 сан, 142 бит.

**Чишмәләр кинәт йомылса,**
**Коелар томаланса,**
**Чишмә буйларындагы күк,**
**Күңелне томан баса.**

С. Хәкимнең акыллы һәм моңсу лирикасы, олы шагыйрьләргә хас булганча, башыннан ахырынача кешеләргә мәхәббәт белән сугарылган, аларның бәхете өчен көрәш белән рухланган. Шагыйрь елдан-ел вакыт агышын кискенрәк сиземли, аның белән бергә атларга тырыша. Бу юлда аның таянычы — туган җире.

**Минем күк эшкә ашыга**
**Юлымда кырмыскалар.**
**Бүген дә җирем исән, дим,**
**Яшь, дим, тормыш һаман.**

Туган як, туган җир образларына турылыклы шагыйрьләр, халык иҗатының, язма поэзиянең бай һәм олы традицияләренә таянып, электән таныш төшенчәләргә, күренешләргә яңа шигъри юнәлеш бирәләр, үзгә эстетик «сулыш өрәләр». Нәкъ менә шул сыйфатлары белән Н. Мадъяров, Р. Гәрәй кебек урта буын шагыйрьләр иҗаты үз укучысын тапты.

Н. Мадъяров бигрәк тә соңгы елларда тыныч авыл тормышы, туган иленең яшьлеге турында иң яхшы әсәрләрен язды. Шагыйрь туган җиренең «һәр түмгәген, һәр үләнен йөз төрле хис» белән тануы, «аңа йөз төрле уй-хисләр белән баш» июе турында горурланып яза. Аның поэзиясе Татарстан табигате кебек үк тыйнак, самими матурлыгы белән яшь.

**Һаман алга,**
**Еракларга әйди**
**Офыкларым, сөзәк үрләрем...**
**Тормышымда яхшы максатыма**
**Мин бит шулар аша үрләдем.**

Н. Мадъяров беркайчан да поэзия мәҗлесендә түрдән урын сорамады, үз җае белән, салмак кына «спай» гына сүзләрдән «фикер чылбыры» төзеп, аларны ныграк ялгауның яңа юлларын табып, алга хәрәкәтен дәвам иттерә.

Татар поэзиясенең күркәм традицияләренә тугрылыгында шагыйрь ялгыз түгел. Р. Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Г. Рәхим, Ф. Сафин иҗатларында да туган җиргә, туган илгә бирелгәнлек хисләре, аның әлегәчә беркем игътибар итмәгән яңа катламнарын, гүзәллекләрен ачкан шигырьләр җитәрлек.

Табигатьнең үз табигый яшәеш рәвешен, матурлыгын югалта баруының кешелек, бигрәк тә киләчәк буын өчен олы бер проблема булачагын Ш. Маннапов бик самими итеп, улы белән гадәти диалог аша ачып бирә.

**— Тирән елга суы кайда, әти!**
**— Кипкән, улым, кипкән.**
**— Болан сазлыгының боланнары!**
**— Киткән улым, киткән.**
**— Имәнсәрнең имәннәре ник юк!**
**— Күптән киселеп беткән.**

Олылар өчен иң авыр сорауларны бала бер-бер артлы сөйрәп чыгарып тора. Җавап тыштан тыныч булса да, эчке сызлану, борчылу сизелеп тора. Сөйләшүнең киеренке нотада киселеп калуы да шуңа ишарә ясый шикелле.

Табигать белән кеше арасындагы мөнәсәбәтнең төрле аспектлары С. Хәким, И. Юзеев, Ә. Баянов, Р. Харис, Ф. Сафин, Рәшит Әхмәтҗанов һ. б. шагыйрьләр иҗатында һәрвакыт игътибар үзәгендә. К. Сибгатуллинның «Авыл урыны» исемле колоритлы, тәгәлләнгән композицияле шигыре шактый олы бер мәсьәләне калкытып куя.

Кайчандыр шаулап-гөрләп, килен төшереп, бәби туйларын үткәзеп, шатлыгын-кайгысын бергә кичергән кешеләр таралышып, зур шәһәрләргә күчеп беткән. Шагыйрь урбанизация процессының табигый, законлыклы күренеш икәнен аңлый, прогресска каршы чыкмый. Ләкин гаять көчле, күңелдә тирән эрнү хисе уята алырдай детальләр аша сурәтләнгән авыл урыны күңелдә төрле уй-кичерешләр уята: «Урыннары әле беленеп тора, Нигез саен — чокыр, багана», «киртәләрен баскан алабута», «авып ята черек казыклар». Кешеләрдән башка табигать тә күркәмлеген җуя, елгалар буылмый, чишмәләр кибә...

Әйе, туган җирдә барган үзгәрешләр табигый, тормыш шуны таләп итә. Ләкин чордашыбыз бүгенне үткән белән тоташтыручы рухи җепләрне, изге хисләрне саклау турында уйларга, аларга турылыклы кала белергә тиеш, ди шагыйрьләр.

Җитмешенче еллар поэзиясендә лиризмның яңа сыйфатларга баюына, күңел катлаулыкларын, мохит матурлыкларын ачуда торган саен активлаша баруына мисалларны күпләп китереп булыр иде, әлбәттә. Шунысы бәхәссез, поэзиядә риторика чигенә, конфликтлар төрләнә, тормышчан, уйланучан һәм форма ягыннан яңача шигырьләр күбәя бара. Дөнья, яшәеш, кеше гомеренең мәгънәсе турында уйлану лиризмның нык, төгәл сүзле шигырьнең көчәюенә алып килә.

## II

Соңгы еллар татар шигыре күләме белән кыскара, җыйнаклана, тыгызлана бара. 1979 ел аралыгында гына да «Казан утлары» журналында Р. Фәйзуллин, М. Рафиков, Х. Төхфи, Рәшит Әхмәтҗановларның үзәккә бер психологик халәтне, күренешне, уйлануны, фикер борылышын, ассоциацияне эченә алган кыска шигырьләрдән торган цикллары басылып чыкты. Хәтта С. Хәким дә җитмешенче елларның соңгы чирегендә илһамын еш кына тар мәйданлы шигырьгә ышанып тапшыра башлады.

Кыска шигъри әсәрдә кичерешне җәеп җибәрү, хисне динамикада, үсештә ачу, рухи дөнья нечкәлекләрен тәфсилле сурәтләү мөмкинлеге кысылган. Шул сәбәпле ике-дүрт юллык парча уйлану, фәлсәфи очкын, әйтем, антитеза, метафорик борылыш рәвешен ала һәм укучыга нәтиҗәне үзенә ясарга, зиһенен эшкә җигәргә җай тудыра.

Р. Фәйзуллинның бу юнәлештәге эзләнүләре кыска шигъри форманың абруен бермә-бер күтәрде. Татар һәм башка халыклар поэзиясенең көчен, акыл эшчәнлеген, (бу башлангычларны хискә каршы куймыйча, аның хокукларын кысмыйча) интеллект казанышларын күтәреп алып, шагыйрь кыска формага тормыш фәлсәфәсен, психологик тыгызлыкны, фикри киеренкелекне алып керде.

Р. Фәйзуллинның кыска шигырьләренә сораулар, өндәүләр, бергә утырып, тормыш һәм вакыт агышын тыңлап, киңәшләшүгә чакырулар хас. Вакыты белән рационалистик фикер лирик геройның кичерешен, хис агышын чикләп тә куя.

> Арысландай басып үлəндə йөр
> һәм лачындай оча ал җилпенеп.
> Нужаларны күтәр сулар кебек,
> Хәсрәтләрне йота ал Җир кебек.

Бу дүртьюллыкта Р. Фәйзуллин масштаблы төшенчәләргә таяна, укучысына фикерен чагыштырулар аша җиткерә, әмма идеясен аныграк, тулырак җәергә омтылып, рационалистик өйрәтү-чакыру юлына баса. Мәгълүм булганча, лирика соңгы алымны өнәп бетерми: ул аның табигатенә кулай килми.

Кичереш тирәнлегенә яңа юллар эзләвен, шигырьне табигый яшәү ысулларын яңартуын, тормыш һәм иҗат турында уйлануларын дәвам итә шагыйрь. Кайбер шигырьләренә «лиризм һәм моң җитми» диган фикерне, беренче чиратта, аның һәр әсәрендә дә менә шул гармонияне табып җиткерә алмавы дип аңларга кирәктер.

Мәгълүм булганча, Р. Фәйзуллин кискен контрастлар, көтелмәгән лирик борылышлар һәм ассоциация шагыйре. Аның фикерләү рәвешенә, индивидуаль стиленә кыска лирик шигырь кулайрак. Ул поэма шагыйре түгел. Аның «Көрәшчеләр», «Гадиләргә гимн»нары сәнгать әсәрләре, ләкин аларны чын мәгънәсендә поэма дип атавы кыен. Алар шагыйрьнең тормыш һәм кеше турында уйлануларыннан, төрле эпизод-

лардан торган шигъри колтәләр. Р. Фәйзуллинны эстетик тарлыкта, поэманың тарихи кануннары белән санашмауда гаепләү дөрес булмас иде. Һәркемнең үз иҗат юнәлеше, ахыр чиктә, мөмкинлеге бар.

III

Хәзерге поэзия тукымасында барлыкка килгән үзгәрешләрнең берсе — төрле стильләрнең якынаюы, реалистик һәм романтик, лирик һәм драматик, фәлсәфи һәм героик башлангычларның үзара керәшүе, берсен-берсе тулыландыруы. Бу процесс бигрәк тә поэзиягә алтмышынчы елларда аяк баскан шагыйрьләр иҗаты өчен хас. Мәсәлән, Р. Харис кешенең әхлакый эзләнүләрен, эчке халәтен, «җан диалектикасын» лиризм аша, иҗтимагый проблемаларны героик, драматик чаралар ярдәмендә ачарга, шигъриятебезнең эстетик офыгын киңәйтергә, абруен күтәрүгә омтылышы, кешене олылау рухы белән талантлы чордашларына якынлаша бара.

Р. Харис шартлаулы, көтелмәгән алымнар, кыю метафоралар шагыйре. Лирик герое да көчле, нык ихтыярлы шәхес (аның каләме тудырган тарихи образларны гына искә төшерик — Мулланур Вахитов, Фатих Кәрим һ. б.). Рухи дөньяны да шагыйрь элегик моң, сагыш аша түгел, ә «ихтыярлы» ритмнар, мускуллы сынландырулар, экспрессия, трагик-ситуацияләр аша сурәтләргә ярата. Аналитик фикер, эзләнүчән хис шагыйрьгә тормышның төрле яссылыкларына үтеп керү мөмкинлеген бирә.

М. Әгъләмов турында тәнкыйтьтә татар поэзиясенең реалистик традицияләренә, халык иҗаты кыйммәтләренә якын юлдан атлаучы шагыйрь дигән фикер урнашып килә. Бу — олы бәя. Чыннан да аны эстрада үзенә нык тартмады, «интеллектуаль шагыйрь» дигән исем өчен дә ул көрәшмәде, сынландыру, эчке монолог алымнарына таянып, рухи матурлыкны җырларга тырышты.

М. Әгъләмов «лирик компасын» күбрәк үз субъектына, үз эчке кичерешләрен ачуга юнәлтсә, Р. Харис тышкы дөньяга, «читкә» игътибарлы. Предметлы чынбарлыкны сурәтләү, катлаулы ассоциатив борылышлар аша, шагыйрь «үзенә» әйләнеп кайта. Беренчесе өчен шигырьдә иң мөһиме табигый хис, кичерешнең эзлекле агышы булса, икенчесе кичерешкә интеллект һәм фикер аша юл ала. Шигырьләренең стилистикасы да төрле. Беренчесе көнкүреш, табигать сыннарын, матди дөнья сурәтләрен фәлсәфи-әхлакый фикерләр, уйлар, нәтиҗәләр, ассоциацияләр, хөкемнәр ташкынына, стихиясенә буйсындырса, икенчесе тормышның гадәти күздән яшеренгән детальләрен, тирәлек күренешләрен, җисемле образларны күңеленә тирәнрәк сеңдерә һәм аларга хисләре, кичерешләре, уйлары аша чыга. М. Әгъләмов та фикер йөртергә, зиһен ташкынын уятып һәм уйнатып алырга ярата, әмма аның шигъре рационализмнан азат.

Дөньяны кабул итү үзенчәлекләре, лирик геройның кичерешләрен ачу алымнары, стильләре буенча бер-берсеннән аерылып торсалар да бу ике шагыйрь татар поэзиясендә эз калдырырга, яңа сүз әйтергә, аның композиция һәм сурәтләләк алымнарына, рифма һәм ритмика байлыкларына яңалык өстәргә омтылулары белән якынлашалар. Ул гына да түгел, ике шагыйрь дә дөньяны имперш һәм бер яссылыкта гына кабул итмиләр, аны күп кырлы, бинийһая төрле төсле итеп күрәләр, әйбер һәм күренешләрнең эчке мәгънәсенә үтеп керергә ашкыналар. Сурәтле фикерләүләренә хас бу киңлек геройның рухи дөньясын гаҗәеп бай итеп сурәтләргә мөмкинлек бирә.

Р. Харис уенча, кешенең дөньяга карашын, характерын, тормыш позициясен, әхлагын камилләштерүдә тирәлек мөһим роль уйный. Табигатьтә ул кеше тормышына, кеше язмышына күзгә бәрелеп тормаган, вакыты белән аңлатуы да кыен булган тирән эчке якынлык, туганлык күрә. Натурфилософик рухта язылган пейзаж шигырьләрендә дә кешелек тормышына, буыннар алышынуга кинәя сизелеп тора. Кеше үзенең гуманистик ниятләрендә табигать ярган, миллион еллар сынаган эздән бара:

Җирдән чыгып Җиргә тигәнче
Күпме изгелек эшли Кояш,
Күпме зыян, күпме хата...

Тулы булып үтсә кеше гомере
Кояш кебек зураеп бата.

Уңышлы шигырьләрендә Р. Харис гражданлык пафосын, кешеләргә мәхәббәтен, чор һәм хакыйкать турында катлаулы уйлануларын кыска, җыйнак композиция, сыгылмалы ритмика, үзенчәлекле лирик чаралар аша укучысына җиткерә белә. («Безнең гасыр», «Китмибез», «Һәм нинди», «Гасырларны дистә-дистә санап...»)

Әлбәттә, Р. Харисның хәзерге чор иҗатын каршылыксыз, идиллик кабул итү һәм бәяләү урынсыз булыр иде. Аның берише шигырьләренә тормышны диалектик каршылыклары белән кабул итү, самимилек һәм музыкаль аһәң җитенкерәми («Язгы сөйләшүләр», «Җылы буран» һ. б.).

Тулаем алганда, Р. Харис, яшьлеге белән саубуллашып, аннан иң асылын үзе белән алып, аның рухын саклап, социалистик реализм методының, гуманистик әдәбиятның киң юлына чыга килгән шагыйрь. Аның иҗатын ниндидер бер юнәлешкә генә кайтарып калдыру, тар киштәгә сыйдыру мөмкин түгел. Публицистик җыр үсешенә өлеш кертү, тантаналы әсәрләр язу белән беррәттән, Р. Харис төп җегәрен кешене табигать, олы дөнья белән бәйләүче җанлы җепләрне лирик чаралар ярдәмендә сурәтләүгә, шулар аша рухи дөнья матурлыкларын аңлауга зур көч куя.

М. Әгъләмов лирикасы да елдан-ел катлаулана, заман кешесенең рухи бөтенлеген, тормыш тулылыгын киңрәк чагылдыру юнәлешендә үсә килә. Шәхеснең эчке кичерешләрен нечкә сиземли белүе, табигый матурлыкны аңлавы, шигъри индивидуальлеге лирик уйлануларында ачык төсмерләнә. «Һәр бәйрәмең», «Зарланабыз», «Буйга да үскәнсең...», «Яшәү», «Үзебез дә белми генә үскән бишекләрдән...», «Белмим, туганым» кебек кичерешнең бер моментын яисә яшәешнең бер гадәти күренешен үзәккә алган лирик миниатюраларында шагыйрь дөньяга карашын, эчке халәтен, тормыш фәлсәфәсен лиризм һәм табигый интонация белән ачып бирә алган.

**Белмим, туганым, ничә яшь сиңа,**
**Нинди сыйфатта күрсәтә көзге!**
**Кайларда йөрмә, кайларда булма,**
**Мохит төрлечә үзгәртә безне.**

**Идел-йортында бер чишмә ага.**
**Ничә кат анда юындың үзең...**
**Кайларда йөрмә, бер кайтып кара**
**Тик шул чишмәдә булыр чын йөзең.**

Сигез юллык шигырь үз эченә тормыш һәм туган ил турында уйлану, туган җиргә якынлык идеяләрен ала.

М. Әгъләмов иҗатында фәлсәфи эчтәлекле, бай хисле, кеше җанына сизгер шигырьләр белән беррәттән, «Авылга керү», «Хөерле көн, кояш», «Каладан кайткан кунак һәм безнең бозау», «Кара сыерыбызны юату җыры» кебек үзәге табылмаган, мәгънәсе ачылмаган, ашыгыбрак язылган шигырьләр дә бар. Шагыйрь вакыты белән эзлеклелек, кичереш динамикасы турында да уйлап җиткерми («Күңелгә килгән», «Мең»), уңышлы табылган шигъри детальне ахыргача үстерми («Юлга чыкма»).

## IV

Поэзия әдәбиятның башка төрләреннән экспрессивлыгы (хисне үзәккә алуы), шартлылыгы, ритмикасы һәм, Белинский сүзләре белән әйткәндә, субъектив якка, шәхеснең кичереш дөньясына якынлыгы белән аерылып тора. Эпик һәм драматик әсәрләрдә автор үзенең дөньяга карашын, җәмгыятьнең иҗтимагый хосусиятләренә мөнәсәбәтен, аларны аңлавын вакыйга һәм типик хәлләр аша ирештерсә, лирик әсәрдә исә иҗатчының характеры, дөньяга карашы «мин»нең кичерешләре аша җиткерелә. Чынбарлыкны һәм рухи дөньяны ачуда лирикада сүз-образ аерым әһәмияткә ия. Сүз шигырьдә күчерелмә (образлы) мәгънәләрдә яши, эчке җегәрен, илаһи көчен, тәэсири куәтен контекстта, башка сүз-образлар белән катлаулы бәйләнештә ача.

Тарихи вакыйгаларга бай, омтылышлы, дәртле һәм үзгәрүчән чорыбыз тормышның барлык сфераларына да тәэсир ясый, шул исәптән әдәбият белән сәнгатьнең сурәтле фикерләү алымнарын да баета, яңарта.

«Ай» сүзе сәнгатькә күптәннән килеп керә. Бу атама галәмнең бер матди кисәгенә билгеләмә булу белән берրәттән, бик күп сурәтле, образлы төшенчәләр ала. Халык җырларында ул матурлык, гүзәллек, тыйнаклык, ялгызлык, моңсулык, сагыш символлары буларак урнаша, шул төсмерләре белән язма поэзиягә килеп керә. Һәм меңләгән лирик «мин»нәрнең эчке серләрен, мәхәббәтен, сөенеч-көенечләрен ачуда ышанычлы таяныч була.

Һәр яңа дәвер шагыйрьләре бу образда ачылып җитмәгән потенциаль мөмкинлекләр табалар, аның семантик-эстетик кырын киңәйтәләр, җәяләр. Һ. Такташ «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасында айны әдәби персонаж дәрәҗәсенә күтәрә. Новатор шагыйрьдән соң бу образга яңа функция өстәү, аның башкалар күзе төшмәгән кыйблаларын табу мөмкин түгелдер кебек тоела иде. Чөнки бу юнәлештә эзләнүләрнең кайберләре Һ. Такташны кабатлауга кайтып калды.

Ләкин шагыйрьләрне олы традиция куркытмый. Аерым алганда К. Сибгатуллин, элгәрләренең казанышларына таянып, бәхәсләшеп, «Кар шыгырдый» исемле шигырендә образны үзенчә үстерә, яшь ай белән бишектәге яшь бала язмышы арасында якынлык күрә:

**Көмеш тоякларын**
**тугайларга**
**сузып яткан ап-ак тай кебек,**
**бишегендә — күктә кырын ята**
**кичә генә туган Ай көлеп.**

Бер куплетка бер-берсен кысрыклап, тыгызлап һәм ачыклап килгән метафора, чагыштыру, эпитетлар сыйган. Шигъри сөйләм тыгызлыгы, тасвирчылыкны кискен кире кагуы белән бу юллар Х. Туфанның егерменче еллар иҗатын хәтерләтә. Ай «бишегендә — күктә» кырын ятып кына калмый, яшь балалы өйгә күз сала. Идиллик картина озакка сузылмый, лирик геройның күңеленә шомлы, куркыныч, салкын уй-хисләр дә үрли. Алардан берничек тә котылып булмый. Чөнки миллионнарча корбаннар алып килгән Бөек Ватан сугышы олы әрнү, тәнгә сеңгән кургаш кыйпылчыгы кебек, һаман да йөрәктә, хәтердә, күңелдә. Яшьлеге сугыш елларына туры килгән лирик герой олы дөньяга сугыш фаҗигаләре, йодрык чаклы алтыннан да кыйммәтрәк бер сыньщ икмәк, тынычлык, дуслык кебек төшенчәләр аша карый. Шул фонда янәдән сурәткә килеп кергән Ай образы да бөтенләй үзгә:

**Иске табак кебек кзелгән Ай —**
**бозлы тәрәзәдә шәүләсе.**

Вакыт һаман үз шөгылендә — уза тора, ага бирә. Фашизмның оясын туздыргач, дөньяларга иминлек сеңә. Гомер агышының, буыннар алышынуның яңа шаһитлары, киләчәктә җир шарын — авыр һәм хрусталь пыяладай нечкә йөкне — үз кулларына алырга тиешле оныклар дөньяга килгән. Ай образы, алкалы композиция тудырып, шигырьнең ахырында янәдән беренче төсмеренә кайта:

**Кичә генә туган ай елмая,**
**Бишек уйный, уйный җаныбыз.**
**Тышта салкын... Булса юрганыгыз,**
**Яңа туган айга ябыгыз.**

Картина шундый нәтиҗәгә этәрә: бишек тибрәнгәндә, кичә генә туган ай елмайганда тормыш туктап тора алмый, дәвам итә, киләчәк безгә таба атлый.

«Кар шыгырдый» әсәрендә К. Сибгатуллин берничә катлам традициягә таяна. Алдарак без аның Х. Туфанның «Урал эскизлары», «Башлана башлады» кебек поэмаларына хас чагыштыруга мөрәҗәгать итүен искәрткән идек. Ай образын җәеп җибәрүдә, төрле функцияләрдә үстерүдә, шагыйрь Һ. Такташ алга сөргән композицион стереотипка якын килсә, сугыш драматизмын, халык фаҗигасен, шәхеснең йөрәк сыкравын сурәтләүдә автор, һичшиксез, С. Хәким тәҗрибәсенә таяна.

К. Сибгатуллин үзен тормыш трагизмына, кеше кайгысына сизгер шагыйрь итеп танытты. «Иргә чыкмый калган апалар» һәм югарыда телгә алынган шигырьләреннән күренгәнчә, аның фаҗигане сурәтләве идеалга, гармониягә, бәхеткә омтылышның чагылышы булып тора.

V

Татар поэзиясе үсешендә элек-электән берничә стиль юнәлеше аерым ачык тәсмерләнеп килде. Аның төп юлы халыкчан ачык образлылыгы, лиризмы, музыкаль иҗеге һәм халык җырына, халык моңына якынлыгы белән характерланды. Бу стиль юнәлеше үсешенә Г. Кандалый, Я. Емельянов кебек шагыйрьләр зур өлеш керттеләр. Бу агым чал тарих төпреннән юл алса да, Тукай иҗатында гына үзенең потенциаль көчен тулысынча ача алды, вулкан төсле бәреп чыкты, гражданлык хокукы алды, киләчәген раслады.

Реалистик поэзия традицияләре совет чорында яңа көч белән үсеп китте. Тормыш һәм кеше турында фәлсәфи концепцияне тирәнтен ачу юлында чикләнмәгән мөмкинлеге булган бу стиль юнәлеше М. Җәлил, Ф. Кәрим, С. Хәким, Ш. Маннур, Н. Арсланов һ. б. шагыйрьләр иҗатында югары үрләргә күтәрелде. Зыя Мансур, Ш. Галиев, Х. Камалов, Г. Афзалларның сурәтле фикерләре дә үзен шул агымда раслады. Бай традиция аларга дөньяны һәм шәхес характерын хис аша сурәтли белүгә, яңа алымнар, яңа бизәкләр табуга булышты. С. Сөләйманова, Р. Гәрәй, Н. Мадьяров, К. Булатова, Ш. Маннаповларның элегик поэзиясе дә шул ук реализм океанына коючы бер елгачыкны хәтерләтә.

Татар поэзиясенең үсешендә икенчерәк фикерләүгә корылган стиль дә тирән эз калдыра. Аның да юл башы күз иңләрлек тарихи аралыктан еракка юл ала. Чөнки бу юнәлешкә исемнәре безгә килеп җитмәсә дә, аларның акыл, зиһен куәтен, йөрәк җылысын саклаган мәкаль-әйтем, олы тормыш тәҗрибәсе сеземтәсе булган хикмәтле сүз, фразеологик берәмлек, рационалистик фикерләү традицияләре нигез сала. Бу чишмәнең куәтен Акмулла үзенә сеңдерә, баета һәм бу агым XX гасыр башында Дәрдмәнд иҗатында мөстәкыйльлек ала.

Егерменче елларда бу традициядә Х. Туфан, Г. Кутуй, К. Нәҗми, Сирин кебек яшь шагыйрьләр өермәле, катлаулы чорга бәрабәр образлар таптылар. Көйләүне сурәтләү кысрыклады. С. Баттал антитеза алымына киң таяна, Ә. Давыдов, музыкальлекне һәм тасвирчылыкны читкә кагып, чорның катлаулы нервы агышына бәрабәр ассоциатив образлар тудыру юлына баса.

Стиль — катып калган төшенчә түгел. Ул — иҗтимагый күренешләргә гаять сизгер. Әйтик, татар поэзиясе тарихында халык иҗаты традицияләре төп рольне уйнаган дәверләр дә булды. Дөньяны реалистик күрү, лиризм, гасырлар түрендә формалашкан шигъри алымнар яңа чорда үз мөмкинлекләрен киңәйтәләр, яңача ачылалар. Талантлы һәм эзләнүчән язучы иҗаты бер стиль юнәлешенә генә сыеп бетә алмый. Моңарга мисал итеп Х. Туфан исемен атау да җитә.

Куәтле шагыйрьгә бер стиль рамкасы тар булса, ул реалистик стильдән романтик фикерләүгә, лирик стильдән тормышны сатирик тасвирлауга иркен күчсә, урта кул шагыйрь гомере буена бер стильнең магнит кырында калырга мөмкин. Без, күрәсең, вакыты белән табигый сәләте чикле, Х. Туфан сүзләре белән әйтсәк, «рифмачлар»га югары таләпләр куеп, аларның кояшта иңгән чүпрәк кебек тоссез, декларатив һәм туң фикерле әсәрләрен еш кына мактап һәм тәнкыйтьләп, киңәш биреп, вакытны һәм җегәрне юкка сарыф итәбез, шуның аркасында чын казанышларны хәтта читтәрәк тә калдырабыз булса кирәк. Бу төр шигырьләргә Ә. Фәйзи бик дөрес бәя биргән иде:

Синең иҗат бик зур, диңгез күк,
Аның да, нәкъ шулай суы күп.
Тик бер ягы аның ятышсыз,
Диңгез суы тозлы, бу — тозсыз.
(«Бер шагыйрьгә»)

Табигый сәләткә ия шагыйрьләр һәм әдәби әсәрләр арасында типологик якынлык эзләү татар поэзиясе үсешенең кайбер мәсьәләләрен ачыкларга ярдәм итәр иде.

Алтмышынчы елларның иҗтимагый-тарихи атмосферасы кичереш белән беррәттән чорның фәлсәфи-әхлакый эчтәлеген, шәхеснең уйлану рәвешен, зиһен эшчәнлеген тирәнрәк ачуны таләп итте. Шактый катлаулы рухи дөньяга бәрабәр поэзия тудыру ихтыяҗы эстетик концепцияләрне, стиль юнәлешләрен, сурәтле фикерләү сферасын баетуны, төрләндерүне сорады. Роберт Әхмәтҗанов, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Миңгалимов, Р. Гатауллин кебек шагыйрьләр башлангыч чор иҗатларында Ә. Фәйзи, Э. Давыдовның ачышларына, Х. Туфанның егерменче елларда алга сөргән шартлаулы стиленә киң таянып, чордашларының уйлану, фикерләү рәвешенә, кичереш дөньясына үтеп керүнең юлларын киңәйттеләр.

Узып киткән унъеллыкта поэзиягә килгән сәләтле яшьләр иҗатында музыкаль, көйле-җырлы башлангычның роле үсте. Ул — халык теленең матурлыгын, самимилеген, сафлыгын сакларга омтылуда да, табигать образларына еш мөрәҗәгать итүдә дә, ритмик җыйнаклыкта да, интонацион сулышның киңәюендә дә күренә.

Р. Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Ш. Маннапов, К. Сибгатуллин, З. Насыйбуллиннар иҗатында табигать палитрасы гаять бай һәм төрле төсле. Тирәлекне иңләүдә, туган як, туган җир хозурлыгы аша шәхеснең уй-хисләр дөньясын, кешелекле моңын ачуда алар С. Хәкимгә якын юлдан атлыйлар. Шул ук вакытта һәркайсының үз биографиясе, үз язмышы, тормышны үз сиземләве булган шикелле, аларның табигатькә үз мөнәсәбәтләре, шуннан килеп чыккан үз буяулары, үз аһәңнәре бар.

Роберт Миңнуллинның уңышлы шигырьләренә образ үсеше белән фикер үсеше тәңгәллеге, форма төгәллеге, үтә күренмәлелек хас.

1979 елда басылып чыккан китаплар арасында аның «Сөенсеннәр әле каеннар» җыентыгы дөньяга шагыйрь күзе белән каравы, гражданлык пафосын, туган ил матурлыгын лирик моң аша сурәтләве белән күңелне җәлеп итә.

**Яшерелгән безнең Сөю**
**Күңелнең иң түренә:**
**Сүзебездән күренмәсә,**
**Күзебездән күренә,**

— ди шагыйрь «Ватанга мәхәббәт» әсәрендә.

«Бураннарым белән барам», «Каеннарны сеңел сана», «Иртәнге пейзаж», «Испан шагыйре Федерико Гарсиа Лорканы үтергән пуля монологы», «Мәңгелек сәфәр» кебек шигырьләрендә Р. Миңнуллин чор һәм кешеләр язмышы турында җитди уйлана, туган ил белән ихлас күңелдән җырлый.

Табигать хозурлыгы белән кеше характеры, холкы, аның кичерешләре арасында якынлык эзләвендә дә Р. Миңнуллин үз кыйбласына турылыклы кала. Бакый чынбарлыкка хас илаһи гүзәллек чагылышларында яшь шагыйрь эчке мәгънә, үзара бәйләнеш эзли: бер хәрәкәт, бер күренеш икенчесеннән үсеп чыга, аның дәвамын тәшкил итә.

Кешегә хас сыйфатларны табигатькә күчереп, дәресрәге, анда кешедә булырга, кеше гомере буена шуларга омтылырга тиешле уңай билгеләрне табып, шагыйрь аларны тагын да камилләштереп үстерү турында хыяллана:

**Өянкеләрдә — моңсулык,**
**Тупылларда — турылык:**
**Ул турылык әллә ничә**
**Горурлыкка торырлык.**

Туып-үскән җиреннән читтә яшәгән лирик герой электән таныш төшенчәләрне яңача төсмерли: моңсу өянкеләр җылый, горур тупыллар кайгыра. Психологик параллелизм, янәшәлек аша шагыйрь кеше характерына хас сыйфатларны табигатькә күчерә. Табигать аша, халык тормышы күренешләренә үтеп керүгә омтылышында Р. Миңнуллин халык иҗатында таралган сурәтләргә, шигъри калыпларга, Х. Туфан, С. Хәким поэзиясе казанышларына таяна. Таныш образлар, интонацияләр акрынлап яңа принципларга буйсына, яңача яңгыраш ала.

Р. Миңнуллинга әле эзләнәсе, үзен раслыйсы, башкаларның эзе, сулышы кагыл-

маган үз юлларын табасы бар. Аның беренче шигырен укыгач, ул әле эстетик яктан катлаулы тормыш вакыйгаларын шигъри югарылыкта калкытып куюга һәр очракта да әзер түгел дигән тойгы кала. Вакыты белән ул үзен югалта, әлифбадан алынган хакыйкатьләрне шигырь юлларына күчерә башлый. «Нинди кунак да мин...» шигырендә гади күзәтү өстенлек итә.

Шул ук вакытта аның үз-үзеннән әле тулысынча канәгать булмавы, кыюсызлыгы өчен оялуы, үзенә рәнҗүе, кыскасы, үз иҗатына тәнкыйть белән карый алуы сизелә, шулар аның килəчәгенә зур өмет уята.

Тормышны үтә лирик чаралар белән иңләргә омтылуы, табигый салмак интонациясе, халык җырлары аһәңенә якынлыгы белән Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты җитмешенче еллар уртасында ук тәнкыйтьнең игътибарына һәм уңай бәясенә лаек булды. Яшь шагыйрьнең Туфан иҗатыннан үрнәк алуы, олы дөнья мәшәкатьләрен шигъри деталь аша тасвир кылуы, халык җырларының бизәк-үлгеләренә таянып, тыныч кына үз юлын эзләве турында да фикер әйтелде.

Р. Әхмәтҗанов чынбарлык белән шәхес, табигый матурлык белән сәнгать арасында эчке якынлыкка, гармониягә омтыла. Ул — күңеле белән «кояш эзләп» юлга чыккан шагыйрь. Туктаусыз хәрәкәт һәм үзгәреш-яңарыш чорында, информацион шартлау заманында тормышта тынычлык һәм иплелек эзләү бәркадәр сирәк тә тоелырга мөмкин. Ләкин тынычлык эзләү белән тынычлану һәм гамьсезлекне бутарга ярамый. «Алдан әйт...» шигырендә, мәсәлән, дөньяның шактый катлаулы бер күренеше тасвирлана:

> **Я кырда җилләр ыжгыра:**
> **Әйтерсең бүген менә**
> **Бәхетсез ятып елый күк**
> **Кешеләр йөрәгенә...**

Янәшәлек алымы тормышта төп юнәлешен югалткан, кылган эшләренең очын җуйган бәхетсез кеше образын тудыруга өеткы бирә. Алдагы юлларда параллелизмны антитеза «кысрыклый», шагыйрь әлеге фикеренә үзе үк каршы чыга, метафораны икенче мәгънәви ягы белән әйләндереп куя.

> **Бәхетсез кеше елый дип**
> **Сөйләдем юри генә.**
> **Кыюлар ятып еламый**
> **Кешеләр йөрәгенә.**

Р. Әхмәтҗановның уңышлы әсәрләренә тыйнаклык, эчке җыйнаклык, табигый моң, үзәккә алынган идеяне ашыкмыйча, каударланмыйча үстерү хас. Ул ай, кояш, кыш, буран, җил кебек күләмле сурәтләргә таяна, аларны җанландыру аша яңа образ-күзаллаулар тудыра, сурәтле фикерләү хәзинәсенә яңа буяулар өсти.

Шагыйрьнең халык җырларына мәхәббәте, шул байлыкның рухын аңларга омтылышы бигрәк тә игътибарга лаеклы. Җыр стихиясе тышкы бизәк, милли орнамент кына булып калмый, аның фикерләү рәвешенә, дөньяны кабул итү концепциясенә тирән тәэсир ясый. Шагыйрьнең лирик герое әхлакый сафлыгы, характер бөтенлеге белән күңелдә кала.

Р. Әхмәтҗановтан тагын да кыюрак шигъри адымнар көтәргә кирәк. Тематик һәм жанр диапазоны киңәеп, сурәтле фикерләү алымнары төрләнә, гражданлык пафосы тирәнәя төшсен иде. Аның иҗатында вакыты белән «көн кадагына» сугу, заман проблемаларына аваздашлык җитми.

*

* *

Дөнья 80 нче елларга аяк басты. Философлар, социологлар, тарихчылар үтеп киткән унъеллыкка әйләнеп карыйлар, бәя бирәләр, киләчәккә күз салалар. Тәнкыйть һәм әдәбият белеме дә сүз сәнгатенең казанышларын, үсеш кыенлыкларын аңларга омтыла. Үзәктә яткан проблемалар арасында иң мөһиме — нык үскән социализм шартларындагы тормышның әдәбиятка көчле уңай йогынтысы, милли сәнгатьләр арасындагы тирән әдәби бәйләнешләр тәэсирендә туган яңа әдәби ситуацияне өйрәнү. Бу проблема үз эченә социалистик реализмның теориясен һәм тарихын, классик мирасын, әдәби бәйләнешләрне өйрәнүне дә, совет әдәбиятларының олы контекстында карауны да эченә ала.

Әзһәр Мөхәммәдиев

# ТӘҢКӘЛӘР ТЕЛГӘ КИЛСӘ...

Болгарда яңадан акча сугу XII гасыр ахырларында башлана. Алтын Урда чорында исә ул Көнчыгыш Европада үз акчасын әйләнештә йөртә торган бердәнбер үзәк булып кала. XIII йөзнең 50—80 нче елларында тәңкәләр бары шәһри Болгарда гына басылган. Бу фактка аеруча басым ясап үтү урынлы, чөнки ул Болгарның экономик куәте һәм әһәмияте турында сөйли, Алтын Урда төзелгәннән соң, янәсе болгарлар халык буларак яшәүдән туктаган, аларның башкаласы юкка чыккан дигән фикернең нигезсез булуын күрсәтә.

Алтын Урданың башка шәһәрләрендә — мәсәлән, Хәрәзм, Сарай, Биләрдә — акча басу 80 нче елларда гына башлана. Шунлыктан тәңкәнең тышкы кыяфәтен эшләү, аны сугу рәвеше генә түгел, гомумән, акча-хисап берәмлекләрен билгеләү дә хәлиткеч дәрәҗәдә болгар традицияләренә таяна.

Урта гасырларда Шәрыкка хас булганча, тәңкәләрдәге язулар, нигездә, гарәп телендә башкарылган. Ләкин, аерым ихтыяҗ туганда, мәсәлән, көмеш һәм бакыр тәңкәләр нисбәте чикләнгәндә, хөкүмәт әлеге язуларның җирле халык телендә булуы да мөмкин дип санаган. Акча йөзләренә төрки телдәге теләк-дога сүзләре язылу да билгеле бер максатны күздә тоткан. Ачыграк итеп әйткәндә, чираттагы акча реформасыннан соң халык яңа тәңкәләрне яратыбрак кабул итсен өчен, хөкүмәт әнә шундый «телдә» сөйләшергә мәҗбүр булган.

Болгар, Сарай-эл-Җәдид, Сарай-эл-Мәхруса шәһәрләре урынында табылган урта гасыр хәзинәләренең төп өлешен бакыр акчалар тәшкил итә. Чөнки бер көмеш дирһәм кыйммәтенә утыз ике бакыр пул туры килгән. Болгарда сугылган бакыр акчалар, көмеш тәңкәләрдән аермалы буларак, шул төбәктә, җирле халык кулында гына йөргән. Алардагы язуларга караганда, Болгар кешеләре гомумтөркигә якын шивәдә сөйләшкәннәр, дип фараз кылырга мөмкин.

Төрки язулы тәңкәләр халык арасында бик киң таралган булырга тиеш. Аларның күптөрле типлары һәм вариантлары очрап торуы шуңа бер дәлил булып тора. Гомумән, сүз киң таралган һәм яхшы сакланган, ләкин ни өчендер әлегәчә тарихчыларның да, телчеләрнең дә тиешле илтифатына лаек булмый калган тел материалы турында бара! Тәңкәләрдәге язулар Шиһаб Мәрҗани «Идел буе төркисе» дип атаган телгә, ягъни гомумтөрки характердагы тел нормаларына туры килә. Шул ук вакытта алар чор ягыннан эпиграфик истәлекләрнең II стиль дип аталган[1] төренә якын (мәгълүм булганча, II стильдәге борынгылык төсмерләре «аерым» болгар теле файдасына сөйли).

Хәлбуки, II стиль кабер ташлары Идел буе халыклары тарихының кыска бер чорында гына булганлыгы да билгеле. XIII гасырның 80 нче елларына кадәр һәм XIV гасырның 50 нче елларыннан соң, мәсәлән, алар очрамый инде. II стиль кабер ташларыннан алдарак һәм алардан соңрак теркәлгән эпитафик язмалар исә гомумтөрки характерда булып, II стильгә хас тел үзенчәлекләреннән азат булулары белән аеры-

[1] Юсупов Г. В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.—Л., изд. АН СССР, 1960.

лып торалар. Бу шактый кызыклы күренеш ни сәбәптәндер хәзергә кадәр тикшеренүчеләрнең игътибарыннан читтә калып килгән һәм, әлбәттә, махсус аңлатуга мохтаҗ. Чыннан да, әлеге истәлекләрнең XIII йөз ахырында пәйда булып, XIV гасыр башында киң таралуы һәм гасырның икенче яртысында бөтенләй мәйданнан китүе нәрсә белән бәйләнгән? Бу сорауга җавап бирү өчен тәңкәләр үзләре «телгә килә»... Болгар тәңкәләренең II стиль ташлар белән бер үк вакытта барлыкка килүе һәм бер үк вакытта юкка чыгуы әлеге чорда Идел буенда политик һәм идеологик көрәшнең көчәюе турында сөйли. Тикшеренүчеләрнең игътибары да әнә шундый әчке тарихи бәйләнешларга юнәлсен иде.

Идел буенда яшәүче халыкларның язма мирасын өйрәнүгә багышланган хезмәтләрдә соңгы вакытта ике юнәлешнең көчәеп китүе сизелә. Бер яктан, «борынгы болгар» теле гомумтөрки тип телдән үзгә булган дип расларга омтылу [1], икенче яктан, XIII—XIV гасыр әдәби мирасын «борынгы болгарлар» культурасыннан аерып карарга тырышу күзгә ташлана. (Кара: Наджип Э. Н. «Хосроу и Ширин» Кутба и его язык.— «Тюркологический сборник». М., «Наука», 1966. Аның ук. О языке памятника начала XIII века «Кысса-и Юсуф» Али. — «Советская тюркология». Баку, 1976, № 2, 74 бит.) Сүз уңаенда, әлеге хезмәтләрдә әдәби ядкарьләрнең иҗат ителү урыны турындагы фаразлар да тарихи яктан җитәрлек нигезләнмәгән булуын билгеләп үтәргә кирәк. Мәсәлән, Үзбәк ханның варисы Тинибәк Сыр-дәрья буендагы җирләрнең хакименә әверелгән. Белгәнебезчә, «Хөсрәү вә Ширин»дә Котб аны Ак Урда ханы дип атый. Ак Урданың үзәге Идел буенда булуы белгечләр тарафыннан ышандырырлык итеп исбатланган иде инде (Сафаргалиев М. Г. Распад Золотой Орды. 1960, 14—15 битләр. Федоров-Давыдов Г. А. Общественный строй Золотой Орды. М., изд. МГУ, 1973, 141 бит.) Икенче хезмәттә исә монгол яулары килгәнче Идел буенда кыпчак угыз кабиләсе яшәгәнлеге искә алынмаган (Путешествие Абу Хамида Ал-Гарнати, М., «Наука», 1971, 27 бит). Шунлыктан «Кыйсса-и Йосыф» поэмасы угызлар даирәсендә иҗат ителгән (ягъни Идел буенда түгел) дигән төп тезис та безне ышандыра алмый.)

«Аерым» болгар теле булган дип раслау өчен, гадәттә, башлангыч нигез итеп II стиль эпитафик язмалар алына. Ләкин, инде искәртеп үтелгәнчә, II стиль кабер ташларының мәгълүм бер чорда гына «кулланылышта булуы» өстенә, Идел буенда XII—XIV гасырларда мондый үзенчәлекле телдә сөйләшү факты ни язма, ни археологик, ни башка чыганаклар белән расланмый (гәрчә әлеге чор шактый яхшы өйрәнелгән булса да). Бу — бик җитди каршы аргумент. Әгәр инде әлеге телдә зиратта гына «сөйләшсәләр», ягъни күмү ритуалларында гына аннан файдалансалар (чөнки текстта ритуаль сүзләр булмаганда, II стиль ташъязмалар теле гомумтөрки төс ала: мәсәлән, «Чәримсән суына барса — үлти») [2], сүз гарәп теле сыман ук дин теле турында бара дип фараз кылырга мөмкин булыр иде. Ләкин моның болгарларга нинди мөнәсәбәте бар?! Билгеле булганча, аларга гыйбадәт кылу өчен гарәп теле хезмәт иткән.

Элеккерәк чорга караган II стиль ташъязмалар теленең үзенчәлекле элементлары Төньяк Кавказда табылды. Югарыда китерелгән мисаллар белән янәшә куйганда әлеге факт көтелмәгән уйлануларга этәргеч бирә: гыйбадәт кылу өчен хезмәт иткән архаик тел борынгы хазарларныкы булып, II стиль язмалардагы ритуаль лексика кисәкчәләре безгә килеп җитмәгән борынгы хәзәр теле калдыклары түгел микән?

Инде тәңкәләрдә очрый торган язмаларга хронологик эзлеклелектә тукталып үтик.

Акча сугуда файдаланыла торган гарәп терминнары XII—XIII гасырда ук әдәби тел сүзлегенә керәләр һәм һич тә чит-сеер тоелмыйлар. Мәсәлән, Насретдин хәлиф исеменнән сугылган көмеш Болгар тәңкәләренең уң ягында: «Өн-насретдин аллаһе әмир-эл-мөэмин» дип язылган. Икенче якта: «Әд-динар әл-мал-әз-зарб Болгари», ягъни «Динар. Болгарда сугылган тәңкә» дигән язуны укырга мөмкин. Акча, аерым

---

[1] Ахметьянов Р. Г. Сравнительное исследование Татарского и чувашского языков. М., «Наука», 1978, 7—12 битләр. Кызганычка каршы, автор мәсьәләне шактый гадиләштерен, аерым чагыштырулар, янәшә куюлар белән генә чикләнә, әлеге чагыштырмалыкның тарихи фактлар белән раслануы-расланмавы хакында кайгыртмый. Бу хәл аның фаразларын нык көчсезләндерә.

[2] Хакимзянов Ф. С. Эпитафия волжских булгар. М., «Наука», 1978. 104 бит.

алганда, көмеш тәңкә «динар», «мал» дигән сүзләр белән «Кыйсса-и Йосыф» поэмасында да бик еш телгә алына.

Насретдин тәңкәләрендә теләк-дога рәвешендәге гарәпчә язу очрый (соңрак андый язулар төрки телдә дә кабатлана). Ул язуның мәгънәсе: «Дөнья — бер сәгатьлек, аны изге эшләргә файдалан».

Ислам диненә күчкән Беркәй хан заманында (1257—1266) болгар тәңкәләрендә «тамга-и-гали» дигән язулы махсус тамга күренә. Кыпчак балбалларын хәтерләтә торган яңа тамга сугылган мондый тәңкәләр меңәрләп чыгарыла. Димәк, әлеге язудан улус үзе дә, аның тамгасының да бөек Мункә каганнан бәйсез булуы күренә (әлегәчә болгар тәңкәләре бөек каган исеменнән һәм аның тамгасы белән сугылып килгән). Гомумән, XIII гасыр урталарында болгар тәңкәләрендә аерым тамга һәм язулар барлыкка килү Идел буендагы җирле феодалларның шактый көчле һәм бәйсез булуы турында сөйли.

XIII гасырның 80 нче еллар башы болгар акчаларын сугу өлкәсендә үзенчәлекле урын биләп тора. Туда-Мәңге хан хакимлек иткән чорда (1280—1288 еллар) «гали тамга» басылган тәңкәләр әйләнешкә керә, ләкин аларда хан исеме бөтенләй телгә алынмый. (Бу кызыклы фактка алда махсус тукталыныр әле).

Кайбер тәңкәләрдә гарәп һәм төрки телләрендәге язулар очрый. Мәсәлән, 1967 елда Болгарда табылган бер хәзинәдә «Уңыш, куәт, дәүләт» мәгънәсендәге гарәпчә язулы тәңкәләр бар. Татарстан дәүләт музеенда саклана торган кайбер көмеш тәңкәләрдә гарәп хәрефләре белән «котлыг булсун» дип язылган. XIV гасырдагы кайбер бакыр пулларда «Богар пулы» дигән язуны укырга мөмкин. Бу тәңкәләрнең икенче ягында — уртасына «гали тамга» басылган, ә нурлар арасына ел исәбе куелган биш почмаклы йолдыз балкып тора. Кайберләренең сугылу вакыты да (һиҗри исәбе белән 734 ел) бик ачык укыла.

Шундый ук йолдызлы, әмма сугылган урыны күрсәтелмәгән бакыр акчалар да игътибарны җәлеп итә. Сурәт һәм язу рәвешенә карап аларны да Болгар акчалары дип санарга мөмкин. Бу тәңкәләрнең уң ягына: «Ун алты пул — дәник» дип язылган. (Ягъни уналты пул бер дәник көмешкә тора. Болгарда бер көмеш акча ике дәниктән торган). Аларның кайберләрендә «Болгар» дигән язу да очрап куя.

Шундый ук язулы тәңкәләр Сарай шәһәрендә дә сугылган. 726 (һиҗри) ел тәңкәсенә (ТАССР дәүләт музее, № 18302) «Ун алты пулиг — дәнкә», 721 (һиҗри) ел тәңкәсенә (шунда ук, № 18305) бизәкле куфи белән «Ун алты пул—дәнки» дип язылган. «Котлыг булсын яңа пул!» дигән язулы бакыр тәңкәләр шулай ук зур бер төркемне тәшкил итә.

Әлеге тәңкәләр 1310—1311 еллардагы акча алышынудан соң әйләнешкә кертелгәннәр. Акча реформасы үзе Туктагу хан (1290—1312) исеменнән бик күп санда көмеш тәңкәләр чыгу белән башлана. Ләкин бакыр тәңкәләр, шул исәптән югарыда телгә алынган язулы акчалар Үзбәк хан (1312—1342) идарә иткән елларда сугыла. Моның хикмәте шунда, бакыр акчаларны әйләнешкә җибәрү һәрвакыт зур кыенлык тудырган, арзанлы металлдан сугылган тәңкәләргә халык, гомумән артык ышаныч багламый. Шуңа күрә бакыр тәңкәләрне төрлечә бизәкләп-чуклап, дога-теләк сүзләре язып чыгарырга туры килә. Хөкүмәт бакыр акчаларны махсус боерык белән дә таратырга тырыша. Мәсәлән, Үзбәк хан заманындагы Сарай пулларында: «Дөкма һөмаюн» (ягъни «падишаһ әмере белән!») дигән рәсми язу күзгә ташлана. Шул ук вакытта төрки язулы бакыр тәңкәләр бары тик җирле әһәмияткә генә ия булганнар дип аерып күрсәтергә кирәк. Башка төбәкләрдә үз кыйммәтләрен көмеш акчалар гына саклый алган.

Тәңкәләрдәге һәм кабер ташларындагы язмаларның график үзенчәлекләре турында да берничә сүз әйтеп китик. Болгар дәүләтенең акча сугучылары әле XII йөз ахырында ук тәңкә бизәгендә сульс язуы ысулын кулланганнар. II стиль кабер ташларындагы язмалар, тел үзенчәлекләреннән тыш, VIII—X гасырларда хәзар һәм болгар тәңкәләрен бизәүдә кулланылган архаик куфи язу рәвешен дә чагылдырган. Бу исә кабер ташларындагы язмаларның анахронизм икәнлеген, ягъни аларның XIII—XIV гасырлардагы болгар теле белән бәйләнешләр бик аз булуын күрсәтә.

Әлеге фикер I стиль кабер ташларындагы язмалар белән раслана. Билгеле бул-

ганча, Болгарларның һиҗри исәбе белән 642 нче елга (1244) караган иң борынгы эпиграфика ядкәре Идел буе төрки телендә язылган.

Тәңкәләр болгар теле һәм язуы үрнәкләрен генә биреп калмыйча, тарихи чыганак буларак та зур игътибарга лаек. Мәсәлән, аларның сугылу яки сугылмау чоры II стиль ташларының таралу яки таралмау елларына туры килә. Бу II стиль ташларының халык арасында киң таралган дини йолалар белән бәйләнешен генә түгел, бәлки, кайбер тәңкәләр кебек үк, иҗтимагый-политик һәм идеологик көрәш чагылышы булуын да күрсәтә.

Мондый тәңгәллек II стиль ташларының килеп чыгуы һәм югалуын эченә алган берничә катлаулы чордан тора. Ул еллар аерым әһәмияткә ия.

I. XIII гасырның 80 нче елларында болгар акча сугучылары күп кенә аноним тәңкәләр чыгара башлыйлар. Шул ук елларда Сарайда, Хәрәзмдә һәм Биләрдә акча сугу урыннары ачыла, алар да эшләрен аноним акчалар чыгарудан башлап җибәрәләр. Хәрәзмнең аноним тәңкәләренә һиҗри исәбе белән 678 нче ел (1279—1280), Сарайда сугылганнарына 681 нче ел (1282—1283) куелган [1].

Акча сугу хокукы Туда-Мәңге хан (1280—1288) хакимлек иткән чорда шулай тупас бозыла.

II стиль үзенчәлекләре булган төрки клерикаль лексикалы ташъязмаларның беренче үрнәкләре XIII гасырның 80 нче еллары башына туры килә. (Юсупов Г. В. Күрсәтелгән хезмәт, 1 нче таблица). II стиль иң борынгы кабер ташына һиҗри исәбе белән 680 нче ел (1281—1282) куелган һәм ул Болгарның үзендә түгел, бәлки Казаннан көньяк-көнчыгышка таба 40 чакрымда урнашкан Урмат янындагы шәһәр харәбәләрендә табылды.

Аноним тәңкәләренә һәм II стиль кабер ташларына язылган сүзләрнең Идел буенда феодаль сугыш ачылган елларга, ягъни болгарларның монгол ханнары властена каршы яшертен көрәше белән бер чорга туры килүе кызык. Әгәр шул хәл властьлар тарафыннан рәсми рәвештә, көчләп кертелә торган яңа дингә каршы чыккан ортодоксаль ислам белән бәйле булса, бу тайпылу әлеге чуалыш елларында болгарлар арасында аеруча тирән тамыр җибәрер һәм киң таралыр иде. Әмма, югарыда күрсәтеп үтелгәнчә, аноним тәңкәләр Болгарда гына түгел, Хәрәзмдә, Сарайда һәм Биләрдә дә сугыла. Ул, гомумән, яңа ханга каршы юнәлдерелгән булган дип уйларга кирәк. XIII гасырның соңгы чирегe — II стиль кабер ташларының беренче үрнәкләре барлыкка килү чоры, ә алар XIV гасырның беренче яртысында гына таралалар.

Тәңкәләр һәм кабер ташларында бу елларның политик көрәше һәм идеологик көрәшнең кискенләшүе чагылыш таба. Ортодоксаль дин Туда-Мәңгенең үз сараенда ук таралган булырга мөмкин. Чөнки ул көчле болгар аристократларыннан һәм рухани феодалларыннан бәйсез булырга омтылган. (Аны шушы тәхеткә үз чорында Батый хан хатыны Бәрәкчин тәкъдим иткән була. Ләкин Батыйның уллары үтерелгәч һәм Бәрәкчин җәзалангач, ислам динен кабул иткән һәм җирле аксөякләр тарафыннан яклау тапкан Беркәй җиңә.)

Туда-Мәңге, тәхеткә утыргач, Мисырга илчеләр җибәреп, үзенең хакимлек итә башлавын һәм ислам динен кабул итүен белдерә, солтаннан үзенә мөселман исеме бирүне сорый. Солтан Туда-Мәңгегә кайбер таләпләр куя [2]. Мисыр һәм Алтын Урданың үзара мөнәсәбәтләренә карaганда, бу таләпләр политик характерда булырга тиеш түгел. Алар дини мәсьәләләргә кагылгандыр дип уйларга кирәк. Күрәсең, Туда-Мәңге барыбер мөселман исеме ала алмаган. Һәрхәлдә ул хакимлек иткән чорда мөселман исеме куелган акчалар сугылмаган.

Туда-Мәңге чорында дини ызгышлар килеп чыгу язма истәлекләрдә дә чагыла. Байбарс фикеренчә, Туда-Мәңге «саташа», ул «шәехләргә һәм дини дәрвишләргә нядәшә». (Тизенгаузен В. Г. Искә алынган хезмәт, 105—106 нчы битләр). Бәлки Туда-Мәңге шәехләрнең ортодоксаль динне яклаучыларына нялешкән булгандыр.

---

[1] Федоров-Давыдов Г. А. О начале монетной чеканки в Хорезме и Сарае в конце XIII века.— Эпиграфика Востока. XIV том. М., изд. АН СССР, 1961 ел. 79 бит.

[2] Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. 1—2 томнар. СПБ, 1884. 69 бит.

һиҗри исәбе белән 685 елда (1286—1287) Туда-Мәңге илчеләре Мисырга тагын баралар. Хан аларга солтан таләпләренә риза булуын әйтеп җибәрә. Әмма Туда-Мәңге җирле руханилар һәм аксөякләрнең көчле каршылыгына очрый, алар һиҗри исәбе белән 686 елда (1287—1288) аны тәхеттән баш тартырга мәҗбүр итәләр (искә алынган хезмәт, 105—106 битләр). Шулай итеп, бу чорда Урта Идел буенда Алтын Урда ханы Туда-Мәңге тирәсендәге шәехләр алга сөргән ортодоксаль ислам диненең генә яшь алуы күренә. Моңа аноним тәңкәләр һәм II стиль кабер ташлары дәлил булалар.

2. XIII гасырның соңгы чирегеннән башлап Урта Идел буенда таралган ортодоксаль дин турындагы тезис болгар тәңкәләрен сугу һәм II стиль кабер ташлары арасындагы параллельләр белән дә раслана.

Билгеле булганча, феодаль сугыш шәһәрләр һәм купецлар тарафыннан яклау тапкан Туктагу ханның (1290—1312) тәхеткә утыруы белән тәмамлана. Сарай феодаллары, болгарлардан аермалы буларак, яңа ханны тиз таныйлар. Ул хакимлек итә башлауга (һиҗри исәбе 690 елда) аның исеме белән Сарай тәңкәләре чыгарыла. Беренче тәңкәләргә хан исеме уйгур шрифты белән языла. Ханның хакимлеге рәсми динне танучы даирәләргә дә, ортодоксаль ислам динен яклаучы даирәләргә дә бәйсез була. Беренче ундүрт еллык хакимлеге чорында Туктагу Мисырның идарә итүчеләре белән дипломатик элемтәләргә керми.

Феодаль сугыш елларында Болгарда аноним акчалар сугу дулкыны Туктагу тәхеткә менгәч тә бераз вакыт дәвам итә. Инде ул, күрәсең, яңа ханга каршы юнәлгән булгандыр. Болгарның һиҗри исәбе белән 692 ел куеп сугылган аноним тәңкәләре билгеле.

XIII йөзнең 90 нчы елларында II стиль кабер ташларының элекке еллардагыдан күбрәк таралуы күренә (Юсупов Г. В. Күрсәтелгән хезмәт, 3, 4, 5 таблицалар). Бу чорда Болгарда ортодоксаль дин тагын да киңрәк колач алган булырга тиеш. Әмма бу хәл феодаль сугыш тәмамлангач кына була.

3. Болгар феодаллары әлеге дуамал эшләре өчен каты җәзасын алалар. Акча сугуның иркле булуы, теләгән һәр кешенең үз көмешеннән тәңкәләр суктырып ала алуыннан соң, ханның 1310—1311 елларда акча реформасы үткәрүе, Болгарда акча чыгару эше туктатылу сизелерлек удар булган. Ул чорда сугылган Болгар акчалары мәгълүм түгел.

Туктагу үз дәүләте өчен башкала итеп тынычрак шәһәр булган Сарайны сайлый. Сарай тәңкәләренә беренче тапкыр буларак «әл-мәхруса» (ягъни, иминлеге тәэмин ителгән) дигән күп мәгънәле эпитет сугыла башлый.

Акча реформасы чорыннан соң II стиль кабер ташлары да күренми. 1311—1314 еллардагы кабер ташларындагы язмалар гадәти Идел буе төрки ысулында башкарылган (шунда ук, 10, 12 нче таблицалар).

4. 1312 елда Үзбәк хан тәхеткә утыргач Болгар феодаллары үз өстенлекләрен кире кайтаралар. Болгарда яңадан акча сугу эше башлана һәм шактый киң җәелә. Болгар тәңкәләрендә, Сарай акчаларындагы кебек, «әл-мәхруса» эпитеты чагыла.

II стиль кабер ташларының күбесе Үзбәк хан (1312—1342) идарә иткән чорга туры килә. Провинциаль Болгарда ортодоксаль диннең таралуы Үзбәкне артык борчымаган, күрәсең. II стиль кабер ташларының билгеле булган 47 үрнәгеннән 30 ы Үзбәк хан чорыныкы[1]. II стиль кабер ташларының бизәү үрнәкләре Үзбәк чорында чагыштырмача бертөрле булу алар бер җирдә, үзәкләштерелгән тәртиптә эшләнгәннәр икән дип уйларга нигез бирә.

Әгәр без болгарлар аерым телдә сөйләшкән, дигән фикерне алга сөрсәк, алар бу телдән Үзбәк хан чорында гына файдаланганнар дигән нәтиҗә килеп чыгар иде.

5. Болгар феодалларының экономик куәте (Урта Идел буендагы археологик эзләнүләр вакытында аларның йөзләрчә һәм меңнәрчә тәңкәләрдән торган хәзинәләре шул хакта сөйли) һәм ортодоксаль диннең йогынтысыннан ычкынган тарафдарлары башкала руханиларын һәм аксөякләрен ярсыта. Җанибәк тәхеткә утыргач (1342—1357), болгарларның акча сугу кәсебе бөтенләй тыела. II стиль кабер ташларының да бетә

[1] Юсупов Г. В. Күрсәтелгән хезмәт, 11, 13, 14, 16, 17, 21, 23—26, 47 нче таблицалар. 1, 2 текст. Хәкимҗанов Ф. С. Күрсәтелгән хезмәт, 8—18 нче таблицалар.

баруы бу тыюларның закон төсен алуы турында сөйли. Җанибәк чорында, күрәсең, ортодоксаль динне катгый рәвештә тыя торган указлар чыккандыр. II стиль ташларының соңгылары 1357—1358 елларга, ягъни Җанибәк хакимлегенең соңгы елларына карый.

Шулай итеп, XII—XIV гасырларда Идел буенда кимендә өч язма тел булган. Таралу характеры буенча аларны мондый тәртиптә куярга мөмкин: тәңкәләрне һәм I стиль эпитафияләрен бизәү, рәсми кәгазьләр тутыру өчен хезмәт иткән Идел буе төрки теле; тәңкәләрдә һәм эпитафияләрдәге, көнкүреш әйберләрендәге (чынаяклар, шәмдәлләрдәге һ. б.) гарәпчә язмалар теле; II стиль эпитафия теле.

Болгар тәңкәләрендә һәм эпитафияләрдәге язмалар XIII—XIV гасырлардагы II стиль кабер ташлары теленең гыйбадәт кылу өчен генә саклануын күрсәтә. II стиль кабер ташларындагы үзенчәлекле архаик клерикаль лексика, язу рәвеше дә шуның нәтиҗәсе түгел микән? Шундый урынлы сорау туа: Идел буенда башка тарихи чыганаклар буенча билгесез булган архаик төрки клерикаль лексика каян килеп чыккан соң?

Мишәр диалектының чуваш теле белән һич кителмәгән уртак яклары булуына игътибар итик. Ул халаҗ теле кебек үк (Иранда яшәүче халаҗлар телендә бик борынгы төрки теле элементлары сакланган), үзендә кайбер борынгы формаларны саклап калган. Л. Т. Мәхмүтова, шушы ике тел өчен генә характерлы параллельләрне китереп, асылда аларны борынгы төрки катламнар уртаклыгы белән бәйли[1]. «Борынгы төрки катлам» төшенчәсе киң чыганаклар белән төгәл килү мәгънәсендә йөргенләктән, әлеге уртаклыкларны конкрет һәм шактый төгәл итеп — хазар теле белән бәйләп аңлатырга кирәк дип саныйбыз. Чөнки мишәрләрнең дә, чувашларның да болгарларга турыдан-туры мөнәсәбәте юк. Хазарлар бик озак христиан динен дә, ислам динен дә кабул итмиләр. Алар Византиягә һәм гарәпләргә бәйле булып яшәргә теләмиләр. 737 нче елда гына гарәп полководецы Мәрван Идел буенда җиңүгә ирешә һәм Хазар каганын ислам алласына табынырга мәҗбүр итә. Бу — Идел буенда ислам дине рәсми кабул ителүнең датасы булып тора. Шактый көчле булган хазарлар гыйбадәт кылу теле итеп барыбер үз төрки телләрен калдыра алган булырга мөмкиннәр. Болгарларның исә гарәп телендә гыйбадәт кылуы мәгълүм.

XIII гасырның 80 нче елларына кадәр Болгарда II стиль эпитафик язмаларының булмавы, ә Төньяк Кавказда Идел буендагы II стиль язмаларының бөтен үзенчәлекләре чагылган язулар табылу[2]— әлеге фикерне яклаучы көчле аргумент.

Идел буенда хазар йогынтылы ислам диненең таралуы Алтын Урда ханнары эшчәнлегенә дә бәйле булгандыр. Чөнки алар, хазарлар кебек үк, гарәпләргә буйсынмаслык дәрәҗәдә көчле булалар. Чыңгыз варислары арасында ислам динен беренче булып кабул иткән Беркәй хан биләмәләренең исә Төньяк Кавказда булуы мәгълүм. Аның якын кешеләре арасында ортодоксаль ислам динен яклаучылар да булырга мөмкин. Ортодоксаль исламның әүруча көч алуы соңрак — Туда-Мәңгә хан заманына туры килә. II стиль кабер ташлары да нәкъ әнә шул чорда күренә башлый.

---

[1] Махмутова Л. Т. Опыт исследования тюркских диалектов. М., «Наука», 1978 ел. 260 бит.
[2] Байчоров С. Я. Северокавказский ареал древнетюркской рунической письменности. Филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен автореферат. М., 1977 ел.

# КЕЧКЕНӘ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**Җәүдәт ДӘРЗАМАНОВ. ТӨНГЕ МАҖАРА.** Әкият-поэма. Кече яшьтәге балаларга. Татарстан китап нәшрияты. 1980 ел.

Соңгы елларда балалар өчен бер-бер артлы нәни җыентыклар чыгарган бу авторның иҗат үзенчәлеге инде шактый гына ачык булып төсмерләнеп килә: теле шактый җанлы һәм йөгерек, фикерләве гадилеге һәм балаларга хас самимилеге белән аерылып тора. Шунда ук аның нәниләргә, аларның табигатенә игътибарлы булуын һәм үзенең геройларын чиксез яратуын билгеләп узарга мөмкин. Холык-фигыле, әйләнә-тирәгә, кешеләргә мөнәсәбәтендә исә аны, барыннан да элек, мөлаемлек һәм эчкерсезлек сыйфатлары характерлый булса кирәк. Кыскасы, Җ. Дәрзаманов табигате белән үк нәниләрнең үз язучысы. Ләкин шуңа да карамастан, әле башланып кына килгән иҗатына шактый ук җитди кимчелекләр дә хас. Шуларның байтагы, аерым алганда, «Төнге маҗара» дип исемләнгән шигъри әкияттә дә чагылыш тапкан.

Әкият халкыбызның борын-борыннан тупланып килгән авыз иҗатында мәртәбәле, үзгә бер урын алып торган жанр. Традицияләре аның иксез-чиксез. Шунда ук бу жанрга балаларның аеруча игътибарлы булуы да сер түгел. Димәк, әкият язарга алынган заман язучысы укучы алдында гына түгел, жанрның бай традицияләре алдында да икеләтә җаваплы сизәргә тиеш үзен. Миңа калса, «Төнге маҗара» авторы бу хакта өлешчә оныта төшкән. Беренчедән, ул үзенен сюжеты, композициясе һәм үзәккә алынган конфликты белән яңа түгел. Икелегә укыган малайның төштә күргән маҗаралары хакында илебез әдәбиятында да инде ай-һай күп язылды. Ни өчендер, ул һәр очракта малай була иде, икеләләре белән, ни гаҗәп, төштә генә очраша, ул куркыныч төш була һәм, кагыйдә буларак, вакыйгалар көндәлек янсә кадерсезләнгән китап битләренә барып тоташа. Үзен нәниләр әдәбиятына багышларга җыенган Җ. Дәрзамановта да боларның шул ук хәлдә кабатлануы, әлбәттә, уңай күренеш түгел.

Икенчедән, әкият булгач, андагы вакыйгаларга патша һәм вәзирләрнең килеп керүе һәр очракта да мәҗбүри микәнни? Вакыйга һәм анда катнашучылар бүгенге бала күңеленә якынрак булганда, әсәр бермә-бер ота гына төшәр иде бит, югыйсә. Конфликтны чишүдә дә бердәнбер чараның сугыш һәм кан коешка гына кайтып калуы белән дә килешәсе килми. Ә инде әкият булгач, анда теләсә нинди куркыныч вакыйга һәм картиналарны да тасвирларга мөмкин, дигән караштан чыгып иҗат итү бөтенләй кирәкмәс иде. Заман баласына сугыш һәм үтерешләргә кайтып калган әкият сөйләүнең ихтыяҗы зурмы икән — автор бу хакта да уйланмаган, ахры. Тырнакларны куптара-куптара үрмәләү дисеңме, асукисү дисеңме, күселәр мыжлап торган салкын базга ябып кую дисеңме, җаны булган образ итеп тәкъдим ителгән «өчле»не мичтәге ялкын эченә ташлап, аннан сандалга сузып салып чүкеч белән чаң да чоң кыйнауларны — болар баланы гына түгел, өлкән укучыны да чиркандырырлык рәвештә куркыныч итеп тасвирланган. Әкият осталары булып алар да әлегедәй куркыныч картиналардан элек-электән качарга омтылган. Андый очраклар булган хәлдә дә, куркыныч вакыйгаларга романтик төс, әкияти шартлылыкка төрелгән җиңеллек, оптимистик рух өстәргә омтылганнар. Мисал өчен, бөтен дөньяга танылган мәшһүр әкиятче Андерсен әсәрләрен искә алу гына да җитәр. Ә инде татар әдәбиятында бу уңайдан иң кулай мисал, ул, әлбәттә, А. Алишның кояшлы әкиятләре. Балалар өчен әкият язарга алынган автор үз әсәрләрендә тасвирланган вакыйгаларның педагогик функцияләре, бала күңеленә, сабыйның саф-чиста рухына ничек тәэсир итүе хакында барыннан да элек уйланырга тиеш иде, минемчә. Бала өчен әкият йөгәнсез хыял җимеше генә түгел, ә чынбарлыкны өйрәнү булып та тора. Юкка гынамы бала, кагыйдә буларак, төшендә дә әкиятләр күрә?! Ә нигә әле аңарга «хәерле төн», «тыныч йокы» һәм «тәмле төшләр» телисе урында куркудан саташып уянырлык сугыш картиналары тәкъдим итәргә?

Өченчедән, кече яшьтәге балаларга тәкъдим ителгән әкиятнең логик эзлеклелеге дә шактый башваткыч булып чыккан. Бишлеләргә генә укучы бала төшенә икеләләр һәм берлеләр каян килеп кергән? Һәм, гомумән, «берле» дигән билге бармы ул? Гел «берле»ләрдән генә торган көндәлеккә каян килеп керә бишлеләр (вакыйга бит төшкә кергән конкрет бер көндәлектә башланып киткән иде)? Төшкә логикасызлык та хас булырга мөмкин дип акланыргамы? Алай икән, нәни укучыга төш сөйләми, ә әдәби әсәр тәкъдим итә түгелме соң автор? Әкиятне укыган нәни укучы шул рәвешле сорауларга җавап табып бетерә алырмы икән!

Дүртенчедән, әсәрдә төгәлсезлекләр, тел кытыршылыклары, рифма янсә ритмны төзекләндерү өчен генә китерелгән ясалма строфа һәм сүзләр дә байтак. Әйтик, «Бауны шундый каердым, Җебен җепкә аердым. «Өч»ләрне ду күчердем. Өстән бәреп төшердем», — дип яза Җ. Дәрза-

манов. Ә нәни укучы «бауны каерып буламы икәнни...», «ду күчерү ничек була икән ул...» дип баш ватарга тиешме?! «Дүртле»ләрне кол иттем. «Берле»ләрне кыл иттем»,— дигән сүзтезмәдә «кыл итү»нең мәгънәсен аңлау шулай ук җиңел булмас. Рифма өчен китерелгән кысыр сүздән башка берни түгел бу! «Әй «берле»ләр сөенә, җырлый «әтнә» көенә: «Дошманыбыз тончыкты, тончыкты, җаны чыкты!»,— кебек строфаларда да авторның сүзләр яңгырашына мөкиббән китеп, мәгънәви эчтәлегенә игътибар итеп җиткермәве ачык чагыла. Нигә әле халык күңелендә җылы урын алган «Әтнә» көенә шундый мәгънәсез, дорфа сүзләр китереп сыларга... Аерым юлларда башка шагыйрьләргә иярү дә үзен сиздереп куя. Мисал өчен «Тик бу ни хәл, бу ни эш? Болай булмаска тиеш!» Бу юлларның Ш. Галиевтән алынуы искәртелмәгән.

Кыскасы, аңлашылып җитмәгән нәрсәләр байтак. Шул җөмләдән «Төнге мажара» әкиятенә нәшриятның үзгә мөнәсәбәте дә бигүк аңлашылып җитми. Ул бер үк вакытта аерым-аерым ике китап булып рус һәм татар телләрендә һәм, алай гына түгел, күп төсле матур рәсемнәр белән бизәлеп чыккан. Ирексездән, «ни өчен?» дигән сорау туа.

**Ринат МӨХӘММӘДИЕВ.**

---

**Адлер ТИМЕРГАЛИН. ТАШ АЛНЬӘ.** Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980 ел.

---

Һәркемнең мажарадан туймас бер чоры бар. Ул чорда тау битләрендә ялтырап яткан һәр пыяла кисәге дә якуттыр төсле, инеш буендагы таш араларында затлы табылдык ятадыр кебек; авызын ачып торган агач кувышлыгы җир астына сәяхәткә чакыра сыман... Һәм мажаралар туа: үзебез геолог, үзебез эзтабар, кирәксә, тылсымчы да.

Адлер Тимергалинның яңа китабындагы геройлар да әнә шундыйлар. Җәй уртасы. Каникул вакыты. Тынгысыз малайларның нәрсәдер эшлисе, дөньяга таныласы, халыкны шаккатырасы, һич югы аз гына булса да мактау сүзләре ишетәсе килә.

Китапның тышлыгыннан ук үзенә җәлеп итәчәк мажаралы вакыйгалар бусагасында торуыңны сизенәсең. Ләкин ул мажара повестьта эзләнелә торган хәзинәләр төсле бик ерак яшерелгән әле...

Буалап куйгач Торналы авылының гади инеше дә киңәя, гирәнәя. Җилкәннәр киерелерлек мәйдан ачыла. Төзелә ул җилкәнле көймә... Автор повестьның беренче ун бүлеген кызганмыйча сабыр гына малайлар белән җилкәнле көймә корып йөри. Инеш — көймә — кораб... Дингез сугышы да куерып ала. Тик укучының күңеле тыныч түгел: хәзинә кайда соң? Инеш уртасындагы атаудамы? Әллә Әбүзәр эзли торган пәһлеван кабереndәме? Бәлки бояр утарындадыр?!

Шәһәр малае Таймасның авылга килеп төшүе укучыны сагайта. Октябрь давыллары чорында ук эзсез югалган хәзинәне безнең көннәрдә искә төшерәләр. Моңарчы ник эзләмәгәннәр? Теләүчеләр табылмаганмы? Әйе, тәвәккәл, акыллы, тынгысыз эзтабарлар бик кирәк икән бу дөньяда. Менә Таймас та нәкъ шундый инде. Ул мәктәптә фәннәрнең тәмен белеп укый, мажаралы китаплардан эзләнергә өйрәнә, гади генә нәрсәгә дә сокланып карый. Җир шарының теләсә кайсы ноктасында да адашмаячак ул — почмакларны ярты градус төгәллек белән үлчи белә. Күк гөмбәзенең безгә күренгән бихисап күп йолдызлары арасыннан әллә нинди йолдызларны бармак төртеп күрсәтә ала. Автор хәтта үзе дә Таймас белән бәхәскә керергә җөрьәт итми, аның сүзенә өстенлек бирә һәм нәтиҗәдә безне дә шуңа ышандыра. Әйе, бүгенге балаларның бер дә белмәгәне юк. Әбүзәр кебекләр мамонт белән бронтазаврны ничек күз алдына китерәләр; Рәүфләр Полинезия халкының алласы Кон-Тикины иске танышлары кебек итеп кенә телгә алалар, хәтта Сәрия дә Тур Хейердал, Олен Бомбар кораблары турында мәгълүматлы.

Шулай итеп, укучы мажара көтә, ул «Кызлар һәм курчаклар», «Пауза турында әкият», «Олы корабка — олы юл» дигән бүлекләрне ашыгып кына үтеп китә дә, «Яшерен эшләр»гә туктала. Чынлап та, уйларың белән Әбүзәргә ияреп мамонт сөякләрен эзләсәң дә, җилкәнле көймәдә атауга юнәлсәң дә, гел Таймасны көтәсең. Таймас иске шкафтан табышмакка охшаш кәгазь тапты бит. Бу инде аңа башка малайлардан алгарак чыгарга, укучы алдына эре план белән басарга ярдәм итә.

Бер генә нәрсә борчый: вакыйгалар куерып мажарага якыная барса да, малайлар арасында дуслык җитенкерәми — һәркайсы үзенчә эзли, ялгыз хәрәкәт итә. Инде Апанаевлар бакчасы да телгә алынды, Мәмдүдә абыстай да күзгә чалынды... Ә малайлар гел аерым. Повесть үзенең кульминациясенә күтәрелеп җиткәч кенә автор дуслаштыра аларны. Шунда кинәт чын дуслык тантана итә!

Дуслык дигәннән, зур эшкә тотынгач олылар киңәше дә кирәк икән. Каникул уртасы булганлыктан, автор мәктәп ишегенә йозак та элеп куя алыр иде. Ләкин мәктәп ачык. Мәктәп директоры, китапханә мөдире һәм өлкән пионервожатый эзтабарлар белән җәй буе тыгыз элемтәдә. Үзен һавалырак тотарга яраткан Әбүзәр ишек аркылы гына булса да укытучылар бүлмәсеннән тиешле диалектиканы ишетеп кала.

«Төпле балалар,— дип уйлады ул /директор/.— Фәкать аз-маз контроль генә кирәк. Тик контрольнең чиге булырга тиеш, югыйсә ул кулдан тотып җитәкләп алып баруга әйләнә, күрсәтмә көтеп ятучан, умырткасыз, ихтыярсыз һәм фикерсез кешеләр тәрбияли. Ә андыйлар бездә болай да буа буарлык». Сүз балаларның җәйге каникул чорын да педагогик чараларга буйсындыру, инициативалык, мөстәкыйльлек, тәвәккәллек кебек күркәм сыйфатларны тәрбияләү турында бара. Ләкин артык борчылырга урын юк, малайлар нефть трассасындагы аварияда да, җир асты келәтендә бикләнеп кал-

ганда да үзләрен җитди һәм тыныч итеп тота беләләр.

Повесть хәзинәнең табылуы белән тәмамлана. Ләкин, авторның үз сүзләре белән әйтсәк, романтиканың формуласы: икс, игрек, зет... Димәк, мажаралар мәңгелек һәм һәркемнең үз мажарасы. Бары халык риваятьләренә, легендаларга һәрвакытта да игътибарлы булырга, хәзинәләр табылганчы эзләргә генә кирәк.

**Камил КӘРИМОВ**

---

Резеда **ВӘЛИЕВА. ЗӘҢГӘР ИРТӘ.** Казан, Татарстан китап нәшрияты. 1980 ел.

---

Дистәдән артык китап авторының бүгенге иҗатыннан чыгып үткәннәренә күз саласың да, бер матур хакыйкатькә ышанасың. Шагыйрә туган ил, патриотизм, интернационализм, иҗади хезмәт, яшәү мәгънәсе мәсьәләләренә заман таләбеннән чыгып кат-кат әйләнеп кайта. Чорның эстетик фәлсәфи тәҗрибәсе нигезендә ул проблемаларга яңадан-яңа төсмерләр өсти. Бу исә — аның иҗатында бер бөтен үсеш процессы тудыра, шигырьләрнең логик эзлеклелеген көчәйтә. Шуңа күрә дә иҗат иртәсендәге шигъри бөреләрнең соңгы китапта, буыннан-буынга сикереп, сабакка үрләвен күрү гаҗәп түгел. «Зәңгәр иртә»дә ике олы сабак тармаклана: берсе — тормыш хакында тирән уйлар белән тулы лирика, икенчесе — авыз чите белән генә елмаючы, яки нык кына чәнчеп алучы юмор-сатира. Шагыйрә шушы алымнар ярдәмендә матурлык белән ямьсезлек, батырлык яки куркаклык хакында фикер йөртә. Кай очракны гына алса да, шигырьләрне конкрет бер күренешкә корырга омтыла.

Юләр икәнсең Ниса,
Аңлар идең ичмаса.
Мәктәбебез чын булмый ич,
Күчерүче булмаса!

Көләсең дә уйланасың да. Шагыйрьнең уйлары күңелне кытыклап, көлдерүгә генә кайтып калсалар, андый кытыклаулар безгә бер минутлык кына ләззәт бирер иделәр. Өзеге мисалга китерелгән әсәрдә мәсәлән, автор үз максатына үгет-нәсихәт уку юлы белән түгел, геройның тискәре сыйфатларын вакыйга-хәрәкәт эчендә ачып бирү ярдәмендә ирешә. Ләкин алар арасында укучыны борчылыр дәрәҗәгә җиткергән, артык төс-бизәкләргә бай булган шигырьләр дә очрап куя. «Без — нәни игенчеләр»нең геройларын бер матур изге теләк берләштерә: илгә, җиргә, халыкка файдалы булу. Баксаң, алар җирнең — безнең заманда трактор белән сукалануын да, игеннең техника ярдәмендә чәчелгәнлеген дә белмиләр икән. Бабалары сыман көрәк белән җир казып, кул белән орлык чәчмәкчеләр. Заман баласы ни өчен бүгенге тормыш хакында искечә фикер йөртергә тиеш? Геройларның дөньясын, фикер офыкларын ясалма рәвештә тарайтып кына контрастлыкка ирешү — шигъри осталыкка китерми. Шул сәбәпле шигырьдә икмәк үз тәмен, су — шифасын югалта. Шуңа күрә дә шигырьне укыгач «очучы кыз Камилә»не генә түгел, авторның үзен дә кешеләр арасына — заманыбызга, җиргә чакырасы килә.

Кайвакыт шигырьләрдә логик эзлеклелек югала. Бу исә үз чиратында әсәрнең композицион бөтенлеген, мәгънәсен кирәкмәгән якка үзгәртә.

Менә бу курчакны
Күр инде бер генә,
Әйтерсең күбәләк,
Өс-башы гөл генә!

Шигырь ахырында исә:

Гөл кебек үсә бит
Хезмәткәр баласы...

дигән юлларны укыйсың да, гаҗәпләнеп каласың. Өс-башы күбәләк кебек, гөлләр кебек үскән бала... Поэтик бизәкләр урынын, чамасын белеп кулланылмаган. Шагыйрә әйтергә теләгән фикер укучы күңелендә урын табу түгел, үз иҗатына бизәк тә була алмый. Бу уңайдан күзгә аеруча ташланып торган тагын бер кимчелек хакында әйтеп китү кирәктер: шигъри юллар вакыт-вакыт, фикер дигән финишны сизмичә үтеп киткән йөгерешчене хәтерләтәләр. Фикер әйтелгән, ә шигъри юллар әле дәвам итә. Шагыйрә үз хисләрен кирәкле моментта йөгәнли алмыйча ваклау, детальләштерү юлына баса. Бу сыйфатлар бигрәк тә «Дәрес әзерләгәндә», «Әбекәй хикәяте», «Гомәр һәм һөнәр» кебек шигырьләрдә күзгә ташлана.

Р. Вәлиева китабында поэмаларга зур урын бирелә. Темалары, чишелешләре белән үк алар автор иҗатындагы публицистик пафосның үсә баруын дәлиллиләр. Шулай да вакыт-вакыт ул поэмаларда шигъриятнең җаны булырга тиешле моң югала. «Канатлы җайдак», «Шагыйрь гомере», «Ильичка хат» кебек әсәрләрдә шагыйрә төрле чор вакыйгаларына мөрәҗәгать итә. Аларда эре һәм вак масштаблы вакыйгалар, тарихи борылышлар, дөньякүләм әһәмиятле хәлләр шәхси пландагы тар күренешләр белән аралашып, бергә үрелеп китүчән. Бу алым, бер яклап, шәхси материалның яңгыраш диапазонын киңәйтсә, икенчедән, зур тарихи вакыйгаларны индивидуальләштерә, аларга конкрет төс бирә. Поэмаларның кимчелекләре дә, уңышлы яклары да әлеге үзенчәлеккә килеп тоташа.

Язманың ахырында моңа кадәр игътибардан читтә калып килгән тагын бер матур булмаган күренешкә игътибар итәсе килә. Ул да булса дөньяны балалар аңлавы аша күрү һәм күрсәтергә омтылу. Бу беренче карашка шигырьләрне аңлаешлырак, мавыктыргычрак итәдер кебек. Әмма аны ясалма рәвештә гаять беркатлы һәм шәрә итә. Соң чиктә мондый шигъри «әсәрләр» нәни укучыны баетуга түгел, аны рухи чикләнгәнлеккә этәрә.

Һәр шигырь — мәгълүм бер тойгының гәүдәләнеше. Ләкин шагыйрьне дулкынландырган тойгы һәм фикер никадәр генә зур һәм әһәмиятле булмасын, ул художестволы иҗатның башлангычы, бары тик бөресе генә. Зәңгәр иртәләр матурлыкларын, ямьнәрен югалтмасыннар өчен тышкы бизәкләр генә җитми, аның өчен күңелне биләгән уй-тойгыларның образын, бердәнбер дөрес эстетик чагылышын да табу кирәк.

**Хәкимҗан ЯНОВ.**

Рафаэль Мостафин

# ЭВМ НИ ӘЙТЕР?..

Билгеле булганча, туган илгә М. Җәлилнең ике шигырь дәфтәре әйләнеп кайтты. Икенче дәфтәрнең тышлыгында: «Әсирлектә һәм тоткынлыкта— 1942. IX—1943. XI — арасында язганнарым — 125 шигырь һәм поэма. Ләкин кая языйм? — Үзем белән бергә үләләр», — дигән сүзләр бар.

Моабит дәфтәрләре аша илгә кайткан шигырьләрнең саны — 93, аларның да 13е әлеге үкенечле юллардан соң, ягъни 1943 елның ноябреннән соң язылган. (Шагыйрь кайдандыр берничә бит кәгазь юнәтә һәм шуларга 13 яңа шигырен күчерә. Ул битләр тегелмәгән, ә блокнот эченә салып кына куелган була). Шул рәвешчә, шагыйрьнең үз сүзләренә таянып, аның 1942—43 елларда тоткынлыкта иҗат иткән һәм безгә билгеле булмаган тагын 40 тан артык шигыре һәм бер поэмасы бар, дип расларга мөмкин. Инде 1944 елда иҗат иткән әсәрләреннән (билгеле булганча, җәлилчеләрне 1944 елның 25 августында җәзалап үтерәләр) безгә нибары берсе — 1944 елның 1 гыйнварендә язылган «Яңа ел теләкләре» шигыре генә билгеле. Хәлбуки, камерадаш иптәшләренең сөйләвенә караганда, бу чорда М. Җәлил бик күп һәм нәтиҗәле эшли.

М. Җәлилнең әсирлектә язган һәр шигыре диярлек татар поэзиясенең чын хәзинәсе ул. һәм ул хәзинәне арттырырга тырышу, югалганнарын эзләү, аларны тузаннан, төрле катламнардан арындырып, халыкка җиткерү теләге шулай ук бик аңлашыла. Бу юнәлештә эзләнү эшләре дә күптәннән дәвам итеп килә.

Шаһитларның сөйләвеннән чыгып, без бер нәрсәне ачык беләбез: хәрби әсирләр өчен оештырылган лагерьларда Җәлил шигырьләре күңелдән ятланган, кулдан-кулга, лагерьдан-лагерьга күчеп йөргән. Алар фашизмга каршы язылган прокламацияләр һәм совет информация бюросы хәбәрләре белән бер дәрәҗәдә хезмәт иткән.

Билгеле, әлеге төрмә һәм лагерьлардан бик азлар исән чыга. Исән чыкканнарның да күбесе хәтер яңа чакта ул шигырьләрне кәгазьгә төшерергә өлгерми. Күп кенә язмалар һәм документлар сугыш утында, репатриация вакытында һәм сугыштан соңгы кырыс еллар мәтәвыгында юкка чыга. Шулай да, еллар узу белән, акрынлап, Җәлилгә нисбәт ителеп йөри торган шактый шигырь туплана.

Илленче елларда, «Моабит дәфтәрләре» басылып чыгып, М. Җәлил исеме бөтен дөньяга шаулый башлагач, яңа табылган шигырьләрнең һәммәсен Җәлилгә нисбәт итү тенденциясе көчәеп китте. Ләкин әсирлектә, М. Җәлилдән тыш, А. Алиш, Х. Мөҗәй, Р. Саттар, Ә. Симай, профессиональ язучылар һәм журналистлар да, Г. Курмаш кебек укытучылар да шигырь язган. Моңардан тыш, тоткынлыкның авыр шартларында без исемнәрен дә белмәгән дистәләрчә яшь шагыйрь кулына каләм алган бит. Эш тагын шуның белән катлаулана, бөтенесе үк булмаса да, Җәлил тирәсендәге шагыйрьләрнең күбесе аның иҗади тәэсиреннән котыла алмаган, аның кебек булырга, аның кебек язарга тырышкан. Шуңа күрә, ул шигырьләрнең кемнеке булуын төгәл итеп ачыклау өчен, бер стилистик анализ гына җитми. Әлеге шигырьләрнең күбесе тоткыннарның хәтерендә ничек саклanса, шулай язып алынган, мондый очракта бозу һәм үзгәртүләр, төрле редакцияләүләр, кыскарту һәм өстәүләр котылгысыз.

70 еллар башында, М. Җәлилнең дүрт томлык сайланма әсәрләрен хәзерләү эше башлангач, бу мәсьәлә төзүчеләр алдына бөтен җитдилеге белән килеп баса. Җәлил-

гә нисбәт ителгән шигырьләрне томнарга кертергәме-юкмы? Керткән очракта барысын да алыргамы, әллә сайларгамы?

Ныклы бер фикергә киленә: томнарга идея пафосы ягыннан да, эчтәлеге һәм стилистик үзенчәлекләре буенча да Җәлилнең шигъри алымына аеруча якын торган шигырьләрне генә кертергә. Дүрттомлыкның икенче томына шундый уникe шигырь һәм «Шүрәле» музыкаль комедиясенең либреттосы кертелә. Ә шагыйрь китапханәсе сериясендә М. Җәлилнең рус телендә чыгарылган зур җыентыгына («Советский писатель» нәшрияты, Ленинград, 1979) әлеге шигырьләр хәтта «Дубия» (ягъни нисбәт ителә дип уйлый торган) бүлеккә дә кермәделәр.

Бервакыт мин университетта кибернетика буенча лекцияләр укучы Р. Г. Нигъмәтуллиннан әдәби әсәрләрнең авторларын ачыклау эшендә ЭВМны (электрон исәпләү машинасын) файдаланып булмыймы, дип сорадым. Рошаль Габделхаевич бу фикерне күтәреп алды. Мәскәүгә баргач, ул ЭВМ ярдәмендә объектларны танып белү белән шөгыльләнүче зур белгеч, Ленин премиясе лауреаты, физика-математика фәннәре докторы Ю. И. Журавлев белән очраша һәм әлеге идея белән аны да мавыктырып җибәрә. СССР Фәннәр Академиясенең Исәпләү үзәге директоры академик А. А. Дородницын исә Җәлил шигырьләрен шулай ачыклау эшен планнан тыш башкарырга рөхсәт бирә. Мәсьәләне турыдан-туры чишү һәм аның барлык математик якларын хәл итү эшенә КДУның механика-математика факультеты студенты Рәхилә Шиһапова алынды, диплом эшенең җитәкчесе итеп Ю. И. Журавлев билгеләнде.

Эшне гадиләштерә төшү өчен, бу юлга өч кенә объект сайлап алынды: машинадан дүрт томлыкка кертелгән унөч әсәрнең генә я Җәлилнеке, я Алишныкы, я булмаса, шартлы рәвештә «Билгесез шагыйрь» дип алынган өченче кешенеке икәнлеген ачыклатырга. Димәк, күптән билгеле әсәрләр нигезендә һәм мәгълүм параметрлар буенча машинаны әлеге өч авторны тану эшенә «өйрәтергә» кирәк иде. Кирәкле бу параметрларны миңа табарга һәм эшкәртергә туры килде. Сүз машинага салу өчен микъдари градациягә бирерлек бәяләр турында бара. Ә Җәлилнең граждanлык хисе — бер бөтенгә, ә Алишныкы бөтеннең яртысына тигез, дип булмый бит. Алар лирикасының мотивлары турында да шуларны ук кабатларга мөмкин: җиңүгә ышаныч, Туган илне сагыну, хәрби антка тугрылык һ. б.

Ахыр чиктә мин бөтенләй бүтән 12 параметрга туктaлдым:

1. **Ритмик сурәт.** Билгеле булганча Моабит циклы иҗатында Җәлил ирекле үлчәмнәрдән качарга тырышкан. Аның шигырьләренең ритмикасы төгәл, классик дәрәҗәдә төзек, шагыйрьнең юлдагы иҗекләр саны белән билгеләнә торган яраткан үлчәме: 10—9. М. Җәлил, Х. Туфан һәм Һ. Такташ шигърияте белән яхшы таныш кеше, аларның моңарчы укымаган яңа берәр шигырен очратса, аның кемнеке булуын интуитив төстә тәгаен диярлек билгели алачак. Димәк, алар шигъриятенең ритмик сурәте хакында аңда инстинктив хәлдә шактый төгәл төшенчә яши дигән сүз. Әгәр тәҗрибәле белгеч әлеге параметрга таянса, шуңардан чыгып эш итсә — җиткән.

Әмма машина ифрат дәрәҗәдә бертөрлелекне ярата икән. Шуңа да, машинага салу өчен Җәлил поэзиясенең ритмик сурәте хакында мәгълүмат хәзерләгәндә, мин нигездә аның сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәләре ягыннан иң өлгергән, иң көчле шигырьләренә таяндым: «Җырларым», «Кичер, илем», «Син ышанма» һ. б. шулардан чыгып, машина «Кызыл ромашка» шигырен, мәсәлән, М. Җәлил стиле өчен характерлы түгел, дип тапты. Чыннан да, фольклор традицияләренә таянып язылган бу баллада интонацион үзенчәлекләре ягыннан югарыда саналган шигырьләрдән нык аерылып тора.

Машина Җәлилнеке булуы ап-ачык билгеле кайбер шигырьләрне аныкы дип танырга теләми икән, бу инде — параметрлар өстендә эшләүне дәвам итү һәм камилләштерү кирәклеге хакында да сөйли.

2. **Рифма төзү системасы.** Кагыйдә буларак, һәр өлгергән шагыйрь рифманы үзенчә төзи. Җәлилнең Моабит шигырьләрендә рифма гадәттә авазларның аһәңдәшлеге белән аерылып тора:

**Кызны котлап җәүһәр муенсалар,**
**Беләзекләр б ү л ә к и т т е л ә р.**

**Тик барсы да кире җавап алып,**
**Буш кул белән кайтып киттеләр.**

Рифма юл азагындагы авазлар белән генә чикләнми, игътибар беләнрәк карaганда, аның бөтен юлга җәелүен күрәсең. Әйтик, «иттеләр» белән «киттеләр» генә рифмалашып калмый. Рифманы үзләштерүгә алдагы «бүләк» сүзе дә катнаша. Ул гүя ки җитмәгән «к» авазын тутыра. Авазлар аһәңдәшлеген тудыруда шигырь юлы тулысынча катнаша дисәк, тагын да төгәлрәк булыр: «Беләзекләр бүләк иттеләр — **буш кул белән** кайтып киттеләр». Монда кабатланып килгән «б» һәм «л» дә, сузык авазларның үзара чиратлашуы да мәгълүм роль уйный. Халык авыз иҗаты традицияләренә таянып, М. Җәлил еш кына юл башындагы сүзләр аһәңдәшлегенә дә мөрәҗәгать итә, бу исә аның иҗатында рифма төзү мөмкинлекләрен чиксез баета.

3. **Шигъри образларның, метафора, чагыштыруларның оригинальлеге.** Бу параметр хакында күп сөйләп торуның хаҗәте юктыр кебек, — аның эчтәлеге һәркемгә аңлашыла. Зур шагыйрь, нинди дә булса эчтәлекне бирү өчен, һәрвакыт яңа образлар, көтелмәгән метафоралар, төсләр эзләячәк, башлап язучы яки кечерәк масштаблы шагыйрь, бик ихтимал, тапталган юлдан китәчәк, билгеле булган, күп тапкырлар очраган, гомумнормага әйләнгән нәрсәләргә таяначак — сүз шул хакта гына барырга мөмкин. Мисалга Җәлилнең «Үлем җиле исә күңел гөленә, яфрагын да ләкин селкетми» дигән метафорасын алыйк. Ике юлда яңалыгы, оригинальлеге белән таң калдырырлык тулы бер картина бирелгән. Яки «Тимер баулы таш капчык, хәлең җитсә ташлап чык!» дигән юлларны алып карагыз. Хәзер бу тәгъбиргә без ияләндек, ә шуны табу өчен шагыйрьдән күпме кыюлык, хәтта батырлык соралган. Әмма сүз ниндидер аерым юллар турында гына түгел, ә бәлки үзләре бер киңәйтелгән метафора төсендәге («Имән», «Тау елгасы» һ. б.) шигырьләр хакында бара. Шундый образлар ярдәмендә шагыйрь зур фикерләр белдерә, тирән, фәлсәфи гомумиләштерүләр ясый. Машина төгәллекне таләп иткәнгә күрә, без М. Җәлилнең иң яхшы шигъри табышларының оригинальлеген 1 индексы, ә башлап язучының күп кулланудан төссезләнеп беткән образын 0 индексы белән билгеләргә булдык. Әлеге чик нокталарның ике арасына җиде градация урнаштырылды.

4. **Поэтик сүзлек.** Шагыйрь ни хәтле кызыклырак, талантлырак, эрудициялерәк булса, аның сүз запасы да шул хәтле баерак була. Сүз байлыгын төгәл генә санап та була, тик без бу юлы да сыйфат күрсәткечләреннән чыгып эш итәргә булдык. Дүрт дәрәҗә сайлап алынды: ярлы (башлап язучы дәрәҗәсендә), уртача (кул шомарткан шагыйрь дәрәҗәсендә) уртадан югары һәм бай сүзлек.

5. **Татар, рус һәм чит ил классиклары, шулай ук халык авыз иҗаты традицияләрен ныклы үзләштерү.** Без башлап язучы (билгесез шагыйрь), хәтта талантлы булган очракта да, традицияләрне иҗади үзләштерә алмый дигән караштан чыгып эш иттек. Чөнки моның өчен мәгълүм бер дәрәҗәдә профессиональ өлгергәнлек сорала. Әйтик, М. Җәлилнең «Назлы сөяркә» шигырендә шәрык поэзиясе традицияләрен файдалану нык сизелә. «Кар кызы» шигыре шагыйрьнең шул исемдәге легенда белән генә түгел, ә бәлки А. Островский әсәре белән дә таныш булуы турында сөйли. «Алман илендә» шигырен Гете, Гейне, Шиллерга гашыйк, Бетховен симфониясен тыңлап тетрәнгән, немец эшчеләр хәрәкәте тарихы белән дә, марксизм классикларының биографияләре белән дә яхшы таныш кеше генә яза ала.

Шул хәтлесен дә әйтергә кирәк, сүз биредә гади бер эрудициялелек, традицияләрне аңлы рәвештә осталарча файдалану турында гына бармый. Тәҗрибәле шагыйрь традицияләрне иҗади эшкәртә һәм шулар нигезендә бөтенләй яңа, мөстәкыйль әсәр иҗат итә. Традицияләрне үзләштерү дәрәҗәсен сыйфат ягыннан гына түгел, микъдар ягыннан да бәяләп була (без аны, мәсәлән, алты градациягә бүлдек).

6. **Тәгъбирләрнең лаконизмы.** М. Җәлил иҗатының өлгергән чоры өчен аз гына сәнгать чаралары ярдәмендә кечкенә мәйданда зур эчтәлек, тирән фикер бирү хас. Билгеле, лаконизм бер Җәлилгә генә түгел, һәр зур шагыйрьгә хас сыйфат. Әмма бу очракта аны, башка шагыйрьләр поэзиясеннән аера торган төшенчә буларак, ул ярыйсы ук мөһим урын тота. Җәлилнең «Серле йомгак» исемле шигырен генә алыгыз:

**Әкияттәге серле йомгак булып**
**Тәгәрәде тормыш сукмагым,**
**Озак бардым, ахры, көн батканда**
**Шушы йортка арып туктадым.**

Нибары дүрт юлга күпме хис һәм кайнарлык салынган! Сугыш, канлы кыйнаш, әсирлек газабы, зинданга ябылу — бу юлларда һәммәсе дә бар. Шагыйрь натуралистик детальләр санауга бирелми, көпшәк һәм сүлпән тасвирдан кача. Шигырь юлларының чын көче — тыгыз образлылыкта.

7. **Психологизм, хисләр диалектикасы.** Башлап язучы яки зур талантка ия булмаган шагыйрь дә теге яки бу хисне белдерергә сәләтле. Шунсыз поэзия булмый да. Тик чын мәгънәсендәге психологизм, капма-каршы тенденцияләрнең көрәшен, хисләр диалектикасын бирү бары зур шагыйрьләр кулыннан гына килә. Әйтик, Җәлил сөйгәненә багышланган шигырьләр циклында мәхәббәтенең көче, сагышы турында гына сөйләми. Ул сөйгәнем мине көтәме икән дип шикләнә, сөйгәнем мине онытыр дип борчыла. Шигырь тормышның бик күп катлаулы мәсьәләләре хакында уйландыра.

Мисалга «Соңгы үпкә» исемле шигырьне алыйк. Шагыйрь өчен иң кадерле, иң изге булган хис турында күпме әрнү, күпме үпкә, күпме сыкрану аңарда. Шуларның һәммәсе өстеннән бер нәрсә — олы җанлы, батыр йөрәкле ирнең характер көче тантана итә.

Тирән психологизм, кеше хисләрен аларның диалектикасында һәм капма-каршы мотивларның бәрелешендә күрсәтү — Җәлил иҗатына аеруча хас сыйфат. Бу параметрны сайлаганда без шул карашка таянып эш иттек. Дөрес, хисләр диалектикасы һәрчак күзгә ташланып тормый. Шуңа күрә без бу параметрның 0 дән 1 гә хәтле булган мәгънәсен алдык. (Өлге булып һәр очракта Җәлилнең иң яхшы үз шигырьләре торды).

8. **Лирик дулкынлану, эмоциональлек.** Бу параметр алдагысына якын тора, әмма аның белән тәңгәл килеп бетми. Ул артык шәрехләүгә мохтаҗ түгел. Бу сыйфатны, индивидуаль кабул итүгә таянып, алты мәгънәгә бүлдек.

9. **Шигырьнең музыкаль формаларын ныклы үзләштерү.** Бу параметрны Җәлилнең авторлыгын нык ышаныч белән билгеләү өчен керттек. Билгеле булганча, Җәлил — берничә дистә популяр җыр авторы. Аларның күбесе композиторлар белән бергәләп язылган. Көй таләпләрен истә тотып, Җәлил әле сугышка хәтле үк гаҗәеп күп төрле строфиканы, кушымталарның төрле формаларын, рифмалаштыруның катлаулы төрләрен виртуоз төстә үзләштергән булган. Менә бер генә мисал:

**Йөгерә-йөгерә көн дә иртән**
**Су сибәм гөлләремә.**
**Гөлләремне бүләк итәм**
**Иң якын күргәнемә.**

**Ах... матур соң гөлләрем!**
**Гөлчәчәкле туган илем**
**Саклаучыга бүләгем!**

Строфаның схемасы: аб аб; в г в.
М. Җәлилдә җыр строфаларының үзенчәлекле төрләре дистәләрчә.

10. **Тәгъбирләрнең афоризмлыгы.** Җәлилнең күп кенә шигъри юллары хикмәтле сүз булып яңгыраганына шагыйрь иҗатын өйрәнүчеләр күптән игътибар итеп киләләр:

**Утта булган балчык кире кумас,**
**Эштә булган тимер тутыкмас.**
**Эш күрсәткән ирне ил онытмас,**
**Каберенә эзне суытмас.**

Билгеле, Җәлилнең барлык шигырьләре дә афоризм кебек яңгырамый. Әмма шуңарга омтылуы аның шигырьләрен башкаларныкыннан аеру өчен ышанычлы дәлил булып тора.

11. **Авазлар байлыгы.** Рифма тезү бүлегендә бу хакта бераз сүз булган иде. Тагын бер мисал китерик:

**Байрак итеп илгә турылыкны**
**Утны-суны кичте бу егет.**
**Автоматы түгел, аты түгел,**
**Анты белән кочле бу егет.**

Монда авазларның эчке аһәңдәшлеге генә түгел. Эчке рифма (автоматы — аты— анты) үзенә бер төрле көчле агыш тудыра, гүяки ул әсәрнең төп мәгънәсен «анты» сүзен интонацион яктан да, авазлар яңгырашы ягыннан да аерып куя. Алда Җәлил шигырьләренең афористлыгы хакында әйтелде. Авазлар яңгырашы ягыннан да нык «тегелгән» булса гына афоризм чынга әйләнә, тиз хәтердә кала. Яңгырашның мондый камиллегенә ирешү өчен бик яхшы музыкаль сәләткә ия булу кирәк. Шуның белән бергә, М. Җәлил иҗатында авазлар аһәңдәшлеге һич тә үзмаксат түгел, ул һәр чак әсәрнең идея эчтәлеген көчәйтүгә хезмәт итә.

12. **Тегe яки бу кешегә, җисемгә, күренешкә мөрәҗәгать итүләр.** Җәлил иҗатын өйрәнүчеләр (Г. Кашшаф, Р. Бикмөхәммәтов, Н. Юзиев һ. б.) күптән инде бер нәрсәне ачыкладылар: аның байтак шигырьләре мөрәҗәгать рәвешендә язылган. Мөрәҗәгать рәвешендәге шигырьләр поэтик иҗатның киң таралган төре, шулай да ул вакыттагы һәм үз тирәсендәге башка шагыйрьләр белән чагыштырып караганда, Җәлил иҗатында алар күбрәк очрый. Моабит циклындагы шигырьләрнең өчтән бере диярлек турыдан-туры мөрәҗәгать формасында язылган. Хәтта өченче зат исеменнән язылган тыныч характердагы шигырьгә дә кинәт мөрәҗәгать детале килеп керә:

**Күп татыдым җирдә мин ачысын**
**Үзәк өзгеч авыр сагышның.**
**Елатып һәм кайнар үбештереп**
**Дустым белән, язмыш, кавыштыр!**

Димәк, бу сыйфат Җәлил шигырьләренең авторлыгын билгеләүдә тагын бер төпле параметр була ала.

Әлеге саф филологик бәяләмәләрдән тыш, математиклар соравы буенча, машинага тагын бер — **унөченче параметр да салынды:** ул — **белгечнең субъектив фикере.** Монда тегe яки бу шигырьнең Җәлилнеке (яки икенче бер авторныкы) булуына шәхсән ышану дәрәҗәсе күздә тотылды. Аны без түбәндәге рәвештә бүлдек: 0, $^1/_7$, $^2/_7$, $^3/_7$, $^4/_7$, $^5/_7$, $^6/_7$ һәм 1. Шуның белән бергә, шигырьне башка параметрларга бәйләмичә, бер бөтен сәнгать әсәре буларак кабул итү турында сүз барды.

Бергәләп хәзерләнгән менә шушы параметрлар нигезендә без башта Җәлилнең әлектән билгеле шигырьләрен тикшерә башладык. Рәхилә Шиһапова һәр шигырьгә махсус схема төзеде. А. Алишның безгә билгеле шигырьләренә дә шулай ук схема эшләнде. Машина үзенә тәкъдим ителгән параметрлар буенча ул шигырьләрне танырга өйрәнеп җиткәч кенә, аңа алда телгә алынган 12 шигырь һәм бер либретто тәкъдим ителде.

Эшнең математик ягы турында сөйләп тормыйк. Тик шунысын һичшиксез әйтергә кирәк: методның асылын үзләштерү, булган мәгълүматларны машина теленә әйләндерергә һәм нәтиҗәләрне эшкәртергә өйрәнү өчен Рәхилә тулы бер уку елы дәвамында Мәскәүдә махсус стажировкада булды. Ярый, әлеге шигырьләр турында галиҗәнап машина (СССР ФА Исәпләү үзәгенең БЭСМ-6 маркалы электрон-исәпләү машинасы) ни әйтте соң? Машина биргән мәгълүматлар өметле генә түгел, хәтта, белгечләр фикеренчә, менә дигән булып чыкты. Унөч очракның унберендә машина «Белгечләр советының» (бу очракта — дүрттомлык редколлегиясенең) фикерен тулысынча раслады, бер очракта гына кире какты, ә бер очракта шактый нык шик белдерде.

Менә машинага тәкъдим ителгән әсәрләрнең анализ нәтиҗәләре (баллар Җәлил поэзиясенә хас сыйфатларның кимү тәртибендә китерелә):

«Шүрәле» — 9,6; «Соңгы сүз» — 7,7; «Вислага» — 7,6; «Төн. Төрмә» — 6,8; «Кайту маршы» — 4,8; «Гариф дуска» — 4,3; «Ил» — 3,4; «Җыр» — 3,3; «Язлар килер» — 2,8; «Төн» — 2,5; «Улыма» — 2 балл.

Әлеге серле баллар нәрсә турында сөйли соң? Алар — Җәлил поэзиясенә хас сыйфатларның гомуми суммасы. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, балл никадәр югары булса, әсәрнең Җәлилнеке булу ихтималы да шул хәтле зур диген сүз. Бер үк вакытта машина «Алиш файдасына» һәм «Билгесез шагыйрь файдасына» да баллар җыйнады. Билгесез шагыйрь бөтен очракларда берсүзсез төшеп калды. Бу аңлашыла да. Чөнки без анализ өчен Җәлилнеке булу ихтималы зур булган иң өлгергән шигырьләрне сайлап алдык. Анализланган кайбер шигырьләрдә машина Алиш поэзиясенә хас сыйфатлар да тапты: «Төн. Төрмә» (1,6 балл), «Вислага» (1,6 балл), «Соңгы сүз» (1,5 балл), «Гариф дуска» (1,1 балл), «Шүрәле» (1,1 балл), «Ил» (1 балл). «Җәлил файдасына» җыелган баллар белән чагыштырып карауга, Җәлил поэзиясенә хас сыйфатларның өстенлек алуы шик уятмый.

Әлеге баллар артында ни ятканын ачыграк күрсәтү өчен, Җәлилнең электән билгеле үз шигырьләре җыйган баллар санын да китерик.: «Җырларым» — 15,7, «Соңгы җыр» — 13,3, «Кичер, илем» — 12,4, «Ышанма» — 11,4 балл. Болары — иң югары күрсәткечләр.

Җәлилнең башка типтагы әсәрләрен — саф лирик һәм балладаларын — анализлаганда машина балларга шактый саран булып чыкты: «Упкын» — 4,4, «Сөю» — 4, «Син онытырсың» — 2,8, «Урман» — 2 балл. Шулай да, бу мәсьәләдә машинаны артык гаепләп булмый, ул, алда әйтелгәнчә, Җәлил поэзиясенең иң югары казанышы буларак, Моабит циклындагы лирик-публицистик шигырьләрне танырга өйрәтелгән иде.

Инде авторлыгын билгеләү мәсьәләсендә машина килешмәгән шигырьләр хакында берничә сүз. Сүз барыннан да бигрәк «Азатлык маршы» турында бара. Анализ нәтиҗәләре буенча аның Җәлилнеке булу ихтималы — 0,01751376. Алишныкы булу ихтималы да — 0,01751376. Гади генә итеп әйтсәк, бу шигырьнең Җәлилнеке булу ихтималы да, Алишныкы булу ихтималы да бик кечкенә. Аның ниндидер башлап язучы әсәре булу ихтималы тагын да азрак. Моннан нинди нәтиҗә чыга? Күрәсең, аның авторы сәнгатьчә осталык дәрәҗәсе белән башлап язучыныкыннан югарырак, ә иҗат алымы белән Җәлилдән дә, Алиштан да аермалы булган, без белмәгән, без исәпкә алмаган ниндидер дүртенче берәү (Курмаш, Симай яки башка кемдер) булган. Кызганычка каршы, Җәлил группасына кергән шагыйрьләр хакында без аз беләбез. Шул хәл машинаны да аптырашта калдырды. Р. Шиһапованың сөйләвенә караганда, машина ул шигырьне кабул итүдән «баш тарткан», ул мәгълүм параметрларга һичничек сыймаган. «Таң маршы» белән дә шундыйрак хәл килеп чыкты. Менә анализ нәтиҗәләре: «Җәлил файдасына» — 0,83, «Алиш файдасына» — 0,18, «Билгесез шагыйрь файдасына» — 0,16 балл. Формаль яктан машина Җәлилгә өстенлек бирә кебек. Ләкин баллар суммасы шул хәтле кечкенә (бер бөтенгә дә тулмый), бу шигырь безгә билгесез дүртенче кешенеке булырга тиеш.

Йомгаклап шуны әйтик. КДУның кибернетика кафедрасында диплом эшен яклау бик уңышлы узды. Оппонентлар башкарылган эшнең оригиналь булуын һәм математик яктан югары дәрәҗәдә икәнлеген билгеләделәр, диплом яклаучының ифрат сәләтле булуына басым ясалды. Р. Шиһапова СССР Фәннәр Академиясенең Исәпләү үзәгенә аспирантурага тәкъдим ителде. Иң мөһиме шунда, әлеге хезмәт ЭВМ ярдәмендә авторлыкны ачыклауның мөмкин генә түгел, ә бәлки нәтиҗәле булуын раслады. Бу әле эшнең сынау характерындагы беренче этабы гына. Модельне алга таба камилләштерә һәм тикшерүнең филологик базасын киңәйтә төшкәндә, Җәлилгә нисбәт ителә торган барлык шигырьләрнең авторларын ачыкларга мөмкинлек туар дип ышанырга мөмкин.

# САДРИ ҖӘЛӘЛНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Зур дәрья йөзләрчә елгалар, инешләр суыннан җыелган кебек, матур әдәбият та бик күп әдипләр көче белән үстерелә, иҗат колачы һәм таланты төрле дәрәҗәдә булган һәр иҗатчы бу уртак эшкә көче җиткәнчә үзеннән өлеш кертә. Гражданнар сугышы чорында һәм егерменче елларда татар прозасында, публицистикасында шактый актив эшләгән һәм билгеле бер эз калдырган язучы Садри Җәләл шундый әдипләрнең берсе.

Садри Җәләл (Вәлитов Садрислам Хәйретдин улы) Татарстанның Апас авылында туа. Әтисе, иске карашлы мулла, башта аны үзе укыта, аннары муллалыкка хәзерләү максаты белән Казанның кадимче Мөбәрәкҗан хәзрәт мәдрәсәсенә кертә. Әмма малай әтисенең өметләрен акламый. Мәгърифәткә, дөньяви белемгә омтылучан, хәр күңелле Садрислам тиздән Сарапул шәһәрендәге туганнан туган абыйсы Җамал Вәлиди ярдәмендә шул заманның алдынгы уку йортларыннан саналган Буби мәдрәсәсенә күчеп китә.

Мәдрәсәне тәмамлап туган авылына кайткач, Садрислам зур тырышлык белән рус телен өйрәнергә керешә, рус классиклары әсәрләренә чума, бигрәк тә И. Тургенев әсәрләрен мавыгып укый. Шуның аркасында диндар ата зур җәнҗал кузгата, улының китапларын ертып ташлый, утта яндыра. Үсмер егет әтисенең өен ташлап чыгарга, Идел, Кара диңгез пристаньнарында бәхет эзләп эшмәгорлыкта йөрергә мәҗбүр була.

1911—1915 елларда Садри Җәләл Казанда Учительская школада укый, шул чорда ул әдәби иҗат эшчәнлеге белән шөгыльләнә башлый. Балаларга адреслап язган беренче хикәяләре «Ак юл» журналында дөнья күрә, «Дим буенда» исемле хикәясе «Аң» журналында басыла. Татар мирзаларының паразит катлау буларак таркалуын, бетүгә баруларын сурәтләгән бу зур күләмле хикәя шул ук елны аерым китап булып та чыга һәм каты тәнкыйтькә очрый, төрле бәхәсләр кузгата. (Бу хакта сүзне озынга сузмыйча, тәнкыйтьче Сәләх Атнагуловның 1929 елда әсәргә әтрафлы анализ ясап, объектив бәяләвен һәм 1965 елны композитор Х. Вәлиуллин белән драматург Х. Вахитның шул хикәя мотивлары буенча опера язуларын искәртеп үтәргә кирәк).

Садри Җәләл 1915 елны солдатка алына һәм ике ел хәрби училищеда укый.

Совет властеның беренче елларыннан Садри Җәләл зур активлык белән халык мәгарифе һәм вакытлы матбугат органнарында эшләргә керешә: Арчада укытучылар хәзерләү курсларына җитәкчелек итә, «Кызыл Армия», «Эш», «Татарстан» газеталарына язышa, 1922—1931 елларда «Труд и хозяйство», «Безнең юл», «Чаян» журналларында җаваплы секретарь булып эшли. Татрабфакта, Художество техникумында татар теле һәм әдәбияты укыта, хикәяләр, нәсерләр, очерклар, әдәби тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләр яза.

Садри Җәләл әсәрләре, барыннан элек, кешелеклелек идеяләре белән сугарылган булуы, иске Россия шартларында изелгән, җәберләнгәннәрнең якты омтылышларына теләктәшлеге белән җәлеп итә. «Инде мин аңа рәнҗемим» исемле лирик хикәянең героинясы язмышка, шәригать кануннарына колларча буйсынып үскән гади авыл кызы Газизәнең халык бәхете өчен көрәшүче учитель Әсгать белән дуслыгын, һәртөрле гайбәт, кимсетүләргә карамастан, үзенең мәхәббәтенә турылыклы калуын һәм иҗтимагый аңы ачылуын автор дулкынландыргыч драматик кичерешләр аша күрсәтә. «Хәзер мин күп нәрсәгә икенче күз белән карыйм, һәм бер-береңнең гайбәтен

ашап, кеше гаебен тикшереп йөрүдән башка кайдадыр икенче бер газаплы, ләкин шулай да кызыклы тормыш барлыгын томанлы гына булса да аңлыйм», — ди Газизә.

Гражданнар сугышы чорында һәм егерменче елларда Садри Җәләлнең иҗади эшчәнлеге тагын да активлаша, әсәрләренең тематикасы киңәя, оптимистик пафос ала. «Кадерле кунаклар», «Иртә белән», «Кызыл солдатның хатирә дәфтәреннән», «Егет һаман күренми иде» һ. б. хикәя, нәсер, очеркларында автор кызыл сугышчыларның батырлыгына дан җырлый, хезмәт иясе крестьяннарның аларга булган җылы мөнәсәбәтен, уртак омтылышларын тирән лиризм белән гәүдәләндерә. Әнә шуңа күрә дә, Г. Ибраһимов 1922 елны «Татарстан хәбәрләре» газетасында басылган күзәтү мәкаләсендә: М. Гали, Садри Җәләл кебек элекке вакытта ара-тирә күренгәләгән яшь язучыларыбыз... фикерләренең бөтен барышы, бөтен язулары белән ачыктан-ачык иҗтимагый революция рухына төштеләр һәм шул рухта язганнары белән киң укучы дөньясына танылып баралар», — дип язды.

«Әфләтун», «Тимер ага баласы» псевдонимнары белән «Чаян» журналында басылган күп санлы сатирик һәм юмористик хикәяләрендә, фельетоннарында С. Җәләл халык аңын агулаучы дин әһелләрен, яңа шартларга ярашучы элекке җилкуарларның чын йөзен фаш итә, искелек калдыкларыннан, һәртөрле хорафатлардан үткен көлә.

Журналист буларак, Садри Җәләл актуаль проблемаларга багышланган публицистик һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр белән вакытлы матбугатта актив катнашып килә, татар телендә беренчеләрдән булып, 1927 елда «В. И. Ленин турында истәлекләр җыентыгы» әзерләп чыгара, М. Горький, А. Куприн, Д. Фурманов әсәрләрен тәрҗемә итә.

Төрле елларда Садри Җәләлнең өч тапкыр сайланма әсәрләре, биш хикәясе аерым китап булып чыкты, балалар өчен язган аерым хикәяләре мәктәп сериясе җыентыкларында, класстан тыш уку китапларында басылды. Үзләренең эчтәлеге һәм әдәби эшләнеше белән ул әсәрләрнең күпчелеге хәзер дә әһәмияткә ия, аларда без элекке заманда хезмәт халкының авыр язмышын, якты, бәхетле тормыш өчен көрәшкән ата-бабаларыбызның җанлы образларын күрәбез.

**САФА САБИРОВ.**

# ИГЕЛЕКЛЕ ИҖАТ

*Гарәфи Хәсәновка 60 яшь*

Укучыларның күбесе бу язучыны, мөгаен, күреп белми дә торгандыр. Табигый хәл. Чөнки Гарәфи Хәсәнов радио һәм телевидение аша алай еш чыгучылардан түгел, шулай ук зур җыелышларда, шау-шулы әдәби кичәләрдә дә аны әллә нидә бер генә очратасың. Шулай да укучы балалар һәм яшьләр соңгы ун-унбиш ел эчендә чыккан повесть һәм хикәяләре аша аны яхшы беләләр. Язучылар арасында исә ул, барыннан да бигрәк, тыйнаклыгы, аз сөйләп күп эшләве, каләменең үзенчәлеге белән танылган язучы. Китапларының саны да әллә ни күп булмаса да, Г. Хәсәновның кече яшьтән үк үзен канатландырып килгән якты идеалы, шуңа бәйләнешле яраткан темасы, бай тормыш тәҗрибәсе, укучысына әйтер сүзе һәм, димәк, шулай булгач, әдәбиятта ныклы урыны да бар.

Бу язучының тормыш юлын да, башыннан уздырган төрле катлаулы хәлләрне дә гадиләр дип, гадәти дип кенә әйтеп булмый торгандыр. Ул ун яше тулар-тулмас ук яза башлаган кеше. Аның беренче хикәясе «Яшь ленинчы» газетасында 1932 елда ук дөнья күргән. Унөч яшендә ул, мәктәп партасында утырган чагында ук, яшь язучы буларак, СССР язучыларының I съездында катнашкан, анда балалар әдәбияты хакында речь белән чыккан. Яшь язучының шунда әйткән фикерләренә үз вакытында М. Горький игътибар иткән, бу чыгышка ул «Известия» газетасында уңай бәя биреп

узган. Шуннан соңгы елларда тормыш өермәләренең әле берсе, әле берсе аша узып, илленче елларда Гарәфетдин Хәсәнов әдәбият дөньясына бөтенләй яңа баштан килеп керде.

Беренче ишетүгә сәеррәк кебек тоелса да, турысын әйтергә кирәк: хәзерге заман яшьләренең күпчелеге әдәби иҗат дөньясына турыдан-туры әдәбиятның үзеннән, ягъни китаплар аша, ә кайберәүләр исә табигать һәм тормышның кайнап торган урыныннан, җир-су, кыр-урман киңлекләреннән, балта-чүкеч, ышкылар, пычкылар чыңлап-шаулап торган хезмәт мәйданыннан күтәрелеп килеп керәләр. Гарәфи Хәсәнов нәкъ әнә шундыйлардан. Ул табигать һәм җәмгыять гыйлемен китаплардан укып кына өйрәнмәгән. Юк, ул язмыш сукмакларыннан үз аягы белән җәяүләп узган, бик күп сынауларны үз җилкәсендә күтәргән, бала чагыннан өлкән яшьләренә кадәр табигать кочагында гади хезмәт белән шөгыльләнеп яшәгән. Менә шушы хәл, билгеле, аның иҗат юлын сайлауга да, әдәби-эстетик зәвыгы формалашуга да тәэсир итмичә калмаган. Үз вакыты җиткәч, ул барлык көчен, бай тормыш тәҗрибәсен, әдәби сәләтен туплап, проза әсәрләре язарга керешкән. Аның иҗаты тулысынча табигатьне тасвирлауга, кошлар, киек җанварлар һәм үсемлекләр дөньясын гәүдәләндерүгә багышланган.

Дөрес, хәзер совет әдәбиятында табигать хакында язучылар шактый ук күп очрый. Чөнки бу замана таләбе. Ләкин Г. Хәсәнов үзенең табигатьне белү һәм аңлау тирәнлеге, аңа мөнәсәбәте, аны әсәрләрендә гәүдәләндерү алымы ягыннан бүтән язучыларның берсенә дә охшамый. Мин аның хикәя һәм повестьларын, кечкенә генә детальләренә кадәр баштанаяк фән казанышларына таянып язылган матур әдәбият әсәрләре дип атар идем. Аның әсәрләре, эстетик ләззәт бирү белән бергә, укучыга табигать турындагы белемен арттырырга да ярдәм итәләр. Аның китаплары аша без табигатьнең үзебез моңа кадәр җитәрлек игътибар итмәгән бик күп яңа серләренә, беренче карауга күзгә чалынмый торган гаҗәеп нечкә үзенчәлекләренә төшенәбез. Әнә бит, керәшә дигән нәни кош көненә өчәр йөз мәртәбә балаларына азык алып кайтып ашата, бер көндә Казан белән Мәскәү арасы кадәр җирне очып уза, баласын һавада очып барган вакытында да туйдыра ала икән. Кызык бит! Яки менә мондый мисал китерергә мөмкин: еланның исемен ишетүгә үк бездә ничектер үзеннән-үзе аңа тискәре һәм дошманлык тойгысы уяна. Кара елан исә элек-электән үк күңелләргә мәкерлелек, рәхимсезлек, явызлык символы булып кереп калган. Иң явыз, иң мәкерле кеше турында сүз барганда: «Аның эчендә кара еланнар ята»,— диләр, яки: «Аның телендә елан зәһәрләре бар!» — дип сөйлиләр. Борынгыдан ук килгән менә шундый нигезсез, сукыр ышану нәтиҗәсендә без, адәми затлар, еланнар токымын табигатьнең башка төрләре кебек үк, мәсәлән, кешеләр кебек үк, дөньяда яшәргә хаклы җан ияләре дип түгел, бәлки мәңгелек дошманыбыз итеп күргәнбез. Бу ялгыш карашның нәтиҗәсе дә күз алдында, без аның инде зарарын да күрәбез: урманнарыбызда, әрәмәлекләрдә еланнарның агулысы гына түгел, агусыз тузбашлар да кырылып бетте диярлек. Г. Хәсәновның әсәрләре безгә шундый һәм шуңа охшашлы башка дорфалыкларны төзәтергә ярдәм итә, дип уйлыйм.

Табигый үзенчәлекләрен тирән аңлап, үзен дә шул табигатьнең бер кисәге рәвешендә хис итеп язганлыктан, Г. Хәсәновның табигать турында әйтер сүзләре дә күп. Ул кошларны, җәнлекләрне, хәтта үсемлекләрне дә нәкъ кешеләр турында язган кебек, җанландырып, кызыксынып укырлык итеп яза белә. Аның әсәрләрен, башка кайбер китапларны укыгандагы кебек, нәрсә буласын алдан ук белеп түгел, бәлки үзең өчен яңа ачышлар көтеп укыйсың. Билгеле, укучыда табигатькә мәхәббәт уяту өчен аны белеп язу гына җитми. Г. Хәсәнов табигатькә чын күңелдән соклана, хәтта аның кайбер күренешләренә гаҗәпләнә, хәйран кала, аларның яңадан кабатланмый торган матурлыкларын күрә һәм аларны эчкерсез беркатлылык белән ярата белә. Балалар язучысы буларак, Г. Хәсәновның тагын бер күркәм сыйфаты шул, өлкән яшьләргә җитеп килүенә карамастан, ул балаларга хас беркатлы гадилекне, самими гаделлек хисен әле дә югалтмаган. Димәк, ул «бала була белә», әсәрләренең кайбер урыннарын чын-чыннан балаларча хис итеп яза. Нарат үсентесен — үзенең героен яшьтәше итеп таный, очрашкан саен аның белән исәнләшә, аның зур үсүенә куана. «Шатландым, таң калдым. Шатланудан һаман тукта-

мыйм. Чөнки (табигатьтә) нинди генә ачыш ясамыйм, аның һаман да иге-чиге күренми. Һәр ачкан берем күңел түрендә. Мин һаман шулай байый барам шикелле».

Менә шулай бөртекләп җыйган күңел хәзинәсен Г. Хәсәновның чын күңелдән якын итеп, үз итеп укучыларына да бүләк итәсе, алар белән дә уртаклашасы килә. Аның соклануы, куанулары укучыларына да күчә, аларны да битараф калдырмый.

Гарәфи Хәсәновның гомумән теле дә, язу алымы да ярыйсы ук үзенчәлекле. Әсәрләре балаларга, яшьләргә багышлану сәбәпледер, күрәсең, ул кыска җөмләләр белән, мөмкин кадәр «авылчарак» итеп («булгачтын, килгәчтен, дигәчтен... булучан, килүчән, сизүчән, белүчән һ. б.), гадирәк итеп язарга тырыша. Халык мәкальләрен, әйтемнәрне дә еш кулланырга ярата: «Май салкын — кесә тулы алтын, игенгә туклык, чебенгә юклык»,— дип язып куя. «Көнозын ачка тук»,— ди ул. Оядагы кош балалары хакында: «Үзләре бишектә, күзләре ишектә»,— ди. Укый торгач, аның әсәрләрендә халык әкиятләренә хас алымнар да очрап куя: «Ун көн, ун төн утыргачтын, йөрәк парәләрен күрде ул»,— ди. Менә шундый матур итеп әйтелгән үткен фикерләр, бәхетле табышлар Г. Хәсәнов әсәрләренең телен бик тә бизиләр.

Балалар теленә якын булсын, аларның игътибарын җәлеп итсен өчен, билгеле, байтак кына ямашә җөмләләрне Г. Хәсәнов рифмага салып бирергә омтыла: «Бөтен янган җир шау чәчәккә күмелде, шунда инде бал кортлары да тәмам рәхәткә тиенде»; «Кайталар, урын җәеп яталар»; «Калкынып та күренер, өскә таба үрелер» һ. б. Авазлар яңгырашын уйнату да шул ук яхшы теләктән чыгып эшләнә булса кирәк: «Мин кырачка кырын карауны да оныттым» һ. б. Җөмләне күп нокталар белән уртасыннан бүлеп, аңа берникадәр юмористик тон бирергә омтылу алымы да еш очрый. Автор инверсияне дә күбрәк кулланып җибәрә шикелле. Вәхалән ки, күп кенә язучыларның иҗат тәҗрибәсе күрсәтүенә караганда, әдәби әсәрдә бер үк форманы чамадан тыш мул куллану көтелгән нәтиҗәне бирә алмый, хәтта киресенчә! Авторның үз теле белән әйткәндә, бер үк нәрсәне күп кабатлау гадәттә тиз туйдыручан, яхшы әсәрдән дә укучының күңелен биздерүчән.

Гарәфи Хәсәновка шушы елның июнь аенда алтмыш яшь тула. Әдәбиятыбызның бу талантлы һәм тырыш әдибен шушы бәйрәм белән чын күңелдән котлап, аның әдәбиятта тагын да югарырак баскычка күтәрелүен, озак еллар сау-сәламәт, нәтиҗәле иҗат итүен теләп калыйк.

**ГОМӘР БӘШИРОВ.**

# ГАБДЕЛХӘЙ САБИТОВКА 50 ЯШЬ



Габделхәй Сабитов — матурлыгы халык җырларында мактаглан Минзәлә якларыннан. Ул Югары Тәкермән авылында туган. Урта мәктәп тәмамлагач берничә ел мәктәптә укытучы, район газетасында тәрҗемәче булып эшли. 1956 елда Татарстан Язучылар союзы аны Мәскәүдәге М. Горький исемендәге әдәбият институтына укырга җибәрә. Шуны тәмамлап кайткач, Казан телевидение студиясенең әдәби-драматик тапшырулар редакциясендә өлкән редактор, «Ялкын» журналында әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире булып эшли. Соңрак «Чаян» журналында әдәби фельетончы, аннары журналның җаваплы секретаре була.

Габделхәй әдәбият белән бик яшьли кызыксына, мәктәптә укыганда ук үзе дә шигырьләр яза, аларның кайберләре район газетасы һәм «Үсү юлы» альманахы битләрендә басылып та чыга. Әмма алга таба ул проза һәм драматургия жанрларына торган саен ныграк тартыла, шул жанрларда үзенең иҗат йөзен билгели дә. Аның «Кечкенә ярдәмче», «Туган җир туфрагы» исемле беренче хикәяләре, чирәм җир турындагы язмалары «Социалистик Татарстан» газетасында, «Ялкын» журна-

лында, «Идел» альманахында басыла. «Өч күңел», «Корбан ашы» хикәяләре «Казан утлары» һәм «Чаян» журналларында дөнья күрә.

«Туган җир туфрагы» хикәясе аеруча бәхетле һәм озын гомерле булып чыкты. Ул, вакытлы матбугатта басылу белән бергә, яшь язучыларның күмәк җыентыкларына, татар әдипләренең русчага тәрҗемә ителеп, «Советская Россия» нәшриятында басылып чыккан «Төнге учаклар» исемле хикәяләр җыентыгына, мәктәп дәреслекләренә кертелде. 1963 елда Татарстан китап нәшрияты язучының шушы ук хикәя исеме белән аталган беренче җыентыгын бастырып чыгарды. Аңа тупланган әсәрләрендә автор гади кешеләрнең туган җиргә булган олы мәхәббәтен, тормыш һәм хезмәт романтикасын үзенә хас матур буяулар, хәтергә сеңеп калырлык образлар аша гәүдәләндерә. Кайбер хикәяләрдә исә безгә бөтенләй ят булган искелек калдыкларыннан, дини хорафатлардан арынып бетмәгән кире персонажлар сурәтләнә.

Язучының 1964 елда чыккан «Үлемсез Акылгали» җыентыгындагы тылсымлы хикәяләрендә илгә, Ватанга, аның гади, саф күңелле, риясыз кешеләренә, һичбер нәрсәгә алыштыргысыз матур, сихри табигатенә, халыкның теленә соклану хисе бөркелеп тора. Ул хикәяләрне укыганда авторның хыял байлыгына, сурәтләү чараларын сайлап алуда һәм куллануда зур осталыкка ия булуын, сүз сайлауда төгәллеккә һәм нәфисләлеккә омтылуын тоясың.

Габделхәй Сабитов үз әсәрләрендә әледән-әле табигать күренешләренә мөрәҗәгать итә, теге яки бу героеның эчке дөньясын, хис һәм кичерешләрен ачып бирү өчен алардан киң файдалана. «Карурманның күзләре бар» җыентыгында басылган бер хикәясенең төп герое Сәфәрдән ул, мәсәлән, менә мондый сүзләр әйттерә: «Кечкенәдән йомшак күңелле идем мин: кешеләрне яраттым, җирне яраттым, тереклек ияләрен, агачларны, урман-болыннарны яраттым...» Бу сүзләрне Габделхәйнең үзенә карата да кабатларга мөмкин. Әлеге җыентыкка урнаштырылган «Йолдыз яктысы», «Ярсулы яз», «Кәккүк ялгыша икән», «Бизәкле чиләк» хикәяләрендә ул туган ягы табигатен белеп һәм яратып, туган җир туфрагының җылысын аеруча тирәнтен тоеп яза. Бу хикәяләр аның каләменең йөгереклеген, иҗатында әдәбиятыбызның күркәм традицияләренә — халык рухына, ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләренә, борынгы һәм хәзерге йолаларына тугрылыклы булуын тагын бер тапкыр раслый торган әсәрләр дип бәяләнергә хаклы. Җыентыктагы «Хәвефле җәй», «Туй бүләге» хикәяләрендәге Кыяметдин һәм Гөлүсә кебек образлар тормыштагы иң катлаулы ситуацияләрдә, иң киеренке моментларда үз вөҗданнарына хыянәт итмәгән, рухи матурлыкларын саклап кала алган замандашларыбызның күркәм сыйфатларын гәүдәләндерүләре белән күңелгә кереп калалар һәм укучының аерылмас юлдашларына әвереләләр. Бу инде — язучы үз алдына куйган максатка ирешкән диген сүз.

Габделхәй Сабитов драматургия һәм очерк жанрларында, шулай ук балалар әдәбияты өлкәсендә дә эшләүче язучыларыбызның берсе. Минзәлә татар дәүләт драма театры аның «Кичерелмәс гөнаһ» һәм «Гарасат» пьесаларын сәхнәгә куйды. Ул пьесаларның соңгысы драматургларның республика конкурсында Татарстан Культура министрлыгы премиясенә лаек булды. Театр 1979 елда Казанда уздырган гастрольләрен шушы әсәр белән башлап җибәрде.

Тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителгән, республикабыз районнарында гына түгел, Башкортстанда, Ижевск, Свердловск кебек шәһәрләрдә дә күп тапкырлар уйналган һәм зур уңыш белән барган бу драма башта «Казан утлары» журналында, аннары «Чулпан таңны уята» диген исем белән аерым китап булып басылды һәм илебезнең төрле почмакларында яшәүче күп санлы укучыларга, күп санлы үзешчән сәнгать коллективларына да барып иреште.

Габделхәй Сабитовның драма әсәрләре кискен конфликтларга, мавыктыргыч вакыйгаларга, тормышчан конкрет детальләргә, кичереш-хисләргә бай булулары белән аерылып торалар. Тамашачы күңелен алар әнә шуның белән җәлеп итәләр дә. Образлар тудыру өстендә эшләгәндә ул үз-үзен кабатлаудан кача. Шуңа күрә дә аның күпчелек персонажлары бары тик үзләренә хас булган яклары белән ачылалар. «Кичерелмәс гөнаһ» драмасында, мәсәлән, туган туфрагыннан аерылуны хәтта уена да китерә алмаган, бөтен дөньяны гөлбакча итәргә хыялланган Галәви, ире яу кы-

рында мәңгелеккә ятып калгач та аның исеменә тап төшермәгән, олы мәхәббәтенә тугрылыклыгын саклаган Галия, баштарак җилбәзәгрәк булып күренгән, әмма соңыннан тормышта үз юлын, үз урынын тапкан Фәхрия, дошман вакытлыча басып алган җирдә калып, әсирлектә мең төрле газаплар кичергән, ләкин кешелеклеген югалтмаган Нәзирә образлары һәркемдә патриотик хисләр — туган җиргә, Ватанга бирелгәнлек хисләре тәрбияли.

Тәнкыйтьчеләр һәм театр белгечләре тарафыннан халык язмышын чагылдырган әсәр дип бәяләнгән «Гарасат» драмасында чит-ят җирләргә сөрелгән кешеләрнең кичерешләре, уй-тойгылары һәм шулар белән бәйле киеренке вакыйгалар тасвирлана. Шул вакыйгаларның эчендә кайнаган, үзәгендә торган Мирсәлим карт, башкорт егете, тегермәнче Иркенбай, якут Ләгәнтәй, шәхси милекчелек чиреннән арына алмаган Сәлмән, бунтарь йөрәкле Зөлфәт, аның сөйгәне саф күңелле Сөмбел, кызу канлы, кыю Сабир, ямаулыкны да өфектән генә салырга хыялланучы Әлми, шахта управляющие Акулов, большевик Рузанов образлары калку һәм истә калырлык итеп сурәтләнгәннәр. Социаль-тарихи планда язылган бу драманың төп конфликты — хезмәт ияләре белән байгуралар арасындагы сыйнфый бәрелеш. Татар-башкорт авылларының берсендә башланган вакыйга Себердәге алтын приискасында дәвам итә. Прииска хуҗалары авылдагы шул ук Имай байларның интересларын яклыйлар, аларның бары тик исемнәре генә бүтән. Максаты төрле катлам, төрле милләт вәкилләренең авыр, катлаулы юллар аша революциягә килүен күрсәтүдән гыйбарәт булган бу әсәрнең материалы татар драматургиясе өчен әр-яңа. Ул да булса — татар эшчеләренең 1912 елгы Лена вакыйгаларында катнашуы. Әсәрдә социаль закончалыклар бер-берсен кабатламаган индивидуаль характерлар, алар арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләр уртасыннан юл яра. Автор тормыштагы кызыклы, гыйбрәтле вакыйгаларны драма жанры таләп иткәнчә куерта, үстерә белә. Зур тырышлык белән ирешелгән бу осталыгын ул әдәби очерклар язганда да бик теләп эшкә җигә.

Вакытлы матбугатта, шулай ук аерым җыентыкларда басылган очеркларында Г. Сабитов замандашларыбызның тормыш юлын сөйләп, эшләгән эшләрен бер-бер артлы санап чыгу белән генә чикләнми, аларның күңел җылылыгын, шатлык-кайгыларын, туган җирне, табигатьне сөюләрен тирән лиризм белән сугарылган картиналар аша гәүдәләндерә. Моны без аның «Чәчәк ата миләшкәй», «Юл буенда һәйкәлләр», очеркларын укыганда аеруча ачык тоябыз.

Габделхәй Сабитов әсәрләрендәге төп геройларның берсе — табигать үзе. Моны бигрәк тә аның балаларга багышланган хикәяләренә һәм курчак театры өчен язган «Ай сукмагы» исемле пьесасына карата әйтергә мөмкин. «Ай сукмагы»нда чәчәкләр тереклек чыганагы, кыз сурәтендәге Таңсылу исә гүзәллек символына әйләнә. Табигатьне бәладән йолучы, аның кочагында яшәүче, аның белән гомерлеккә дуслашкан кеше генә бәхетле һәм күр күңелле була ала дигән фикер әсәрнең буеннан-буена кызыл җеп булып сузыла. Табигать күренешләрен кешенең эчке халәте, хис-кичерешләре белән тыгыз бәйләнештә сурәтләү Сабитов иҗатына аеруча хас сыйфат.

Каләмдәшләре арасында Габделхәй Сабитовны, аз яза, акрын яза, дип әйтүчеләр юк түгел. Аларның сүзләрендәге дөреслекне инкарь итмәгән хәлдә, бу авторның ашыгып язмавына әллә ни үпкә дә белдерәсе килми. Үз алдына ул күп язуны түгел, сыйфатлы итеп язуны максат итеп куя, әйтергә теләгән фикерен укучыга җиткерү өчен төрле чаралардан файдалана, туктаусыз эзләнә, әсәрләренең телен җентекләп чарлый. Күп кенә хикәя һәм очеркларының газета-журналлар үткәргән конкурсларда беренче яки икенче премияләргә лаек булуы үзе үк күп нәрсә турында сөйли шикелле.

Ул байтак еллардан бирле инде рус һәм чит ил язучыларының күренекле әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. Эрис Распеның «Барон фон Мюнхаузен маҗаралары», П. Л. Трэверсның «Мэри Попинс», Феликс Зальтенның «Бельби» («Урман әкияте») повестьлары татар укучысына аның тәрҗемәсендә тәкъдим ителде.

Каләмдәш дустыбыз үзенең беренче илле еллыгын иҗатында яңа бер баскычка күтәрелү чорында каршылый. Киләчәктә ул үзенең укучыларына берсеннән-берсе матуррак әсәрләр бүләк итәр дип ышанабыз.

РӘШИТ ГӘРӘЙ.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

1—2 апрельдә Г. Тукай исемендәге клубта Татарстан Язучылар союзының әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышы булды. Аны кереш сүз белән ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты. Аннары төрле жанрлар буенча докладлар тыңланды. Әдәбиятыбызның узган ел ирешкән уңышлары һәм кимчелекләре турында Фәрваз Миңнуллин (проза), Хәсән Хәйри (әдәби тәнкыйть), Ринат Мөхәммәдиев (поэзия), Геннадий Паушкин (рус язучылары иҗаты), Ризван Хәмид (драматургия), Фаил Шәфигуллин (балалар әдәбияты), Илида Бәширова (тәрҗемә әсәрләре), Мансур Вәлиев (очерк һәм публицистика) сөйләделәр.

Докладлар буенча фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателенең яшьләр белән эшләү буенча урынбасары И. Юзеев, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсе секретаре И. Гатова, шагыйрьләр һәм прозаиклар С. Хәким, Г. Иделле, Җ. Тәрҗеманов, Г. Шәрәфи, М. Маликова, К. Булатова, Р. Хисмәтуллин, Р. Вәлиев, «Татарстан яшьләре» газетасы редакторы И. Әхмәтҗанов, «Казан утлары» журналының баш редакторы Зәки Нури, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, РСФСР язучылар союзы идарәсенең җаваплы хезмәткәре В. Александров иптәшләр катнашты.

Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин чыгыш ясады.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

Апрель башында Татарстан Язучылар союзы идарәсенең киңәйтелгән утырышы булды. Утырышта Чаллы һәм Әлмәт язучылар оешмаларының отчеты тыңланды. Отчет белән оешма җитәкчеләре Э. Касыймов һәм Ә. Маликов чыктылар. Фикер алышуларда катнашкан Х. Туфан, Р. Мөхәммәдиев, Р. Даутов, Т. Миңнуллин, И. Юзеев, Ә. Баянов, М. Хәбибуллин, Р. Мингалимов иптәшләр Чаллы һәм Әлмәт оешмаларындагы уңай һәм кимчелекле якларга тукталдылар.

Идарә утырышында шулай ук әдәби ел йомгакларының, Мәскәүдә үткәрелгән Муса Җәлил юбилееның нәтиҗәләре, поэзия көнен азерлек мәсьәләләре каралды.

Утырышта партия өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

* * *

7 апрельдә Чаллы шәһәрендә язучылар оешмасының гомуми җыелышы булды. Җыелышта Чаллыда, Түбән Камада, Алабугада яшәүче язучылар, «Орфей», «Ләйсән», «Кама таңнары», «Данко» әдәби берләшмәләре членнары, яшь язучылар, Казан әдипләре катнашты.

Җыелышта Чаллы язучылар оешмасының бер еллык эше турында Э. Касыймов отчеты тыңланды.

Фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре, тәнкыйтьче Р. Мөхәммәдиев, драматург Т. Миңнуллин, «Орфей» һәм «Ләйсән» әдәби берләшмәләре члены М. Сафин, «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе җитәкчесе Р. Хисмәтуллин, «Данко» әдәби берләшмәсеннән М. Федосенко, прозаик А. Чурбанов катнаштылар.

Партиянең XXVI съезды делегаты Г. Ахунов җыелышта катнашучыларны съезд карарларын тормышка ашыру өчен Татарстан Язучылар союзы идарәсе төзегән планнар, эшлисе эшләр программасы белән таныштырды. Чаллыда «Яңа шәһәрләр. Советча яшәү рәвеше. Әдәбият» дигән темага ил күләмендә киңәшмә уздыру, шулай ук ил күләмендә иң яхшы композиторлар, шагыйрьләр, җырчылар катнашында Чаллыда җыр фестивале үткәрү планлаштырылганын әйтеп китте. Татарстанда үткәреләчәк Каракалпакстан әдәбияты һәм сәнгате көннәренә әзерлек эшләренә керәкләгенә тукталды.

Язучы Э. Касыймовның иҗат эшенә күчүе сәбәпле, Чаллы язучылар оешмасы җыелышы аны җаваплы секретарь вазифасыннан азат итте. Оешманың яңа бюросына Р. Вәлиев (җаваплы секретарь), Т. Галиуллин, Р. Хисмәтуллин сайланды.

## СӘНГАТЬЛӘР ФЕСТИВАЛЕ

Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле Идел буе шәһәрләрендә, шул исәптән Казанда, сәнгатьләр фестивале бара. Татарстан башкаласында ул М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында «Ватан күкләре астында» дип исемләнгән концерт белән ачылып китте. Фестиваль концертында Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе һәм М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет те-

атрының танылган артистлары катнашты. Концертның үзәген РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты И. Шакиров, ТАССРның халык артистлары Ә. Афзалова, Э. Җәләлетдинов, Г. Ильясов, ТАССРның атказанган артисткасы Н. Теркулова, опера һәм балет театры солисткасы Р. Нуриева чыгышлары тәшкил итте.
Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 111 ел тулуга багышланган фестиваль концертлары республикабызның башка төбәкләрендә дә күрсәтелде.

## В. И. ЛЕНИН һӘМ КИТАП

1980 елның декабрь аенда Мәскәүдә «В. И. Ленин һәм китап» дигән гомуми тема астында В. И. Ленинның тууына 110 ел, «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» исемле мәкалә чыгуга 75 ел тулуга багышланган бөтенсоюз конференциясе булды. СССР Фәннәр академиясе, СССР Министрлар Советы каршындагы нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе дәүләт комитеты, В. И. Ленин исемендәге Дәүләт китапханәсе тарафыннан оештырылган бу конференциядә Мәскәү, Ленинград, Киев, Казан, Кишинев шәһәрләреннән, ГДР, Польша, Болгариядән күренекле китап белгечләре һәм галимнәр катнашты.
Конференциядә филология фәннәре докторы Әбрар Кәримуллинның докладын аеруча кызыксыну уятты. Аның докладында В. И. Ленин үзе исән чакта татар телендә басылып чыккан басмаларга багышланган иде. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни хезмәткәре Искәндәр Абдуллин татар большевистик матбугатын тудыруда В. И. Ленинның конкрет роле турында сөйләде. Казан Культура институты доценты Талия Корбангалиева докладында В. И. Ленинның татар әдәбиятын белүен, яшь татар совет матбугатының Тукай традицияләрен дәвам иттерәчәгенә ышануын, карт большевикларның истәлекләреннән өзекләр китереп исбатлады, революциядән соң Ленин әсәрләренең татар телендә өч миллионнан артык тираж белән чыгуы турында сөйләде. Конференциядә катнашучылар В. И. Ленинның 1980 елны Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Яшьләр союзларының бурычлары» исемле миниатюр басмасы белән таныштылар.

## КОНКУРС ЙОМГАКЛАРЫ

Республикабызда 1980 елның 1 нче августыннан алып 1981 елның 15 нче февраленә кадәр КПССның XXVI съездына багышлап «Бүгенге көн геройлары» дигән девиз астында иң яхшы очеркка һәм публицистик мәкаләгә конкурс барды.
ТАССР Журналистлар союзы һәм Язучылар союзы идарәләре, Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитеты әлеге иҗади ярышка йомгак ясадылар.
Беренче премияләр «Эзләп тапкан бәхет» дигән очерклы өчен Г. Кашаповка һәм «Кеше нәрсә хакына яши?» дигән очеркы өчен Н. Кожевниковага бирелде. «Казан утлары» журналының 1980 елгы 9 нчы санында басылган «КамАЗ кешесе: кем ул?» дигән публицистик мәкаләсе өчен Н. Фәтхуллин һәм «Социалистик Татарстан» газетасында басылган «Адымым дөрес микән» дигән очеркы өчен М. Миңлебаев икенче бүләккә лаек булды.

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ 75 ЕЛЛЫГЫНА

Чаллыда герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 75 ел тулуга багышланган юбилей көннәре үтте. Бу мөһим чара атналык рәвешендә үткәрелде.
18 февральдә герой-шагыйрьгә багышланган кичә Чаллының Муса Җәлил исемендәге Үзәк китапханәсендә булды, шагыйрьнең хәрби һәм иҗади батырлыгы турында сөйләнде, шигырьләре укылды, шагыйрь сүзләренә язылган җырлар, арияләр яңгырады.

*
* *

1981 елның 21 февралендә Оренбургның «Россия» Культура сараенда герой-шагыйрь Муса Җәлилгә 75 ел тулу уңаена багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.
Бу кичә шагыйрьнең Оренбургта беренче басылып чыккан «Бәхет» шигыре белән башланды.
Яшь башкаручылар шагыйрьнең Оренбург чорында һәм Моабитта язган күп кенә әсәрләрен укыдылар. Кичәне алып баручы Зиннур Шакиров М. Җәлил һәм җәлилчеләр турында сөйләде. Кичә барышында документаль кинокадрлар һәм слайдлар киң кулланылды.
Кичә кунаклары — М. Җәлилнең бертуган сеңелесе Хәдичә Җәлилова һәм Оренбург журналисты Владимир Альтовның чыгышларык да тамашачылар кызыксынып тыңладылар.
Кичәнең икенче бүлегендә «Россия» Культура сараеның «Чулпан» вокаль-инструменталь ансамбле чыгыш ясады.
Шушы ук көннәрдә «Южный Урал» һәм «Комсомольское Племя» газеталарында Муса Җәлил турында мәкаләләр басылып чыкты, радиодан тапшыру оештырылды.

*
* *

15 февральдә Магнитогорск шәһәренең төзүчеләр Культура сараенда Муса Җәлилнең тууына 75 ел тулуга багышланган зур әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәне Культура сарае каршындагы ансамбль җитәкчесе композитор Рафаэль Бакиров оештырды. Кичәдә катнашу өчен Чиләбе өлкәсе язучылар оешмасы каршындагы «Муса Җәлил» исемендәге әдәби берләшмәдән дә кунаклар чакырылды. Троицк шәһәреннән — Басыйр Рафиков, Чиләбедән — Салисә Гәрәева, Миасстан — Энҗе Гыйрфанова килгән иде. Алар Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты турында сөйләделәр, шигырьләрен укыдылар. Кунаклар шулай ук училищеларда һәм тулай торакларда Муса Җәлилгә багышланган очрашулар үткәрделәр.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!

Инде журналның алдагы айда чыгачак 7 нче санына кергән язмалар белән таныштырыйк.

Бу сан шигырьләргә дә, проза әсәрләренә дә шактый бай булачак. Беренче битләрдә шагыйрь Г. Латыйпның «Таңнар, таулар...» дигән гомуми исем астына тупланган яңа шигырьләре урын алган. Болардан тыш журналда Г. Рәхим, Р. Хәлиуллина, С. Баттал, Ә. Мәхмүдов шигырьләре бар.

Проза әсәрләреннән С. Сабировның «Утлы фарватердан» повесте басылган. Әсәрдәге вакыйгалар гражданнар сугышы чорына карый.

Очерклар һәм публицистика бүлеге һәр сан саен КПССның XXVI съезды карарларын тормышка ашыру җәһәтеннән башкарыла торган эшләргә, шул вакыйгалар эчендә кайнаган хезмәт кешеләренә багышланган язмалар биреп килә. Язучы М. Зариповның бу сандагы очеркы шундый.

Әдәби тәнкыйть бүлегендә Г. Ахунов, С. Маннапов, Ф. Галимуллин, Э. Нигъмәтуллин, Ф. Әгъзамов мәкаләләре бар.

«Культурабыз тарихына материаллар», «Дуслар иҗаты», «Төрлесеннән», «Безнең календарь», «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары» рубрикаларына тупланган материаллар да укучыны кызыксындырыр дип ышанабыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА